www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Салисә ГӘРӘЕВА. Каныбызда – ана телебез... *Шигырьләр*. ....3
Миргазиян ЮНЫС. Кыпчак кызы Аксанә. *Роман*. ....8
Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Һәр акыллы җанда чыңлыйдыр саз... *Шигырьләр*. ....68
АХИР. Кыргый алмагач. *Повесть*. ....72

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Әскәр ДОДУЕВ. Таш сыртында бүген утырам мин... *Шигырьләр*.
*(Балкарчадан Рафис КОРБАН тәрҗемәсе)*. ....131

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фәтхулла АБДУЛЛИН. Кемгә сөйлим серләремне… *Повесть*. ....135

ЯҢА ИСЕМНӘР

Фәридә АЙДАРОВА. Мин очышка әзер... *Шигырьләр*. ....150
Зилә САБИТОВА. Таныш кешем. *Хикәя*. ....154
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....161

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. «Ил капкасын кагам...» ....163

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Фотоархив: Шәүкәт Галиев тормышыннан мизгелләр. ....166
Шәүкәт ГАЛИЕВ. Саумысыз, арышларым! *Шигырьләр*. ....168

ЮБИЛЕЙЛАР

Бәхтияр МИҢНУЛЛИН, Фәүзия СӘГЪДИЕВА, Рифат МИРХАЕВ.
Фәнне галимнәр үстерә... *(Илида Бәшировага 80 яшь)*. ....172
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кызган күмер *(Хәбир Ибраһимга 60 яшь)*. ....179
*Безнең календарь:* Шамил Анакның тууына 90 ел. ....182

ХӘТЕР

Геннадий МАКСИМОВ. Югалган моң. ....183

АК ҖИЛКӘН

Алинә НАСЫЙРОВА. Әминә. *Хикәя*. ....186
Елена НУЖДИНА. Әни. *Шигырь*. ....187
*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. ....188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.10.2018, график буенча 31.10.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-2927. Тираж 4167.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Салисә Гәрәева

# КАНЫБЫЗДА – АНА ТЕЛЕБЕЗ...

## Туган телем

Туган телем! Кайнар каным булып,
Тамырларда минем агасың.
Һәм ят телле төрле башкалардан
Аерасың татар баласын.

Чал тарихның тиңсез бүләге син –
Шигъриятең яңгырый ташлардан.
Үлән булып ничә дистә гасыр
Шытасың син шәһит башлардан!..

Үзгәрүчән, тик картаймый торган
Мәңге яшәр гүзәл агач син!
Җирдән, судан кабат бар буласың,
Баш киселеп, илләр аугач син.

Син тауларда кыя ташы булып,
Җир куйнына тамыр сузгансың.
Син, җыр булып, газиз Җиребезнең
Кыйтгаларын кичеп узгансың.

Беркайчан да алмаштырмам сине,
Яңгырап торган башка бер телгә.
Син каныма, мигә, геннарыма
Якты иман итеп кертелгән.

Тамырларга балта чабылса да,
Без – мәңгелек, исән, тере без!
Дистә телдә оста сөйләшсәк тә,
Каныбызда – ана телебез!

---

Салисә ГӘРӘЕВА (1938) – *шагыйрә; «Уралым», «Тау сукмагы», «Йолдыз яңгырлары» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

## Олыгайгач

Олыгайгач,
Дан һәм шөһрәт
Кызыктырмый.
Яшәр өчен
Икмәк һәм су
Булса ярый…
Уйлап – башым,
Сөйләп – телем,
Йөрсәм – гәүдәм,
Кайчак хәтта…
Кешедән дә
Күңелем арый!..

Ни куркыныч
Бер чордашсыз
Бу дөньяда, –
Ялгыз калып
Карау заман
Болганышын!

Заманахыр,
Дип торырсың,
Кешеләрнең
Күрсәң дөнья
Куган чакта
Кыланышын!..

Кичерәсе –
Кичерелгән,
Эчерәсе –
Эчерелгән
Һәм сөелгән
Сөеләсе!
…Инде килә
Җәннәтләрнең
Багларында,
Кунак булып,
Күк назына тиенәсе!..

## Киләм

Бик бәхетле, көләч чакларым бар, –
Тулган айдай балкыйм.
Шигъри очрашу бу!
Бәйрәм өчен
Рәхмәт сиңа, халкым!

Күзләрдә – яшь, җаннарда моң күрәм,
Минем белән сез дә!
Җан берлеген, тел берлеген тою
Насыйп әле безгә!..

Шуннан да зур бәхет буламы соң?!
Беләм, беләм кадрен!
Уртак борчу, уртак шатлык белән
Яна минем бәгърем.

Киләм әле, киләм очрашуга,
Насыйп булса, кабат.
Бәхетле мин йөрәгемне ачсам,
Сезнең күзгә карап!..

## Имин түгел дөнья

Чиләбедә, Кыштым, Кунашакта,
Касли урманнары эчендә
Атом фаҗигасе дәвам итә,
Көчле нурланышлар төсендә!

Караболак, Мөслим, Бәрәскәләр
Гел киңәйтә бара зиратын:
Яшен түгеп, җир куйнына сала
Хатын-кызын, сабый, ир-атын…

Чернобльдә шушы фаҗиганең
Кабатланды тагын олысы:
Украина, Белорусьны кисте
Төссез, иссез атом кылычы!

Тора анда шомлы һәйкәл булып
Үле шәһәр – Припять каласы.
Ул кисәтә Җирне: булдырмагыз
Атом шартлавының яңасын!..

Плутоний, цезий, кадмийларның,
Стронцийларның тыны – һәлакәт!
Әле ничә миллион халык китәр,
Күпме йөрәк алыр җәрәхәт.

Өстебезгә ява, агу сибеп,
Атом йөрткән янгын челтәре.
Ватыла бара ДНКлар рәте,
Сүнә өзелеп нәсел җепләре!

Күпме гарип күккә кулын суза,
Ярдәм сорап, шашып, тилмереп! –
Атом белән бергә үлем килде,
Яшәү кануннарын җимереп!

Имин түгел дөнья! Илләр буйлап
Сугыш мәйданнары ут чәчә.
…Заман ахырларын вәгъдә итеп,
Үлем белән яный Киләчәк!

## Игезләрем

Мин күпләргә, ахры, охшаганмын:
Йөзем сызыклары гадиләр.
Урамнарда килеп эндәшәләр:
– Исәнме, әй, – диләр, – Гадилә!

– Ләйлә! – диләр, килеп кочаклыйлар,
Оялалар, кире чигенеп:
– Укытучы бит син, Кунашактан,
Йә әйтәләр:
– Сары килене!..

Ачулары килә:
– Нигә инде
Үз-үзеңнән шулай танасың?!
Оялталар:
– Үзебезгә кайткач,
Күзебезгә ничек карарсың?!.

Ант та итәм, исбатлап та карыйм,
Көлгән булам. Кайчак ярсынам:
Кайчак Чиләбедә миңа охшаш
Әллә ничә үзем бар сыман.

Уртакмындыр йөзем-төсем белән,
Буем-сыным белән охшаштыр!
Үпкәләмим.
Язмышыма әйтәм:
– Игезләрем белән тоташтыр!..

Нәкъ үземдәй берәү очраганда,
Дулкынланам үзем нигәдер.
...Музам белән горур җитәкләшеп,
Язмыш, бәлки, каршы киләдер,
Мине... үзе, диеп беләдер!

## Сихерчеләр

Заманахыр якынлаша бугай –
Гөмбәләрдәй үрчи «колдун»нар!
Коръән әйткән: алар үрчер шулай
Заманахыр булыр алдыннан...

Сихерчесе, колдун, багучысы,
Күрәзәче, имче дигәне –
Шарлатаннар, дингә өндәүчеләр
Басып китте бөтен илләрне!..

Берәүсенә Күктән «Коръән иңә»,
(Мөхәммәтне кая куярбыз?!)
Икенчесе имли, чир дәвалый, –
Ашатырбыз, сарык суярбыз...

Берсе «оча Җиденче кат Күккә» –
Ул... Тәңренең үзен «кочаклый!»
Кайберәүләр шуңа ышаналар,
Ник надан без димен, бу чаклы?

Алла бар ул, юллар гына төрле!
Пәйгамбәрнең узган соңгысы...
Пәйгамбәргә иңгән Коръән-шәриф –
Иманлының тугры, чын дусты!..

## Авыл карты

Шомырт, сирень арасында
Йорт тора – бүрәнәдән.
Телевизоры күренми, –
Антенна көйләнмәгән.

Анда ялгыз бабай яши,
Тормышы көйләнмәгән.
Карчыгы үлеп киткән дә,
Ул кабат өйләнмәгән...

Коймасы – гади тактадан,
Капкасы – бүрәнәдән.
Монда низаглар чыкмаган,
Көфер сүз сөйләнмәгән.

Үз тормышы. Зур дөньяга
Үзенең карашы бар.
Болай боек та түгел ул,
Тик йөрәк ярасы бар...

Узган-барганга ачык ул,
Фикере җыйнак, кыска.
...Һаман карчыгын сагына, –
Мохтаҗ ул якын дуска.

## Килер бер көн

Килер бер көн:
Кояш баткан кебек,
Алга манып болыт читләрен,
Мин китәрмен якты бу дөньядан,
Аңлап зая гомер үткәнен...

Тормыш биргән балам битем япмас,
Соңгы сүзләремне ишетмәс.

Тереләргә нәрсә?
                        Алар җанын
Үлем тыны әле өшетмәс!..

Үкенүләр яше, үз-үзеңне
Гаепләүләр соңрак киләчәк.
...Сорауларга,
                  үксеп елауларга
Тынлык кына җавап бирәчәк!..

## Яшьлек горур була

Яшьлек горур һәм тәкәббер була:
Син Галәмнең гүя кендеге!
Язмышның бер селтәнүе җитә –
Ачылып китә кемнең кемлеге!..

Акыллыга шул ишарә җитә –
Үз-үзенә бәя куярга.
Ләкин ничек шашкын йөрәк белән
Тормыш аранына сыярга?!.

Китә көрәш, китә аяк терәш,
Төз умырткаң шунда сынала!
Шундый кырыс без яшәгән заман:
Корыч холыкны да сыгала!..

Син сыгылма!
Йөрәк ялкынына,
             Рухың саулыгына инан да!
Килми калмас Бәхет!
                    Рәхәт булыр,
Күкрәгеңә Җиһан сыйганда!..

Тәкәбберлек үткән.
                      Тик горурлык
Һәм Иманың алга әйдәгән.
Алар сиңа очар канат биргән, –
Азат иткән бөтен бәйләрдән!..

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Миргазиян
Юныс

# КЫПЧАК КЫЗЫ АКСАНӘ

РОМАН

**Дүртенче бүлек**

**1**

Бу юлы да Рахманкулов, кунакханәдә торудан баш тартып, дусты Дадоновларга тукталды. Юрий Владиславович бер атнадан Италиядән кайтырга тиеш иде. Нина Ивановна үзенең аптекасына иртән китә, кич кайта. Ул, очрашу белән, республика ярышында өченче урынны яулаган кызлары Евгениянең соңга калып кайтуына зарлана башлады.

Дан-шөһрәт бераз кыйммәткәрәк төшә шул... Әнә кояш. Әнә зәңгәр күк. Усак яфракларының кабаланып серләшүе. Туйганчы кара, ләззәтлән. Әлеге рәхәтлекләр һәркемгә дә тигез өләшенә. Ә менә синең исемеңә тез чүгү, син яулаган уңышларга табыну... Мәҗүсилек бит бу! Нигә шушы гөнаһны аңларга кешеләрнең зиһеннәре җитми?

Төнне Габдрахман җир өстендә, адәм балалары көн күрә торган өй рәхәтендә уздырды. Аста – җиргә салынган таш нигез. Идән һәрдаим тынычлыкта. Өйнең диварлары әүмәк-тәүмәк килеп чайкалмый. Һәм иң зур, иң ышанычлы иминлек – монда дошман кулына эләгү куркынычы янаганда, өегезгә ут төртеп яндырыгыз дигән катгый боерыкның булмавы. Корабта исә андый куркыныч сине даими сагалап тора иде.

Киенер алдыннан Рахманкулов тәрәзәгә карады. Көзге вак яңгыр сибәли. Шәһәр өстен бүселергә торган авыр болытлар каплаган. Одесса көзе – елның кыяфәтсез чагы.

Чалбарын кигәндә, күзе өстәлгә төште. Эре хәрефләр белән язылган ярты дәфтәр бите.

«Габдрахман Бәкерович!

Казылык, йомырка, сыр, май – суыткычта. Чәй – шкафта. Төшке ашка безгә килеп, Оксананың хәлен белешсәң, әйбәт булыр иде. Ул бит ярыштан имгәнеп кайтты. Син килгәндә, Евгения йокыдан тормаган булса, уятып, укуына куып җибәр.

Ачкычның кая яшерелгәнен беләсең, урыны үзгәрмәде. Нина.»

Рахманкулов табага май агызды, вак итеп ипи һәм колбаса турады, тоз сипте, кызара башлаганчы кыздырды, шуннан соң гына ике йомырка сытты. Йомырка агы пешеп катты, сарысы сыек килеш калды. Бу аның үзе уйлап чыгарган ризыгы иде. Шунлыктан һәм корабтагы общепит ашына охшамаганлыктан, гаҗәеп тәмле тоелды.

Оксана... Бу исемнең кәгазьгә язылганы тавыш белән әйтелгәненнән

*Дәвамы. Башы узган санда.*

тәэсирлерәк икән. Кадрлар бүлегенә кереп, инде җиденче ел шунда эшләсә дә, күнегелгән корабына путёвка алу һәм, өч-дүрт көннән соң шуңа утырып, Апеннин ярыматавына турист халкының Мәккәсе һәм Мәдинәсе саналган Италия портына әле беренче тапкыр юл тотуы гына иде.

Габдрахман урамга чыкты – һава юешлектән шыксыз. Әнә, җәен кояш нурларына коенып утырган карагай ботакларыннан, салкын күз яшьләре дымсу тротуарга тама. Йорт диварлары төссезлеккә төренгән. Салкын юешлек кешеләрнең кыяфәтен җимергән. Каршы килүче җәяүлеләрнең кашлары җыерылган, чырайларында канәгатьсезлек.

Пушкин урамының өч кварталын үткәч, ул, Дерибас урамын аркылыга кисеп, Опера театры каршысындагы мәйданга чыкты. Мәйдан читенә тезелгән юеш эскәмияләрнең бушлыгы, Диңгез буе бульварында яфрагын койган каштан агачларының шыксызлыгы һәм бульварның урта бер җиренә урнашкан Пушкин һәйкәле тирәсендәге моңсулык, бу – шат күңелле, уйнап-көлеп яшәргә күнеккән Ильф һәм Петров каласын матәм кәефендә күрсәтә.

Воронцов сараена ике-өч йөз адым чамасы кала Габдрахман бина эченә үтте. Озын коридор. Кадрлар бүлеге начальнигының, инспекторларның ишекләре төбендә нибарысы бишәр-алтышар кеше. Кайда коридорга сыймыйча ишегалдына бүселеп чыккан, язмыш көтеп зарыгучы чиратлар?.. Габдрахманның корабы теркәлгән инспекторның ишеге каршында, өнме бу – төшме, күптән чүплек башын сагынган пиджак кигән сыңар диңгезче. Янына килеп басуга, ишектән кызарып-бүртенеп чыккан стиляга артыннан күтәрәм хәленә җиткән диңгезче дә эчкә чумды. Рахманкулов үзе генә калды. Чиновник карамагына кергәндә, ялгыз басып тору катлаулырак икән...

– Кто крайний? – Рахманкуловның дәвамы булмаган чиратына берьюлы өч кеше килеп басты.

«Последний» дими хәзер совет чынбарлыгында чират торуларга күнеккән коммунизм төзүче. Хезмәтенә күрә, акча түлисе урынга, социалистик ярыштагы алдынгылык, ударниклык кытлыгы биргән коры куанычларга сөенгән бичараның «соңгы» сүзеннән шүрләве инде «крайний» мескенлегенә күчкән...

– Ә, Рахманкулов! – Инспектор аны аягүрә басып каршы алды. Ничәмә ел эшләп, бу чиновникның шулай шат чырай белән каршы алганы юк иде әле. Шушы кысыр рейстан соң, инспекторның якты йөз күрсәтүе Габдрахманны шикләндереп җибәрде. Бәлки шуңадыр, гадәттәгечә, яңа тәкъдимен ишетүгә, аның җавабы да шактый коры килеп чыкты:

– Җитмәдеме икән минем алмашка йөрүем?! Инде дүрт тәүлектән үз корабым кайта. Мин бит «Чолман» экипажы штатында. Башка корабларның тишекләрен ямап торудан арый башладым. «Чолман»га җибәрүегезне сорап, приказ алырга килдем.

– Сез бит үзегез әйттегез, яңа илләрне, яңа диңгезләрне күреп йөрергә яратам, дип. Онытыгызмыни?

– Онытмадым, шулай да яңа экипажга, яңа корабка күнегү мәшәкате туйдыра башлады.

– Үз пароходыңа кайтканчы, бүлек мөдиренә кереп чык. Сине Ткаченко эзли.

Габдрахманның күңеленә курку йөгерде. Начальникның үзенә тора салып кына чакырмыйлар. Диңгезчеләр арасында файдалы портларга йөрүче корабка эләгү өчен, аяусыз астыртын көрәш барганда, сине зур түрә болай гына кабул итми. Чакыру «Академик Крупчатов»тагы мәрәкәгә бәйләнешле булырга охшаган?!

Бүлек начальнигы янына керергә теләүчеләр дистәдән артык иде.

Рахманкулов чиратның койрыгына барып басты. Монда торучылар инспектор ишеге янындагыларга охшамаган иде. Күпчелегенең кашлары җимерек, йөзләрендә нәфрәт катнаш тирән төшенкелек. Болар «хакыйкать эзләүче»ләрдән булса кирәк. Кемнеңдер семофорын[1] япканнар. Кемнедер самодур капитан «ашаган»[2]. Шушы бәхетсезләрнең күпчелеге, һичшиксез, аларның туры әйтүен сыйнфый дошманлыкка санап, чит илләргә йөрүдән мәхрүм иткән патриот рухлы куштан һәм надан помполит корбаны иде. Коридорга начальникның секретарьшасы чыкты:

– Арагызда Рахманкулов бармы?

– Мин – Рахманкулов... – диде Габдрахман һәм, кызга ияреп, кабинетка узды.

– Сезне «күршеләр» чакыра, – диде Ткаченко, диңгезченең сәламенә җавап биреп тормыйча гына.

– Кем соң ул «күршеләр»? – диде Рахманкулов. Аларның кем икәнлекләрен ул белә иде. Шул исеме генә дә дер калтырата торган оешмага чакырылу аның буыннарын йомшартып җибәрде. Тетрәнүен яшерер өчен бирде бу сорауны.

– Сез, мариман калдыклары, әлеге йортны «Белый дом» дип атап йөртәсез. Сакчыга фамилиягезне әйтсәгез, шул җитә. Сезнең белән сөйләшәсе кеше үзе чыгып алып керер. Уңыш телим.

Начальникның теләге егетнең йөрәгенә ук булып кадалды. Ул йорттагы «уңыш» подвалга кереп мәңгелеккә олагу, юкка чыгу түгелме соң?.. Ежов, Берия, Абакумов төзегән оешмадан тагын нинди изге гамәл көтәргә мөмкин...

Габдрахманның ишеткәне бар, үлемгә хөкем ителгән Лубянка корбанын атарга алып чыкканда: «Шарфымны бәйләргә онытканмын. Минем тамагыма бик тиз салкын тия», – дип, камерасына кереп, муенына шарфын урап чыккан, имеш. Шундый игелек эшләсәләр генә инде...

Рахманкуловның күңелен бары бер нәрсә тынычландыра: Берияне, Абакумовны атып үтереп, дистәләрчә миллион гөнаһсыз ГУЛАГ корбаннарына, сүздә генә булса да реабилитация ясап, Никита Хрущёв совет кешеләрен дер калтырап яшәү золымында тотучыларның җинаятьләренә чик куйды. Шушы хакта уйлау Габдрахманга өмет терәге биреп тора иде. Кадрлар бүлегеннән чыккач, ул Потёмкин баскычына янәшә яр өстенә тотылган челтәрле тимер рәшәткәгә терәлде дә причалда йөк бушаттырып яисә төятеп торган пароходларга, тышкы рейдта йокымсырап чират көткән корабларга бертын карап торды. Ярдан караганда, кораб эчендәге михнәт, зарыктыргыч диңгезчеләр тормышы күренми. Йөк төялеп беткәч, корабларның ерак диңгез-океаннарга, ымсындыргыч бай, маҗаралы тормыш кичергән илләргә юл тотачаклары гына күз алдына килеп баса. Әгәр Колумб, Магелланнар, төрекләрдән чыккан «диңгез бүресе» Барбароссалар чорында аларның язмышы КГБ кулында булса, ерак илләргә, хәтта моңа кадәр кешелек дөньясына билгесез кыйтгаларга юл ачылыр идеме икән?!

## 2

Ак йорт. Гадәттә, АКШ Президенты яшәгән йортны шулай дип атап йөртәләр. КГБның диңгезчеләр эше белән шөгыльләнгән бүлеге бинасына да шундый ук исем бирелү бик үк аңлашылып бетми, әлбәттә. Диңгез ягыннан караганда, бу йорт Вакуленчук урамының уң ягына урнашкан. Йортның акка буялган биек дивары түгәрәкләнеп эчке якка батып тора. Рококо ысулына

[1] Семафор – диңгезчеләр шивәсендә виза.
[2] «Ашаган» – гаделсезлек эшләп, корабтан куылган.

алмашка килгән французлар классикасы. Бинаны Одессага нигез салдыртучы Дюк Решелье төзеткән. Җитди эшкә тотыныр алдыннан, Габдрахманның әнисе Фәриха карчык дога укый, Хозыр Ильястан юлдашлык сорый иде. Бала чагында аның чәченә кадәр әнисе ала иде. Эшен бетергәннән соң, күлмәк-ыштанына сырышкан чәчләрне сыпырып төшерә дә тәңречелек чорыннан калган ырым сүзләрен такмаклап ала: «Карчыгадан – кан, ябалактан – йон. Кошка-киеккә түмгәк булып күрен! Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы».

Ишек төбендә аяк сөртергә каеш җәймә. Янәшә бернинди белдерү куелмаган. Габдрахман, мәңгелек өчен эшләнгән авыр имән ишекне ачып, бусага аша эчкә атлады.

– Сез кемгә? – диде хәрбиләрчә киенгән кеше, каршы чыгып.

– Минем фамилиям Рахманкулов.

– Сезгә килделәр, – диде ишек саклаучы, телефон трубкасына.

Ишек сакчысы, күзе белән Габдрахманны капшап, сиздермичә генә тенти иде. «Нәрсә эзли икән бу бәндә?» – дип уйлап алды Габдрахман. Коридорда аңа таба килүче бер кеше күренде.

– Исәнмесез, – диде ул җылы гына. – Сез Рахманкулов буласызмы?

– Әйе, мин Рахманкулов.

– Әйдәгез.

Алар коридордан янәшә атладылар. Бераздан соң, каршы алучы арткарак калып, бер ишекне ачты:

– Рәхим итегез. Утырыгыз, – диде ул, өстәл янындагы урындыкка күрсәтеп. Үзе каршы якка барып урнашты. – Безгә сүзнең дөресе генә кирәк. Иң дөресе. Курыктыгызмы кингстонны ачарга?

– Аны бит моторист Ясиненко ачты.

– Ачты? Ә нишләп соң корабка су кермәде?

– Ул вентильне кирегә, ябылу ягына борган.

– Кире якка борганын күргәч, нигә әйтмәдегез?

– Мин аны ача дип уйладым. Ясиненко сулагай.

– Нинди аерма? Сулагайга да бит ачар өчен сулга борырга кирәк. Сез аның ябу ягына боруын аңларга тиеш идегез. Дөресен әйтегез, Ясиненко белән сүз куешып ялганлыйсызмы?

– Сүз куешкан булсак, мин аны ломга йөгертмәс идем.

– Ярый. Дөресен әйтергә теләмисез инде. Куркасыз. Безнең бит ялганны ача торган приборыбыз да бар. Ачыклыйк әле, – кабинет хуҗасы селектор төймәсенә басты. – Миңа детектор кирәк. Көтәм.

Кабинетка, мунча кирәк-яраклары йөртә торган чемодан зурлыгы тартма күтәреп, өлкән сержант килеп керде. Тартманы ачып, эченнән кабель чыгаргач, Габдрахманның кулларына ике беләзек белән тоташтырды. Сорау алучының алдына – экран, җавап тотучыга каратып өстәл сәгате зурлыгы прибор куелды.

– Ток җибәримме?

– Җибәрегез.

Өстәлдәге нәрсә ишетелер-ишетелмәс кенә безелди башлады.

– Минем сорауларга сез дөрес, бары тик дөрес кенә җавап бирергә тиешсез. Аңладыгызмы?

– Аңлашылды.

Америка Үзәк разведка идарәсе уйлап чыгарган «ялган тоту детекторы»на ишарә иде бу прибор. Америка приборын кайда гына мыскыллап бетермәделәр. Хәзер инде үз мыскылларын үзләре үк куллана башлаганнар.

КГБчы бу юлы сорауларын читләтебрәк, бераз серлерәк итеп бирергә тырыша иде. Үзе экранга карап та тормый. Әлеге хәл «ялган тота торган детектор»ның куркытыр өчен генә куелган алдавыч икәнлеген ачык күрсәтә иде. Курыкканда адәм баласы сагая. Бу чакта аның көче, зиһене шул куркуны җиңүгә китеп бетә. Бу хәлне Габдрахман суга батып үлү куркынычы үткәч аңлады. Кингстонны ачарга төшкәндә, аның мие таш булып каткан иде. Аңлап, акыл белән эш итү сәләте юкка чыккан. Кораб суга батканнан соң, башкалар белән ул үзе дә үләчәк бит. Менә шул тончыгуның үлем икәнлегенә аның күңелендә бер генә бөртек тә ышану юк иде. Сөаль алучы хәлне аңларга әзер түгел. Бу халәтне ул урыс телендәге «трусость» дип атый. Курыкканда син, телисеңме-юкмы, сагаерга, шул куркыныч алып килгән афәткә каршы чара эзләргә тиешсең. Илле җиде мең тонна авырлыктагы корабның суга батуына каршы тора алырлык чара табу мөмкинме соң? Капитанның сейфында сакланган секретный боерыкта диңгезчеләрне коткару турында бер генә сүз дә юк иде. Бу бит очраклы хәл түгел. Алар катгый рәвештә батып үләргә тиеш иделәр. Исән калсалар, американлылар кулына эләгеп, серне сөйләүләре мөмкин ич...

Аларны батырырга җибәрүче капитанның да башы каткандыр. Кингстонны ачуга, ул үзе дә батып үлә. Ә кем исән кала? Әлбәттә, боерык кәгазен язучылар исән кала. Кубага ракета илтүне оештыручылар да исән калачак. Алар әле исән калу белән генә чикләнмичә, бер бөек вакыйганы оештыручы даһилар булып тарих битенә керәчәкләр.

Ватан сугышында фашист гаскәрләренә каршы атакага баручылар, чигенә калса, аларны атып үтерергә кулларына мылтык тоттырып артларыннан заградотряд җибәрелгән шикелле чаралар да бүгенге көндә лаеклы алым санала. Ә менә үләсе урынга исән калу!.. Моторист Ясиненконың, капитанның, батып үләсе урынга исән калган өчен, ни сәбәпле приказ үтәлми калганын ачыклаган булып җаннарын алалар иде. Алай гына да түгел, «Академик Крупчатов»ның экипажы тулысынча кара исемлеккә эләкте. Хәзер аларның барысы да совет чынбарлыгында Ватанга тугры булуларын югалттылар. Шушы хәлне көнбатышта яшәүчегә сөйләсәң, ул сине ялганчыга санар иде. Ә алар илендә бу табигый нәрсә.

– Башка соравым юк, – диде КГБчы, куркытырга көйләнгән сораулар белән сәгатькә якын Габдрахманның җанын газаплаганнан соң. – Менә шушы кәгазьгә язылганны дикъкать белән укып кул куясыз һәм, кисәтәм, бу йортта булганыгызны беркем дә белмәскә тиеш.

Кәгазьгә шул ук «күрмәдем, белмәдем, кабергә кергәнче беркемгә дә сөйләмичә, сер итеп сакларга ант итәм» сүзләре язылган иде.

«Ак йорт»тан чыккач, Габдрахман, трамвайга утырып, туры Ланжеронга юл тотты. Трамвайдан төшеп, Шевченко паркы аша диңгез ярына чыкты. Җил аударган агач кәүсәсе янында үзен кая куярга белмичә басып торгач, шул агачка менеп утырды. Еракларда йөреп кайткан кораблар, диңгез яры буеннан Воронцов маягына турылап, портка таба ашыгалар. Сәяхәткә китүчеләр, палубага баскан килеш һаман ерагая, әкрен генә югала, җуела килгән үги туган җирнең ярларына карап, ирексездән үзләренең хыялый киләчәгенә чумалар.

Колумблар, Джеймс Куклар чорында да инквизиция исемле кара көчләр, һичшиксез, булмый калмаган. Тик ни өчен бу гамәлләрнең рәхимсезлеге, кешелекнең аңы үскән саен, аз гына да кимүгә таба бармый?..

Христофор Колумб Җир шарының Библиядәгечә өч кенә кыйтгадан

тормавын ачты. Магеллан, инквизиция учагында яндырылган Джордано Бруноның сүзен куәтләп, Җир шарының түгәрәк булуын, аның Кояш тирәсендә әйләнүен раслады. Аларга бит инквизиция тимәде. Ә син, Бәкер улы Габдрахман, Американы сугышта җиңү максаты белән халкын ярым ач, ярым ялангач тотып, миллиард, триллионнарга төшкән ракета ясауны тәнкыйтьләп кара әле – Советлар Союзының инквизициясе сине төрмәдә черетәчәк...

**3**

Йокысыз төн. Ул нигә шулай озын була икән? Иртән Рахманкулов «Чолман»га путёвка алырга кадрлар бүлегенә килде. Чират озын иде. Ниһаять, ул инспектор каршында.

– Ял сорап гариза языгыз, – диде инспектор.

– Мин бит «Крупчатов»ка утырыр алдыннан гына ял иттем. Минем үз корабыма утырасым килә.

– Җитәкчелек сезне ялга җибәрергә куша.

Ялдан соң Габдрахман бары бер генә тапкыр диңгезгә чыкты. Әле бит ялда тотарлык акча да ала алмады. Өстәвенә көзнең иң шыксыз, иң елак чагы. Мондый шыксызлыкны ул Африкада, гарәп илләрендә, Һиндстанда үткәрергә ярата иде. Ялга китәргә куштылар – син буйсынырга тиешсең.

Боерыкның «күрше»ләрдән килүе көн кебек ачык иде. Алар, Габдрахманның визасын ябар өчен, тырнак астыннан кер эзли башлаячаклар. Хәзер аңа беркем ярдәм итә алмый. «Күрше»ләр шулай куша. Бу карар Аллаһы Тәгаләнеке белән дәгъвалашыр дәрәҗәдә иде. Аның визасы ябылу кадрлар бүлеге инспекторы өчен дә файдалы иде. «Чолман» даими рәвештә Италия портларына йөри. Димәк, Рахманкуловның урыны өчен әйбәт кенә ришвәт алырга була.

Эш көне тәмамланганда, мәсьәлә хәл ителгән иде инде. Җилнең кайсы яктан искәнен ул аңлый... Дадоновның хатыны аңа Оксананы күрмичә китмә, дигән иде. Кыз бит аны ошатмады шикелле... Баскыч төбенә килеп туктауга, ашыгып өенә кереп китте. Кызның телефоны да юк иде аңарда. Хәзер бит очрашуны телефон аша оештыралар. Ул гына иске гадәтеннән арына алмый. Сүз, югыйсә, сөйләшүнең бер өлеше генә. Күреп сөйләшкәндә, адәм баласының күз карашы, туктаусыз үзгәреп торган йөзе, аяк-кулларының хәрәкәте, хәтта киенеп килүе – боларның барысы да әңгәмәгә катнаша. Кайчакта күз карашы, яисә кешенең йөзендә туктаусыз үзгәреп торган хисләр чагылышы сүзнең эчтәлегеннән дөресрәк була. Шуңа күрәме, телефоннан сөйләшкәннән соң барлыкка килгән бушлык аның күңелен озак кына кыбырсытып тора иде.

Рахманкулов Нина Ивановна эшкә китәр алдыннан язып калдырган телефон номерын җыйды. Шактый вакыт трубканы алмый тордылар. Ниһаять:

– Тыңлыйм.

Йа Хода! Аллаһы Тәгалә хатын-кызга тавышның шундый да матурын, тәэсирлесен биргән бит! Телефон трубкасындагы аваз каяндыр тирәннән, хисләрнең куе һәм кайнар төпкеленнән чыга иде.

– Рахманкулов мин. Хәтерлисезме икән, без Дадоновларда танышкан идек. Исәнлек-саулыкмы?

– Рәхмәт. Зарланырлык түгел.

– Минем сезнең белән очрашасым килә. Сәгать ничәдә, кайда очраша алабыз?

Тынлык. Трубкадан кызның сулыш алганы ишетелә шикелле.

– Нигә кирәк сезгә минем белән очрашу?

– Женя Дадонова миңа Киевта узган спартакиада турында сөйләде. Сезне дә искә алды. Шул турыда минем үзегездән ишетәсем килә.

– Женя сөйләгән бит инде. Ул турыда минем сөйләшәсем дә килми.

«Шалтыратуыгызга рәхмәт, сау булыгыз», – дип трубкасын куйса, шалтырату мөмкинлеге юкка чыгачак. Кыюрак кыланырга кирәк, дип уйлады Габдрахман һәм ашыгып әйтте:

– Кичке сәгать алтыда мин сезне бульварда, Пушкин һәйкәле янында көтәм. Үтенеп сорыйм, килми калмагыз, яме?

– Белмим әле... барасы җирем дә бар иде.

– Бергәләп барырбыз. Мин сезне көтәм...

– Килмәсәм... Килә алмасам... Кичерегез.

Моңа кадәр аның очрашудан баш тарткан кызга очраганы юк иде шикелле. Ни өчен? Ул, чакырганчыга кадәр, башта кызның очрашасы килүен ачыкларга тырыша иде. Кыз сиңа кызыкмый икән, аның белән очрашу нигә кирәк?

Очрашасым килми дип өзеп әйтмәде бит. Ярышта җиңә алмавын авыр кичерә. Кызның очрашырга атлыгып тормавы аның теләген көчәйтеп җибәрде. Бераз көтәргә дә кабат шалтыратырга.... Парикмахерскига кереп, чәчне алдырырга кирәк булыр. Бу фикер аңа көлке тоелды. Фраер! Син нәрсә, әллә горурлыгыңны сындырырга җыенасыңмы? Очрашасы килмәвен белгертте бит. Төкер. Сине көчләп ялга җибәрәләр. Авылыңа кайт. Мәхәббәтне туган авылыңнан эзләргә кирәк. Гаилә корыр вакыт җиткән. Нәсел калдыру турында оныттыңмыни? Төкер! Төшермә абруеңны. Шалтыратма ул кызга. Спорт белән шөгыльләнүчеләрнең кем икәнен белмисеңмени...

Габдрахман, бухгалтериягә кереп, ялга тиешле акчаны алып чыкты. Әз түләделәр. Аны саклык кенәгәсенә күчерде. Мондый акча белән ялга кайтырга ярамый. Парикмахердан чәчен алдырды. Телефон трубкасындагы таныш тавышны ишеткәч кенә, каботажда йөзгәндә бергә эшләгән дусты Виктор Смирновка шалтыратасы урынга Оксананың телефон номерын җыйганлыгын аңлап алды.

**4**

– Алло! Оксана тыңлый.

– Һаман мин әле бу, – диде Габдрахман, уңайсызланып. – «Украина» кинотеатрында «Девять дней одного года» исемле фильм күрсәтәләр. Төп рольне Алексей Баталов уйный. Карыйсыгыз килмиме?

Озак кына җавап булмады.

– Кайчан?

– Сәгать икедә башлана. Курыкмагыз, өлгерәсез әле.

– Минем поликлиникага кереп чыгасым бар иде.

– Өлгерәсез. Сезне касса янында көтәм. Танырсыз бит?

Җавап урынына трубкада «пип»ләгән тавыш ишетелде... Көтеп торуның газаплы рәхәте. Көткән чакта нигәдер вакыт агымы әкренәя. Күңел түреннән тынгысыз уйлар калкып чыга башлый. Әгәр килми калса?.. Кыбырсынма инде. Тынычлан. Әнә, Собор мәйданы ягыннан бу якка ашыккан кыз күренде. Оксанамы? Менә ул, Преображенскаяны аркылыга узып, Дерибас урамына чыкты. Ашыга. Юк, бу башка кыз. Яһүдиләргә хас кылыч борын, ярым кысылган җитди иреннәр. Атлап килүе исә шундый җиңел, килешле.

– Исәнмесез!

– Исәнмесез, – диде Габдрахман, югалып калуын сиздермәскә тырышып.

Оксана аңа сул кулын сузды.

– Кичә генә гипсны салдырдылар. Кыймылдатырга куркам.

Сеанс башланырга ярты сәгать вакыт бар иде әле.

– Башланганын монда көтәбезме, әллә керикме? – дип сорады Габдрахман бераз кыюланып.

– Миңа барыбер.

– Әйдә, керик алайса. Мин фойеда артистларның сурәтләрен карарга яратам.

Фойега уздылар. Рахманкулов туңдырма алырга чиратка басты. Оксана, аның янына килеп, җиңеннән тартты:

– Үзегезгә генә алыгыз. Миңа кирәкми.

– Яратмыйсызмыни?

– Яратмыйм да, аннан соң...

– Әйтеп бетерегез. Аннан соң нәрсә?

– Аңлатмасам ярыймы?

– Ярый да, минем беләсем килә, туңдырма алып бирүнең сезгә ошамаган ягы бармыни?

– Бу дөньяда бит бернәрсә дә бушлай бирелми. Соңыннан шул бәяне кайтарырга кирәк була.

– Ничек инде кайтарырга? Берничә ай үткәч: фәлән тапкыр туңдырма алып бирдегез, фәлән мәртәбә киногa керергә билет алдыгыз, ә бусы – трамвай акчасы, дип, сез миңа кире кайтарырга тиешмени?

– Кайтарып бирү гадәте юк, анысы дөрес. Беренчедән, мин түлисене түләү сезне юмарт итеп күрсәтүгә көйләнгән. Икенчедән, хак зурая барган саен, сезгә буйсынуым белән хокуксызлыгым көчәя генә. Әнә бит, алган эш хакын бәхилләтү өчен, көне-төне бил бөгәләр. Банктан алган кредитны да арттырып түлиләр.

Мондый фикерне Габдрахманның беренче тапкыр ишетүе иде. Ул рәхәтләнеп көлде.

– Әнә, звонок бирделәр. Кереп утырыйк... Сез уң ягыгыз белән бәрелгән идегезме?

– Әйе, уң як җилкә.

– Алай булгач, мин алдан керим әле.

Салмак кына караңгылана барып, ут сүнде. Зал эчен караңгылык капласа да, Оксананың сурәте югалмыйча, күз алдында торуын дәвам итә иде. Күз генә түгел, тәннең һәр күзәнәге тәнне чымырдата торган шушы тылсымны тоеп, күреп тора шикелле иде. Әнә, кыска итеп калдырылган куе чәч. Кыйгач каш, татар халкының җырларында сурәтләнгән уйчан кара күзләр. Алар хәзер кул белән үрелеп тотарлык янәшәдә. Бу мизгелдә Оксананы аңлау өчен сүзнең кирәге юк иде.

Экранда кеше сурәтләре хәрәкәтләнеп тора. Сөйләшәләр. Дуслык һәм астыртын дошманлык. Фәнни институтта атом төшен өйрәнәләр. Галимнәрнең көндәлек эшләре – Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләрен җимереп, миллионлаган японнарны агулап үтергән атом көчен эшкә җигәләр. Габдрахманның иң яраткан артисты Алексей Баталов атом радиациясе белән агуланган. Ул тиздән үләргә тиеш. Шунлыктан, үлгәнче эшен тәмамлап өлгерер өчен, көне-төне эшли. Экранда хезмәт, дуслык-дошманлык хисләре, фильм персонажларының мәхәббәтләре хәрәкәткә килеп тора. Башка чакта артистлар уйнап күрсәткән ясалма тормыш аңа тәэсир дә иткән булыр иде. Бүген аның дикъкатен янәшә утырган кыз тулысынча яулап алган да, җибәрмичә, тетрәндергеч ләззәт ялкынында тота.

Егетнең уң кулы кызныкын эзләп тапты. Тотты. Оксана тоттырырга теләмичә, кулын тартып алырга теләде. Карышуда хисләр сизгерлеге генә тоя алырлык сүлпәнлек сизелде. Габдрахман кулны җибәрмәде. Әкренләп егет учындагы бармакларның каршылыгы сүнде.

**5**

Ут кабынды. Габдрахман кызның кулын ычкындырды. Әнә, әле генә күңелләре белән экрандагы сурәтләр арасында яшәгән тамашачылар, урыннарыннан кузгалып, ишеккә ашыга. Бераздан дөнья көтүнең әрсез, вак мәшәкатьләре кинофильм биргән хисләрне юып ыргытачак. Тормышның кануннары катгый. Никадәр тырышып карасаң да, син кинодагы шикелле яши алмыйсың.

Дерибас урамында көн саен бәйрәм. Аралашу, күлмәк күрсәтү, менә мин кем белән култыклашып йөрим дип мактану бәйрәме. Хәзер алар да бәйрәм итәләр. Кыз белән егетнең аяк атлаулары үзара берләште. Ара якыная төште. Күрегез, менә без бу! Башлап җибәрергә сүз генә табып булмый, чөнки чиктән тыш акыллы, яңа, күңелне рәхәтләндерә алырлык хисләргә тәңгәл тантаналы сүз кирәк. Көндәлек мәшәкатьләрдә кулланыла торган төссез, артык еш кулланудан таушалып беткән сүз монда яңгырый алмый.

– Мине ял итәргә җибәрәләр, – диде Габдрахман, лаек сүз таба алмавына тәмам газапланып.

– Ял итүе рәхәт бит. Шатлана торгансыздыр?

– Мин соңгы рейска чыгар алдыннан гына ялдан кайткан идем. Көчләп җибәрәләр.

Оксананың йөзенә елмаю йөгерде. Елмаю адәм баласына эчке бер рәхәтлек, канәгатьлек алып килә. Кызның матурлыгы тәэсирлерәк булып киткәндәй иде.

– Ялдан баш тартмас идем мин. – Кызның күз карашы тоныкланды. – Хәзер минем эшем дә, ялым да юк. Спортны ташлыйм. Өч ел укыганым бушка китте.

– Укуыңны да ташлыйсыңмы?

– Мин бит юләр булганмын. Уку йортымыни ул спорт институты. Марксизм-ленинизмнан башка бернинди фән керми. Физиология белеме буенча сынау тапшырдым. Шушы көнгә кадәр бавырымның да, бөеремнең дә кайда икәнен белмим.

Сәрби, каштан агачлары төбенә куелган эскәмияләрдә буш урыннар бар. Шуларның диңгез ягына караганын сайларга да әңгәмәне утырып дәвам итәргә иде. Урынны, гадәттә, егет сайлый. Әңгәмәне алып бару да, гадәттәгечә, егет карамагында булырга тиеш. Габдрахман, утырсак әңгәмә туктар, дип курыкты. Дадоновларда утырганда, беренче тапкыр озата барганда, кызны сөйләштерү авыр иде. Бүген тыңларга гына өлгер.

– Мединститутка күчәргә уйламыйсыңмы?

– Анда бит читтән торып укытмыйлар. Әниемнең пенсиясе үзенә дә җитми. Заочныйга күчәргә уйлыйм.

– Нинди факультетка?

– Әдәбиятныкына.

– Филфакка? Мин бит, читтән торып, шул факультетны тәмамладым.

– Женя әйткән иде. Аңламадым. Диңгезчегә әдәбият белеме нигә кирәк?

– Әдәбиятны белү һәркемгә дә кирәк. Яшәү тәҗрибәсенең күп өлеше әдәбият битләренә тупланып калган.

– Тарихка түгелмени?

– Дөрес, тарихта да бар ул. Тарих фәнен сәясәт басып киткән. Диңгезгә бер

күтәрәм китап алып чыгам. Йөзү вакытында китап укудан да зур юаныч юк. Китапны ял вакытында Мәскәүнең букинист кибетләреннән эзлим. Сатучылар арасында минем танышларым бар, күбрәк шулардан алам. Билгеле, белмәгән кешегә сатмыйлар. Алар белән университетта укыганда танышкан идем.

– Корабта стукачлар да шактый була, дип сөйлиләр бит. Курыкмыйсызмы соң?

– Андый китапларны яшереп укырга туры килә. Күз буяр өчен, китапханәдән алганнарын өстәлемдә тотам. Диңгезче халкы күп укый. Бу турыда америка язучысы Эрнест Хемингуэй да «диңгезчеләр арасында китап яратучылар күп», дип язган. Шымчылыктан тыш безне бит әле даими тикшереп тә торалар. Тревога уйнап, экипаж әгъзаларын шлюпкага төшереп утырталар да стукачлар каюталарда актарынып тентеп йөриләр. Евгениянең әтисе белән мин эшли торган пароходның капитаны Иван Андреевич мине алдан кисәтеп куя. Корабта «шмонь» булыр алдыннан укырга ярамаган китапларымны капитан каютасына кертеп яшерәм.

– Ул үзе стукачлардан курыкмыймы соң?

– Курка. Башкача мөмкин түгел. Алар бит астыртын эшлиләр. Карап торырга, болай, аерым дошманың да юк шикелле, ә сине меңләгән, йөз меңләгән тулы бер система идән астыннан эзәрлекләп тора. Берияне атканда, Колыма бозлыгында алар кулыннан үткән миллионлаган мәет ятуы ачыкланды.

Сөйләшеп бара торгач, суга батырылган инглиз корабы «Тигр»дан алып һәйкәл итеп куелган тупны, Пушкин һәйкәлен, Потёмкин баскычын үтеп, хәзерге пионерлар йорты – князь Потёмкин сараена барып та җиттеләр.

– Эчкә керәбезме?

– Рөхсәт итәләрме соң?

– Керергә ярый торгандыр, сакчы юк бит.

Алар, сарайның матурлыгына сокланып, бертын карап торганнан соң, яр өстенә урнашкан колонналар янына – пропилеигә уздылар.

Аста, ярның итәге белән портның биек таш коймасы арасында урам. Койма эчендә дәүләтләрне үзара тоташтырып, сәүдә итеп, байлык туплау мөмкинлеге биреп торучы могҗизалы диңгез порты.

## 6

Габдрахман курткасын, салып, колонналар нигезендәге ташка җәйде:

– Рәхим итегез.

– Пычрана бит.

– Юарга була. Без керне бауга тагабыз да диңгезгә ташлыйбыз. Ярты сәгатьтә чип-чиста итеп юыла.

– Кайсы илнеке бу куртка?

– Мин аны Сингапурдан алган идем. Инглизләрнеке булса кирәк.

Оксана сумкасыннан баш яулыгы алды да куртка урынына җәйде.

– Сез шул чит ил киемнәрен киеп, кызларның күзләренә төтен җибәреп йөрисез бит. Таушалмасын инде.

Габдрахман кызның урнашканын көтеп торды да янына килеп утырды. Оксана читкәрәк шуышмады. Габдрахман шатланып куйды. Димәк, каршы түгел. Беренче тапкыр озатканда, кызның кочакларга рөхсәт итмәвен ул якынаясы килмәүдәндер дип уйлаган иде. Ялгышкан икән.

– Миңа ял сорап гариза язарга куштылар. Көчләп җибәрәләр.

– Ялга җибәрсәләр, мин шатланыр гына идем. Ярышка катнаша башлаганнан бирле ял дигән нәрсә онытылды.

Кызларның матурлыгы алардагы күп нәрсәне каплап-яшереп куя. Кызлардагы матурлык акыл юклыгын, холыксызлыкларын күрсәтми. Чибәрлеге җитмәгәннәренең кимчелекләре күзгә бәрелеп тора, матурларныкы исә өйләнешкәннән соң гына ачыла башлый.

– Туган авылыма кайтышлый мин Мәскәүгә тукталам. Теләсәгез, алып барам. Ял итеп кайтырсыз. Башкалада булганыгыз бардыр бит?

– Юк шул. Киевтән соң Мәскәүне күрермен дип хыялланып йөри идем. Менә бит ничек килеп чыкты...

Габдрахман кызның кәефе кырылганын сизеп алды. Спорт, ярышлар, гомумән, кызның бүгенге хәленә кагылмаска кирәк иде.

– Икебезгә дә күңелле булыр, әйдә, Мәскәүгә бергә барыйк.

Кыз көлеп җибәрде:

– Дадоновлар сезне тыйнак дип мактыйлар. Минемчә, ирләрнең барысы да бертөрле.

Беркемнең дә башкаларга охшыйсы килми. Һәр адәм заты үзенең бердәнберлегенә ышанып яши. Оксананың башкаларга тигезләве Габдрахманга ошамады.

– Сезнең бу фикерегез белән килешмим мин, – диде Рахманкулов. – Һәр кеше аның үзенә генә хас сыйфатларга ия. Минемчә, адәм заты башка җан ияләреннән шушы ягы белән аерылып тора.

– Мин бит җир йөзендә яшәүчеләрнең бөтенесе турында сөйләмим. Ирләр җенесе турында гына сүз алып барам. Әнә, обком секретаре. Мин бит аның оныклары яшендә. Шул карт шакал сөяркәлеккә кодалый. Ул әле баш тартырмын дип уйлап та карамый. Пароходчылыкның пассажир лайнерлары белән идарә итүче ике балалы Маланский[3] мине люкс каютага утыртып круизга барып кайтырга кыстый. Ә бит аларның кесәләрендә кызыл тышлы партбилет. Үзләре әхлаклы булу, хатыннарга хыянәт итүнең зур гөнаһ икәнлеге турында безгә туктаусыз тукып торалар. Ә үзләре?

– Сез мине нигә шул карт алашаларга тиңлисез? Беренчедән, мин нәкъ сезнең шикелле ялгыз, буйдак. Икенчедән, обком секретаре шикелле чиратсыз фатир бирә алмыйм. Владлен Лебедев шикелле бушлай круизга да җибәрә алмыйм. Дөрес, Мәскәүгә барып кайтырга билет юнәтә алам. Кунакханәгә түләү мөмкинлегем дә бар. Бу егет мине Мәскәүгә алып барган өчен аның белән түшәккә ятарга тиешмен дип уйлый күрмәгез. Шикләнсәгез: «Мин Габдрахман Рахманкуловтан әҗәткә фәлән сум акча алып тордым, эш хакы ала башлау белән, кайтарырга вәгъдә бирәм», – дип, расписка язып бирегез. Аннан соң мөнәсәбәтләребезнең сафлыгы өчен мин Дадоновлар каршында җаваплы. Белмим, минем турында сезгә әйттеләрме икән, Оксана саф күңелле, кулдан кулга йөреп таушалмаган кыз, дип алдан кисәтеп куйдылар. Бу гаиләгә булган изге мөнәсәбәтемә тап төшерәсем килми.

– Алар миңа да әти-әнием кебек якын. Танышларыбыз Евгенияне бертуган сеңлем дип ышанып йөриләр.

– Оксана, – диде Рахманкулов. – Иртәгә иртүк аэрофлот кассасына билет алырга барам. Әле вакыт бар, уйлагыз: күрәсегез киләме Мәскәүне, юкмы. Иртәгә мин сезгә шалтыратырмын.

– Мин риза, – диде Оксана, бертын уйлап торганнан соң. – Тик бер генә көнгә... Күпме түләгәнегезне әйтерсез. Мөмкинлек туугач сезгә тоткан акчагызны кайтарып бирәчәкмен.

[3] Одессада яһүдләрне шулай атап йөртәләр.

**7**

Үзәк почта бинасы янына җиткәч, Габдрахман җир шарын күтәргәндә үләргә җитеп көчәнгән атлант сыннары янына тукталмыйча узмый иде. Борынгы греклар адәм баласындагы акылга, аның көченә һәм матурлыгына сабыйларча сокланып карый белгәннәр. Алар, чыннан да, кешелек дөньясының сабыйлыгы чорында яшәгәннәр. «Ә без, – дип уйлады Рахманкулов, үзәк почта яныннан узганда, – «салкын сугыш» дип аталган чорда яшибез...» Сабаниев күпере янындагы йортка иртәнге сәгать алтыга килеп җитәргә тиеш иде. Инде җиденче өч минут. Уйланып торырга вакыт юк. Ул ашыгып атлый башлады.

Әнә, баскыч төбендә аны Оксана көтеп тора. Габдрахманның күңелендә горурлык уянды. Кыз Мәскәүгә барудан баш тартыр дип юкка гына хафаланган икән...

– Гафу итегез, биш минутка соңга калдым. Хәерле иртә.

– Хәерле иртә. Зур җүләрлек инде минем Мәскәүгә баруым. Анда соң миңа нәрсә калган?

– Башкала белән танышырга кирәклегең калган. Әйдә, киттек. «Дулкын» ресторaны янында такси тукталышы. Шул якка барабыз.

– Аэропортка автобус йөрмимени?

– Йөри. Аэропортка егерме минуттан кузгалырга тиеш.

– Әйдәгез, автобуска утырыйк. Таксига, гадәттә, шапырыныр өчен утыралар.

Алар Ильф һәм Петровның китабында сурәтләнгән «Фанкони» кафесы янындагы автобус тукталышына юл тоттылар.

Кызның өстендә тәненә сыланып торган ак свитер, тез астына төшеп туктаган кара итәк, аягында тәбәнәк үкчәле арзанлы туфли. Юл йөргәндә кирәк-ярак әйберләрен, спорт киемнәрен сала торган көрән сумкасын җилкәсенә аскан. Баскыч төбендә аның килгәнен көтеп торган Оксананы күрү белән, Габдрахман шуны аңлады: кызлар үзләрен матур итеп күрсәтү өчен юкка гына Парижның данлыклы кутюрьеләре теккән кыйммәтле күлмәк киеп, меңәр, йөзәр мең сумга төшкән бизәнү әйберләрен тагып барлы-юклы матурлыкларын көчәйтергә тырышалар. Аллаһы Тәгалә биргән матурлыкны зурайтып та, кечерәйтеп тә булмый, бары тик гәүдәгә килешле гади кием, хуҗаның чибәрлегенә комачаулык китермичә, аның балкуына юл биреп торырга гына тиеш.

Габдрахманга бүген җир шары Оксананың матурлыгы тирәсендә әйләнгән кебек тоела иде. Әнә, алар автобуска килеп керү белән, кырык яшьләр тирәсендәге бер ир, урыныннан күчеп, янәшә утыру мөмкинлеге бирде.

Башта – шәһәр үзәге, аннан соң Исаак Бабель әсәрләрендәге Молдаванка, җирдән яңа күтәрелә башлаган йортлар каплаган шәһәр чите... Ниһаять, адәм балаларын кошлар дөньясы – могҗизалы күккә озата торган тылсымлы урын – Одессаның аэропорты каршыларында әкияттәге шикелле үсеп чыкты.

**8**

– Без бит инде Мәскәүдә кунып тормабыз? – дип сорады Оксана, самолётка кереп утыргач.

– Билетны кичке рейска компостировать иткән булсам, концертның яртысын гына карый алыр идек. Мин инде билетны иртәнге самолётка компостировать иттем.

Оксана җавап бирмәде. Егеткә ияреп Мәскәүгә бару турында ул озак баш ваткан булса кирәк. Кичләрен Дерибас урамында, Диңгез буе бульварында култыклашып йөрү – бусы табигый. Тойгыларның кузгалганын, бер-береңнең

хисле сүзләреннән исерә башлаганыңны тоеп йөрү – кыз белән егет арасындагы гадәти хәл. Ә менә очкычның кәнәфиенә чумып утырганнан соң, бергәләп күкләргә менгәнеңне тою, кул кысышып билгесезлек кочагына кереп югалу – бу инде култыклашып йөрүдән дә, озатышулардан да җитдирәк нәрсә.

Очкыч, урыныннан кузгалып, очу кырына бара башлады. Самолётка кушылып егет белән кызның да тәннәре калтырый кебек иде. Ниһаять, очкыч тукталды, пилот, тормозга басып, двигательләрнең әйләнүен тизәйтә башлады. Калтырану һаман көчәя. Улап сызгыруның иң көчле бер мизгелендә пилот аякларын тормоздан алды. Самолёт мизгел саен тизлеген арттыра барып, бетон өстеннән шашынып йөгерә иде. Кинәт җир очкычтан аерылып китте. Туган көнеңнән алып куенына кереп ятканга кадәр адәм баласын саклый, тота, өстендә йөртә торган җир тәэсире юкка чыгу күңелгә шом салды.

– Әллә куркасыз инде? – Габдрахман Оксананың кулын кысыбрак тотты. – Гимнастика уенында сез бит һавада очып йөрисез, сальто ясап, әллә ничә тапкыр бөтерелә аласыз. Ә монда арбага утырып барган кебек кенә.

– Җаным өлгерә алмыйча, җирдә калган шикелле булды. Мин җанымны югалттым кебек тоям.

– Юк инде. Сез бит батыр кыз. Сер бирмәгез.

– Әйтүе җиңел. Әгәр сезнең белән Мәскәүләргә барып йөргәнемне әнигә җиткерсәләр... Беләсезме, бездә кызларның үзләрен тота белмәүләренә ничек карыйлар?..

– Бездәгедән дә катырак, катгыйрак түгелдер инде...

– Сездә ничек икәнен белмим. Безнең хуторда кияүгә чыкмый торып егет белән әллә кайларга барып йөргәнен белсәләр, сиңа беркем өйләнми.

«Кирәк тә түгел, мин сезгә үзем өйләнәм», – дип әйтүдән Габдрахман көчкә тыелып калды.

– Йә ничек, ошыймы күккә менү?

Оксана, сүз таба алмыйча, зәңгәр күккә түшәлгән болытларга карап алды:

– Тойгыларым буталып китте. Минем бит беренче тапкыр очуым.

– Каникулга самолёт белән кайтмыйсызмыни?

– Львов аэродромыннан авылыма кырык километр, тимер юл станциясеннән бары өч кенә.

– Одессадан ярышка барганда да очмадыгызмыни?

– Без гел поезд белән бардык.

Болытлар артта калды. Самолёт саф зәңгәр чиксезлек кочагында иде.

– Өстән караганда, җир картага охшаган икән, – диде кыз, сабыйларча көләч куанып. – Ә юллар! Авыл йортлары шырпы кабы зурлыгы гына. Елгалар нигә турыга гына акмый икән? Әнә, ничек боргаланып агалар.

Кызның болай шатлануын Габдрахман беренче тапкыр күрә иде. Оксананың матурлыгы җанланып тышка бәреп чыкты.

– Елгалар гына түгел, безнең яшәеш тә шулай боргаланып ага бит, – диде Рахманкулов. – Көнкүрештә төрле киртәләр, сикәлтәләр очрап торганга шулай түгелме икән?

– Шушы сәгатькә якын араны очып түгел, җәяүләп үткәндә, күпме вакыт кирәк булыр иде икән?

– Атна-ун көн чамасы кирәк булыр иде.

Оксананың йөзенә кинәт кенә боегу билгеләре чыкты:

– Сез бит кунакханәдән миңа аерым номер алырмын, дидегез. Кыйммәткә төшмәсме?

– Сез арзан тормыйсыздыр бит? Мин загранкага йөрим... Аерым номерга гына түләрлек мөмкинлегем бардыр әле.

– Мөмкинлегегез барын беләм. Мине башка ягы борчый. Телисеңме-юкмы, әҗәтне кайтарып бирер вакыт җитәчәк. Киевта җиңеп чыксам, Мәскәүгә бушлай да барып булачак иде. Мин аңлыйм, акчалата кайтарып бирә алмаганда, кызларның нәрсә белән түләргә тиешлекләрен аңлатып торасы юктыр?

– Юкны сөйләмәгез әле. Сезнең белән янәшә утырам – миңа рәхәт. Мәскәүдә бергә йөрербез – тагын бер зур рәхәтлек. Мин сезгә үзем укыган университетны күрсәтеп горурланырмын. – «Горурлану» сүзе аңа бу очракта урынсыз тоелды. Фикерен эчтән дәвам итү рәвешендә Габдрахман Оксанадан сорап куйды: «Горурлану белән мактану арасында берәр аерма бармы ул?»

– Әллә тагын. Бу турыда уйлаганым юк. Әйтә алмам шикелле.

Рахманкулов исә, гадәтенә тугры калып, тормыш тәҗрибәсенә таянып, әлеге ике сүзнең фәлсәфи-психологик нигезләрен ачыкларга ябышты:

– Без, совет халкы, әйтик, Бөек Ватан сугышында олы җиңү белән горурланабыз. Фашистлар ягыннан дүрт миллион чамасы кеше сугышкан. Совет ягыннан – сигез миллионнан артык. Бу сугышта кырык җиде миллион совет кешесе үтерелгән булса, нимес ягыннан бары тик өч миллион чамасы. Ә инде тар-мар ителгән Германиянең бүгенге көндә иң бай, иң рәхәт яшәүче, ә Советлар Союзында һаман хәерчелек хөкем итү турында әйткән кеше бу илнең дошманына әверелә. Ә без әлеге дәүләтнең санап бетергесез сугышларында гел җиңеп торуы белән горурланырга тиеш булабыз. Җиңү бит ул бушка бирелми. Сугышларда кырылган корбаннар турында сөйләп тә торасы юк. Җиңүнең икенче ягында җиңелү барлыкка килә. Җиңүчеләрнең горурлыгы белән янәшә җиңелүчеләрнең хурлыклары, юкка чыгарылган ирекләре, мәсхәрәләнүләре яши. Минемчә, җиңү белән горурланып яшәү үзе үк зур гөнаһ. Бу турыда сез ничек уйлыйсыз?

– Тукта әле, – диде Оксана, пошаманга калып. – Фикерегезне аңлап та бетерә алмыйм бугай... Җиңү турында без гел горурланып сөйләргә күнеккәнбез. Икенчедән, сез чит илләргә йөрүдән колак кагармын дип курыкмыйсызмы?

– Бу турыда теләсә кемгә сөйләп йөрмим ич.

– Ә минем стукач түгеллегемне каян беләсез?

– Мин бит гомерем буе кешеләргә йотылып карап йөрим. Һәр әйткән сүзне күңелемнең аяусыз цензурасы аша үткәреп, ихласмы бу, әллә үзен югарырак күрсәтер өчен әйтәме, дип анализлап барам.

Кыз Рахманкуловка текәлеп карап торды.

**9**

– Сез куркыныч кеше икәнсез. Мин сезгә күпме юләр сүзләр әйтеп өлгергәнмендер инде?

– Киресенчә, минем әле кызлардан бу кадәр айнык фикерле сүзләр ишеткәнем юк иде... Иллюминатордан карагыз әле. Без башкалага якынлашып киләбез.

Очкыч, биеклеген югалтып, аска төшә башлады. Моңа кадәр бер-берсеннән ара калдырып урнашкан йортлардан кыр ягына бәрәңге бакчалары сузылган булса, Мәскәүгә җитәрәк, урман эчендәге агачлар арасына, җимеш бакчаларына төренеп утырган йортлар күренә башлады. Алпавыт утарларын хәтерләткән корылмалар арасында номенклатур урындагыларның ихата эчендә су коену бассейннарына тиклем тотканнары табигатьнең иң гүзәл урынын сайлап урнашканнар иде.

Очкыч, сөзәк кенә вираж ясап, сулга борылды.

– Юл күрсәтә торган радиостанциягә килеп җиттек, – дип аңлатты Габдрахман. – Өч тапкыр борылып, очучылар телендә «коробка» ясаганнан соң, җиргә төшеп утырачакбыз.

Егетнең сүзен раслагандай, стюардесса игълан итте:

– Каешларыгызны эләктерегез! Урыныгыздан күчеп йөрү катгый тыела! Дикъкать белән тыңлавыгыз өчен рәхмәт!

Дүртенче вираждан соң Габдрахман:

– Хәзер очкыч тәгәрмәчләрен чыгарырга тиеш, – дип куйды.

Берничә минуттан идән астыннан дөпелдәгән тавыш ишетелде. Очкыч дерелдәп куйды, аның текә генә аска төшә башлавы сизелеп тора иде.

– Сез моны каян белдегез?

– Мин, диңгезчелеккә урнашканчы, унбер ел хәрби авиациядә очтым. Пилотның осталыгын шуннан беләм, – диде Габдрахман.

Бу сүз дә тыйнаклыкка буйсынмыйча әйтелгән, үзенә соңыннан үкенү кичерешләре генә тудырачак мактану иде. Рахманкуловның моңа кадәр күңелендә яшәгән тормыш тәҗрибәсе бүген чәлпәрәмә килде. Ул бит моңарчы кызларның матурлыгы үзеңнең тыйнак, акыллы булуыңа тәэсир итә дип тирән ышана иде. Оксана янында исә аның үзен-үзе тотуы бу канунга буйсынырга һич теләмәде.

Көпчәкләр җиргә тиде. Самолётның ярсып алга ургылуын җир өнәми шикелле иде. Пилот башта әкрен һәм кыска гына итеп тормозга баскалап алды. Очкыч аяусыз зур тизлек белән алга ыргылды. Ниһаять, ул, очучының теләгенә буйсынып, аэропорт бинасына борылды. Пассажирлар кабаланып чыгарга җыена башладылар.

Рахманкулов исә үзенең күзәтү һәм шуңа бәйле төстә очыш фәлсәфәсеннән әле һаман аерылып җитә алмаган иде. Әллә Оксанага, әллә үз-үзенә шул күзәтүләрен фәлсәфи йомгаклап куюны кирәк тапты:

– Бу турыда минем күп мәртәбәләр уйланганым бар, – диде Габдрахман. – Очкычның көпчәкләре беренче тапкыр аэродромга тигән мизгелдә җир аңа дошманлык күрсәтә шикелле. Сакланырга, зур түземлек күрсәтергә тиеш пилот шушы мизгелдә. Миңа җир-ана үзеннән аерылып күккә менүчеләрне өнәп бетерми шикелле тоела.

– Ә мин очкан чакта авариягә юлыгырбыз дип бер генә тапкыр да борчылмадым, – диде Оксана. – Хәзер инде мин – һавада очуны татыган тәҗрибәле кеше!

**Бишенче бүлек**

**1**

Внуководан Мәскәүгә барырга җыенганда, Оксана таксига утырудан баш тартты:

– Сез бит «акча эшләргә өлгерә алмадым, ялдан соң ялга җибәрәләр», дидегез. Туздырмагыз инде акчагызны.

Габдрахманга кызның аны кайгыртуы ошый иде. Димәк, Оксана аңа җиңеллек китерергә, егетне бурычка кертмәскә тырыша.

Көнбатыш илләрендә җитештерелгәннәргә охшатырга тырышып ясалган йомшак утыргычлы, эче якты автобуслар йөри башлаган чор иде. Авылларның тәрәзә каршыннан артка таба йөгерүләрен карап барырга керештеләр. Каршы яктан килгән йөк машиналары арасында «Москвич»лар, «Волга»лар чабып уза иде. Алда Мәскәү тирәсендәге авылларны йота барып үсеп чыккан тугызар,

ундүртәр катлы яңа төзелешләр күренде. Төзелештән калган бетон плитәләр, кирпеч өемнәре, җир өстендә өем-өем таралып яткан кызыл балчык, яңа торак бәхетенә ирешкән хуҗаларның балконнарында иминлек байрагы булып җилфердәгән керләр.

– Бусы Ленин проспекты, – диде Габдрахман, моңа кадәр очрамаган киң урамга күрсәтеп. – Өскә таба тарая, очлана барган биек бинаны күрәсезме?

– Күрәм. Нинди бина бу дип сорап та тормыйм. Мәскәү университеты бинасы сурәтләре белән газета-журнал битләре тулган.

– Без әле аның эченә дә кереп карарбыз, – диде Габдрахман, күңелендә кабат мактанулы тойгы бәреп чыкканын тоеп.

Автобус машиналар теземенә төртелә язып туктап калды. Каршыда милиционерлар, сыбызгы сызгыртып, машиналарны юл читенә куа иде.

– Нигә туктадык? – дип сорады Оксана.

– Бер зур түрәнең кортежы үтә булса кирәк. Әле алар узып киткәнче тотачаклар.

– Ә нигә зур начальствоның машиналары башкалар шикелле йөрми? Аерым йөргәч, куркынычрак кына түгелме соң?

– Нигә соң патшаларны бер көтү кораллы җайдаклар озатып йөргән? Үзләренең гади халык түгеллеген күрсәтү өчен шулай кыланалар.

Башта очып кына милиция машинасы үтеп китте. Берничә минуттан мотоциклчылар саклап алып барган өч кара «Зил» – халык телендә «членовоз»лар узып киткәч тә, машиналарга юл бирми тордылар.

– Кем икән бу? – диде Оксана, егетнең колагына пышылдап.

– Брежнев тирәсендәге кеше булырга тиеш.

– Үзе үк түгелмени?

– Үзе булуы да мөмкин. Брежневтан түбәнрәкләрен мотоциклистлар озатып йөрми.

– Ә нигә өч машина? Берсенә генә сыймый микәнни?

– Гади халыкның күзенә төтен җибәрер өчен, билгеле. Юлбашчының кайсы машинада икәнлеген беркем белмәскә тиеш.

– Джон Кеннедине мин әле һаман кызганам. Теләсә, ул да менә шушындый сак астында йөри алыр иде. Ә нигә Брежнев шикелле үзен саклатып йөрмәгән?

– Сакчылары булган аның. Ул бит демократик илнең президенты. Демократия җитәкчеләргә гади халык белән аралашып идарә итәргә куша.

– Бездә дә иң көчле демократия, милек халык кулында, идарә итү дә халык карамагында, диләр. Ә тормышта – киресенчә. Мин шуны аңлап бетерә алмыйм.

– Борынгы Греция дә әнә демократия шартларында яшәгән. Демос – гади халык, милекле булган. Колларны, Рәсәйдәге крепостнойларга тиң колонналарны исә идарә итүгә, хәтта җәмгыятькә дә якын җибәрмәгәннәр. Бездә дә бит хакимият белән җәмгыять арасында тирән упкын. Шул упкынга салынган күпер хезмәтен партаппарат үтәп тора. Элек ул элемтәне патша чиновниклары үз кулында тоткан.

Оксана алардан алгы рәттә утыручы карасу зәңгәр макинтош кигән иргә ымлап күрсәтте. Ирнең сөйләшкәнне йотлыгып тыңлавын башын алар ягына янтайтып куюыннан аңлап була иде.

«Тукта әле, – дип куркып куйды Рахманкулов. – Мин нигә дип әле болай бөтенләй тугарылып беттем? Теләсә кайда телемне тыймыйча, уйларга да куркыныч сүзләр сөйләп барам».

Автобус Революция мәйданына килеп җиткән иде. Йөртүче кычкырып белдерү ясады:

– Үзәктә төшеп калучылар, чыгарга әзерләнегез.

Габдрахман макинтошлыны күзәтә иде. Ул хәзер төшәрме, юкмы? Макинтош урыныннан торды, Габдрахманның артына килеп басты. «Горбатого могила исправит», диләр урыслар. Аның ничә тапкырлар телен тыярга сүз биргәне, сәясәткә кагылмаска тәүбә иткәне булды. Тукталышка төшү белән, бу бәндә түш кесәсеннән кызыл күн тышлы таныклык чыгарып, Рахманкуловның борын төбенә китерәчәк:

– Минем белән барасыз. Анда ачыкларбыз...

Алла саклады бу юлы. Макинтош кигән кеше тукталышка төшүгә, сул якка борылып, «Метрополь»гә таба юл тотты.

– Без хәзер кая барабыз?

«Метрога артың белән борылып басып торганда, нәкъ каршында «Москва» кунакханәсе, аннан уңда – мәйдан уртасында Карл Маркс һәйкәле, «Большой театр»ның мәһабәт колонналары өстендә квадрига – ике көпчәкле җиңел арбага җигелгән, җир тетрәтеп барган дүрт атның дилбегәсен тоткан Аполлон, тагын да уңдарак мәшһүр «Малый театр», Үзәк мунча, «Метрополь» бинасы каплап торган «Морфлот» йорты. «Метрополь»дән уңдарак, метрога янәшә, кызыл кирпечтән төзелгән җимерелми калган данлыклы «Кытай дивары...» Боларның һәммәсен дә Оксанага сөйләп таныштырырга кирәк булыр, дип, Габдрахман инде күңеленнән сәнгать һәм архитектура күренешләрен бер-бер артлы барларга керешкән иде.

**2**

– Мәскәү урамнарының ташлары аягыгыз астында, – диде Габдрахман, тантаналырак әйтергә тырышып. – Әйдә, әйтегез, сезнең иң беренче чиратта нәрсә күрәсегез килә?

– Кызыл мәйдандыр инде, – диде Оксана, кыяр-кыймас кына. – Мәскәүдән кайтучылар беренче чиратта шунда булганнарын сөйли башлыйлар.

– Әгәр Кызыл мәйданны закускага калдырсак, сез моңа ничек карыйсыз?

– Сез бит Мәскәүне яхшы беләсез, минем беренче килүем. Үзегез карагыз инде.

– Иң башта, каршы килмәсәгез, мин тамак ялгап алырга тәкъдим итәм. Ресторанга керәбезме?

Оксана елмайды:

– Беләм бит кесәгезнең тирән түгеллеген. Минем каршыда шапырынасыгыз киләмени? Гайбәт җыя дип уйлый күрмәгез, Дадоновлар да кисәттеләр. Кызларны ресторанга чакыруның максаты миңа мәгълүм. «Кто платит, тот музыку заказывает», – диләр. Ашханәгә керик, акчасын икәү түлибез.

Кызның сүзендә торачагын Габдрахман аңлый башлаган иде инде, бер башланса, бу ниятнең таудан тәгәрәп төшкән җепшек кар шикелле туктаусыз зураясын да белә иде.

– Миңа ашханә сайларга рөхсәт итәсезме?

– Билгеле.

– Әйдә, алайса университетныкына керәбез. Берочтан минем укып йөргән яшьлек эзләреннән дә тагын бер кат үтәрбез.

– Еракмы соң ул?

– Ленин тавындагысы ерак. Без аның Моховая янындагысына – автобустан төшкән җиргә кире кайтып барырбыз.

Әнә, уңда журфак бинасы каршында таш Герцен һәм таш Огарёв, элеккечә таш булып каткан караш белән, кыбырсып йөргән студент халкына тыныч кына карап торалар. Филфак күчеп киткәннән соң, монда университет карамагындагы Азия һәм Африка институты урнашкан иде.

Алар уртадагы бинаның ярым подвалына урнашкан ашханәгә керделәр. Шул ук турникет. Касса. Турникет янына куелган пластик поднос өеме, кашыкчәнечкеләр, пыяла витрина эчендәге тәлинкәләрдәге винегрет, закускалар. Тәлинкәләргә шулпа, ботка салып торучы хатыннар да алышынмаган шикелле күренәләр иде. Чиратта торганда кабаланып, имтихан биреп чыккач ук онытылачак белемне конспект дәфтәреннән күзләре белән йотып торучы бу яшьләр әйтерсең лә Габдрахман укыган чактагы студентлар иде!

Алар Оксана белән чират ахырына барып бастылар. Шушы ашханәдә соңгы тапкыр ашаганнан соң, ничә ел вакыт узды икән? Алты кыш, җиденче җәй. Шул вакыт эчендә Габдрахманның марҗага өйләнгән үзбәк дусты Өметгали атеизм фәне буенча диссертация якларга, Баграт сценарий язып ике фильм чыгарырга, ике тапкыр өйләнеп, ике тапкыр аерылышырга өлгергән иде инде.

Ниһаять, аларга да чират җитте.

– Нәрсә алабыз?

Сыек аш, кәбестә шулпасы белән токмач, икенчегә котлет салган дөге боткасы һәм төйгән бәрәңге белән сосиска бар. Рахманкулов укыган елларны монда шашлыкка кадәр була иде. Коммунизм төзүчеләр лагере дип аталган Көнчыгыш Европа илләреннән, Африкадан, Кытай, Корея, Вьетнамнан килгән студентларга социализмның өстенлеген торак, ашау-эчү сыйфаты аша күрсәтү шарт итеп куелганлыктан, илнең данлыклы уку йортында бик нык тырышалар иде. Әле дә тырышалар шикелле, әмма күзгә җибәрелгән төтен, әнә, елдан-ел сүлпәнәя төшкән.

Алар кәбестә шулпасы белән сосиска алдылар. Монда күзгә чалынган һәр әйбер, һәр кашык студент елларының хатирәләрен уята иде. Ул чакта сосисканы өлкән яшьтәге бер татар хатыны сата иде. Әлеге хатынның киенүен дә, үз-үзен тотуын да марҗаларныкыннан аерырлык түгел иде. Сөйләшүе? Юк, татарның урысчасын өлкән абзыйларныкыннан аеруы шактый катлаулы. Грузиннар исә урыс телендә ничек кенә оста сөйләшмәсеннәр, аларның телләре милли үзенчәлекләрен барыбер саклый. Хәтта урыска иң якын милләт – украинлылар йөз процентка урыслашып беткән очракта да «г» авазын кыпчакларча «һ» рәвешендә яңгырата. Урыс телендә татар шома сөйләшә. Бәлки, шул тел каршылыгы булмау аны бик тиз урыслаштыра торгандыр? Милли үзенчәлекнең тамыры, аның җимеше телгә бәйләнешле. Саф урысча сөйләшүче сосиска сатучының татарлыгын Габдрахман беренче күрүдә үк чамалап алды. Иренең сугышта үтерелүе, бердәнбер малаеның марҗага өйләнеп урыслашуы – боларның барысы да гадәттәгечә иде. Ә менә урыс башкаласында яшәүләре инде өченче буынга җиткән кешенең телен, динен, милли гадәтләрен саклый алуы – моны аңлавы шактый катлаулы иде. Татар хатыны саткан сосискаларның тәмлерәк булуы студентларга мәгълүм иде. Моның серен Рахманкулов хатынның үзеннән сорады.

– Сатып бетергәч, башкалар шикелле, сосиска пешкән шулпаны түгеп китмим мин. Аны бәләкәйрәк савытка салам да суыткычка куям. Шулпа кайнаткан саен куера, койкага әверелеп бетә. Әзәйгәч, мин аңа су гына өстим. Суын яңартып торганда, сосисканың тәме шулпага чыга, миндә, киресенчә, шулпадагы тәм сосискага кереп тора...

***

– Менә хәзер мин сезгә үземнең альма-матерым – университетны күрсәтәм, – диде Габдрахман.

Алар Моховой урамының тугызынчы һәм унберенче йортларына урнашкан иске университетны һәм Горький исемендәге китапханәне карап чыктылар.

– Яңа университет белән чагыштырганда, искесенең нинди өстенлекләре бар? Шуны аңлый алдыгызмы?

– Кайчакта сез кызык кына әйтеп куясыз. Ничек аңлыйм инде мин аның яңасын күрми торып...

– Соңгы килүебез түгелдер әле. Яңасын да карарбыз. «Впереди вечность!» дигәнен ишеттем мин гасырның иң бөек шагыйре Арсений Тарковский авызыннан.

– Сез аны күрдегезмени?

– Мәскәү университеты безгә белемне бирә алдымы, белмим. Иң мөһиме – ул безгә гыйлемне ничек һәм кайдан эзләргә кирәк икәнлеген аңлата алды. Аннан соң, монда укыганда, без атнасына ике тапкыр даими төстә иң күренекле шәхесләр белән очрашып тордык. Шул очрашулар, бәлки, университет программасына кергән фәннәрдән кыйммәтрәк тәдер әле. Мин, мәсәлән, өч тапкыр Илья Эренбург белән очрашуда катнаштым. Баш сөягенә тәңгәлләп, әллә ничә гасыр элек вафат булган кешеләрнең йөзләрен ясау серен ачкан антрополог Михаил Михайлович Герасимовның лабораториясенә кергәнем булды. Назыйм Хикмәт, Константин Симонов, Сергей Антонов, артист Бабочкин, кинорежиссёр Михаил Ромм шикелле данлыклы шәхесләр белән очрашуларны саный башласаң, очына да чыгып булмас иде. Университет миңа культураның нәрсә икәнлеген аңлата алды шикелле. Культура белән цивилизация арасындагы аерманы төгәл генә белүчеләр чиктән тыш сирәк очрасалар да.

– Хәзер аңладым инде кызларның күзенә төтен җибәрүне кайдан өйрәнгәнлегегезне.

**3**

Алар Ленин музее яныннан узгач, тарих музеена җитәрәк сулга борылып, Советлар Союзының һәм коммунистлар хәрәкәтенең кәгъбәсе саналган Кызыл мәйданга чыктылар.

Уңда, Кремльнең кирпеч диварына терәлә язып, революция пәйгамбәре, аның идолы һәм кумиры Ленин мумиясен сакларга ясалган таш Мавзолей урнашкан. Аның янына килеп җиткәндә, Мавзолейда каравыл алышынган чак иде. Җилкәләренә мылтык салган өч солдат, олтаннарын ташка бердәм бәреп, Спасс капкасыннан килеп чыктылар да, барганда аякларын билләре турына кадәр күтәреп, Мавзолей ишеге төбендә сакта торучылар каршына килеп туктадылар. Яңалары ишек саклаучыларны алыштырды. Өченчесе нәкъ шулай парадтагыча атлатып алышынганнарны капкадан Кремль эченә алып кереп китте.

Сулда – башкалага килүчеләрнең сиксән процент вакытларын кабып йотучы суперкибет – ГУМ. Каршыда – Явыз Иван вандалларының Казан ханлыгын җимергәндә агызган кан елгалары истәлеген саклаучы Василий Блаженный чиркәве, җәзалап үтерелгән меңнәрнең ядкаре – Лобное место һәм Рәсәй дәүләтен коткаручы князь-воевода Пожарский белән Нижгород керәшене

Минин-Миңлебаевка куелган мәшһүр һәйкәл. Европада яшәүчеләрнең әбәд вакыты булгангамы, җырга һәм табыну сүзләренә әверелеп беткән коммунистик гыйбадәт кәгъбәсендә халык шактый сыек иде.

– Әлегә сезгә әйтеп кенә узам, – диде Габдрахман, үзенең тәмам гид роленә керә баруын тоеп. – Без монда иркенләп йөрербез әле. Ул чакта һәр нәрсәне җентекләп карарбыз. Бу инде урыс шовинизмы белән изеп, коммунизм фанатиклыгы белән басылган җир шарын яулап алу диненең Мәккәсе һәм Мәдинәсе.

– Әйдә, «син» дип сөйләшүгә күчәбез. Ризамы?

– Студент халкы үбешкәннән соң гына «син»гә күчә. Без үбештек тәмени инде?

Оксана рәхәтләнеп көлде. Көлгән чакта аның күзләре кысыла төшеп, бит алмалары чокыраеп китә, күкрәктән агылып чыккан тавышы егетнең колагына дәртле музыка сыман ишетелеп, бөтен тән күзәнәкләрен уятып җибәрә иде.

– Башка чакларда да үзеңне шулай тотсаң, чит илләргә чыгып йөрүдән күптән колак каккан булыр идең инде. Син минем белән тәмам тугарылып сөйләшәсең. Мин бит западенка. Аңлыйсыңмы бу сүзнең мәгънәсен?

– Бандера тарафдары дигәнне аңлата инде. Червонно-блокидный байрак. Самостіная Украина. «Западенка» шуны аңлата төсле.

– Шул чама инде. Совет шартларында украиналы белән татар язмышы үзара охшаш. Безне дә бит көчләп урыслаштыралар. Минем сиңа нәрсә әйтәсем килә – теләсә кем белән алай тугарылып сөйләшмә.

Нәкъ шул вакытта, алдан килешенгәнчә, алар янына шыпырт кына, дәшмитынмый гына Габдрахманның башкалада укып яткан энесе Варис килеп басты. Кочаклашып күрештеләр.

– Әле бит яңа гына ялдан эшеңә кайтып киткән идең. Бусы тагын нинди ял соң?

Варис янәшә басып торган Оксанага күз сирпеп алды да сөйләвен дәвам итте:

– Бәлки, сиңа акча туздырып, кунакханәгә урнашу кирәк тә түгелдер. Тулай торакның мин яшәгән бүлмәсендә буш урын бар.

– Мин бит берүзем генә түгел. Таныш булыгыз. Минем вечный студент энем Варис, ә бу туташ – Оксана Тарасовна Ярёменко.

Варис абыйсының юлдашын очраклы таныш кызына санаган булса кирәк. Танышканнан соң, ул югалып калгандай булды.

– Тулай торакта безне кызлардан аерым тоталар. Кирәк икән, мин Оксанага да берәр буш койка табып карармын... Әле бит эшкә чыккан гына идең шикелле, нишләп ял алырга уйладың?

– Уйларга ирек биреп тормадылар. Көчләп җибәрделәр.

– Моңа кадәр мин көчләп эшләткәннәрен генә белә идем. Көчләп ялга җибәрү – мәзәк бит, ә?.. Өйләнергә җыенуың түгелдер бит аны Мәскәүгә алып килүең? – диде ул, берара Оксана читкәрәк борылганда.

Габдрахманның күңелен туктаусыз тырнап торган иң әрнүле мәсьәлә иде бу. Вариска дөресен әйтергә аның батырлыгы җитмәде, туры җаваптан үзенчә качып котылу ягын карады:

– Мәскәүгә генә түгел, мин бит аны әнигә күрсәтергә Караярга алып кайтам...

Варис әлеге сүзләрнең әллә шаярып, әллә җитди әйтелгәнен ахыргача аңлап

бетермичә, берникадәр аптыраулы халәттә калды. Тик Оксана каршында бу хакта җентекләп сорарга базмады.

Энесе белән Оксана танышуга ук үзара уртак тел таптылар. Варисның Совет илендә иң абруйлы саналган, чит илләргә чыгу, илчелекләрдә дипломат булып эшләү өметләре вәгъдә иткән ымсындыргыч МГИМО[4]да укып йөрүе Оксанага гаҗәпләндергеч бер тәэсир ясады. Газета битләрендә һәм трибуналарда әйтелгән нотыкларда милләтләр арасындагы тигезлек ялганы даими яңгырап торса да, тарих дәреслекләрендә һәм совет кешесенең күңел түрендә татар-монгол золымы җинаяте белән пычратылган татар егетенең Кремль хуҗалары балалары арасында укып йөрүе авырлык белән генә ышана алырлык хәл иде. «Шул институтка да кереп буламыни? – дип, Оксана Варис сузган студент билетын кат-кат карады. – Шунда укучыларны минем үз күзем белән күрәсем килә иде, ниһаять, күрдем», – диде ул.

## 4

МГИМОга кергәнче, Варис, Бөгелмәдә педучилище һәм икееллык укытучылар институтын тәмамлап, Шөгер районындагы керәшен авылы Федотовка мәктәбендә бер ел психология фәнен укытты һәм Баулы районының мәгариф бүлегендә елдан артык инспектор булып эшләде. Инде стипендия акчасына тукланып яшәү егетнең кыяфәтендә дә чагылып өлгергән иде.

Варис белемгә омтылу ягыннан абыйсына һәрвакыт үрнәк булды. 1944 елны Габдрахманны армиягә алып киттеләр. Сугыш Алман җирендә бара иде. Ул чакта Советлар Союзы дип аталган урыс империясе үзенең җиңүләре белән шапырынып яшәвен дәвам итте. Ничә гасырдан бирле яулап алу сугышлары өчен генә яши башлаган бу ил үзенең яшәеш ысулына әверелгән хәерчелеген дә, дәүләткә туктаусыз яңа колонияләр өстәп торып, йөзләгән башка халыкларга кан һәм күз яше китерүен, аларны милли изүгә дучар итеп, колларча хокуксызлыкта көн күрсәтүен дә инде күптән аңлый алмас дәрәҗәгә җиткән иде. Португалия, Испания, Бөекбритания шикелле илләрнең, колонияләренә ирек биреп, үз халкының иминлеге өчен яши башлаулары да Рәсәйгә үрнәк була алмады. Советлар Союзын толлар, ятимнәр, сугыш имгәткән гарипләр иленә әверелдергән сугыш исә бу империянең аппетитын тагын да көчәйтеп җибәрде. Үз-үзен ватан өчен сугыш корбаны итүдән тәм табып, шуның белән горурланып яшәргә өйрәнгән татарлар булмаган очракта, Рәсәй җиңә алыр идеме икән? Бу сорау Рахманкуловның уйлануларында гел кабатлана иде. Күңелен даими тырнап торган тагын бер соравы бар иде аның: без, татарлар, нилектән «кеше булу» турында хыялланып яшибез икән? Рахманкуловлар гаиләсендә «кеше булу»ны уку, белем алу белән бәйлиләр иде. Дөрес, офицер дәрәҗәсенә ирешү дә инде «кеше булу»га тиң иде. Әмма Габдрахманның җилкәсендәге ука погон гына аны канәгатьләндерә алмады. Ул да укып «кеше булу» турында хыяллана иде. Бишенче классны Габдрахман мәктәпкә йөреп тәмамлады. Алтынчыда язгы чәчү башланганчы гына укыды. Җиденче класста мәктәпкә йөреп уку кыш вакытында гына тәтеде. Шуңа карамастан, аңа җиде класс бетергәнлеккә таныклык бирделәр. Сугыш елларында хезмәт иткән хәрбиләрне училищега характеристикасы яхшы булган очракта тугыз класс белән дә алалар иде. Габдрахман училищега керер өчен, кардәшлек аша, тугыз класс бетергәнлеккә таныклык оештыра алды. Училищены гел «бишле» билгесенә бетерү аның җинаятен акларга

[4] Московский государственный институт международных отношений.

тиеш иде кебек, тик ул армия хезмәтендә кичке мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач кына күпмедер тынычланды.

Габдрахманның энесе озакламый өченче дипломга ия булачак. Аның да энесеннән һич калышасы килми иде. Дөрес, ул да югары белемгә иреште. Иреште генә түгел, Советлар Союзында иң данлыклы, беренче уку йорты саналган Ломоносов исемендәге университетны тәмамлады. Шуңа карамастан, энесе укыган, дипломатлар әзерли торган институт нигәдер аның өчен университеттан да абруйлырак тоела иде.

Нинди көч, нинди дәрт, нинди үгет туктаусыз өндәп, куып алып барды икән аларның белемгә омтылуларын: буыннар чакыруымы, өлкәннәр теләгеме, яшерен кимсетү-мыскыллауларга эчке бунтмы, милләтнең көчләп чукындырылу, илнең чираттагы канлы басып алу сугышларына каршы тору реакциясеме?!.

***

– Хәзер мин профессор Трухановский лекциясенә ашыгам. Сәгать ничәдә, кайда очрашабыз? – диде Варис.

– Тулай торагыңа ничәләрдә кайтасың?

– Сәгать өчләр тирәсендә.

– Мин сиңа үзем шалтыратырмын. Көтеп тор.

Китәр алдыннан Варис Оксанага текәлеп карап алды. Үзгәрешләр көтү, борчылуы, абыйсының язмышын җентекләп күзаллау омтылышы язылган иде аның күзләрендә.

– Тукта әле, – диде Габдрахман, энесе артыннан барып. – Әйтергә онытканмын. Тулай торагыңда син шулай да миңа бер урын сөйләшеп куй әле... Оксана янында калып булмас дип уйлыйм.

– Одессада куна кертергә рөхсәт итә торган кызлар юкмыни? Урынны табарбыз. Пока.

Варис тукталышка барып җитү белән, трамвай килеп туктады. Пассажирлар ташкыны егетне эләктереп эчкә таба алып китте. Ишек ябылды. Трамвай, тимергә тимер бәрелгән шыксыз тавыш чыгарып, алга таба шуышты.

## 5

– Оксана! – диде Габдрахман. – Әгәр дә каршы килмәсәң, сине ярты гына сәгатькә монда калдырып, йөгереп кенә Чайковский залына концертка билетка барып килер идем. Әлегә Кызыл мәйданны, биналарны, мондагы халыкны тамаша кылып тора аласың. Аннан соң без синең белән Измайлов бакчасын күреп кайтырбыз. Син анда, һичшиксез, булырга тиеш. Шуны күрми торып, татарларның кем икәнлеген аңлау мөмкин түгел.

– Җаваплылык синең өстеңдә, – диде Оксана, – кая алып барсаң, шунда барам.

***

Габдрахман әйләнеп килгәндә, Оксана Василий Блаженный чиркәвенең гөмбәз стильләрен чагыштырып карап йөри иде.

Тәненең аскы өлешенә сыланып торган гап-гади кара итәк. Балтырлар... Соң бит Аллаһы Тәгалә хатын-кызны һәйкәл булып алдыңа чыгып басар өчен яисә бар вөҗүдеңне үзенә ияртеп алып китәрдәй затлы адымнар белән иләсләндерү өчен яраткан. Аның аякларының, гәүдәсенең сихри тылсымын борынгы грек сынчылары яхшы аңлаганнар.

Франсуа Вийон исә:

Где твои тугие груди?
Где плеч атлас? Где губ бальзам?
Где тело, чтимое как храм,
Куда приходят издалека?..

– дип, нәкъ Оксананыкына охшаган хатын-кыз гәүдәсенә дога кылуга тиң мәдхия җырлаган. Борынгы грек сынчылары, Вийон, бөек шагыйрьләрнең һәрберсе хатын-кыз матурлыгын тасвирлаганда, һичшиксез, бүгенге Кызыл мәйдан уртасының төп каһарманы Оксана сурәтен күз алларында тоткандыр...

Аның яныннан узганда, ир-атның атлап баруы үзгәрә. Узып киткәннән соң да борылып караудан тыела алмыйлар. Хатын-кызлар да текәлеп карап уза. Күбесенең күз карашында нәфрәткә охшашлы көнләшү билгесе. Менә каршы яктан бер грузин килә. Кыз янына җиткәч, ул туктады, кавказлылар кайнарлыгы белән, Оксананы аздыргыч хисләренә күмеп ташлады. Сокланыргамы, битләренә төкерергәме грузин ирләренең? Үз хатыннарын алар гарәпләрдән ким саклап тотмыйлар. Марҗаларның нindие дә алар өчен танышу белән түшәккә сөйрәргә яраган кәнтәй, чөнки алар марҗа халкын Кавказ курортларында ял итүчеләргә тиңли.

Һаман басып тора проклятый кацо! Китәргә теләми. Оксана аңа метро ягына төртеп күрсәтте. Янәсе, мин сөйгән егетемне көтәм... Кызның шушы хәрәкәте Габдрахманның күңеленә рәхәт җылылык бөркеде. Менә мин нинди кызны яратам... Белегез, ул да миңа карата битараф түгел, аңлагыз. Һәм егет үзендә горурлык хисе уянуын, шуның белән бергә үк күңеленә әллә ниткән көнчелек давылының килеп бәрелүен дә тоеп алды. Әгәр кызны күндереп, аңа өйләнеп җибәрсә, ул Оксананы менә шушы грузинга охшаган ике аяклы айгырлар арасында калдырып, ялыктыргыч озын айлар буе диңгезләрдә йөзәргә ни җаны белән китә алыр икән?.. Бушка баш ватмыйк әле! Габдрахман үзен көтеп торган кызга таба атлады.

Шәһәр Оксанага ошамый иде. Хәтта ошамый дип әйтү генә дә аз кебек иде. Кая ашыга Мәскәү халкы? Нигә алар кабынырга җитеп чабалар? Кешеләрнең күплеген аңларга була әле. Башкаланың зурлыгы өстенә бүтән шәһәр-авыллардан килүчеләр, үтеп баручылар да хәйран күп монда. Мәктәп елларында класстагы географик картадан Оксана Советлар Союзының барлык тимер юллары Мәскәүгә килеп тоташуын күреп гаҗәпләнгән иде. Бәлки, юлларын дәвам итәр өчен икенче поездны көткәндә, халык данлыклы башкаланы карарга шулай урамга чыга торгандыр... Күбрәк күрәсе килүдән шулай ашыгалар булыр?.. Ә үзара шундый битарафлык. Бусы нәрсәдән?

– Дөресен әйткәндә, – диде, Оксана, егеткә, – Мәскәүне мин башкачарак күз алдыма китерә идем.

– Яхшырак итепме, начарракмы?

– Мондагы халык кая ашыга соң?

– Сигез миллионга якын кеше яши монда. Кысынкылык. Эш урыны торган җирләреннән еракта урнашкан. Одессадагы шикелле ашыкмыйча гына йөреп булмыйдыр, мөгаен.

– Хәер, минем туган хуторым белән чагыштырганда, Одессада да кыбырсып яшиләр, – дип килеште Оксана.

## 6

Габдрахман Оксананың иңбашыннан җиңелчә генә кочаклап куйды:

– Йә, киттекме Измаил бакчасына? – дип сорады ул. – Ял көннәрендә татар яшьләре шунда җыела.

– Капитан ничек дип әйтә инде... – диде Оксана, егетенә елмая төшеп.

Алар метроның «Шоссе энтузиастов» станциясенә төшеп, утыз дүртенче трамвайга утырдылар да Сигезенче лачын урамы дигән җиргә кадәр килделәр. Будённый проспектына чыга торган кыска гына урам иде бу. Мәскәүнең йогышлы авыруларны дәвалый торган иң зур поликлиникасы һәм юләрләр йорты яныннан уздылар, шәһәрне урап алган тимер юл күперен үткәч, бакча күренде.

– Бу парк Европа күләмендә иң зур бакчаларның берсе санала, – дип аңлатты Габдрахман.

Алар шактый зур телескоп куелган обсерватория һәм зур китапханә бинасы яныннан уздылар. Уң якта «Лето» дип аталган кинотеатр калды, милиция идарәсен үткәч, уңга борылып, урман эченә керделәр. Асфальт юлдан сукмакка төшү белән, каршы яктан килгән җыр һәм гармун тавышлары ишетелде. Киң сукмак аларны аланлыкка алып чыкты. Шул аланлыкка шыгрым тулган яшь егетләр, сан ягыннан егетләрдән күбрәк икәнлекләре күзгә бәрелеп торган яшь кызлар төркем-төркем җыелып җырлыйлар иде.

– Минем әбием җырлый торган борынгы украин халык җырларында да шулай зар белән елаганга охшаш авазлар яңгырый иде, – диде Оксана.

– Алар татар халык җырларын җырлыйлар.

– Кемнәр соң алар?

– Киемнәренә карап чамалый алмыйсыңмыни?

– Авыл кызларын хәтерләтәләр.

– Аларны татар авылларыннан җыеп алып килгәннәр. Мәскәү төзелешләрендә өске катларга носилка белән кирпеч, измә ташыйлар. Хөкүмәткә кран белән ташудан арзанракка төшә. Бусы әле аларның башкалага килүләренең төп сәбәбе түгел. Сугыштан соң озак еллар яшьләрне татар авылыннан беркая җибәрмичә тоттылар. Хәзер, киресенчә, татар яшьләрен авыллардан чүпләп алып китеп кенә торалар. Анда бит күпләп нефть чыга башлады. Татарстаннан елына йөз мең тонна кара алтын суырырга ирешү буенча аяусыз ярыш-көрәш бара. Яшьләрне туган туфракларыннан аерып алып китәләр дә нефть чыгарырга илнең төрле почмакларыннан әтрәк-әләмне китереп тутыралар. Татар милләтен шул юл белән юкка чыгару сәясәте тормышка ашырыла. Тоташ татарлар яшәгән җирдә тел дә, гореф-гадәтләр дә саклана, читкә олактыргач, алар әкренләп туган телләрен оныталар, катнаш никахлар барлыкка килә. Казан ханлыгын басып алганнан соң, туктаусыз чукындырулар, җирсез калдырулар, чукынырга теләмәүчеләрне йорт эченә бикләп яндырулар даими булып торган. Менә хәзер инде аның башка, цивилизацияле юлын таптылар.

– Нигә соң Украинадан яшьләрне алып китмиләр?

– Сезнең бит өлкән абзыйлардан аермагыз юк диярлек. Телегез үзе әкренләп бетәчәк. Сез бит үз иркегездән урыслашасыз. Армиядә украин офицерлары урысныкыннан күбрәк. Җитәкчелектә дә украинлылар шактый күп. Диңгезчелектә сезнең милләт, бәлки, урыстан күбрәк тәдер әле.

Урта бер җиренә пычкы түбе түшәлгән, карт сөян, имән һәм каен агачлары уратып алган аланлыкта туган авылларыннан, гаилә җылылыгыннан, туган

телләреннән язган авыл кызлары, монда армия хезмәтен үтүче татар егетләре җанны әрнетеп торган сагыну моңнарыннан җырлап бушаналар иде. Бу урынны урыслар читтәнрәк урап уза. Җырлаучылар арасында исерекләрне ауларга теләүче милиционерларның ачуы эчкә сыймый. Аларга исерек татарларны җыеп, айныту йортына олактырырга, зур штраф салырга, эшләгән җирләренә язып торып, шул юл белән милләтчелек үрчетүче бу аланнан биздерергә дигән боерык бар. Тик татар яшьләре мәйданда җырлап йөргәндә, авызларына бер тамчы аракы капмыйлар. Кайтырга чыккач, бакча артта калгач, аракысын да эчәләр, тәртибен бозарга да күп сорамыйлар анысы. Анда да әле бик сак кыланалар...

**7**

Алар залга кереп утыру белән, концерт башланды.

Моисеев ансамбле еллар буе чит илләрдә гастрольләрдә йөри. Сирәк-мирәк кенә Мәскәүдә берничә концерт бирә дә тагын юкка чыга. Дәүләт шул ансамбль ярдәмендә валюта туплый.

Метроның «Маяковский» станциясеннән алып бөек пролетар шагыйренең һәйкәленә каршы урнашкан баскыч төбенә, залның ишегенә кадәр араны тутырып, артык билет өмет итүчеләр тезелгән иде. Аларны күрү белән башланган сәерсенү Чайковский залына кергәч тагын да көчәеп китте.

– Күрдеңме, Оксана, – диде Габдрахман, – урамда калганнарның йөзләрендә билет таба алмаммы дип көтү, өметләнү көче нинди икәнлеген? Залга керә алганнарның йөзләренә кара: әйтерсең, гомер буе Ходайга табынып, догалар укып, изге гамәлдә генә яшәүче бәндәләр, ниһаять, җәннәткә керү бәхетенә ирешкәннәрдән бер дә ким түгел. Үзеңә янәшә утырган карчыкка күз сал әле. Шундый шатлык белән нәрсә көтә икән ул ансамбльнең биюеннән?

– Ярыш башланыр алдыннан да шул ук хәл. Нәрсә көтә торгандыр тамашачы нәфис гимнастикадан? Зал син снарядка атлап барганны күзләре белән йотардай булып күзәтә. Иң катлаулы композицияләр ясаганда да, тамашачыларның сиңа карап нәрсәдер көтеп утыруларын тәнең белән сизеп торасың.

Музыка уйный башлады. Оркестр чокырыннан чыккан салмак көй залга агып керде, тамашачыларны ялгызлыктан алып, үзара тоташтырды. Сәхнәгә болын чәчәкләрен хәтерләткән төсләрдәге сарафан кигән кызлар агылып чыкты. Ак толымнарны маңгай өстеннән таҗ итеп урап беркеткәннәр. Тулы күкрәкле, зифа буйлы марҗа кызлары, җепкә тезгәндәй, музыка тавышына тоташып, сәхнәне тутырдылар. Сәхнә өстенә җан бөркелде. Кызлар тоташ бoжра ясап шуышалар, парлашалар, төрле төркемнәргә бүленеп китәләр. Нәрсә сөйли аларның хәрәкәтләре? Урыс хатын-кызларының ирләрен, егетләрен сугыштан көтеп зарыгуларынмы? Һәр сугыш өләшеп чыккан каһәр толлыкнымы? Әллә гасыр буе җәмгыятьнең бер катламыннан икенчесенә күчеп, үзара берләштереп торган түнтәреш газапларын, сөргеннәрне, баш күтәрүләрне, Степан Разинлык, Пугачёв яуларын, урыс тарихының аркылысына-буена җәелгән канлы вакыйгаларын әлеге хәрәкәтләр ярдәмендә тамашачыларга сөйләп аңлатырга тырышуларымы?..

Сәхнәгә киң кызыл ефәк күлмәк киеп, билләрен ефәк бау белән бәйләгән, күнитекле, картуз кигән ир-егетләр атылып чыкты. Боларның һәр хәрәкәте сугышка сусау, кылыч селтәү, ату, җимерү кыланышлары белән тулган иде. Без дошман эзлибез, күрсәтегез, кай тарафта бүгенге дошман. Дошман юк чакта, яшәеш тәмен югалта. Дошмансыз без бер-беребез белән бугазлаша башлыйбыз.

Дошман безне берләштерә, рухыбызны күтәрә. Безнең бар тапкан малыбыз дошманны җиңеп, шулардан тартып алынган ганимәт... Урыс ирләренең һәр хәрәкәте, хәрәкәт арасындагы бер генә мизгелгә туктап калып, яшәешне дәвам итү юнәлешен сайлаулары – әнә шуны аңлата иде.

Оксананың онытылып, сәхнәдәге тамашага кереп оеп бетүе Габдрахманның тоемлавын, фикер йөртүен көчәйтеп, җанландырып тора иде. Сәхнә бушап калды. Зал җанланды. Алкышлау бинаның диварларын дерелдәтеп, тойгыларның ташып чыгуын аңлата иде. Габдрахман уң як иңбашына рәхәт җылылык сырышканын сизеп алды. Оксана, бер генә мизгелгә аны кочаклап:

– Рәхмәт сиңа. Бу минем өчен шундый зур бәхет. Әлеге ансамбль барлыгын ишетеп кенә белә идем, – диде.

Инде сәхнәгә, салмак кына атлап, тар чалбар, түше ачык кара күлмәкнең билен киң кара тукыма белән кысып буган испан ир-егете чыгып килә иде. Оркестр кыска-кыска гына итеп тавыш биреп ала. Алты кыллы испан гитарасының көчәйтелгән тавышы залга агыла. Фламенко – испаннар җирендәге андалузлар биюе. Бу бию, бәлки, Пиреней ярыматавы гарәпләр кулында булган гасырларда тугандыр? Бәлки, аннан да элегрәк, монда Атилланың баскан җирләреннән очкын чыгарып, Европага нәсел орлыгы чәчеп йөргән чакларда ук шыта, бөреләнә башлагандыр. Әндәлүс испаны булып биюченең басып торуында, аның һәр йөрәк тибүеннән кан тамырларына таралган талпынулы хәрәкәтләрнең һәр мизгелендә мөселманнарга хас тыштан тыюлы эчке ярсу, күкрәген бәреп чыгарга әзер хисләр ташкыны эчкә яшеренгәне сизелә.

Биюче уң кулын җиңел генә бөгә төшеп өскә күтәрде. Сул кул артка каерылып, билне кочаклады. Аяклар сак һәм әкрен генә сәхнәне капшарга кереште. Әйтерсең, күңеле, җаны белән испанга әверелгән биюче, талпынып һавада оча башласам, сәхнә такталары сынмасмы икән дип тикшерә иде. Олтанның сәхнә тактасына бәрелүе салмак кына кыза, ешая башлады. Гәүдә әле һаман төз, хәрәкәтсез. Тыштан гына хәрәкәтсез. Шул тыныч хәрәкәтсезлеккә яшеренеп, эчтә менә-менә бәреп чыгарга торган ниндидер сихри көч ятканын тамашачы тоя, түземсезлек белән, шомлы тынгысызлык белән көтә. Аякларның хәрәкәте һаман тизәя, олтанның сәхнәгә бәрелү көче арткаиннан-арта бара. Юк, бу гадәти таптану, сикергәләп йөрү генә түгел. Аяк тавышы бер үк вакытта музыканы алга этеп һәм сөйрәп бара. Юк, аяклардагы хәрәкәт белән испан музыкасының берләшүен, адәм баласының, киләчәктәге ымсындыргыч бәхеткә йөрәк тибүенең соңгы тамчы көчен кызганмыйча, бар җегәренә, барлык ашкын өметләренә ябышып, тәкъдиренә омтылуын «сөйрәп» сүзе аңлата алмый. Биюченең күкрәк эчендә дөрләп ут яна. Ул аны җаны-тәне белән яшерергә, сакларга тырыша. Менә шул эчтәге ут чәчрәтеп торган хәрәкәт-омтылыш көче һәм тышкы яктагы көч-хәл белән сакланган тынычлык тамашачының эченә үтеп кереп, кан тибешен көчәйтә, ашкындыра, күңел тоемлавын күкләргә очыртып алып менеп китә.

Рахманкулов нәкъ шул чакта һәм соңрак, испаннарның үзләренең биюләрен күргәч, бер нәрсәне аңлый башлады: Каталун кырындагы Атилла гаскәрләренең сугышы испаннарга мәңгелек сабак булып сеңеп калган. Тарихчылар Наполеонның Испан җирен басып ала алмавын мең төрле сәбәпләр белән дәлилләп, мең төрле сылтаулар белән аңлатырга тырышалар. Соң бит Атилланың йөз утыз мең сугышчысының яртысы да кире Дәште Кыпчак җиренә әйләнеп кайтмаган. Бөек яугирнең хатын-кызга карата туймас тамак булуын сурәтләргә яраталар. Аның сугышчылары да шундый булмый

калмагандыр? Габдрахман Европа илләрендә йөргәндә, кешеләрнең йөзләренә йотлыгып карый иде. Аны ниндидер инстинкт һәр очраган кешенең күзе аша күңеленә сеңдереп китәргә мәҗбүр итә иде. Еш, бик еш очрый иде аңа нәкъ Караярда яшәүче авылдашларына охшаш кешеләр. Бигрәк тә Испаниянең Каталониясендә, Франциянең көньягында, хәтта Британ утрауларында да татар кыяфәтле кешеләр очрап тора иде. Әнә бит испаннар үзләрен Наполеоннан җиңдермәгәннәр. Әгәр аларны француз яугире яулап алган булса, кем белә, испаннар мондый биюне башкара алырлар идеме икән?!

Тоталитарлык чоры, коммунистик пропаганда совет кешеләренең миендәге сырларын имгәтү белән генә чикләнмәде. Тоташ буйсынуда, дер калтырап яшәү тәндәге хәрәкәт иреген дә имгәтеп ташлады шикелле. Биюне карап утырганда, Габдрахманның күңеленнән шушы уйлар бер-бер артлы агылып уздылар.

**8**

– Мин сине «Метропль» кунакханәсенә урнаштыра алырмын дип уйлаган идем. Барып чыкмады, – диде Габдрахман янәшә атлап барган кызга.

– Кая урнашабыз?

– Энем Варис «Балчуг»тан урын таба алган.

– «Балчуг» «Метропль»дан начарракмыни?

– Алар Мәскәүнең иң яхшы, иң кыйммәтле кунакханәләре. Йөзүдән кайткан чак булса, мин анда урнаша алыр идем. Ә болай ялның азагында ришвәткә түләрлек акчам юк.

– Син ришвәтче дәмени әле?

– Рәсәйдә ришвәт бирмичә яшәп буламыни?! Гомер буе мич башыннан төшмичә утырган кешегә дә бердәнбер көнне районнан килгән берәр вәкил: «Мәскәүдән фәрман килде: мич башында утыручыларның янып үлүләре бар. Бүгенге көннән беркемне мич башына менгермәскә», – дип куркытып, ришвәт алып китәчәк.

Армия хезмәтендә офицерлыкка ирешкәнгә кадәр, Габдрахман ришвәт күрмичә, аның кануннарын белмичә яшәде. Ул чакта илдәге бар җинаять аңа тиешле ризык рационын интендаттан алып, склад начальнигы, поварларга кадәр даими урлап яшәүләре генә шикелле тоела иде. Дөрес, командирларның өстәгерәкләре солдатларны бакча казуда, дача салуда, кайберләре хәтта утын яруда «куллана» иде. «Кемнең кулында – шуның авызында», – ди татар халык мәкале. Авыл шартларында да бит колхоз рәисе генә түгел, бригадирлар, хәтта завхозлар да колхоз милкенә кул сузудан һич тартынып тормый. Аларның эшләре мәшәкатьлерәк, җаваплырак, катгыйрак. Башкача кем алыр иде өстенә шундый җаваплылыкны? Офицерлыкка ирешеп, шәһәрдә фатирга түләп яши башлагач, Рахманкулов социализм тудырган кытлыкта күзгә күренеп аккан көнкүрештән тыш күзгә күренмичә, законга, әхлак кагыйдәләренә буйсынмыйча аккан «идән асты» тормышы барлыгын белде. Ә инде чит илләргә йөри торган диңгезчелектә урлашып, ришвәт, кода-кодагыйлык ярдәмендә аккан көнкүреш дәрьясының төбе тирән, агымы чиктән тыш көчле икәнлеген үз күзе белән күрә башлады. Күрү белән генә чикләнмичә, ул әле баштарак моңа каршы көрәшеп тә карады. Көрәш һәр очракта иләк белән су ташуга тиң иде.

Советлар Союзындагы яшәүне һәм идарә итүне социалистик демократия нигезендә дип аңлатсалар да, чынында ул шул элекке Явыз Иван, Пётр Беренче заманындагыча дәвам итә иде. Яшәешнең эчтәлеге алдагы сугышта геройларча

үләргә өйрәтү, идарә – бу империягә хас крепостной коллыкны коммунизм төзү дип аталган матур тышлыкка төреп дәвам итү иде.

Алар кичке шәһәр урамыннан Кызыл мәйданга таба баралар иде. Массовет бинасы каршында, Горький урамының сул ягына урнашкан Юрий Долгорукий һәйкәле янына килеп җиткәч, Оксана сорап куйды:

– Оят булса да сорыйм әле. Китап битләрендә йөз тапкыр күргәнмендер бу һәйкәлне. Кемнеке ул?

– Юрий Долгорукийныкы,– диде Рахманкулов. – Атлы һәйкәлләрнең барысы да диярлек Римның Капитолий калкулыгына куелган Марк Аврелий һәйкәленнән күпмедер күчереп эшләнгән. Юрий Долгорукийныкына да шул һәйкәлнең катнашы бар шикелле тоела, асылында Андреа Верроккьоның Кондотьер Коллеони сыны ятса да.

– Шуларның барысын да син кайдан белеп бетерәсең? – диде Оксана, егеткә якынрак сырышып. – Синең белән танышканнан соң, мин әллә нинди чит ил язучылары, чит ил портлары, рәссам-скульпторлар турында ишеттем. Аларны син кайдан беләсең?

– Кайдан дип, күбесен чит илләрдә йөргәндә күрдем. Портка килеп туктауга, диңгезчеләр башта базарга йөгерәләр. Әз түлиләр бит безгә. Эш хакы хатынының бер тапкыр ирен каршы алырга чит портка килүенә көчкә җитә. Әйтик, без Батумига кайтып төштек ди йә булмаса Ленинградка, Ригага... Ә бит дөньяны урап йөри торгач, Владивостокка да кайтып төшкән чакларыбыз була. Ире янына барып кайту хатынына кыйммәткә чыга. Диңгезчеләр арзанлы чүпрәк-чапрак сатып алалар, хатыннары шуны комиссион кибеткә тапшырып акча эшлиләр. Башкача ачка үләрләр яисә гаиләләре юкка чыгар иде.

– Син моны миңа юри, диңгезчегә кияүгә чыкмасын, дип куркытыр өчен сөйлисеңме?

– Анысы да бераз бар инде.

Габдрахман Оксананы Василий Блаженный (Тиле Василий) гыйбадәтханәсе янына алып килде.

– Бу чиркәүне нинди зур вакыйгага багышлап салганнарын беләсеңме? – дип сорады ул.

– Бу юлы син минем наданлыкны тота алмадың. Синең Казаныңны алу хөрмәтенә салганнар, җанкисәгем.

– Син төгәл бер карышка үсеп күтәрелдең. Көтмәгән идем урыс тарихындагы бу хәлиткеч вакыйганы белерсең дип...

Василий Блаженный чиркәве дә артта калды. Алар бертын мәскәүлеләрнең Алтын Урдага илтә торган юлы – Ордынка урамыннан бардылар да сулга борылдылар. «Балчуг» кунакханәсе шушында урнашкан иде.

– Сәер исем, – диде Оксана.– Бездә саман кирпечтән йорт салганда, цемент урынына куллана торган измәне «балчык» диләр.

– «Балчык» – татар сүзе, – дип аңлатты Габдрахман. – Ерак бабайлар сүзгә чиктән тыш талымлы булганнар. Җир, туфрак, балчык. Өстән караганда гына аларның мәгънәләре уртак шикелле. Җир, гомумән, планетаның өстен каплаган каты матдә. Туфрак – бусы инде җирнең эшкәртергә яраклысы. Балчык исә, гомумән, эш материалы – безнең телдә аның карасы, агы, кызылы бар. Акбалчык белән бүрәнәләр арасындагы җөйне сылыйлар, кызыл балчыктан кирпеч сугалар, чүлмәк ясыйлар, кара балчык иген чәчүдә, бакча үстерүдә кулланыла. Кунакханәнең нигә «Балчык» дип аталганын мин белмим. Гомер-гомергә бу районда татарлар яшәгән. Бәлки, кунакханә дә заманында

шуларныкы булгандыр? Урыслар тик торганда андый исем кушмаслар иде.

Авыр имән ишекне ачып эчкә үттеләр. Холл шактый иркен иде. Алар түр яктагы пыялалы контора артында утырган администратор хатын янына килеп туктадылар.

– Монда миңа бронь булырга тиеш, – диде Габдрахман. – Рахманкулов исеменә.

– Әйе, бар, – диде администратор, өстәл тартмасында казынганнан соң.

– Буш люксыгыз бармы?

– Юк. Полулюкс кына. Номер сезнең икегезгәме?

– Әйе, икебезгә, – диде Рахманкулов.

Администратор Оксанага борылды:

– Паспортыгызны мөмкинме?

Оксана паспортын администраторга сузды. Хатын, ике-өч тапкыр актарып караганнан соң:

– Регистрациягез юк бит. Юк, мин сезне бер номерга урнаштыра алмыйм, – диде.

– Регистрация штампы булырга тиеш. Бирегез әле, мин сезгә шуны табып бирәм. – Рахманкулов паспортны алды да читкәрәк борылып, бөкләп йөз сум акча салды. – Бар бит регистрация штампы. Сез аны башка җирдән эзләгәнсез!

Паспортны кире алгач, администратор гафу үтенде һәм, иелеп, түләү кәгазе язарга кереште. Язып бетергәч, каядыр шалтыратты. Зәңгәр униформа кигән яшь кенә бер хатын, баскычтан төшеп, администратор каршына килеп туктады:

– Кайсы номерга?

– Егерме сигезгә урнаштыр. Анда тәртипме?

– Клиент киткәч, тузан суырткыч белән чистартып юып чыктым. Урын-җирне алмаштырдым.

– Яхшы, урнаштыр менә бу парны.

«Пар» сүзе белән ирле-хатынлыны да, күңел ачып йөрүчеләрне дә атыйлар.

Икенче катка менә башлагач, Оксананың йөзе үзгәрде. Аяк атлавындагы җиңеллек бетте, хәтта җилкәләре дә салынып төшкәндәй булды. Нәрсә турындадыр кыз газапланып уйлый, ниндидер бер ачык фикергә килергә тырыша кебек иде.

Кастелянша, ишекне ачып, аларны номер эченә кертте:

– Җәймәләр, мендәр тышлары чиста. Сөлгеләр ваннада. Ванна чистартып юылган. Телефон кенәгәсе өстәлдә. Теләсәгез, рестораннан кичке ашны китертә аласыз. Тыныч ял сезгә. Сау булыгыз.

Оксананың йөзе танымаслык булып үзгәргән иде. Ул тотлыга-тотлыга сүз башлады:

– Син мине түләп Мәскәүгә алып килгәч, мин инде әҗәтле булып калам. Хакын сиңа түшәктә түләргә тиешмени?

– Нәрсә сөйлисең син, Оксана?! Син мине кем дип беләсең?

– Кем дип? Элекке танышларыңа еш кына Мәскәү күрсәтеп йөргән тәҗрибәле донжуан дип саныйм. Әнә бит, администратор белән ничек тиз уртак тел таптыгыз. Димәк, сез аның белән таныш.

– Тукта! – диде Габдрахман, тупас тавыш белән. – Мин энем янына тулай торакка китәм. Самолёт Одессага сигез сәгать кырык минутта оча. Безнең әле тамак ялгап аласыбыз булыр. Сәгать җиденче яртыда торып җыенган бул. Тыныч йокы сиңа!

– Төн уртасында кем шулай кеше бимазалап йөри. Мин диванга ятам. Караватны үзеңә ал. Мин бит сине кисәттем генә. Украина кызлары никахлашканчы теләсә кем белән түшәккә ятмый. Шуны гына аңлаттым.

– Татар кызлары да үзләрен шулай тоталар. Син, Оксана, мине белмисең икән. Әгәр мине синең шул ягың гына кызыктырган булса, андыйлар белән буа буарлык. Ярый, тыныч йокы!

Габдрахман чыгып китте.

**9**

Энесенең тулай торагы метроның «Новокузнецк» станциясе янында гына иде. Егерме минуттан ул Варисны чакыртып чыгарып, аның бүлмәсенә үтте.

– Мин сине ул кыз янында калырсың дип уйлаган идем, – диде Варис бераз көлемсерәбрәк. – Син аңа аңлатмадыңмыни... безнең татарда кыз янына куна керү дигән гореф-гадәт бар икәнен? Гыйффәтләренә тимичә кочаклап яту – гөнаһ эш түгел бит. Ну чибәр дә инде кызың. Син аны каян таптың соң?

– Кайдан дип, Одессадан. Кораб врачы Дадоновның кызы Евгения нәфис гимнастика белән шөгыльләнә. Спорт мастеры. Оксана аның иң якын дусты, сердәше. Оксана – нәфис гимнастика буенча Одесса чемпионы. Мәскәүгә килергә тиеш иде ярышка. Бәлки, Советлар Союзы чемпионы булырга да сәләте җитәр иде, иңбашына зыян китерде. Аңа бик авыр хәзер. Очрашуыбыздан юаныч табып яши. Саф күңелле, әйбәт кыз.

– Син әллә башлы-күзле булырга уйлыйсыңмы?

Варисның соравы, төзәп аткан ук шикелле, абыйсының соңгы көннәрдәге кайнар уйларына килеп кадалды.

– Ошамыймыни сиңа Оксана?

– Эш анда түгел. Караярлыларның холкын белмисеңмени?

– Беләм. Алар марҗаларны өнәмиләр. Беренчедән, Оксана – украинка. Икенчедән, мин Караяр халкы өчен түгел, үзем өчен өйләнәм.

– Караяр халкына татар булмаганнарының барысы да марҗа. Кисәтәсем килә. Безнең авыл әле һаман хан заманындагыча яши, шушы көнгә кадәр урыслашуга ханлыктан колак каккан чордагыча карыйлар. Бусы – бер хәл. Инәки турында уйлыйсыңмы син? Акыл өйрәтергә җыенмыйм... Халыкның хупламавы бер хәл. Фәриха малае мәткәгә өйләнгән икән, дип гауга күтәрерләр дә тынычланырлар... Тик менә синең өйләнүең инәкине нинди хәлгә куяр... Синең өйләнүең аңа инфаркт ясаячак. Түбән оч Габдинең фаҗигасен белмисеңмени?

– Белмәскә. Ул мескен, дипломатлар телен кулланып әйткәндә, «персона нон грата» булып яшәде.

– Белгәч. Беренче чиратта, син авыл халкы каршында инәкине улы урысларга сатылып, марҗаны хатынлыкка алган икән дип хур итәсең, аннан соң Рахманкуловлар нәселен. Мин бит моны синең күзеңне ачу нияте белән генә кисәтеп әйтәм. Сүзеңне сүз итәсең икән, моңа әзер булырга тиешсең...

***

Оксанага өйләнгән очракта Варис аны алда Габди язмышы көтә дип кисәтә. Бу турыда уйларга да куркыныч тоела иде. Биш йөздән артык хуҗалыклы Караяр тарихында армия хезмәтеннән авылга марҗа алып кайткан бер Габди булды. Габдине, носари динле хатынның ире булганлыктан, авыл җәмгыяте кабул итә алмады. Авылдашлары аны гарипләр яисә акылы җиңеләйгән

бәндәләр дәрәҗәсендә күзаллый иде. Ул мескен маржаны авыл халкы нигә кабул итмәде икән? Аны бит колхоз эшенә дә чакырмадылар. Күршеләре белән дә алар аралашып яшәмәде. Гомумән, урамга да чыкмый иде мескен маржа. Сугышка алынырга Габдинең яше өлкән иде. Аны Коми ягына урман кисәргә җибәрделәр, шунда агач басып үтерде. Карчыклар аның фаҗигале үлемен гөнаһлы булуыннан дип юрадылар.

Империя золымы астында яши башлаганга дүрт гасырдан артык вакыт узуга карамастан, Караяр халкы һаман әле хан заманыннан килгән гадәтләрдән ваз кичмәгән. Явыз Иван гаскәрләре татарларның җирен басып алса да, нинди генә чара кулланып караса да, тулысынча урыслаштыра алмаган. Татарлар теш-тырнаклары белән ата-бабадан калган кануннарга ябышып яши биргәннәр.

## Алтынчы бүлек

### 1

Өй тагын да бәләкәйләнә, мескенләнә төшкән. Тәрәзә астындагы өч нигәнең бүрәнәләре муртаеп, тәмам черер хәлгә килгән. Тәрәзә пыялалары тоныкланып беткән. Бура урам ягына таба янтая башлаган. Шунысын аңлап булмый: йортның яңа салынган чагы әле һаман Габдрахманның күз алдында тора иде. Балачакның җылы оясы да әкренләп картая икән.

Ишегалдын бәбкә үләне каплаган. Утынга сүтелгән келәт нигезен әрсез алабуталар басып алган. Заманында алты балалы гаиләнең көнкүреше кайнаган яшәеш мәйданында озакламый кычытканнар хакимлек итәчәк. Алабута арасыннан канатларын җилпеп ак тавык атылып чыкты да, Габдрахманны күргәч, кинәт туктап калды. «Син кем? Нәрсә эшләп йөрисең монда?» – дигәндәй сәерсенүе.

– Мин бит синең хуҗаңның малае. Кайларда йөри минем әнием?

Тавык, кача-поса, алабута арасына чумды.

Тышкы ишеккә калай тас сөяп куелган. Бу – йорт хуҗасының каядыр әзгә генә киткәнлеген белгертә торган күптәнге гадәт. Озакка киткәндә, Фәриха карчык ишек тоткасына тышкы яктан таяк тыгып калдыра иде.

Колхоз Рәсәй халкын әкренләп урлашырга өйрәтте. Колхоз милкен урлаучыны карак, димичә, бераз йомшартып, «несун» – алып кайтучы, дип кенә атап йөртәләр иде. Күпме генә омтылып карасалар да, татарның озак гасырлар шәригать кануннарында яшәгән өлкән буыны бу гөнаһлы гамәлне кабул итә алмады. Фәриха карчык шундыйлардан иде. Тормыш кырыс иде: йә ачка үләсең, яисә үзеңә тиешлене урлап исән каласың. Шундый шартларда да Габдрахманның әнисе урып җыйганда коелган башакны, җирдә калган колхоз бәрәңгесен алып кайтудан тартына иде.

Күрше малы яисә башка авыл кешеләренең милкенә тимиләр. Ә менә колхозныкы? Дөрес, колхоз дигән нәрсәнең исеме бар, ә җисеме? Кемнең үз күзе белән шул байлыкны күргәне бар? «Колхоз каз аламы икән? Колхоз тары аламы икән?» – дип такмаклыйлар иде утызынчы елларда?.. Ягъни, колхоз казала микән, колхоз тарала микән... «Кругом всё колхозное, кругом всё моё», – дип җырлый башладылар сиксәненче елларда. Акционерлык җәмгыятьләре мал хуҗасының өлеше күпме икәнлеген үзләренчә төгәл ачыклап бирергә мөмкин әле. Ә социалистик милек, синеке саналса да, ничә дистә еллар буена түрәләр кулында булды. Бәлки шуңадыр, үз милкеңне алудан нигә тартынып торырга?..

Әнә, Фәриха карчыкның мөлкәте бикләнмәгән, ал да кит!.. Тик урлап алып китәрлек мөлкәт юк иде бу йортта.

Шушы чуалчык уйлар арасында адашып басып торганда, бәләкәй арба сөйрәп, Габдрахманның әнисе кайтып керде.

Габдрахман, почмак артына посып, күзәтеп тора башлады.

**2**

Баштагы яулыкны хан заманыннан калган мескен бүрек каплаган. Өстендә – кече улы Варис Шәмшәрифтән алып кайтып биргән мөселман җиләне. Аякта яңа резин калош.

Ишегалдына уфалла арбасын сөйрәп кертте дә капкага бик сала башлады.

Танклар, континенталь ракеталар ясау эшендә остарган илдә халык заманча итеп «уфалла» ясарга да өлгергән. Әнә нинди матур, җыйнак, тартырга уңайлы арба... Көпчәкләр – резинадан. Тимер тәртәләргә никель йөгертелгән. Арбага сөт йөртергә бидон беркетелгән. Техника тәрәккыяте!

– Сөбханалла! Улым, синме бу? Әллә күземә генә күренәме?

– Мин бу. Өлкән улың. Менә кайттым әле.

Ана үкси башлавыннан көчкә тынычланып, күңелендә йөргән соравын бирде:

– Бөтенләйгәме инде?

– Юк әле. Ялга гына.

Фәриха карчыкның сабыйларча мөлаем, ябык, кызганыч гәүдәсе, күз яшенә тыгылып үксүе Габдрахманның күкрәгенә сырышкан иде.

– Авыр бит ялгыз яшәве! Нигә апалар янына – Таулыга күчмисең? Ул да бит берьялгызы яши.

– Юк инде! Тәрәтләре өй эчендә. Түшәмнәре өстендә исерек урыслар бии. Шундый йортта ничек намаз укып булсын! – Карчык бер адым артка чигенде. – Тукта әле! Нигә болай мәлҗерәп төштем. Корсагың ачкандыр? Хәзер казан асам.

«Карының» түгел – «корсагың». Бу бит... бу бүгенге үлем хөкеме көтеп яткан мескен тел түгел. Бу – заманында Евразия киңлекләрендә яңгыраган хөр, горур шивәнең җанлануы... Бу – Атиллалар чорыннан, баш бирмичә саклана алган «казан асу». Аларның йортындагы казан мич авызының уң ягына урнашкан учак өстенә беркетелгән...

Аш әзерләр алдыннан чатыр каршында янган учак өстенә казан асасы булмаса да, бу борынгы сүз Габдрахманның күңелендә горурлык уятты. Габдрахман әнисенең кулыннан «уфалла»ны алды.

– Башта сөткә баргансыңдыр дип уйлаган идем. Бидоныңда су икән.

– Чишмә суы.

– Коебызның суы киптеме?

– Юк, кипмәде. Чәйгә чишмә суы татлырак. Мин җимерелгән буа янындагы, кыйбла якка аккан изгеләр чишмәсенә йөрим. Суы шундый татлы. Чәе дә куерак чыга. – Карчык җиңел генә баскычка таба атлады. Бикләнмәгән ишекне ачып, өйалдына узды.

Хәрабәгә әверелә башлаган абзар-кураларны, яртылаш алабута баскан бәрәңге бакчасын, ботаклары корып бетә язган карт өянкеләрне карап йөргән арада йортның торбасыннан зәңгәр күккә сыек соргылт төтен үрелде. Ишекне ачу белән, Габдрахманның борынына яшәешкә җан өрә торган шулпа исе килеп бәрелде. Өй эченә каклаган каз итенең тәмле исе таралып, очрашу куанычына ямь өстәп, тантана уятып өлгергән иде инде. Анасын ялгызлыкта яшәргә мәҗбүр иткән гөнаһ һәм үзеңне гаепле итеп тою, бәгырь түрендә

кузгалып, йөрәкне астыртын гына чеметеп, сыкрандырып тора. Алты баланың сабыйчак сулышлары калган кысан, тәбәнәк түшәмле авыл өе. Идән такталары арасындагы таныш ярыклар тагын да киңәя төшкән. Акшары соргылт төскә керә башлаган, карап торырга килбәтсез, шулай да күңелгә җылы хис өреп торган мич, инде музей әсбабына әверелеп килгән йорт җиһазлары. Шуларның һәрберсе, авылын калдырып китеп, зимагурлыкта яшәгән егеткә рәнҗешле караш ташлап тора иде. Әнисе, кат-кат бисмилласын әйтеп, өстәлгә ашъяулык җәйде. Казан өстендәге капкачны алгач, каклаган каз итенең тарихларга барып тоташкан татлы исе тагын да куерды. Агач табакка аш бушатылды. Шулпа агач табактан ике чебешкегә бүленде. Табынга тоз, борыч, катык куелгач, әнисе казанга чиләктән бер чүмеч су салды.

Бу йортта табын янында сөйләшергә яратмыйлар. Алар ашап туйганчы сүзсез утырдылар.

– Чәй кайнатыйммы? – диде әнисе, тынлыкны бозып.

– Рәхмәт, шулпадан соң мин чәй эчмим.

– Мин чәйне шулпадан соң да эчәм. Гел эчеп торам. Рәхмәт чәйнең затлысын җибәреп торуыгызга. – Самавырга учактан соскы белән кайнар күмер салды.

Амин тоттылар.

– Хәл җыеп аласың килсә, мин сиңа урын җәеп бирәм.

– Су буйларыннан урап кайтасым килә, – диде Габдрахман һәм киенә башлады.

– Озаккамы?

– Бер-ике сәгатькә. Бәлки, озаграк та йөрелер.

– Нәрсә ашыйсың килә? Сыерсыз юньле сый да әзерләп булмый инде.

**3**

Бусаганы атлауга, күкрәк эчендәге ачы, кайнар төер, тамакны ачыттырып, тышка бәреп чыкты. Җимерелеп яткан абзар хәрабәләре аша алабута баскан бәрәңге бакчасына чыккач, Габдрахман эче бушаганчы үкседе.

Нишләп безнең көнкүрештә әниләргә урын калмый? Алар бит безне картлык көннәрендә таяныч булыр дип өметләнеп, йөз җәфа, мең мәшәкать эчендә тәрбияләп үстерәләр. Үсеп аягына баса башлаган бала шундук дәүләт тозагына килеп каба да – сау бул, җылы туган оя! Сау булыгыз, эти-әниләр! ...Без читләрдә йөргән арада авылдагы безгә дигән урынны яңа буын вәкилләре били башлаган. Тырышып эзләсәң, урын табылачак. Әйдә, менеп атлан тракторга! Йә булмаса фермага мал асты пычрагын тазартырга яллан... Ә бит син чит җирләрдә абруйлырак урында...

Бераз тынычлана төшкәч, Габдрахман урамга чыкты. Бертын кая барырга белми торгач, зиратка таба атлый башлады. Күрше Миңлениса түтәйләр урынының кычытканнары инде чирәмгә алышынган. Баз урыны тигезләнеп беткән. Монда кайчандыр йорт, абзар-кура, бәрәңге бакчасы, хуҗалык һәм гаилә көнкүреше булуын исбатлый алырлык бер генә эз, бер генә билге дә калмаган. Бусы – Габдулла абзыйлар урыны. Бушлык... Рәттән өч йорт, өч хуҗалык, өч гаилә... Кая китеп олакканнар? Бармы алар, әллә тамырлары корып юкка чыкканмы?.. Нинди каһәрле көч, нинди рәхимсез давыл-өермә, эзләрен җуйдыртып, тамырлары белән йолкып алып ыргыткан! Җавап юк. Өнсезлек... Аңларга зиһене җиткән кешегә бар җавап, нигә булмасын. Йортларның юкка чыгуының яшерен серен Габдрахманга үз йортының киләчәге кинаяләп тора иде. Аларның нигезен дә шул ук кара тәкъдир көтә...

Бусы – Хоснури түтәйләрнең йорты. Абзар-кура, Аллага шөкер, исән. Сугышка кадәр бу йортның хуҗасы ир кеше иде бит. Сугыштан соң ирләр исеме йөрткән гаиләләр хатын-кызныкына алышынып бетте... Ә исеме ничек иде? Онытылган! Бу нигезне дә бит ирләр исеме белән атап йөртәләр иде.

«Никто не забыт, ничто не забыто!» – дип шапырына империянең рәсми агитациясе. Чынбарлыкта исә исемнәр дә, совет власте алып килгән җәәҗүз-мәәҗүз дә, аның фаҗигасе дә онытылачак, киләчәк буыннарга җиңү шапырынуыннан әмәлләнгән коры куык пропагандасы гына калачак. Хоснури түтәйләргә янәшә Шырый Ибрае исемле кеше яши иде. Шырыйныкылар дип атап йөртәләр иде сигез бертуганны. Шуларның берәрсе исәнме икән әле? Урыннарын кычыткан баскан... Урамның каршы ягында шулай ук җиде бертуганнан торган Тартай нәселенең соңгы варисы – Рәиснең йорты авыл читендә ялгыз тырпаеп утыра. Зәки, Мөкаддис, Батыр Тәрәе, Алтынгәрәй, Инсаф. Нигъмәт агайларның урынында да моңсу бушлык... Кая китеп югала, юкка чыга Караяр халкы?.. Әрсез бушлык каян килә?.. «Ватан» исемен бөркәнгән империядәге канлы үтерешләр, колхозлаштыру, дошман эзләү, кулакларны сөрү ашап бетергәнме бу хуҗалыкларны? Уйлап карасаң, сугыш рәхимлерәк, ул ир-егетләрнең генә башын ашый… Хатын-кызлар кайда? Рәсәй дәүләтенең төп, даими горурлыгы – бөек җиңүләр ирләрне кырып ташлау белән генә чикләнми шул. Сугыш хатыннардан толлар, балалардан ятимнәр ясый. Ачлык-ялангачлык алып килә һәр сугыш һәм, беренче чиратта, нацмен тамгасы сугылган халыкларны кырып ташлый, аларны тоташтан кыркып, юкка чыгарып килә…

Ачык чирәмлеккә әверелгән элекке тыкрыктан Габдрахман инеш буена таба юл тотты.

Инешнең аръягында сөзәк таулар тезмәсе. Чаукалык тавыннан башлап Бөгелмә тарафына таба тезелеп киткән Урындык тау, Бакыр тау. Араларында тирән чокырлар.

Бала чакта болытларга тиеп торган таулар яңгыр суларына юылып тәбәнәкләнгәнме, әллә Габдрахман күргән Везувилар, Этна, Стромболи, Альп (аңа ул һәрвакыт «Алып» булып ишетелә иде) таулары белән чагыштырып карау шулай тәбәнәкләндерәме... Күз күргәнне җиңел генә аңлап бетереп булмый.

Тукта әле, мин нигә таулар ягына атлыйм? Башта бит зиратка керергә, этиемнең һәм егерме бер яшендә якты дөнья белән мәңгегә саубуллашкан газиз апам, этиемнең энесе Нәби абзыкайның, әби-бабаларымның каберләрен зиярәт кылып, җавап тотарга тиеш түгелменме?

Габдрахман, кире борылып, зират ягына таба юл тотты.

## 4

– Кайларда йөрдең?

Әнисенең өстендә кешелеккә генә кия торган шакмаклы яшел күлмәге. Башында этисенең Ырынбурдан алып кайткан бүләге – парчалы кашемир яулык.

Эре шакмаклы тукымадан шотланд халкы милли киемнәрен тегә. Фәриха карчык кына түгел, татарларның өлкән буыны да үз итә иде шундый тукыманы. Шуңа өстәп шотландларның (инглизчә – скотлэнд) музыкалары да татарныкы шикелле пентатоникага нигезләнгән. Мондый уртаклыкның сәбәбе булырга тиеш бит. Без урыс көчләп таккан татар-монголлыктан ары китә алмыйбыз шул.

Улы зиратка барган арада карчык бер-ике дистә елга яшәреп киткәндәй

үзгәреп өлгергән. Өйдә кызган май катнаш көйгән камыр һәм бәйрәм исе. Кунак каршылаудан, куанычлы очрашулардан туа мондый ис.

– Нәрсә пешерәсең, инәки?

– Мичкә бәлеш куйдым. Син яраткан ризык – каклаган каз ите турадым бәлешкә.

– Рәхмәт, инәки! Сине сагынган чакларда нәкъ шушы ис җанымны тырнап газаплый.

– Нигә газапланасың? Кайт. Соңгы эшең армия хезмәтендәге шикелле мәҗбүри түгел, дидең бит. Нигә кайтмыйсың?

– Кайтып нинди эш башкара алырмын соң? Җирне хәзер трактор сөрә. Печәнне йөк машинасына төяп ташыйлар. Саламны да инде кибәнгә өйми башлаганнар. Заманында мин башкарган эшләр беткән.

– Укытырсың. Әнә бит Мәскәүдәге иң зур университетны бетердең. Ә монда укытучыларның күпчелеге Бөгелмәдән ары китеп укый алмаганнардан. Укытучылар рәхәт яши бит. Мал асрыйлар. Бакча тоталар. Хәзерге балалар аларны бәйрәм саен бүләккә күмеп ташлый. Атаң мәрхүм, исән булса, синең хәлфә булып йөрүең белән горурланыр иде.

– Ничек инде... ялгызым сыер асрый алыйм. Аны бит саварга кирәк.

– Менә-менә. Мин бит инде ничәмә ел шул бер балык башы турында әйтеп торам. Нигә һаман башлы-күзле булырга теләмисең?

– Синеңчә, минем башым да, күзем дә юкмыни?

– Сукыр булганга, дивана булганга болай әйтмиләр. Өйләнеп, гаилә корып яшәгән кеше дөньяга бөтенләй башкача карый башлый. Аның башы да җаваплырак эшли. Гаиләле кеше буйдакларга күренмәгәнне күрә. Алар аңлый алмаганны аңлауга ирешә.

«Башлы-күзле», диюләре шул инде...

Җиденче дистәне куган карчыкның зирәклеге Габдрахманны хәйран калдырды.

Аны шушы җылы оядан мәҗбүри алып китүләренә ике дистә елдан артык вакыт узды. Читтә йөреп кайткан Караяр кешесенең һәр очракта авылдашлары каршында җитди имтихан тоту гадәте әле һаман исән иде. Нурми исемле бер егет каршы алырга чыккан әнисе белән «здравствуй, мама», дип күрешкән. Инде иртәгесен үк диярлек мескеннең кушаматы «Урыс Нурми» иде. Икенче бер егет, Кәшфи, хезмәтен тәмамлап кайтып, авыл клубындагы танцыга баргач: «Забыл по-татарски, могу только по-русски», – дип мактанган.

Авылның иң җор егетләре Кәшфелмаганны: «Одна девчонка с тобой хочет познакомиться, сама стесняется, нас попросила», – дип, клуб артындагы аулак җиргә чакырып чыгарганнар да туган телен оныткан егетнең кумпылына берне тондырганнар.

– Нишлисез, егетләр?! Ни гаебем бар минем?

– Бәй!.. Син татармыни? Без бит сине урыс дип торабыз... – дигән тегеләр.

Шул сабактан соң егет, урысча белүе белән шапырынудан туктап, авылдашлары телендә сөйләшә башлаган.

Заманнар үзгәрде. Озак гасырлар саф туган тел авазларын, бары тик шуны гына ишетеп яшәгән урамнарда авыз тутырып рус телендә сөйләшеп йөрү әкренләп табигый тоела башлады. Явыз Иван оештырган холокост. Гасырларга сузылган, бер яктан үлем белән янап, икенче яктан түрәлек өстенлеге белән ымсындырулар да татарны милли кыйбласыннан тайпылдыра алмый иде әле. Көтүләп Себерләргә куулар да татарны какшата алмады. 1917 елдагы

түнтәрелештән соң татар күзгә күренеп телен, теле белән динен, дине белән иманын, иманы белән тарих эзен, шул эзләрдәге мирасын туктаусыз югалта бара иде. Шушы ачы уйлар кыска, газаплы минутлар дәвамында Рахманкуловның бәгырен айкап узды.

«Син мине башлы-күзле булырга үгетлисең. Мин, әнием, нәкъ шул турыда синең белән киңәшергә кайттым да инде...» – дип әйтергә иде хәзер. Карчык яулык чите белән күзләрен сөртеп алсын да әйтсен иде: «Йә әле, тыңлап карыйк, сөйлә – кем икән ул Бәкер мәрхүм белән минем киленем буласы кыз?» – дисен иде.

Юк бит, шушы күтеп алынган иң табигый, тансык сөйләшүне дә үз әниеңә юньле-башлы – кешечә җиткерә алмый җәфа чик инде. Ул турыда, бәлки, бәлештән соң сөйләшү хәерлерәк булыр? Бигрәк тә тәмле бит каз бәлеше. Телеңне йотарлык...

Бәлеш исенә кушылып, өй эченә Габдрахман алып кайткан «Граф Грей» исемле чәйнең хуш исе таралган. Алар каз бәлеше белән янып-пешеп чәй эчәләр. Караңгылык тәрәзә пыялаларына килеп терәлгән! Сирәк кенә урамнан узган машиналарның уты тәрәзәдән өй эченә сирпелә дә караңгылык тагын да куерып китә.

Адәм баласының ялгызлыгы кичләрен түзеп булмас хәлгә җитеп көчәя. Ничә ел үтте икән әнисенең берьялгызы яши башлавына? Дистәдән артык бит…

Эх, күпме сүзсез хатирәләр җыелган ике арада?! Әнисенең бишек тирбәтүе. Бишекнең күтәрелә-төшә салмак кына чайкалуын әнисе көйләгән бишек җыры хәрәкәткә китерүенә ул әле дә ышана шикелле.

Бишек җырларын әнисенең уйчан мөнәҗәтләре, «Йосыф китабы»ның маҗаралы чынбарлыгы, фаҗигале бәетләре алыштыра; остазбикәгә сабакка барган, утауга, уракка, ашлык сугуларга йөргәндә булган мәзәкләр, Сабантуй, җыен хатирәләре, Самар губернаторы тройкага утырып авыл аша узганда, ундүрт яшьлек Фәрихане бәйрәмчә киендереп, башка җиде кыз белән шул патша түрәсен каршы алырга куюлары турында сөйләгәннәре әле һаман Габдрахманның хәтерендә. Аларны бит Габдрахман бәләкәйдән күңеленә беркетеп үскән. Ул истәлекләр улының да офыкларын киңәйтеп, аның дөньяга карашы, фикер йөртүләренең үзәгенә яткан җуелмас эз булып сузылган.

Чәйдән соң икәүләп амин тоттылар.

– Чыгып керәсем килә, – диде Габдрахман. Сөйләшүне иртәгәгә калдырырга кирәк, дигән фикергә килде ул. Әнисе ястү намазына баскач, Габдрахман ишегалдына чыкты. Әтисе утырткан карт өянкенең кытыршы тәненә сөялеп һава сулады.

Өйгә кергәндә, түрдәге караватка урын җәелгән иде инде. Мамык түшәк-ястык, дөя йоныннан сырылган җылы юрган. Җир йөзенең башка бер генә җирендә дә мондый татлы рәхәтлек юк шикелле тоела иде Габдрахманга. Ул бит, кисәкләрен бергә кушып алганда, җир шарын инде бер генә тапкыр урап чыкмады. Аллаһы Тәгалә аңа үзен чолгап алган тирәлек-тормышка дикъкатьле кызыксынулы күзәтүне мул итеп биргән иде. Аның хәзер чагыштыру мөмкинлекләре бар. Күп күрде ул оҗмах җирләрне. Башкалар аларны Караярдан күпкә күркәмрәк дип табар иде. Хак иде бу җирләрнең күркәмлеге, әмма аларның берсе дә аңа туган җир түгел иде.

Фәриха карчык та озак кына йокыга китә алмыйча ятты, аның газиз улы да. Сөйләшә башлаудан курыктылар. Әллә кайларга алып китә ул төнге сөйләшү. Йокы тынычлыгы, аның шифалы кочагы төн уртасыннан соң гына ачылды.

**5**

Габдрахманны йокыдан коймак исе уятты. Бала чактан таныш, кайнар коймак, көйгән май исе. Ымсыну чиктән тыш көчле иде. Торуга әнисе аны сыйлый башлаячак. Йончыткан. Баш авырта.

– Хәерле иртә, инәки. Нигә болай иртә торасың?

– Без күнеккән инде. Син дә тор, юын, бергәләп чәй эчәрбез.

– Чәйгә хәтле тауга менеп төшәсем килә.

– Әллә исәрләндеңме? Тын кысыла бит анда менгәндә. Коймагым да суынып бетәр. Әйдә, юын да утыр.

– Син бит беләсең, инәки, мин коймакның таба өстенә таба каплап кайнар мичтә тотып алганын яратам. Һава сулап кайтасым килә, аппетитны уятып.

– Озак йөрмә. Ындыр артларын гына урап кайт.

Габдрахман тиз генә киенеп урамга чыкты. Аның малларны көтүгә куганнарын күрәсе килә иде. Урам буш. Маллар абзарга керде микәнни? Колхоз эшенә баручылар да күренми. Киң, иркен чирәмлектән ул ашыгып инешкә таба атлый башлады.

Инеш. Йа Хода! Аның суы теләр-теләмәс кенә саркып ята. Суның читләренә, уртасына басып чыгарга өч таш салганнар, җан биреп яткан инешнең киңлеге шуңа калган. Атлап чыгар алдыннан ул туктап тыңлап торды. Кайда аның чуерташлар белән серләшеп җырлаган тавышы? Каршы якның балчыгын ашап ясаган биек ярлары кайда?

Ул Карагыш (кара кош – бөркет) кулы дип аталган уенкылыктан өскә, тау сыртына таба атлады. Тыны кысыла башлаганда, Габдрахман тауның уртасына да менеп җитә алмаган иде әле. Кире борылып, төшеп китәргә туры килде.

Төшүе хәтта уңайсызрак та шикелле иде. Ниндидер көч гәүдәне аска таба сөйри. Шуңа каршы торыр өчен, аякларны терәп карышырга кирәк иде. Шунлыктанмы, әкияти балачактан үсмерлеккә күчә башлаган елларның берсендә, тау сыртына тия язып узган болытларга утырып, зәңгәр диңгезләр артындагы әкияти Занзибарны күреп кайту хыялы белән җенләнеп йөргән сукмакларны күреп булмады...

– Тизрәк кулыңны ю, коймак суына, – дип каршы алды Фәриха карчык.

Өстәлдә – пешкәннән соң, кабат мичтә май сеңдереп, тагын да татлылана төшкән коймак өеме. Шуңа өстәп туган йортның шифалы һавасы, газиз анаң, балачак хатирәләрен сеңдергән стеналар…

– Картайдым мин. Сине соңгы күрүемдер, дип куркам.

– Юкны сөйләп утырма инде.

– Варисы да бит һаман укып туймый. Ничә ел Бөгелмәдә ятып укыды. Бөгелмәдә балаларга сабак бирде. Бетереп кайткач, Печмән ягында балалар укытты. Мәскәүгә китәр алдыннан ике ел укытучыларның эшләрен генә тикшереп йөрде. Шул җитмәде микәнни?

– Бәләкәй чакта сез укып кеше булу турында гел тукып тордыгыз. Бишлегә укыганга куанып туймый идегез.

«Белем алуның куркыныч ягы да бар икән...» дип, үзалдына эчтән генә уйлап алды Габдрахман. Халык «укыган кеше – чукынган кеше», дип юкка

әйтмәгән. Бу гыйбарәгә кадәр аның гыйбрәтле, әче тормыш тәҗрибәсе булганга охшый. Әнисе әнә бернинди университетларга кереп укып йөрмәгән. Әмма яшәү гыйлеме, яшәү зирәклеге ягыннан Габдрахман аның янында үзен һаман әле бала итеп тоя иде. Дөрес, ул да укымый түгел... Фәриха карчык һаман намаз укый, ураза тота. Димәк, ул андый-мондый белем генә түгел, үзенә һәм үзенең бөтен нәсел-нәсәбенә кыйбла булырлык гыйлем алуга ирешкән! Көне буе ач йөрү ашказанына зарарлы, дип, аны туктаусыз кисәтеп торалар. Ә ул намаз укуын, ураза тотуын дәвам итә. Сәламәтлек бик кирәк. Дин йоласы сәламәтлектән дә кадерле микәнни? Бу кайтуында Габдрахман әнисенең үҗәтлеген тагын да тирәнрәк аңлауга ирешә. Урыслар Казан ханлыгын яулап, татарларны буйсындыра алганнар. Җир-су аларныкы санала башлаган. Идарә итү алар кулына күчкән. Күчүен күчкән, әмма Фәриха карчык ишеләрне буйсындырырга чара таба алмаганнар. Ачыктан-ачык каршы чыкмыйча гына, буйсынудан баш тартып, Казан ханлыгы чорындагыча намаз укып, ураза тотып, чынбарлыкны туган телләренә төреп, үзләренчә яшәүләрен дәвам иткәннәр. Алар, әҗәлләре килгәч, җир кочагына ислам динен тоткан чын мөселман булып керәчәкләр. Балалары канын да носариларныкына кушуга һич тә риза булмаячаклар. Бу фикер алда торган өйләнү турындагы сөйләшү-аңлашуның ифрат авыр булачагын Габдрахманга тагын бер тапкыр искәртеп тора иде.

## 6

Рахманкуловның Караярга кайтуына бер атна вакыт үтеп киткән иде инде. Көн саен диярлек коеп яңгыр ява. Салкын, бик тиз чылатып ташлый торган көзге яңгыр.

Габдрахман тауларда, урманда, армиягә киткәнче сабан сөргән яланнарда йөреп кайткач, ишелеп төшәргә торган төз лапасны сүтеп, әнисенә утын әзерләде. Таралып төшәргә торган капканы ныгытты, ләм басып бетергән коены чистартып, сиртмәгә яңа чиләк асты. Район үзәгеннән поездга билет алып кайтты.

Тәбикмәкләп ашыкмыйча гына кичке чәйне эчтеләр. Фәриха карчык табынны җыйды, кухня ягына кереп, савыт-сабаны юарга тотынды. Атна буе сүзне нәрсәдән башларга белмичә йөргән Габдрахман, ниһаять, өстәлдә яткан ике беләгенә башын куеп, сүз катып җибәрде:

– Инәки, мин башлы-күзле булырга җыенам.

– Хәерлегә булсын, улым... Синең замандашларыңның балалары үсеп җитте бит инде. Кем кызына?

Фәриха карчык шушы атна эчендә улы авылның бер яшь кызы белән уртак тел табып, ярәшергә өлгергәндер дип уйлый иде.

– Инәки, син аның кем кызы икәнен белмисең. Ул Одессада яши.

Фәриха карчык эшеннән туктады, кулын сөртте дә малае каршысына килеп утырды:

– Марҗамыни?

– Марҗа түгел. Аның милләте украиналы, ә болай тамырларында кыпчак каны ага.

– Ул кыпчак дигәнең кемнәр соң алар? Мөселман өммәтеннәнме, әллә чукынучыларданмы?

Әнисенең шушы дәрәҗәдә җитди, игътибарлы булуын Габдрахманның күргәне юк иде шикелле. Әтисе вафат булганнан соң, ул чакта әле яңа кырыктан

узган, таза, көчле хатынның ярым ятим – әтисез калган балаларының киләчәге турында уйлаганда гына җитдилеге шушы дәрәҗәгә җиткән булгандыр.

– Юк, алар мөселман түгел.

– Носарилармыни?

– Инәки, татар кызларының да барысы диярлек мөселман түгел бит инде хәзер. Әниләре намаз укымый. Шәригать кануннарын белүчеләр үлеп бетте диярлек. Шуңа өстәп комсомол тәрбиясе. Карт буын тота. Ә яшьләр? Бездән башта пионер ясадылар. Аннан соң комсомол иттеләр. Хәзер мин партия әгъзасы. Партиягә кермәсәм, миңа чит илләргә йөри торган корабта эшләргә рөхсәт итмиләр иде.

Фәриха карчык яулык чите белән күзен сөртеп алды.

– Армиягә киткәндә, син бит динне тота идең, ташладыңмыни?

– Юк, ташламадым. Диңгездә каты давыл кузгалганда, каты шторм вакытларында каютаңның асты өскә килеп чайкалган чакларда, Аллаһы Тәгаләгә ялварасың. Аннан башка сиңа беркем ярдәм итә алмый.

Армиягә кадәр Габдрахман ураза тотты. Ул инде намаз укырга да өйрәнгән иде. Казарма шартларында һәм диңгезчелектә ураза тоту, намаз уку түгел, амин тотканда, битеңне сыпырып та булмый иде. Ул «раббанә атинә»не авыз эченнән генә укый иде. Мөселманлык аның күңелендә әнә шулай эчкә яшерелгән, оеткы рәвешендә яши бирде.

– Аллаһы Тәгаләне оныткан очракта океаннарда йөзеп йөреп булмый, – диде ул, фикерен йомгаклап.

– Юк, улым, – диде әнисе, алдагы сүзне яңабаштан ялгап. – Динне берничек тә бетереп булмый аны. Комсомол булсалар да, безнең авыл кызлары тәре тагып йөрми, почмакта эленеп торган потка карап чукынмыйлар. Күзгә ташланып тормаса да, яшьләрдә барыбер мөселманлык яши ул.

– Ял вакытында мин аны Караярга алып кайтырмын, ә син амин тотарга, догага, намаз укырга өйрәтерсең, – диде Габдрахман, әнисен ышандырырга тырышып.

– Телләре безнекеме соң аларның?

– Юк, безнеке түгел.

– Алай булгач, минем белән үзебезчә сөйләшә алмас бит. Авылдашларыбыз каршында да әпә булып йөрер. Син шуннан курыкмыйсыңмыни?

– Куркам. Бар анысы да. Ул миңа бик ошый. Хәйран калырлык матур ул. Күрсәң, син дә хәйран калырсың әле.

– Авылыбызда андый матурлар юкмыни? Караяр кызларының матурлык даны әллә кайларга таралган бит. Узган ел мин Ишендегә кунакка барган идем. Карчыклар авылыбыздан чыккан кызларны иң матур, иң уңган киленнәребез, дип сөйләделәр.

– Сүз дә юк, безнең авыл кызлары матур. Анысы шулай. Ә менә миңа дигәннәре үсеп җитәр-җитмәс кияүгә чыгып өлгерәләр. Өйләнәсе кызым миннән унбиш яшькә кечерәк. Чит җирдә яшь аермасы әллә ни сизелми. Авылда нигәдер алай түгел. Ике-өч яшькә аерма да үтә зур тоела.

– Хәзер алай түгел инде. Әнә Шәмсенаһар кызы бер нифтәник нәчәлнигенә чыкты. Яшь аермасы егерме тирәсе, дип сөйлиләр.

– Урыска чыктымыни Шәмсенаһарттәй кызы?

– Юк, урыс түгел. Теге Каф тавы ягыннан килгән бәндә, мөселман өммәтеннән. Теле дә безнекенә тартым. Бите кара кучкыл. Мыеклы. Шәмсенаһар кызын машинага гына утыртып йөртә. Үтә бай яшиләр, ди. Ашаганнары да гел бал да май, ди.

Берничә минутка сөйләшүне дәвам итәргә сүз таба алмыйча тынып калдылар. Арада көчле киеренкелек иде. Әнисеннән ризалык булмаячагын Габдрахман сөйләшә башлаганчы ук сизде. Сизенсә дә, аны күндерә алуына өмете бар кебек иде әле Габдрахманның. Әмма, алай каты әйтеп карышмаса да, чит җирдә үскән ят милләт кызын өенә килен итеп төшерүгә әнисенең риза булачагы күренми иде. Рахманкулов яңа дәлил китерергә ашыкты:

– Ул кыз, инәки, шигем дә юк, килен булып төшкәч, телебезне өйрәнәчәк. Хәзер бит, инәки, татарлар үзләре дә туган телдә сөйләшми башладылар. Авыл җирендә бу хәл әлегә сизелми. Әнә, район үзәге Таулыда гына да ике татар пыр туздырып үзара урысча сөйләшеп йөри.

– Юк, улым, без исән чакта, Аллага шөкер, кяферчә сөйләшмәбез.

– Бәлки, мөселманлыкка күчәргә дә риза булыр, аңлата алсак. Син моңа ничек карыйсың?

– Нәрсә әйтергә дә белмим инде, улым. Мин гөнаһыннан куркам. Урыслар белән бит аерма диндә генә түгел. Безнең язмышлар төрле. Син татарча сөйләшкән урысны очратканың бармы? Аларның Казан каласын алып, мөселманнарны кырып ташлаганнары турындагы мөнәҗәтне ишеткәнең юкмыни? Ә мәчетләрне җимереп, чукындырып йөрүләре хакында? Синең марҗа алуың турында ишетү миңа бик авыр булачак. Авырлыгын кичерер дә идең... Ә гарьлеге? Авылдашларымның күзләренә мин ничек карармын?! Фәриха малаен тәрбияли алмаган, аның Габдрахманы марҗага өйләнгән... Шушы гарьлектән җир тишегенә керү дә коткара алмас...

Фәриха карчыкның күзеннән яшь бөртеге тәгәрәп чыкты да авыз читеннән ияк астына таба сузылган җыерчык буйлап күлмәк якасына төшеп тамды.

– Син, улым, ул кызга вәгъдә бирмәгәнсеңдер бит?

– Ничек әйтергә? Ул инде минем синнән хәер-фатыйха алырга китүемне сизеп калды. Мондый чакларда бит бер-береңне сүзсез дә аңлап була.

– Нинди гөнаһларым өчен Аллаһы Тәгалә мине болай җәзалый икән? И-и-и Раббым! Абыеңның хатыны Мәрфуга аракы эчә. Больниста эшли бит. Хөкүмәт спирте аның үз кулында. Абыең аны кыйнап та, базга салып та карады. Юк, бизәргә теләми, һаман чөмерә. Сәрхуш ана?! Раббым сакла андыйлардан нәселебезне!.. Олы кызы кулдан-кулга йөри башлаган, дип сөйлиләр. Малайларының да күзләре нурсыз. Тач урыс инде. Ә җизнәң дигән бәндә? Карап торырга юаш кына үзе. Аракыга авызы тию белән, Кадриягә кул күтәрә башлый, дип миңа җиткереп торалар. Уллары ятим бала шикелле, сөйләшергә яратмый. Сабакташлары белән аралашмый. Бишенчедә укый. Мәктәптән кайтып ашый да, йокларга ятканчы, почмакка карап утыра, ди. Кадрия үзен брачка да күрсәтеп караган. Файдасы юк.

Фәриха карчык яулык чите белән авызын каплап елап алды. Тавышсыз гына.

– Йа Раббым! Син мине шулай бала сөюдән мәхрүм итәсеңмени! Марҗа түгел, дисең... Безнеңчә белмәгәч – марҗа инде ул! Мин бит сине, төн йокыларымны калдырып, марҗа өчен үстермәдем. – Әнисенең үксүе тирәнәя, көчәя бара иде. Карчык урыныннан торды, ишектән чыгып китте. Шыгырдап капка ачылган тавыш ишетелеп алды. Йорт эчендә йөрәк әрнеткеч тынлык, өнсезлек урнашты. Кая юнәлде икән әнисе? Аның бит Оксананы күргәне дә юк.

Бер сәбәпсез, тора салып нигә шулай өзгәләнергә? Бер сәбәпсез. Юкка… Бары тик, бары, бары тик татар кызы булмаган өчен генәме? Бәлки, Оксана турында әйтмәскә кирәк булгандыр?.. Шәһәрдә туып үскән татар кызларының күпмесе соң туган телен белә? Әнә бит, бер дә тартынмыйча, үзара кяферчә аңлашалар…

Кич урын җәеп, шактый озак сүзсез ятканнан соң, Фәриха карчык ишетелер-ишетелмәс кенә әйтеп куйды:

– Картлык көнемдә шатланып бала сөяргә язмагандыр инде. Мин ничек аның белән урысча сөйләшермен?!

Җавап бирергә Габдрахман ышандырырлык дәлил эзләп карады. Чыннан да бит, урыс телле ана баласының теле урысча ачылачак. Ә тел сөйләшү, үзара аңлашу коралы гына түгел. Тел – синең кем икәнлегеңнең иң дөрес, иң төгәл күрсәткече.

Әйе, хәле җиңел түгел Габдрахманның. Аның Оксанага өйләнүенә әнисе каршы. Исән булса, әтисе Бәкер дә, һичшиксез, каршы булыр иде. Әйтеп белгертмәсәләр дә, Габдрахманның авылдашлары да, һичшиксез, Оксананы Караяр килене итеп кабул итмәячәкләр. Рахманкуловның марҗага өйләнгән авылдашлары юкка гына авылга ялгыз кайтып йөрмиләрдер? Өйләнсә дә, никахтан баш тартса да, шушы гамәлләрнең икесендә дә оттырыш ярылып ята: өйләнсә, әнисенең хәер-фатыйхасын югалта, баш тартса – мәхәббәтен. Шуларның кайсын сайларга?! Менә нинди хәл итә алмаслык катлаулы сорау каршында калган иде Фәриха малае! Габдрахманның исенә әкияттәге юл чаты тудырган бер өметсезлек килеп төште: «Сулга барсаң – атыңны югалтасың, уңга барсаң – башыңны югалтасың...» Әкият батыры, ике юлдан да ваз кичеп, юлсызлыкны сайлый һәм турыга китә. Турыдан китү – бу очракта өйләнүдән баш тартып, гомерне буйдаклыкта үткәрү иде. Ә бит канда, күзәнәкләрдә нәселне, нәсел аркылы ыруны, соңгы чиктә – милләтне дәвам иттерү инстинкты, тынгы бирмичә, астыртын кыбырсыта иде.

Габдрахманның балачак бишеген тотып торган ыргак әле һаман матчада. Шушы өй эчендә аның Оксана белән туган телдә сөйләшеп утыруы күз алдына килеп басты... Юк, бу хыялый фаразга Габдрахман үзе дә инде ныклап ышана алмый иде.

Кыйбла һәм иманына әнә шундый тугрылык, кагылгысыз ныклык саклый алган инәкәе – Фәриха карчык, үлсә дә, Оксанага өйләнергә ризалыгын бирмәячәк. Аның күргән нужалары, авыр сугыш еллары, яшьли ирсез калуы, үсеп житүгә балаларын үзенә тартып алган империя золымының аяусызлыгы… бу эш белән килешергә юл калдырмаган иде. Әйе, аның сүзенә колак салмыйча, үз теләгеңне генә алга куеп, үзең белгәнчә эш итәргә дә, димәк, Ана йөрәгенә тагын бер төзәлмәс җәрәхәт, тагын бер кан sауган эз калдырып китәргә дә тулы мөмкинлеге бар Габдрахманның бу дөньяда!..

**7**

Китәргә ике тәүлек кала, шулай да алар киләчәк турында сөйләшүгә кабат кайттылар.

– Кышкы бураннарда тәүлегенә ике тапкыр мич ягып нигә интегәсең? Катифә апа Таулыда ялгыз яши. Ике бүлмәле квартиры җылы. Аш әзерләргә газы янып тора, кухнясына суы кергән. Нигә шунда гына тормыйсың? Ул миңа: «Ник миндә торырга теләмидер? Күршеләр нигә әниеңне алып килмисең, дип гел сорап торалар. Үз йортында яшисе килә дигәнгә ышанмыйлар. Дошманлаша торганнардыр дип уйлыйлар», – дип зарланып сөйләде.

– Суы аш пешерергә ясалган бүлмәсендә агып тора. Аны бит эчәрлек түгел. Тутык тәме килә.

– Чишмәләре дә якында гына бит. Чәй кайнатырга шуннан алып кайтырга була.

– Катифәгә баргач, суны шуннан алып кайтып эчәм. Сулары тәмле.

Шунысын пәрием сөйми: түшәмнәре өстендәгеләр шакы-шокы килеп йөреп торалар. Бер баруымда йокыга гына киткән идем, дөбер-шатыр килеп бии башладылар. Акырып улыйлар. Таң атканчы диярлек акыра-бакыра аракы эчтеләр. Баш өстеңдә урыс акырып торганда, намазың да дөрес булмый торгандыр. Тагын бер нәрсәсен үлеп яратмыйм. Аш пешерә торган бүлмәләренә янәшә әбрәкәйләре. Катифәдә торганда, мин җилгә күрше урамга йөрим. Гөнаһтыр ул аш пешеп торган җир янында тәрәт итеп утыру?

– Юкка башыңны ватма инде, – диде Габдрахман, әнисен юатып. – Хәзер инде Мәккә гарәпләре дә шундый йортларда яши. Дөрес, аларның туалеттан, ванна бүлмәсеннән тыш махсус тәһарәт ала торган бүлмәләре, намаз укырга көйләнгән аерым заллары да бар.

– Син аларны үз күзең белән күрдеңме, әллә гәзиттән укыпмы?

– Сөйләдем бит сиңа, мөселман өммәтеннән икәнлегемне ишеткәч, йөк төяүчеләрнең башлыклары мине гел кунакка чакыралар. Мисырда, Гыйракта, Шәм Шәрифтә, Алжирда, Сәгуд Гарәбстаныннан тыш тагын да бик күп гарәп илләрендә кунакта булганым бар.

Карчык, бертын сокланып, улына карап торды.

– Менә бит нинди зур бәхеткә ирешкәнсең. Шуның кадерен белеп кенә яшисе урынга, марҗага өйләнергә кыҗрап йөрисең.

– Зинһар, борчылма бу турыда. Синнән хәер-фатыйха алмыйча, гаилә кормаячакмын. Хафаланма, яме?

– Тәкъдиремә шулай язылгандыр инде, – карчык яулык чите белән битен каплап, эчен бушатып алды. – Әнә, абыеңның олы кызы, мәктәбен ташлап урыска ябышып чыкты. Малайлары начар укый, дип җиткереп торалар. Ата-аналар җыелышына барсам, сезнең турыда мактау сүзләре генә ишетеп кайта идем.

– Монда чакта сине Катифә апага илтеп урнаштырып китәсе иде. Шулай итәбезме?

– Ашыкмыйк әле. Кышка җитәрлек утын әмәлләдең. Ашарыма бар. Җаным тыныч. Оныта язганмын. Институтын бетергәч, Варис кем була?

– Чит дәүләттәге берәр илчелеккә җибәрергә тиешләр. Ул бит гарәп һәм инглиз телләрен өйрәнә. Димәк, мөселманнар арасында эшләп йөриячәк.

– Бу кайтуыңда мәктәпкә дә бармадың. Очраганда, укытучылар синең турында да, Варисның хәлен дә гел сораштырып торалар. Персидәтел дә кызыксына. Ул хәзер кем булып эшли соң, дип сорый. Аны чакырырга кирәк иде. Сөйләшеп утырыр идегез. Киткән чакта Бөгелмәгә барырга машина бирер иде.

– Чакырыр идем дә, хәзер бит андый кешеләр белән табынга аракысыз утырмыйлар. Аракы эчкән җирдә намаз укырга ярамый торгандыр ул?..

**8**

Кайнар кыстыбыйның ымсындыргыч исе. Чынаякларда – сыек гәрәбәне хәтерләткән «липтон» чәе. Татлы ризык, затлы табын, ә йөрәктә… Йөрәктә авыр бушлык.

– Тагын күрешергә язганмы икән инде?.. – Карчык, урыныннан торып, чаршау артына кереп китте. Улының башлы-күзле булырга теләве турында тагын да сүз кузгатырга ул курка иде. Озак еллар читтә йөрүенә карамастан, күкрәк сөте белән туклангандагы газизлеге кимемәгән улын янында тоту мөмкинлегенең дә юк икәнлеген аңлап, шушы фикер белән килешә алмаячак

ана, бераздан ялгызлык кочагы көткәнен тоеп, эчтән өзгәләнә иде. Зарлан, үксеп ела, башыңны ташка бәр…Тәкъдир барыбер аның газиз улын еракларга алып китәчәк тә, карчык кабат шыксыз ялгызлыкта торып калачак.

Бу мизгелдә Габдрахман да чит илләрдә үтәргә дучар ителгән рәхимсез язмышы турында уйлый иде. «Үсеп җиткәч, чит илләрдә үтә безнең язмышлар…» дип җырлый бит татарның балалары. Урыслар да чыгып китә туган җирләреннән. Алар да читтә йөри. Әмма алар илнең нинди генә почмагында булмасыннар, биредә үзләрен алай ук чит итеп тоймыйлар шикелле. Аларга Татарстан да, Кавказ да, башка ерак төбәкләр дә шул ук Рәсәй булып тоела, күрәсең.

Амин тоттылар.

– Мин сиңа юлда ашарга каклаган каз ите, чәкчәк, кипкән җиләк салдым. Кабат күрешергә язганмы икән инде…

Ашъяулыкка төргән юл ризыгын чемоданына көчкә сыйдырып, капкачын япкач, Габдрахман әнисе янына килеп басты:

– Хәерле юл телә, инәки.

– Лә иляһе иллаллаһы йә хәерле халас. Мөхәммәде салуллаһы йә Хозыр Ильяс!

Габдрахман чемоданын күтәреп урамга чыкканда, авыл йокыдан торып, иртәнге чәен эчә генә башлаган иде. Капкадан чыккач, ул әнисе Фәриха карчыкны кысып кочаклады. Карчыкның ябык, газиз тәне аның кочагында сулкылдый. Аерылышу мизгеле.

– Хат язып торырмын. Киләсе кайтуымны көтеп тор инде. Кышка таба, бәлки, апаның квартирына күчеп китәрсең?

– Юк инде...

Элекке көчен югалтып бетерә язган ябык тәне белән карчык улының күкрәгенә сырышты. Авыз эченнән генә юл догасын кабатлый иде.

Габдрахман бераз баргач, урам калкулыгыннан туган нигезенә борылып карады. Әнисе һаман капка төбендә басып тора. Ара ерагайган саен, күкрәк эчендәге әрнүле аерылу, югалту әчесе белән сугарылган бушлык куерып бәгырьне тырный. Уң якта бригада йортының таралып аварга торган такта коймасы. Моннан узгач, аның туган йорты күздән югалачак. Габдрахман кабат борылып карады. Әнисе һаман капка төбендә. Тагын да бөгелә төшкән, бәләкәйләнгән. Ул бит аны ялгызлык кочагына ыргытып, ташлап китте... Шушы булды аның әнисе биргән тәрбиягә җавабы...

Әнә, авылны аркылыга кисеп узган Богырыслан юлы. Таныш күпер. Суын югалтып бетерә язган инеш. Үртәмәй үренең уң ягында белем юлын күрсәткән газиз мәктәп, сул якта колхоз идарәсе, кибет, авыл клубы. Шалты белән Таулы арасында йөрүче автобус тукталышына җиткәч, ул туктады. Чемоданын җиргә куйды. Янына бала күтәргән яшь хатын белән ир кеше килеп басты.

– Во сколько приходит автобус?

Сорау бирүченең татар икәнлеге теленнән тыш аның кыяфәтенә, атлап йөрүенә дә язылган иде.

– Унбиш минуттан килеп җитәргә тиеш, – диде Рахманкулов татарча.

– Сез Габдрахман абый түгелме соң? – диде бала күтәргән хатын.

– Шулайрак шул.

– Рафис, безнең Габдрахман абыебыз бу. Әнием сезнең белән бер класста укыган. Хәлимә кызы мин, Раушана. Бусы – минем ирем Рафис.

Сабакташының кызы ирен этәребрәк аңа якынайтты:

– Күреш Габдрахман абый белән. Ул – моряк. Чит илләрне күреп йөри.

– Я тоже моряк, – диде Караяр кияве. – Служил на ракетоносце «Адмирале Кузнецове».

– Иregез урысмыни? – дип сорады Габдрахман Раушанадан.

– Юк, татар.

– Ә нигә соң урысча сөйләшә?

– Ул бит район үзәгендә туып үскән. Анда бит русча сөйләшәләр.

– Татарча бөтенләй белмисезмени? – диде Рахманкулов «Адмирал Кузнецов»та хезмәт иткән егеткә.

– Нигә белмәскә, беләм.

– Шулай булгач?..

– Татарча кем сөйләшә? Надан карчыклар. Мин НГДУда эшлим.

Автобус килеп туктады. Кереп утырдылар. Яшь буынның өлкән абзыкай теленә күчү сәбәбен сораштырмакчы иде, Хәлимәнең кызы белән кияве арткарак барып утырдылар.

Кайткан көнне син туган авылыңның куенына җиңел генә кереп бетә алмыйча, күңелең белән һаман читтә яшисең. Әкренләп туган-үскән йортың, газиз авылың сине кочагына ала. Инде кабатлана торып та һаман күнектермәс газабы кабат уянып хәрәкәткә килә.

Иң башта машина-тракторлар йөри башлагач, хәтфә чирәменнән мәхрүм калган кантарлы урам күздән югалды. Аның артыннан – изге зират. Зиратның изгелеге каршында большевиклар да, Сталин зобаниларының терсәктән канга баткан куллары, фашистларныкыннан да аяусызрак сәясәте дә көчсез булып чыкты. Караяр зираты – җиләкле яшел чирәм, моңсу канәфер куаклары баскан изге алан үз гомерендә бер генә носарины да кабул итмәде.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, иске автобус инде шәһәр статусы алган район үзәге Таулы автостанциясенә килеп, пассажирларны бушатты.

Кассада Бөгелмәгә баручыларга билет саталар. Алдан алып куйган билет инде Рахманкуловның кесәсендә иде.

Бөгелмә юлы. Монда аның яшьлек эзләре калды. Ул эзләр астында – ханлыкны урыс гаскәрләре канга батырганда, көньяк-көнчыгышка таба чигенгән татарлардан тамган кан эзләре, аннан да астарак – Аксак Тимер чирүләренә каршы Кандырча үзәненә ашыккан җайдаклар эзе. Тагын да астарак – халыкларның бөек күчеше чорында ат тоякларыннан кубып калган каты балчык кыйпылчыклары һәм кызыл балчык катламына якын борынгы төрки кабиләләрнең учак көлләре.

Көнкүреш Габдрахманның күзенә күренеп үзгәрә. Җиңеләя. Камилләшә. Тукта әле! Гасырлар буе Караяр халкы дошман күргән басып алучылар теленең соңгы буынга табигый булып яңгыравы тәрәккыятме соң?! Чиләбе – Мәскәү поезды вагонының өске ятагында Габдрахман шушы сораулар чытырманлыгында баш вата иде. Гореф-гадәтен югалтып, урыс телен культурный булуга санап кабул итүнең чукынып носарилыкка күчүдән дә куркынычрак икәнлеген аңлаудан ник баш тарта халык?

Туган туфрак кабат еракта калды, ул кабат зимагурлык һәм күңелне әрнетеп торган моңсу сагыну кочагында... Инде ничә еллар, ничәмә тапкырлар Караярны ташлап киткәннән соң, ул әрнеткеч бер күңел бушлыгы, эчке вакуум барлыкка килүен тоеп интегә иде. Бу хәл, һичшиксез, туган илдән аерылуга бәйле.

Ниһаять, ул күңеле белән инде Хач-Бәй дип аталган татар авылы утырган

җирдә үсеп чыккан диңгез порты Одессада иде. Габдрахманның Одессага бу китүе, бәлки, соңгысы булыр? Әгәр чит илләргә йөрүдән мәхрүм итеп, кабат каботажда эшләргә тәкъдим итсәләр, ул, йөзүне ташлап, Караярына кайтып китәчәк. Әйе, китәчәк. Китәчәк?..

## Җиденче бүлек

### 1

Пароходчылыкның кадрлар бүлеге иртәнге тугызда эшли башлый. Габдрахман килгәндә, инспекторның ишеге яныннан башланып киткән чират, коридорга сыя алмыйча, ишегалдына бүселеп чыккан иде. Чиратка баскач, ул үзеннән артта булачак диңгезченең килгәнен көтеп торды да эскәмиягә барып утырды.

Җәй башлангач, гадәттә, резерв юкка чыга. Мондый чакларда, үз корабыңның рейстан кайтканын көтеп торырга да ирек бирмичә, алмаш сорап инспекторларның теңкәләрен корыткан диңгезчеләргә алмашка җибәрергә тырышалар. Диңгезчеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлап утырганнан соң, моңа кадәр корал ташу белән шөгыльләнгән корабларның күбесенең эшсез калуы аңлашылды. Гадәттә, ташырга йөк таба алмаган корабны ремонтка куялар. Ремонт барганда, экипажның яртысын гына калдыралар, шунлыктан диңгезгә чыгарга атлыгып торучылар саны күзгә күренеп ишәйгән иде.

– Ялыгыз бетте дәмени инде, Рахманкулов? – Инспектор янәшә өстәлдәге тартмалардан Габдрахманның карточкасын эзли башлады.

– Әҗәткә бирелгән ял тиз бетә икән ул, – диде Рахманкулов.

– Көтеп торыгыз, – диде инспектор, аның эш карточкасын эзләп табып. – Сезнең мәсьәләне начальник хәл итәргә тиеш. Аңлый торгансыздыр?

Инспекторның күз карашында, сүзләрен элеккедән йомшаграк итеп әйтүендә аның җинаятенә караш уңай якка табарак үзгәрүе сизелә иде. Инспектор озак көттермәде.

– Начальник сезне каботажга йөрүче корабка билгеләргә куша. Өлкән штурман итеп. Озак тотмабыз, ди. «Күршеләр»дән рөхсәт килү белән, «Академик Крупчатов»ка кайтарырбыз, ди.

Каботажга бер килеп капсаң, котылу читтән тыш катлаулы икәнлеген белә иде ул. Эше авыр, эш хакы читтән тыш такыр, өстәвенә каботажда эшләгән кораблардагы тәртипсезлек һәм эчүчелек.

– Мин риза түгел, – диде Рахманкулов. – Мин көтәргә риза.

– Оныта язганмын. Капитан Зимин сезгә язу калдырган иде. – Инспектор эш карточкасына беркетелгән конвертны Габдрахманга сузды. – Ярый, мин сезне резервта калдырам. Шартларын беләсез.

Коридорга чыккач, Рахманкулов, конвертны ачып, язуны алды.

«Габдрахман Бәкерович, вакыт табып сугылып китегез әле. Унсигез сәгатьтән соң мин өйдә булам. Адресым: Пушкин урамы, 22, 15 кв., «Моряк» редакциясеннән өч кенә йорт аша. Килүеңне алдан белгертеп куй. Телефоныбыз: 22-64-05.

Ярый, күрешкәнгә кадәр. Зимин».

### 2

Одессаның һәркемгә мәгълүм урамы, билгеле, Дерибасовская. Совет чорында татар авылы Хач-Бәй урынына шәһәр салдырту белән җитәкчелек иткән һәм, диңгез порты үсеп чыкканнан соң, дистә елдан артык шәһәр башлыгы

вазифасын үтәгән Француз де Рибасның исемен өч тапкыр алыштырып караганнар. Халык яңа исемне кабул итмичә, элеккечә – Дерибас дип атап йөртүен дәвам иткәч, шәһәр башкарма комитеты одессалыларның үҗәтлегенә буйсынырга мәҗбүр булган. Инде бу урамда бүгенге көндә «Моряк» газетасы урнашкан йортта бөек урыс шагыйре яшәп киткәнлектән, аны Пушкин урамы дип атаганнар, һәм исем шушы көнгә кадәр сакланып калган.

Егерме икенче йортны эзләп тапканнан соң, Габдрахман, эчкә кермичә, урам ягыннан бина төзелешен җентекләп карап узды. Башта Хач-Бәй авылын, бу җирне урыс яулап алганнан соң, казып чыгарылган кабырчык-таш-ракушечниктан Одессаны төзегәннәр. Мондый төзелеш материалы кирпечтән ныграк, җиңел һәм җылыны да тота. Шуңа аңардан төзелгән торакның диварлары аша йорт эченә саф һава үтеп керә. Хәзерге бетоннан корылган өйләрнең бүлмәләре сулыш алалмый, шунлыктан андый йортларда халык тончыгып яши.

Челтәрле тимер ишектән Габдрахман ишегалдына керде. Борынгы римлеләр стилендә эшләнгән җыйнак патио[5] уртасында совет чорында туктатылган фонтан күренә, патша заманында утыртылган платан агачлары картаюдан инде корый башлаганнар. Габдрахман, авыр имән ишекне ачып, эчке якка узды. Киң мәрмәр баскыч өске катларга алып менә иде. Беренче катта дүрт ишек, дүрт дүртең – уналты, димәк, капитан Зимин дүртенче катта яши.

**3**

Ишекне кырыкларга җитеп килгән ябык гәүдәле хатын ачты.

– Исәнмесез! Сез Михаил Михайловичкамы? Узыгыз. – Габдрахман алып килгән чәчәк бәйләмен килешле итеп иснәгәннән соң, елмаюын киңәйтеп, өстәп куйды: – Мәшәкатьләнмәскә иде. Ялгышмасам, сез бит инде өченче ай резервта. Әйдә, узыгыз.

Шәһәр көнкүрешенә күнегә башлаган совет кешесе – совок буларак, Габдрахман күз сирпеп кенә фатирның зурлыгын һәм җиһазларын чамалаганнан соң, ирексездән уйлап алды. Иван Бунинның «Сны Чанга» исемле хикәясендәге капитан да нәкъ моңа охшашлы фатирда яшәгән булса кирәк. Очы-ахыры күренмәгән резервка юлыкканнан соң, Рахманкулов бөек Бунинның хикәясен инде өченче тапкыр хисләнеп укып чыккан иде.

Иркен алгы бүлмә. Сулга таба сузылган коридорның түрендәге пыяла ишектән савыт-саба шкафы, плитә күренеп тора. Каршыдагы ишектән кунак бүлмәсе – гостинаяга уздылар.

Ял вакытында тазарып китүе Зиминның кыяфәтенә чыккан иде.

– Салют, supercargo[6]!

– Исәнмесез, Михаил Михайлович!

– Туган җиреңә кайтып килгәнсең дип ишеткән идем. Туганнарың исән-саулармы? Кәефләр?..

– Рәхмәт, зарланырлык түгел.

– Диңгезнең чакыруына түзәрлекмени?

– Түзмичә нишлисең? Шулай килеп чыкты бит. Бәлки, диңгез белән бөтенләйгә саубуллашырга кирәктер? Мин инде кайчак шулай да уйлый башладым.

– Кыбырсымаска кирәк. Пароходчылык начальнигы янына керергә иде.

---

[5] Патио *(исп.)* – ачык эчке ишегалды.
[6] Supercargo – зур пароходчылык компанияләрдәге йөк һәм фрахт мәсьәләләре белән шөгыльләнүче диңгезче.

Син бит армиядә офицер булып хезмәт иттем, дип сөйләгән идең. Андыйларга фатирны чиратсыз бирергә тиешләр. Флоттан киткәнче алып калырга кирәк түгелме икән. Начальник янына керергә тырыш әле. Сөйләшкәндә, бу мәсьәләне дә кузгат.

– Кабул итәрме икән соң? Аның кабинеты каршында һәрвакыт мәшхәр бит.

– Алдан языл. Ул чәршәмбедә депутат буларак кабул итә. «Академик Крупчатов»тан икәнлегеңне әйтергә онытма. Сине чиратсыз да кабул итүе мөмкин.

– Куба рейсыннан соң без бик авыр хәлгә эләктек. Сугыш вакытында безнең ишеләрне суд та ясап тормыйча атып үтергән булырлар иде.

– Пароходчылык начальнигы безнең җинаятьне башкачарак бәяли. Очрашып сөйләшкәннән соң аңларсың. Әйтергә онытa язганмын. Американтюсларның эсминецлары безне кысрыклаганда булган хәл турында сөйли күрмә тагын. Стукачлар безнең һәр адымыбызны аларга җиткереп тора. Алар сер сакларга сүз биргән расписка белән тынычланмадылар.

Кунак бүлмәсенә, бер яшь кызны ияртеп, капитанның хатыны килеп керде:

– Таныш булыгыз, бертуган сеңлем, филологиня. Бездә аспирантурада укый.

Капитанның хатыны Елизавета Матвеевнаның университетта филфак кафедрасының мөдире икәнлеген Рахманкулов белә иде. Шуңа күрә капитанның балдызы да филология фәнен сайлавы аңа табигый тоелды.

– Нора, – диде кыз, кулын Рахманкуловка сузып.

– Габдрахман.

Әлеге исемне ишеткәч каушамый калган кызны аның беренче тапкыр очратуы иде. Гадәттә, «Чужак! – дип уйлый Явыз Иван токымы. – Бу бәндә каян килеп эләккән?»

– Күрдеңме Элеонораның сиңа ничек сокланып каравын?

Кыз капыл гына борылды да апасы янына кухняга кереп китте.

– Оялды, – диде капитан. – Аны безгә чакыруымның сәбәбе дә бит синең конкурста җиңеп чыгуыңа бәйле.

– Нинди конкурста? Диңгезгә чыга алмыйча, өч ай ярда аунап ятудамы?

– Кылануыңмы бу? Әллә туган ягыңда йөреп, «Моряк» газетасының соңгы номерын күрми калдыңмы?

– Анда безнең экипажның «Александр Матросов» геройлыгын кабатлаудан баш тартканын язмаганнардыр бит?

Сүзне Елизавета Матвеевна бүлде:

– Сез әтиебезнең бүлмәсендә сөйләшә торыгыз. Без монда Нора белән өстәл әзерләп алырбыз.

**4**

Габдрахманны кунак бүлмәсендәге палисандр агачыннан эшләнгән затлы буфет, арыслан-киек аякларына куелган өстәл, кием шкафлары һәм стенадагы данлыклы рәссамнар иҗат иткән кыйммәтле полотнолар хәйран калдырган булса, капитанның хосусый кабинетындагы китап шкафлары, затлы кызыл агачтан, борынгы җиздән эшләнгән барометр, шкаф өстендәге җилкәнле кораблар, каршы якның стенасына терәп идәнгә утыртылган кеше биеклеге сәгать бөтенләй телсез калдырды. Алар уң як стенага терәлгән, затлы күн белән тышланган кәнәфигә чумып утырдылар.

– Син чыннан да «Моряк» газетасын күрмәдеңмени?

– Нәрсә бар соң анда?

– Анда Константин Паустовскийның җитмеш яшьлек юбилее уңаеннан игълан ителгән конкурсның нәтиҗәсен бастырганнар.

Конкурска үзенең хикәя язып җибәрүе келт итеп Габдрахманның исенә килеп төште.

– Анда мине дә искә алганнармыни?

– Анда син җиңеп чыккансың. Беренче урынны сиңа биргәннәр.

– Кызыклы яңалык...

Шатланырга, ярсып горурланырга тиеш иде кебек ул. Аңа, сыңар бүлмәле авыл йортында сәкедә аунап, абыйсы җилкәсеннән төшкән тузган бишмәт, иске чабата киеп үскән татар малаена, Европа илләренең зыялыларыныкына охшашлы, стенасында интеллигентлык тамгасы эленеп торган кабинетта рус әдипләре ярышында җиңүче икәнлеген белдерделәр. Нигә шатлык аша ачыну, үч тәме килеп торган кимсенү тойгысы эчне әрнетә? Нигә? Моның сәбәбе нәрсәдә икән?..

Әйе, иң еракта тарих катламы астында калып сытылган, имгәнеп беткән әрнеткеч ачы сәбәбе – 1552 елның 15 октябрь вакыйгасы. Шуңа өстәп, тарих фәне дәресләрендәге, утка кыздырып маңгаеңа баскан тимер тамгадай искиткеч «татар-монгол золымы» турындагы шовинистлар яласы…

Җиңү вакытында җиңелүләрен искә алмаган татарда, һичшиксез, манкортлык сыйфаты посып ята. Менә әле дә «җиңү» сүзен ишетү белән, Габдрахманның исенә армия хезмәтенең сугыш чорына туры килгән башлангыч еллары, урысча сөйләшә белмәгәнлектән күргән мәсхәрәләр, «чурка», «йолдаш» кушаматлары төшеп, аның күкрәк эчен айкап-ачыттырып узды.

Конкурста җиңү турында, бәлки, өстәл янында да сөйләшү булыр, аулакта капитаннан сорап өлгерергә кирәк иде.

– Сезне дә йөзәргә җибәрмиләрме?

– Билгеле, мине беренче чиратта.

– Резервка утырдыгызмы?

– Юк. Мин ике ел ялсыз эшләдем... Әле һаман ялда.

– Ялыгыз беткәч?

– Пароходчылык начальнигы белән сөйләшкән идем. Ул көтәргә куша инде. Пароходчылыкка эшкә алырга да әзер. Ә мин мореходкага күчәм. Анда Навигация белән Мореходная астрономия курсын алып барачакмын. Пароходчылык начальнигы Евгений Алексеевич Данченко безнең язмышны Украинаның Үзәк Комитеты аша хәл итәргә вәгъдә бирде.

– Көче җитәрме икән?

– Нигә җитмәсен? Хәзер бит Берия заманындагы КГБ бетте. Алар хәзер партиягә буйсына.

– Сез миңа Данченкога керергә кирәк, дисезме?

– Файдаланып калырга кирәк. Квартира сора. Отставкадагы офицерларга льгота бар бит. Бирергә тиешләр.

– Ә мин, дурак, куркып йөрим. Без бит, югыйсә, Александр Матросовның геройлыгын кабатларга тиеш идек. КГБ вәкиле миңа шулай аңлатты. «Син куркаклыктан Ватан каршында зур җинаять эшләгәнсең. Сугыш вакытында сине, судсыз, карарсыз, стенага бастырган булырлар иде», – диде.

Капитан Зимин рәхәтләнеп көлде:

– Шәрә күкрәк белән амбразура каплау япон камикадзелары үрнәге бит ул. Япон самурайлары бу ысулны башка бернинди юл белән җиңеп булмаган очракта, чиктән тыш сирәк кулланганнар. Үзен корбан итәр алдыннан

камикадзега бер атна нәрсә теләсә шуны эшләргә, иң матур, иң данлыклы гейшалар белән кунарга рөхсәт иткәннәр. Шуңа өстәп, үзен корбан иткәннән соң, ул изгеләр исемлегендә йөри башлаган.

– Табын әзер, – диде капитанның хатыны, ишекне ачып, – көтәбез.

Зимин аңа ванна бүлмәсен күрсәтте. Идәне, стеналары зәңгәрсу чынаяк плиткә белән тышланган иркен бүлмәдә ике-өч кеше сыярлык киң ванна, кул юу урыны. Краннары көмеш катнаш борынгы җиздән эшләнгән.

**5**

– Рәхим итегез, – диде капитанша, сеңлесе яныннан урын күрсәтеп. – Без Нора белән ул хикәянең сюжетын ничек табуыгыз, аны күпме вакыт эшләвегез турында сөйләрсез дип көткән идек! Алар кабинетка бикләнделәр дә һаман шул диңгез турында, кораб йөртү, мариманлык турында сүз куерталар! Сез «Моряк» газетасының соңгы номерын укымадыгызмыни?

– Аны инде күптән күргәнем юк.

– Анда Константин Паустовскийның 70 еллык юбилеена багышланган конкурста җиңеп чыгучылар турында язганнар, – дип кабатлады капитан Зимин.

Габдрахман газетага чынлап та хикәя язып җибәргән иде. Элегрәк тә «Моряк» газетасында мәкаләләр бастырганы бар иде. Бу юлы Рахманкулов хикәясен бәхәсләшеп язды. Ул заманында «Чолман» пароходында бергә эшләгән, хәзер инде бер зур, яңа корабның капитаны Виктор Смирнов каршында ресторанда кызмача баштан шапырынып алды.

– Менә, – диде ул, – «Моряк» газетасы Паустовскийның җитмеш еллык юбилеена конкурс игълан иткән. Теләсәм, мин дә катнаша алам. Хәтта җиңеп тә чыга алам...

– Мин синең Остап Бендер икәнлегеңне белми идем. Одесса үзенең талантлы язучылары белән данлыклы. Син шуларны җиңмәкче буласыңмыни? Җиңәрмен дип өметләнмә. Хикәяңне бассалар, миннән бер шешә «Митакса-Атлас» коньягы.

– Хикәяңә үзгәрешләрне күп керткәннәрме? – диде Елизавета Матвеевна.

– Мин бит әле аны күрмәдем, – Габдрахман дулкынлана башлады.

– Без бит «Моряк» алып торабыз, – диде Зимин. – Лиза, табып бир әле суперкаргога.

– Мин ул номерны Маринага биреп җибәрдем.

– Марина – минем балдызым, – диде капитан. – Ул да шигырь яза. Әдәбиятның чын фанатигы. Сезне таныштырырга кирәк.

Рахманкулов саубуллаша башлады.

– Ашыкма әле, – диде капитан. – Марина күрше йортта гына яши. Чакырсак, ярты сәгатьтә килеп җитәчәк.

Егетнең конкурста җиңеп чыккан хикәяне тизрәк укыйсы килә иде.

Озатырга чыккач, капитанның хатыны күңелгә бал да май булып кереп сыланырлык фикер әйтте:

– Без хикәягезне филфак кафедрасында анализладык. Өлкә язучылары берлегенең җитәкчесе Иван Гайдаенко кукрәгенә сугышта снаряд кыйпылчыгы кереп утырган матрос-рулевой турында хикәя язган. Имеш, ул рульгә басуга, компас угы корабның курсын ялгыш күрсәтә башлый. Ышандырмый! Григорий Поженян шигырь белән катнашкан. Конкурс бит кыска хикәя белән катнашуны сорый. Безгә яшь студент Михаил Жванецкийның хикәясе ошады. Ул егет

язганнарны Аркадий Райкин сәхнәдән укый, дип сөйлиләр. Конкурска биргән хикәясендә диңгез сурәте юк диярлек, диңгезчеләр тормышы турында бер сүз юк. Сезгә беренче урынны биреп дөрес эшләгәннәр.

– Язучы булдым, дип, диңгезне ташлап китә күрмә тагын. Әнә, Джозеф Конрад иң уңышлы әсәрләремне диңгезчелектә эшләгәндә генә яза алдым, дип әйтеп калдырган.

Саубуллашканнан соң, Зимин пароходчылык начальнигы янына керергә кирәклекне кабат Габдрахманның исенә төшерде.

**6**

Ишеккә алтын хәрефләр белән «Кара диңгез пароходчылыгы начальнигы Данченко Евгений Алексеевич» дип язылган элмә такта беркетелгән. Ишектән керүгә, сул якта секретарь хатын утыра. Таза, матур. Кабул итү бүлмәсе халык белән шыгрым тулы. Күбесе – диңгезчеләр. Аларда Габдрахманга таныш капитаннар да бар. Әнә, Кубага ракета ташуны башлап җибәрүче Социалистик Хезмәт Герое Ким Голубенко да тыныч кына чират көтә.

– Мин Рахманкулов, – диде Габдрахман секретарьга. Хатын өстәлдәге исемлеккә күз сирпеп алды.

– Көтегез, – диде ул, дивар буендагы диваннан буш урын күрсәтеп.

Ишектән Данченконың урынбасары Пахолок чыкты. Габдрахман пароходчылыкта эшли башлаган елны Юрий Петрович «Чолман» пароходының капитаны иде. Ул, Рахманкуловны танычач, гадәти елмаю белән генә чикләнмәде.

– Эшләр барамы? – дип килеп тә күреште.

– Бара, Юрий Петрович. «Академик Крупчатов»та икенче штурман.

– Уңыш телим.

Аңа рәхәт булып китте. Пароходчылык хуҗасының уң кулы Куба рейсындагы фаҗигане белми калмагандыр. Нинди җылы исәнләште. Габдрахманның эченә дә җылы кереп китте.

– Ким Германович, – диде секретарь хатын. Кубага ракета ташуны башлап җибәрүче капитан Голубенко кабинетка кереп китте.

Совет чынбарлыгы Габдрахманны көтү түземенә өйрәтте. Ул вакытта язмыш түрәләр кулында. Алар хәл итә синең киләчәгеңне.

Сәркатип хатын, ниһаять, Рахманкуловның исемен атады:

– Аның вакыты тар. Сорау биреп башын катырмагыз, – дип, алдан кисәтте ул. – Әйткәнен дикъкать белән тыңлагыз.

***

Рахманкулов газета битләрендәге сурәте конференцияләр вакытында югарыда, президиум өстәле артында утырганда гына күренгән шәхес тарафына таба атлап бара. Ара һаман якыная. Каршына ук килеп җиткәч, кабинет хуҗасы өстәл каршына куелган ике кәнәфинең берсеннән урын күрсәтте:

– Рәхим итегез. – Хуҗа, урыныннан торып, кулын бирде.

Көтелмәгән хәл иде бу. Моңа кадәр аңа Ватанына хыянәт итүче шикеллерәк карыйлар иде. «Бу зур, абруйлы түрә миңа уңай мөнәсәбәттә икән», дигән фикер рәхәт итеп егетнең эчен җылытып алды.

– Сезне каботажга[7] күчерделәрме?

– Юк. Әлегә мин резервта.

[7] Каботаж – эчке (бер ил портлары арасындагы) флот.

– Каботажга күчерсәләр, сезне өлкән штурман итәргә дә була. Боерыгым шундый. Минемчә, анда сезне озак тотарга тиеш түгелләр.

– Каботажга бер килеп капсаң, аннан загранкага чыгу чиктән тыш катлаулы шул.

– Анысы да дөрес. Валюта тәмен татып караган кеше анда эшләргә бик атлыгып тормый. Миңа дөресен, бары тик дөресен генә әйтегез. Үзегездән ишетәсем килә: кингстонны ачмавыгыз чыннан да куркуданмы? Оялырга ярамый. Дөньяга без яшәр өчен киләбез. Бу очракта курку – табигый.

– Дөрес, куркуы да бар иде инде. Әмма эш анда түгел. Сәбәбе – моторист Ясиненко, сулагай булу сәбәпле, кингстонның тоткасын ябылу ягына борган. Белмим, каушаудан булуы да ихтимал. Әгәр корабны батыруга каршы булсам, мин аны лом алырга йөгертми идем.

Начальник бертын егетнең күзенә туры карап торды. Габдрахман кинәт кенә тоеп алды: начальникның күз карашында янау һәм нәфрәт тойгылары сизелми иде. Киресенчә, Данченконың күз карашыннан: «Син, егет, хакы йөз алтмыш миллион торган корабны, хезмәт ияләренең салым акчасына ясалган ракеталарны, кырык ике кешедән торган теплоход командасын, йөздән артык хәрбиләрнең башын коткарып дөрес эшләгәнсең», дигән хуплау билгесе чагыла иде. Габдрахманның исенә капитан Зиминның фатир сора дигән киңәше килеп төште.

– Евгений Алексеевич, – диде ул, кыюсызлыгын көчкә җиңеп. – Мин сездән квартира мәсьәләсен хәл итүегезне үтенеп сорар идем. Җитмеш өч яшьлек әнием авылда ялгызы яши. Йөргән кызым белән күптән килешенгән. Торакка мохтаҗ мин.

Данченко түшәмгә карап уйлап торды:

– Күпбалалы гаиләләрнең үтенечләрен хәл иткән юк бит әле. Аннан соң, сез бит әле квартира алырга чиратта да тормыйсыздыр?

– Инде бишенче ел чиратта. Өстәвенә отставкага чыккан офицерлар исемлегендә. Безгә торакны чиратсыз бирергә дигән карар бар.

Данченко кабат уйлап торды да телефон трубкасын күтәрде:

– Моисей Зиновьевич, нинди яңалыклар бар диңгезчеләрне тораклы итү өлкәсендә? – Телефон трубкасын җилкәсе белән сулъяк колагына кысып, начальник өстәлдәге кәгазьләрне күз йөгертеп карый башлады. – Аркадиядәге объектны яңа елга кадәр, кровь из носу, тапшырырга кирәк. Сантехника? Нигә элегрәк белгертмәдең? Безнең корабларыбыз бит сантехника өелеп яткан портларга кереп йөри. Инде күптән кайтарткан булыр идек. Хәзер мине дикъкать белән тыңла. Миндә пароходчылыкның киләчәген хәл итәчәк кадр утыра. Син аның квартира мәсьәләсен оештырырга тиешсең! Аңладыңмы? Юк, дисең инде. Нишләп юк? Ә резерв? Минем загажник? Бетте? Кемнәргә өләштегез аларны? Май аена кадәр. Юк, син хәзер үк оештыр. Рөхсәтсез таратып бетердең инде. Шулаймы? Феодосия? Алар төзеп бетерәләрмени инде? Димәк, безнең өлеш тә өлгерә? Ничә квартира? Биш? Без унга сөйләшкән идек түгелме? – Данченко телефон трубкасын учы белән каплады. – Феодосиядә яшәргә ризамы?

Габдрахман югалып калды. Кабул итүгә язылганда да, әлеге сөйләшү вакытында да ул фатир ала алырмын дип өметләнмәгән иде.

– Риза, – диде ул, үзен кулга алып. – Алар бирерләрме соң?

– Нигә бирмәсеннәр? Йорт пароходчылык акчасына салына. Тик шунысы бар: квартиралар әлегә төзелеп бетмәгән. Якынча тагын дүрт-биш ай үтәр

төсле. Әлегә каботажда йөреп торсаң – бу вакытның үтүен сизми дә калырсың. Дөрес, Феодосиядә – пароходчылыктан читтә яшәү бераз уңайсызрак, Одессага күчәсем килә, дип килсәгез, кабул да итмәячәкмен.

Рәхмәт әйтәсе, бу илдә чиктән тыш сирәк, әз очрый торган шатлыгын белгертәсе килгән иде Рахманкуловның, әмма аның алдагы бәхетенә аерым бер шартлар куелып, ул каршылыклы тойгылар эченә ташлануын аңлап, бертын сүзсез калып уйланып торды, ә киләсе мизгелдә инде начальнигының дикъкате башкада, ишектән кереп өстәл янына якынлаша башлаган кешедә иде.

## 7

Әлеге яңа яхшы корабка эләгә алуына Габдрахман һаман да ышанып бетә алмый иде. Мондый корабта, гадәттә, җитәкче балалары гына эшли. Эшли дигәч тә, алар артык бил бөгәргә, имгәткеч авыр диңгезчелек вазифасын башкарырга бик атлыгып тормыйлар. Шуңа күрә ул корабларга Рахманкулов шикелле крәстиян балаларының да билгеләнүе гаҗәп түгелдер...

Габдрахман тормыш-көнкүреше белән күптән инде крәстиянлыктан китсә дә, яшәү принциплары, үзенең яшәү асылы белән гомергә, күрәсең, шушы сыйныф вәкиле булып калуын дәвам итәчәк. Хәер, бу корабка килеп эләгү сәбәбенең дә, ахыр чиктә, бер ягы белән нәкъ шушы хакыйкатькә бәйле булып чыгуы шуны раслый түгелме?!

Гадәттә, төнге вахтага тәҗрибәле, чыдам матросны куялар. Габдрахманга беренче тапкыр диңгезгә чыккан тәҗрибәсез, карап торышка томана һәм культурадан шактый ерак күренгән Петро Семёнович Перебейнос атлы матросны беркеттеләр. Өлкән штурманга ризасызлык белгерткәч, ул: «Капитан кушты, мин аның боерыгын үзгәртә алмадым», – диде. Һәм шул ук көнне капитан Рахманкуловны чакырып, эшнең асылын болай аңлатты: «Перебейносның тәҗрибәсе юк. Беләм, аның белән эшләве сиңа җиңел булмас, синең вахтаңа куюның сәбәбе – ул кадрлар бүлеге начальнигы Ткаченко апасының малае. Син инде түзәргә тырыш. Оста тәрбияче икәнлегеңне пароходчылыкта да беләләр икән. Әгәр егетне чын матрос итеп өйрәтә алсаң, Ткаченко янына аның якын кешесе булып кереп йөри алырсың. Син инде аның туганы безнең начальник булганга, йомшаклык та күрсәтмә, шул ук вакытта аңа карата игътибарыңны да киметмә. Начальникларның туган-тумачасы белән эш итү ифрат авыр. Корабтагы һәрнәрсәне алар начальствога җиткереп тора. Ткаченко үтенеп сорагач, мин берни эшли алмадым, алырга туры килде. Берәр белемле, егетнең культурасын күтәрә алырлык штурманның вахтасына куйсагыз иде, дигәч, кадрлар начальнигының кинаясен аңладым. Сезнең кесәгездә университет дипломы булганын да, «Моряк» газетасы оештырган конкурста җиңеп чыгуыгызны да начальниклар яхшы белә. Бөтен пароходчылык бер юрган астында йоклаган шикелле бит».

Шулай итеп, үзе өчен күктән төшкән бәхетнең кечкенә генә сере дә ачылып киткәндәй булды. Имәндә икән чикләвек дигәндәй, Габдрахман ни өчен үзен, һич көтмәгәндә, инспекторның резервтан чакырып алуын да, ашыгыч рәвештә «Сергей Саблин» корабына утыртып, чираттагы рейска чыгаруларын да берникадәр төшенгәндәй булды. Ахырын хәерле итсен!

Ә инде «Сергей Саблин»га килгәндә, кораб, чыннан да, мактарлык һәм горурланырлык иде. Нишләмәк кирәк, французларда кораб ясау тәҗрибәсе гасырлар буе камилләшкән. «Сергей Саблин» күз сирпеп карау белән Габдрахманның күңелен үзенә җәлеп итте. Диңгез өстен җиңел генә ертып

барырга көйләнгән сөзәк форштевень[8], «Крейсерская» дип аталган җыйнак койрык һәм техниканың соңгы казанышы икәнлеген раслап торучы торба. Төтен палубага төшмәсен өчен, аның арткы ягына беркетелгән уелма. Зур ракеталарны да күтәрә алырлык мачталарга тоташ юан йөк төяү угы, көчле чыгырлар, иркен палуба.

«Сергей Саблин»га охшашлы уналты кораб төзелергә тиеш була. Корабның механизмнары корал ташырга көйләнгән икәнен аңлауга, французлар, бишне тапшырганнан соң, контрактны бозып, төзү эшен туктаталар. Франциядән кайтаргач, хәрбиләр җитәкчелегендә корабка сугышта кулланыла торган механизмнар: койрыкка, бакка һәм өске палубага зенитка урнаштырырга дип куелган нигезләр, солдатлар тончыгып үлмәсен өчен, твиндекка өстәмә вентиляторлар, төп палубага урнашкан спортзалны бозып, уникешәр юынгыч куйгач, кораб баштагы күркәмлеген шактый гына югалтып өлгерә, билгеле. Шуңа карамастан, диңгезчеләр чит илләрдә төзелгән мондый корабларда эшләргә атлыгып тора. Яшәр өчен комфортлы каюта, сауна һәм бассейн, һава сулап йөрергә уңайлы итеп эшләнгән иркен палубалар, Көнбатыш илләрендә һәм Японияда яуланган тәрәккыят траптан күтәрелеп, кораб эченә керүгә күзгә ташлана иде. «Чолман» пароходындагы кысан, тропикларда йөзгәндә тончыгып үләрлек каюта белән чагыштырганда, «Сергей Саблин»дагы икенче штурман каютасында җәннәт шартлары иде.

Тик яшәү шартлары никадәр уңайлы булса да, монда «Чолман»дагы озак еллар бергә эшләп якынайган, туганыңа тиң газиз дуслар юк иде.

**8**

Төнге уникедә башланган вахтага чыгар алдыннан, ике-өч сәгать йоклап ял итеп алсаң, вахта җиңелрәк үтә. «Сергей Саблин»дагы икенче штурман каютасы нәкъ ашханә өстенә урнашкан. Кичке аштан соң һәр совет корабында ашханә бүлмәсендә экипаж кино карый. Һәр кичне, фильмның нинди генә булуына карамастан... Гадәткә әверелгәч, әйбәт фильммы, әллә чын халтурамы, эчтәлеге кызыклымы-түгелме, артистларның уйнавы табигыйме-ясалмамы, режиссёр эшенең сәнгатьлелеге ничек – барыбер. Кичке аштан соң киноаппарат, шыпырдаган тавыш чыгарып, стенага асып куйган ак экранда фильмның геройлары кыймылдап йөри башлау белән, экипаж әгъзалары ашханә бүлмәсенә кереп тула. Һәркемнең үз урыны. Кеше урынына утырырга ярамый, чөнки кино карауның тәме үз урыныңа урнашуга, җае чыкканда, экрандагы геройларның сөйләшүенә катнашып, берәр мәзәк сүз кыстыруга, тамашачыларга ошаган урынны кабат күрсәтүгә бәйле. Һәр корабта иң кызыклы, күңелгә хуш килгән кисәкләрне кисеп алып, шуларны бергә ябыштырып ясаган тамаша ярдәмендә сагынуны басар өчен кулланыла торган винегрет фильм була.

Пароходчылык начальнигының «Кинолентаны кисәргә ярамый, бу эш зур җинаять санала» дигән приказы да бар югыйсә... Әмма Россиядә законны үтәүгә караганда, аны бозу лаеклырак эш санала. Корабта күрсәтелгән киноны карауның максаты да тулысынча диярлек үзгә. «Летят журавли», «Всё остаётся людям», «Девять дней одного года», «Проверка на дорогах» фильмнарыкинофестивальләрдә иң лаеклы призлар яулый алсалар да, диңгезчеләр андый фильмнарны, бер тиенгә дә куймыйча, карарга яраксыз дип саный. Диңгезче халкына «Полосатый рейс», «Пёс Барбос», «Операция

[8] Форштевень *(гол.)* – кораб борынындагы киль белән астан тоташ брус.

«Ы» – чын-чынлап шедеврлар. Алар шундый фильмнарның чиктән тыш аз булуына зарланалар иде.

Ял итәргә яткач, Габдрахманның каютасында кино экранындагы геройларның тавышы йокларга мөмкинлек бирмәде, шуңа күрә Босфорга кергәндә, ул тәмам арыган, ватылган иде.

**9**

Габдрахман ял иткән арада пароходчылыктан радиограмма килеп төшкән икән.

Йөк хуҗасы Одессада төягән прокатны Гонконг портына илтеп бушатырга боерык биргән. Көньяк-көнчыгыш илләренең портларына күбрәк Владивостоктагы Ерак Көнчыгыш пароходчылыгының кораблары йөри иде. Габдрахман йокыдан торганда, экипаж әгъзалары оялары җимерелгән кырмыскаларны хәтерләтә иде. Утыз сигез диңгезче арасында Гонконгны күргән өч-дүрт экипаж әгъзасы булдымы икән?.. Пароходчылыкта эшләргә ялланып кына йөргән диңгезче дә Сингапур турында әйбәт белә. Җир шарында, мөгаен, Сингапурдан да арзанлырак диңгез порты юктыр. Монда пошлинасыз сәүдә. Ирекле порт. Әгәр бәхетең басып совет диңгезчесенең корабы Сингапурга керсә, әҗәл даруыдай мыскаллап түләнгән кысыр валютасына ул комиссион кибеткә тапшырырлык бер күтәрәм товар сатып ала. Сингапурга кереп йөри торган корабка эләгү – совет диңгезчесе өчен бәхетләрнең иң зурысыдыр, шәт? Гонконг та – пошлинасыз сәүдә итә торган ирекле порт. Анда да, Сингапурдагы шикелле, Советлар Союзында дефицит товарлар тулып ята торгандыр? «Сергей Саблин» экипажы бүген үзенең алда торган олы бәхетенә генераль репетициясен кичерә иде. Диңгезчеләр үзара гел елмаеп сөйләшәләр. Җор сүз, көлке фонтан булып бәреп чыгып тора.

Капитан Бородуля пароходчылыкта данлыклы капитаннарның берсе иде. Аның белән эшләү Рахманкуловка тәҗрибә дә, кораб йөртү нечкәлекләрен дә өстәячәк, билгеле. Аннан соң капитан белән икенче штурманны үзара якынайта торган уртак язмыш-тәҗрибәләре дә бар иде. Анатолий Александрович сугыш вакытында истребительдә очкан. Рахманкуловның да унбер елы авиациядә узды. Аулакта очрашканда, алар гел шуны сагынып искә алалар иде. Эшли башлаган көннән үк капитан Габдрахманны якын итүен сиздерде. Димәк, бу корабта эшләү аңа күңелсез булмаячак.

**10**

Рахманкуловның өстәмә вазифасына әверелгән педагогик эшчәнлеге дә вахтадан вахтага, көннән көнгә дәвам итте.

Тәҗрибәле матрос ике беләген дә штурвалга куя да, тыныч кына гирокомпасның репитерына карап, корабның курстан тайпыла башлавын көтеп тора. Кораб, гадәттә, агым, җил тәэсиреннән, тыныч диңгездә винт әйләнүенең каршы ягына таба тайпыла. Тәҗрибәле рулевой корабның кайсы якка һәм күпмегә тайпыласын алдан сизгәнлектән, шул беләкләре белән штурвалга таянган җиреннән әз генә кыймылдаган шикелле итеп ала да теплоходның линейка белән сызгандай туры эз калдырып баруына ирешә. Бу турыда Габдрахман Перебейноска әйбәтләп аңлатты, теплоходны ничек курста тотарга кирәклекне үзе штурвалга басып күрсәтте. Белү генә җитми иде шул диңгезгә беренче тапкыр чыккан тәҗрибәсез матроска. Ике-өч айдан егет корабны курста тоту серен дә, трюм идәне астындагы пьялога җыелган суны

үлчәргә ясалган, балласт, эчә торган су, корабны тигезләү өчен кулланылган танкларның палубадагы бөкеләрен дә бер-берсеннән аерырга өйрәнер. Әмма сәләтсез бәндәне никадәр өйрәтмә, нинди генә таләпләр куеп карама, барыбер андый кешедән оста диңгезче ясап булмый. Юк, диңгезчелек эшендә генә түгел, һәр һөнәрдә шулай. Аллаһы Тәгалә нигәдер адәм балаларының барысына да сәләтне, бигрәк тә талантны тигез өләшмәгән. Җәмгыять вәкилләренең төрле холыклы, акыл, сәләт, талант ягыннан төрле дәрәҗәдә булуы – бәлки, яшәешкә шул кулай шарттыр.

Кораб Эгей, төрекләрнең Ак диңгезләрендә йөзә иде. Бу диңгезләр кайчандыр төркиләр кулында булган. Әнә Мисырда мәмлүк дип аталган кыпчаклар идарә иткән, Аппенин ярыматавында, латиннар яулап алганчыга кадәр, төрки телле этрусклар яшәгән. Этрусклар культурасының югарылыгы әле дә булса тәкәббер европалыларны хәйран калдыра. Төркиләр «төньяк»ны «кара» дип, «көньяк»ны «ак» дип атап йөрткәннәр. Төрки телләрдә символика тәэсире гаять көчле. Әгәр татарлар туган телләрен бөтенләйгә югалтып, урысчага күчсәләр, бу югалту искиткеч зур һәм татар милләте өчен фаҗигале булачак.

Диңгездә барганда, төн аеруча тылсымлы, сүзләр ярдәмендә генә аңлатып булмаслык тирән серләргә төрелгәндәй тоела.

Корабның «тәнен», вакыт агымын хәтерләткән тавыш чыгарып, диңгез ялап узып тора. Күктә – йолдызлар яңгыры. Алар җемелдиләр. Диңгез өстенә нур коеп дерелдәүләре адәм баласына: синең көннәрең санаулы, җирдә изге гамәл калдырырга ашык, вакыт, агымсудай ашыгып, синең дөнья белән саубуллашу көнеңә таба йөгерә, бу турыда онытма, мәгънәсен аңларга, күктәге йолдызлар кебек, дөньяда якты эз калдырып китәргә тырыш, дип әйтергә тели шикелле.

## 11

Рахманкулов коридорда барган җиреннән кинәт тукталып калды. Ябык ишек, переборкалар аша капитан Бородуляның каютасында магнитофон уйнаганы ишетелә иде. Нинди көйләр, нинди җырлар гына уйнатмыйлар Япониядә, Сингапурда яисә Кувейт портында магнитофон сатып алу бәхетенә ирешкән диңгезчеләр. Яңа хуҗалар, үзләренең чит илләргә йөрүен раслапмы, әллә борынгы халык җыр-көйләрен искергәнгә санапмы, үзләрен алдынгы карашлы, бүгенге көн шәхесе итеп күрсәтү өченме, күбрәк ят көйләрне, популяр ансамбль башкарган җырларны уйнаталар иде. Совет корабларында менә ике еллап инде коридорларда каюта ишеге аша бәреп чыккан, «Бони-М» башкарган җырлар яңгырап тора. Шул җырлар арасында иң еш ишетелгәне «Чыңгыз хан», «Распутин» иде. Инглизчә белүчеләр арасында ул җырларның эчтәлеген аңлаучылар да, көйнең җыйнаклыгын, башкаруның югары сыйфатлы икәнлеген тоючылыр да, бәлки, булгандыр. Тик күпчелек диңгезче җырның эчтәлеген белми генә, сүзнең нәрсә турында барганлыгын төшенмичә, хәтта төшенергә дә тырышмыйча тыңлый иде. Советлар Союзында чит ил товарлары, шулар арасында Япониядә ясалган магнитофоннар, магнитолалар күренә башлагач, элек тә абруе булмаган, тупас, инде дөнья базарына чыгар сыйфатлары түбән совет товарлары авыл җирләрендә һәм кыйммәтле чит ил товарларын сатып алырга акча табалмаган кешеләрдә генә калды. Пароходчылык кызыл почмакка, офицерлар салонына һәм капитан каютасына кыйммәтле телевизорлар, магнитолалар куярга онытмый иде. Кораб чит ил портларына туктый, совет диңгезчеләренең тормыш-көнкүрешен карарга чит ил кешеләре килеп йөриләр.

Совет илендәге муллыкны, андагы бәхетле тормышны аларга пропагандалау зур тырышлык белән алып барыла иде.

Капитанның каютасына япон магнитофоны «Акаи» куелганын Рахманкулов белә иде. Аннан тыш Анатолий Александровичның үз магнитоласы – «Сони»ның соңгы модификациясе дә бар иде. Аларда «Мишка, Мишка, где твоя улыбка?» дәрәҗәсендәге китч, шоу-бизнес музыкасыдыр, дип, Габдрахман ялгышкан икән. Әнә, каютадан Булат Окуджава җырлаганы ишетелә башлады. «Капитанның ишеге каршында торганыңны күрсәләр, әллә ни уйлаулары бар», дип, Рахманкулов читкәрәк китте. Музыка монда да яхшы ишетелә иде. Капитан Рахманкулов яраткан «Шарманка-шарлатанка»ны әйләндерә. Җырның беренче куплетлары үткән иде инде. Габдрахман җырның азагын гына ишетте:

Работа есть работа. Работа есть всегда.
Хватило бы только пота на все мои года.
Шагаю еле-еле, вершок за пять минут,
Как дойти до цели, когда ботинки жмут?!
Расплата за ошибки – это ведь тоже труд.
Хватило бы только улыбки, когда под ребро бьют...

Кинаяле фикер... Күпләр аны аңлый алмый. Бәгъреңне сыкратып, яшәвеңне кан елатып торган фикерне Аллаһы Тәгалә укучыга әз генә шагыйрьлек сәләте биргән очракта да киная ярдәмендә әллә нинди катлаулы фикерләрне аңлап була.

«Бу җырын минем турында язган», – дип уйлый иде Габдрахман. «Шагаю еле-еле...» – соң бу безнең яшәү юлыбыз түгелмени?! Рахманкулов та әнә яшәеш юлыннан көчкә ерып атлап бара. Ул да атлаган саен ялгышып тора түгелме?.. Кайберәүләрнең ялгышуы башкаларга зыян китерә, Габдрахманныкы исә һәрдаим аның үзенә зыян сала. Ялгышлык эшләп ташлаганнан соң, шуны төзәтү өчен күпме авырлыклар күрергә туры килә, күпме өстәмә көч түгәргә кирәк. Шул ук вакытта аның, башын иеп, нәрсә кушсалар, шуны эшләп йөрисе дә килми иде.

Бу җыр Габдрахманга Кара диңгез пароходчылыгында Пастернакның «Доктор Живаго» исемле романын тәнкыйтьләүгә, шагыйрьнең үзен, Шолохов әйткәнчә, «Әдәбият власовчысы» икәнлеген раслауга оештырган конференциясендәге үз чыгышын искә төшерде. Конференция тәмамлангач, корабына: «Узган рейста минем чит илгә соңгы тапкыр чыгуым булган икән... Иртәгә минем урынга башка кешене җибәрәчәкләр… визамны ябып, каботажга күчерәчәкләр... диңгез белән саубуллашырга туры киләчәк!» – дип ут йотып, күңеленнән кан елап кайтты.

Югыйсә, аның трибунадан әйткән сүзләрендә Совет системасын тәнкыйтьләү дә, партиянең идеологиясенә тел тидерү дә юк иде. Трибунага менеп баскач, ул болай дип башлады:

– Ничә кеше Борис Пастернакны әллә нинди мәсхәрәле сүзләр белән тәнкыйтьләде. Шуларның берсе дә «Доктор Живаго» романын уку түгел, кулларына да тотып караганын раслый алмады. Бу бит инде сукырның болын чәчәкләрен тәнкыйтьләве белән бер. Аннан соң әдәби әсәрне тәнкыйтьләгәндә, әдәбият белеме кагыйдәләренә таянып эш итәргә кирәк. Әдәбиятны тулысынча идеология җимеше итеп кенә карау – бу үзе үк бик зур ялгышлык.

Шул чакта залдан Рахманкуловка сорау бирделәр:

– Ә сез үзегез «Доктор Живаго»ны укыдыгызмы соң?

Бу кешене Габдрахман таныды. Сорау бирүче өлкән механик Вердеревский иде. Габдрахман «Пингвин бук» нәшриятында инглиз телендә басылып чыккан «Доктор Живаго»ны укыганда, алар Вердеревский белән бер корабта эшлиләр иде. Шул сорауга «әйе, мин укыдым», дип әйтүдән Рахманкулов көчкә тыелып калды. Аны шул коткарды да булса кирәк. Пастернакны яклаганы өчен Габдрахманның визасын да япмадылар, хәтта начаррак корабка да күчермәделәр. Партком секретаре Матузенконың хатыны университетта әдәбият укыта иде. Бәлки, парторгның хатыны филолог булу монда аның файдасына эшләгәндер?..

«Шарманка-шарлатанка» җырыннан соң, Окуджава «Не верьте пехоте, когда они весёлые песни поют» дигән җырын башкарды. Бу җыр да Окуджавага хас тетрәндергеч киная аша пехотада хезмәт итүнең газапларын, анда кешелек сыйфатларын, Инжил китабындагы таш скрижалларга язылган Ун васыятьне (заповедьне) саклап булмаганлыкны исбатлый иде. Габдрахман Мәскәү университетында укыганда, Окуджаваның җырлары нонконформистларның телләрендә дога шикелле яңгырый иде. Капитанның да Булат Окуджава җырларын тыңлавы аның күңелен күтәреп җибәрде. Димәк, бу кеше белән уртак тел табудан тыш, карашларның да уртак икәнлегенә ышанып була иде.

Кичке аш вакытында кают-компаниядә икәү генә калгач, Габдрахман капитанга шул хакта сүз катты:

– Анатолий Александрович, мин сезнең Булат Окуджава җырларын яратуыгызны белдем.

– Кемнән ишеттегез?

– Кешедән түгел, кичә коридордан барганда, каютагызда Окуджаваның җырлары яңгырый иде. «Контора глубокого бурения»гә җиткерүләреннән курыкмыйсызмы?

– «Фрязино» корабында эшләгәндә, мин Окуджаваны Сочидан Одессага алып бардым. Алар Фазыл Искәндәр белән иделәр. Кораб бәләкәй. Юньле каюта юк диярлек. Үз каютама урнаштырдым. Одессага кайтып җиткәнче җырлаттым. Аның җырларына бүгенге көннең кырыс каршылыгы салынган. Окуджаваның җырлары минем дөньяга карашымны, чынбарлыкны тоюымны, йөрәк әрнүләрен, безнең системаның адәм баласын коллыкта тотарга көйләнгәнен – барысын да колачлый. Окуджава җырлый. Мин елап тыңлыйм. Билгеле, елавымны күрсәтмим, яшерәм. Сиңа таныш микән, күз яше чыгармыйча, тавышсыз елау бар бит. Кайдадыр, җан урнашкан җирдә, йөрәк эчендә нәрсәдер өзгәләнеп ыңгыраша, син күргән газапларны сыгып чыгара. Булатның җырлаганын тыңлаганда да, нәкъ шундый елау барлыкка килә. Минем янда Валера да бар иде. Ул күбрәк Фазыл Искәндәр белән сөйләште. Булатны да тыңлады, билгеле. Валера Искәндәрнең әсәрләрен яттан белә диярлек. Минем хатын филолог бит. Миңа кияүгә чыкканчы, Мәскәүдә басыла торган әдәби журналларга мәкаләләр язган. Хәзер вакыты юк. Катлаулы эш бит капитан хатыны булу, әгәр иренең диңгезне яратуын кабул итә алса.

– Анатолий Александрович, күптән сорарга җыена идем, сез нигә хатыныгызны Валера дип атап йөртәсез? Валера бит ирләр исеме.

– Минем хатын андый исемгә лаеклы. Башка капитан хатыннары шикелле түгел, чит илдән алып кайткан кием-салым аңа бер тиен тормый. Хәтта алтын-көмеш, алка-йөзек белән дә мавыкмый. Ул – чын диңгезче хатыны. Портка кайтканымны көтеп яши. Бу рейстан кайткач, мине пассажир лайнерына утыртырга тиешләр. Әгәр башка капитан юлыма аркылы төшмәсә, Валераны кече малаем белән янымда йөртәчәкмен...

Әллә Рахманкуловның йотлыгып тыңлавы күңеленә хуш килде, әллә Булат Окуджаваны ярату уртаклыгы якынайтты аларны? – Капитан мәҗлесне бу сөйләшү белән генә өзәргә теләмәде.

– Нишләп әле без кают-компаниядә сөйләшеп утырабыз. Кают-компания – командирлар җыела торган урын. Әйдәгез, минем каютага.

**12**

Каютага кергүгә, капитан китап шкафына тезеп куелган кассеталарга күрсәтте:

– Аларның күбесе – Окуджаваныкы. «Бони-М», «АББА», джаз кассеталарым да шактый гына. Шулар арасында әле яңа җырлый башлаган бер артистныкы бар. Таганка театрында эшли, диләр. Үзенең танышлары аша Валера Мәскәүдән кайтарткан. Владимир Высоцкий исемле. Җырларының һәр сүзе аткан ук булып йөрәккә килеп кадала. Белмим, озак җырлый алмас шикелле тоела. Һәр сүзе – ачы протест.

Рахманкулов кассеталарны карый башлагач, капитан ишеккә юнәлде:

– Син карый тор. Мин рубкага менеп төшим әле. Сокстра атавына җитеп киләбез. Гадәттә, аны төньякта калдырып китәләр. Миңа бер инглиз капитаны атауны көньяктан узганда, алтмышынчы меридианга кадәр көнчыгышка юнәлгән агым ярдәм итә, дигән иде.

Хуҗа чыгып киткәч, Габдрахман капитанның каютасын җентекләп карарга кереште. Каютадагы әйберләр, аларның урнашулары аша капитанның нindirәк кеше икәнлеген аңларга була.

Иң затлы төрле өстәмә приборлар, кыйммәтле белешмәләр, көмеш сыбызгы, Лондоннан сатып алган фуражка, җиңенә укадан шефрон теккән тужурка, өстәлдә министрдан, пароходчылык начальнигыннан килгән бер өем приказ-күрсәтмәләр, переборкада чит илдән сатып алган ярымшарлар картасы, сирәк очрый торган ялтыравык экзотик сувенирлар – мондый каюталар, нишләптер, надан капитаннарда була. Тик белемне, сәләтне, бигрәк тә талантны стенага элгән кыйммәтле карталар, мактау кәгазьләре, шкафтагы китаплар, аларның тышлары гына билгеләми шул.

Талантлы капитанның каютасында яңгырдан саклый торган иске плащ, шкафында таушалып беткән әллә нинди кулъязмалар, китаплар. Йокы бүлмәсендә дә, эш өстәлендә дә китаплар өеме. Алардан тыш, әнә, Анатолий Александровичның каютасында теләсә кайсы җирдә магнитофон кассеталары чәчелгән. Мондый капитаннар югарыга күтәрелә алмый. Алар, гадәттә, диңгезчеләр арасында гына абруйга ирешә.

Җитәкчелек. Менә кемнәр тирәсендә чуалырга кирәк дан казану өчен. Бүләкләргә, мактаулы исемнәргә, орден һәм югарырак урынга күтәрелүгә, түрәләр тирәсендә чуалган, аларга тәлинкә тотучылар ирешә. Кешелек дөньясы тәрәккыят юлыннан тайпылмаган очракта бу гадәт-традицияләр киләчәк гасырларда да сакланачак.

– Утрауның төньягыннан үтәргә маршрут сыздым, – диде капитан, каютасына кергәч. – Агым корабка ярты узелдан артык тизлек өстәячәк. Җил дә безгә ярдәм итеп тора. Гонконгка барып җиткәнче, ким дигәндә, биш-алты тонна ягулыкка экономия ясыйбыз, ярты тәүлеккә алданрак барып җитәчәкбез.

Капитан суыткычтан Шотландия виските чыгарды, ике җәлпәк рюмка куйды.

– Сыекламыйча эчәсезме? Мин содовой белән сыеклап эчәргә яратам.

– Мин дә содовой белән сыеклыйм, – диде Рахманкулов.

– Окуджаваның нинди җырларын яратасыз?

– Аның һәр җыры безнең чорның маңгаена фәлсәфи ачыш тондыра шикелле. Шоу-бизнес җырлары белән мавыгучыларның гына аның иҗатына буйлары җитми шикелле, – диде Рахманкулов.

Капитан магнитоласына кассета куйды.

Пока ещё Земля вертится, пока ещё ярок свет,
Господи, дай же каждому, чего у кого нет;
Умному дай голову, трусливому дай коня.
Счастливому дай денег и не забудь про меня...

Капитан, кнопкага басып, җырны туктатты:

– Нигә ул акыллы кешегә Алладан баш сорый? Сез шуны аңлата аласызмы?

– Җыр бит Франсуа Вийонга багышланган. Урта гасыр белән Яңарыш чоры арасында иҗат иткән иң зур, иң талантлы француз шагыйренә. Вийон, бүгенгечә бәяләгәндә, бомж булып яшәгән. Принц Оранский оештырган шигырь ярышында ул беренче урынны ала. Бүләк тапшырырга эзли башласалар, Франсуа Вийон – юк. Бераздан соң, исерек килеш сугышып, дин әһелләрен мыскыллап йөргәне өчен, аны төрмәгә ябалар һәм үлемгә хөкем итәләр. Шул чакта ул үзенең тетрәндергеч «Җиде дарга асылганнар турында баллада» исемле әсәрен язып, принц Оранскийга җибәрә. Принц Вийонны үлемнән коткара, аны корольнең китапханәчесе итеп куймакчы була. Әмма шагыйрь патшалар янында озак кала алмый. Ул кача. Аның ничек үлүе турында төрлечә сөйлиләр: иң ышанычлы версия – исерек килеш сугышканда, шешә белән сугып, шагыйрьнең башын яралар.

Булат Окуджава Вийонга багышланган шигырендә антитеза ярдәмендә фикер йөртә. «Акыллыга баш бир» сүзләрен мин: «Җәмгыять законнары нигезендә ярашу, хәйләкәрлек белән яшәргә өйрәт...» – дип аңлыйм. Бәхетле яшәүчеләр, гадәттә, ярлылар арасында күбрәк очрый. Вийон: «Ярлылыкларына канәгать булып яшәүчеләрне акчалы ит», – дип ялвара.

– Мин ул җырны тыңлаганда, Окуджава Алладан: «Адәм балаларына тигезлек бир», – дип ялварып сорый торгандыр дип йөри идем... Миңа аның тагын «Зәңгәр троллейбус»ы бик ошый. Аның философик нигезе дә гаҗәп тирән бит. Чиновниклар эшли торган җиргә кереп кара әле. Югарырак урынга күтәрелгән саен, кабинетлары зуррак, бүлмәләрендәге җиһазлар затлырак. Шулар арасында эшеннән канәгатьлек тапкан түрәне очратканым юк минем.

– Чыннан да, Окуджаваның һәр җыры – притчага, хәтта догага якын. Хәтерлисезме икән, аның « Отгремели песни нашего полка» дигән җырын? Ул анда: «...для чего пишем кровью на песке, наши письма не нужны природе», – дип, кешелеккә чаң кага. Чыннан да бит, сугыш җиңелүчене искиткеч авыр хәлгә куя. Әнә, Казан ханлыгын Явыз Иван яулап алганнан соң, татарлар язмышына карагыз. Тик җиңүче дә бит… рәсми пропаганда аны күкләргә чөеп мактаса да, беркайчан да бәхеткә ирешә алмый. Рәсәйнең җиңүләрен генә алыйк. Җиңү вакытында ике яктан да күпме кан коела… Шундый зур җиңүләргә ирешкән Рәсәй дәүләтенең кан кою ярдәмендә кайчан да булса бәхетле, рәхәт тормыш кора алганы булдымы?

– Бу турыда теләсә кемгә сөйләп йөрмәгез, Рахманкулов. Кара халык, яратмаса да, әле һаман Сталинга табынып яши бит. Сталинны гына түгел, халыкка игелек күрсәткән патшаларны да яратмаганнар. Павел Беренче

алпавытларга хокук биргән. Алпавытлардан соң ул гади халыкны да хокуклы итәргә хыялланган. Шул патшаны үтереп ташлаганнар. Пётр Өченче дә Рәсәйдә Европа илләрендәге тәртипне урнаштырмакчы булган. Аны да үтергәннәр. Ә инде крепостнойлыкны бетергән, ирек игълан иткән Александр Икенчене үтерүләре... Бу инде Рәсәйгә хас искиткеч кыргыйлык. Француз революциясе вакытында да бит башта корольне, аның хатынын һәм алпавытларны үтерәләр. Аннан соң шул революция ясаучылар бер-берсен кыра башлый. Соңрак, гомумән, революционерларны юкка чыгарып бетерәләр. Шул ук хәл бездә дә кабатланып тора түгелме? Менә сиңа кан белән комга язылган язмышлар... – дип уфтанып куйды капитан.

«Менә сиңа әдәби иҗат һәм тормыш чынлыгы! Синең үзеңә дә кулга ныклап торып каләм алырга вакыт түгелме икән, иптәш?!.» – дип, үз-үзеннән сорады Габдрахман.

***

Чәркәләрдә затлы виски, өстәлдә сёмга балыгы, кызыл һәм кара уылдык. Каклаган ит яратканын белеп, Бородуля бастырма турап куя иде.

Әңгәмә тәмле булып, салмак кына ага. Төнге унике тулыр алдыннан Рахманкулов рәхмәт әйтеп кузгала башлый.

– Мин сезне, Одессага кайткач, Валера янына чакырам әле. Әдәбият өлкәсендә үземне дөм кара кешегә санамыйм. Шунысы аянычлы: өйләнгәч, Валераның әдәбият өчен җанын бирергә әзер икәнлеген аңлаганнан соң гына, ныклап торып әдәби әсәрләр укый башладым. Дөрес, элек тә укый идем. Ул чакта укыган китаплар исемә төшкәндә, әле дә кызарам. Башкалардан үрнәк алып, гел макулатура укыганмын икән.


– Рәхмәт, Анатолий Александрович. Бик матур утырдык. Күпме кызыклы нәрсә ишеттем.

– Үзегезгә рәхмәт. Сезнең белән әңгәмә корып утырганнан соң, минем эрудиция күтәрелә. Пассажир лайнеры кабул итеп алсам, мин сезне үземнең командага чакырырга тырышырмын.

– Юк инде, Анатолий Александрович. Дарга ассалар да, мин пассажир лайнерына утырудан баш тартам. Анда бит өч йөздән артык хатын-кыз. Аларның һәммәсе диярлек сиңа җим салачак. Шуңа өстәп, пассажирлар арасында нинди генә чибәр кызлар очрамый? Мин өйләнергә җыенам. Телисеңме-юкмы, анда бит кызлар, бигрәк тә ирләреннән аерылып йөзәргә чыгып киткән яшь хатыннар аздырмый калмаячак.

– Сезнең бу фикерегезне, начальстводан хатынны үзем белән йөртергә сораганда, төп дәлил итеп алачакмын, – диде капитан.

*Ахыры киләсе санда.*



Нурмөхәммәт
Хисамов

#ҺӘР АКЫЛЛЫ ҖАНДА ЧЫҢЛЫЙДЫР САЗ…

## Шәһри Болгар – минем Элладам

*(Элегия)*

Мин язмышка тирән рәнҗүләрне,
Үпкәләрне аннан юлладым.
Гүзәл илем, бөек дәүләтем – син,
Шәһри Болгар – минем Элладам.

Ник безләрне гаҗиз, ятим итеп,
Тарихларга китеп югалдың?
Милләтемнең изге бишеге – син,
Шәһри Болгар – минем Элладам!

Бабаларның даны, намы сеңгән
Ташларыңа ятып еладым,
Иделемнең газиз күз карасы –
Шәһри Болгар – минем Элладам.

Хәрабәләр ята шаһитыдай
Дәүләт эзен кырган елларның.
Манаралар саклый мәгъруурлыгың,
Шәһри Болгар – минем Элладам.

Җаннарыңда йөртә синең сынны
Гүзәл кызлар, батыр улларың,
Син югала торган тарих түгел,
Бөек Болгар – минем Элладам!

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ (1937) – *әдәбият галиме, шагыйрь; «Яз миңа чәчәкләр китерә», «Бөек язмышлы әсәр», «Кол Гали һәм төрки йосыфнамә» һ.б. китаплар авторы. Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты.*

## Каенлы юлда

Иртә таңнан юлга ашкынам,
Урман буйлап чаба машинам.
Каршы яктан йөгерә каеннар,
Әйтерсең, гамь, бер-бер ваем бар.

Бәкәлләре гүя бөгелә, –
Кай арада күргән хәстәрен?
Тигез сафта гүя аларның
Алмачуар атлы гаскәре?

Игенчегә янап салада,
Һөнәрчегә янап калада,
Хәвеф салып ерак даладан,
Килгәндер яу Болгар иленә.

Яшел җилән элеп иңенә,
Булат кылыч тотып кулына,
Күзне текәп дала юлына,
Яу чыккандыр болгар ирләре,
Саклар өчен туган җирләрен...

Тасмаланып артта юл кала,
Үзем очам үрдән аскары.
Офыкларга кереп югала
Каеннарның бердәм гаскәре...

## Үзебезгә тигән мизгел

Ай яктысы уйнар алсу йөзең
Былбыл моңы сеңгән гөлгә тиң.
Камышлы яр ышыгына сыенып,
Мөлдерәгән төнге күлгә тиң,
Керфекләрең күләгәсе төшеп,
Уйга талган серле күзләрең.

Язмышның бер юмарт бүләгедер
Бу карашлар, бу моң, бу ымнар.
Уй, гакыл да адашырлык хәтта
Төн карасы йоккан толымнар.

Ярсу ялкын, бетмәс сусау биргән
Миңа хазар, кыпчак бабамнар.
Кайнар канны, горур җанны биргән
Сиңа болгар – сармат – аланнар.

Күпме сулар аккан, җилләр искән,
Еллар кичкән, кичкән гасырлар,
Бер халыкта килеп кушылганчы,
Безнең хисләр, безнең гакыллар.

Бәхетсез, дип кем әйталыр безне –
Язмыш үзе бирде тезгенне.
Без табалдык чиксез мәңгелектән
Үзебезгә тигән мизгелне...

## Сагышлы яз

*Галим Шәйхи Садретдинов истәлегенә*

Гөрләвекләр ага челтер-челтер,
Күз чагыла нурдан елтыр-елтыр,
Бала-чага чаба тыр-тыр, тыр-тыр,
Трамвайлар уза шалтыр-шолтыр.

Агачларда чут-чут кошлар таушы,
Урамнарда чыр-чу кызлар таушы,
Вокзалларда шау-гөр, яшьләр каушу,
Кая барма, анда язгы шау-шу.

Күкләр аяз, җирдә күләгә аз,
Сөендерә, нурлый, иркәли яз,
Табигатьтән бөрки күңелгә наз,
Һәр акыллы җанда чыңлыйдыр саз.

Тик галәмдә сүнде бер йолдызкай,
Бакыйлыкка күчте Шәйхи дускай...
Яз суынды миңа узмас кыштай,
Кояшы да гүя сагышлы ай.

Әнкәсенең җандай күреп сөйгән,
Һәр дәшкәндә: «Йөрәк кенәм», – дигән,
Кайтуларын көтеп янган-көйгән.
...Ә күзләре шундый зәңгәр, тирән...

Зур шагыйрьләр сызган якты эздән
Шигырьләрне энҗе кебек тезгән,
Гармун сузып, үзәкләрне өзгән
Шәйхи дустым китеп барды бездән...

## Әйтелмәгән монолог

Икәү бергә дөнья гизәргә
Алып чыктым сине – улымны,
Олы мәгънә, олы гамь белән
Бизәр өчен ерак юлымны.

Бар дөньяңны онытып, тәрәздән
Күзәтәсең поезд барганын,
Син белмисең гашыйк әтиең
Нинди уйлар белән янганын...

Синең белән үткән чагында,
Күзләренең түгеп зәңгәрен,
Юл буенда калган «апа» да
Үзе генә белә хәлләрен.

Аңа бәхет биралмаганга,
Күпме айлар менә ут йотам.
Йөрәгемә капкан ялкындай,
Ул артымнан калмый бер тотам.

Сакласа да чиксез сабырлык,
Тәрәзәдә күзе һәр көнне.
Мәхәббәттән миңа син – бүләк!
Мәхәббәт үк даулый бәхетеңне...

Юк, юк, күңлем синсез бәхетне
Үзе өчен бәхет диалмас.
Күзләреңнең гамьсез чагына
Бармыни соң җирдә тиң алмаш?!

## Синең кулың

*Мин кулыңны тоткачтын аштым күккә дә, –*
*Бер дә чиксез гали чарлактыр кулың.*

Г.Тукай

Синең йомшак ак кулларың
Фәрештә кулы сыман.
Кулга-кул узган юлларым
Йолдызлар юлы сыман.

Мине өркетми һич, җаным,
Максатның ераклыгы.
Җанга кагылмый дөньяның
Керләре һәм ваклыгы.

Ничекләр генә сынамас
Язмышның дулкыннары.
Кулга-кул без! Сыгалмас һич
Җилләре, упкыннары.

Авыр йөктән курыкмый йөрәк,
Шифа-көч бар кулыңда.
Алар иң нык терәк миңа
Шушы гомер юлымда.


## Саубуллашу

Юллар тагын мине Одиссейдай
Алып китә синнән еракка.
Сау бул, сау бул, минем Пенелопам,
Күзләреңне, зинһар, чылатма!

Юлларыммы? Беләм, җиңел булмас,
Кайда ташлар мине дулкыннар?!
Кайтмасамчы сиңа Пер Гюнт сыман,
Көймәләрем йоткач упкыннар...

## Көзге уйлану

Тагын көз килә, чумып алтынга,
Бар да үзенчә ямьгә төренгән,
Табигать белән җир-әнкәгәме
Җыеналар күк хисап бирергә.
Миләшләр пешкән, ут-кызыл булып,
Алмагач сыгыла йөге авырга.
Чикләвек тулган – тып-тыгыз тәнле,
Баланнар комач алка тагынган.
Каршылап илнең шундый фасылын,
Һич тынгы бирми бер уй үземә:
Халкым каршына, тотып мул кәрзин,
Килсәмче мин дә гомер көземә.



Ахир

# КЫРГЫЙ АЛМАГАЧ

ПОВЕСТЬ

*Әлеге вакыйгалардан хәбәрдар һәм аларга күпмедер шаһит булган туганым Нурулла абый Яруллинга багышлыйм.*

**Беренче бүлек**

## Ялгызак

– Юк, мин сиңа кайтмыйм!

– Нишләп? – диде Сара.

Дивардагы күкеле сәгатьне дәү калын ачкыч белән борып маташкан Фатыйх, бер сүз дәшмичә, тынып калды.

– Көн саен килә алмыйм, ишетәсеңме?

– Аңладым... килмә...

Сәгать тиктомалдан гына каты итеп суга башлады. Урындыкка басып, диварга үрелгән, җылы оек кигән Фатыйх, ниһаять, сәгать эшен ташлап, идәнгә төште.

– Миндә яхшырак булыр сиңа, – диде Бибисара һәм шундук йөзен чытты. Үзенә күрә түгел: шактый ук үзсүзле һәм тәкәббер хатын. Кешегә ялынырга яратмый, ә бу очракта исә Фатыйхка ялынган кебегрәк килеп чыкты. Сара кайчак үз сүзеннән кире кайтып, бәхәсләшкән кешесе белән килешә алса да, һәрчак горур булып калырга тырыша иде.

– Кайда ничек буласын синнән башка да яхшы беләм...

Фатыйхның җавабы шактый тупас яңгырады. Аның җавабында әллә ни зур мәгънә ятмаса да, анда башка нәрсә – яшәү хикмәте ята иде. Колхозга кермичә гомер итә алган, хуҗалыгы зур булган, ике ат, ике сыер, бер көтү сарык, җитмеш-иксән кош-корт тоткан, илле баш умартасы булган балта остасы өчен Сарага барып керү авылдан күченеп китү белән бер иде. Әйе, терлекне әкренләп Сара йортына күчерергә, артыгын суеп сатарга да була. Ләкин халык ни дияр? Олыгайган көнендә Фатыйх элеккеге хатынына йортка керде, диярме? Өйләнешкәндә, аларның икесенә дә нәкъ егерме җиде яшь иде. Фатыйхның

---

Ахир (Хәбир Ибраһим) (1958) – *язучы, драматург, «Ялгыз тәкәрлек», «Газиз ярым», «Төпчек малай маҗаралары» һ.б. китаплар авторы; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш һәм Ш.Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

тәүге мәртәбә өйләнүе, ә Бибисараның, Хәйбүштән соң, икенче мәртәбә кияүгә чыгуы иде. Алар өч кенә ел торып калдылар. Утыз яше тулгач, кешечә генә яшәп яткан җиреннән Фатыйх кайтты да китте. Үз йортына кайтты, атасыннан калган иске туган йортына. Аннан ул йортны, каралты-курасы белән бергә сүтеп атып, нарат бурадан яңа йорт салырга тотынды. Эш беравыкка тукталды, чөнки йорт күтәрергә акчасы җитмәде. Колхоздан ярдәм сорады. Бер көн дә колхоз эшендә эшләмәгән Фатыйхка кискен шарт куйдылар: йортыңны салып чыгабыз, ләкин аның бер ягына сугыштан соң авыр шартларда яшәгән сугыш ветеранын, Мәрфуга исемле бер ялгыз хатынны кертәсең, диделәр. Фатыйх әлеге тәкъдимгә сөенечле хисләр кичермәсә дә, җитәкчеләргә каршы килә алмады, ләкин акыллы эшләде: йортны ике яклы итеп салдырды...

– Шул өч елда ничек шәп яшәгән идек бит! – дип чәпчеде хатын, Фатыйхның уйларын аңлагандай. Әлеге сүзләрне ул Фатыйхка беренче генә түгел, ә йөз дә беренче мәртәбә кабатлый иде. – Корсаклы да идем...

– Табасың барые, – дип төрттерде ир.

– Кирәкми! Миннән табарга ярамый, дип, үзең үк төшерттердең ләбаса...

– Табарга теләгән хатын ир кешенең сүзен тыңлап тормый ул, тота да таба! Димәк, яратуың шулхәтле генә булган!

– Уф!

– Нәстә уф?!

– Нишләп син шундый булып тудың соң, ә?! – дип акырды хатын. – Ничә ел яшим шушы якты дөньяда, шултикле күп беләм сине! Тик һаман да төшенеп бетә алмыйм. Кем соң син? Нишләп шундый син, ә?!

– Аңлаттым бит инде, – дип, башын аска иде хуҗа. – Миең черек булганга, мин гаепле түгел...

Әйе, Сара белән озын-озак яшәргә, матур гаилә корырга кыюлыгы да, батырлыгы да җитмәде аның. Дөресрәге, курыкты ул, курыкты. Сараның үзеннән түгел, билгеле, ә...

Бу авыр сөйләшүдән кәефе киткән Фатыйх диварга эленгән фотосурәтләргә күз төшерде. Искергән фотоларның инде шактые тоныкланган, берничәсе бөтенләй саргайган, кеше сурәтен танырлык та түгел...

– Әти... әни... сеңелкәш... – дип сөйләнде ул. – Картайды фотолар... безнең күк... Фотограф табып, бер яңартасы иде...

– Тагын качасыңмы?

– Кемнән? Нәрсәдән?

– Туры җаваптан?!

Алтмышка якынлашып килгән Сараның холкы, чынлап та, сәер, чөнки ул бер сөйләгән сүзен, исенә төшкән саен, бертуктаусыз кабатларга ярата иде. Әйе, ул бервакытта да искитәрлек, кеше күргәч «ах!» итәрлек, ирләр күзе төшәрлек хатын була алмады. Карап торышка ямьсез хатын да түгел. Тигез кара кашы, сөйкемле түгәрәк йөзе, зифа буе, төз сыны дигәндәй, бар да үз урынында кебек. Ләкин әллә үзе шундый, әллә кигән киеме бертөрле – нигәдер ул, кайбер сөйкемле хатыннар сымак, үзенә тартып, җәлеп итеп тормый, күрер күзгә күркәм булса да, артык гади һәм шуның өстенә шактый күңелсез кеше иде...

Фатыйх өчен туган йортыннан да изге һәм кадерлерәк нәрсә юк иде бу дөньяда. Моны Сара яхшы аңлый, ләкин аңлап кына бетерәсе килми.

Шушы нигездә Фатыйхның атасы Гаяз җан бирде. Илленче елларда. Сугышлар бетеп, тормышлар тернәкләнеп килгән чорда булды ул аяныч хәлләр. Атасы шушында ачлыктан тилмереп, салкында катып үлде! Мордарлыкка

тиң булды ул – яшисе килмәде кешенең, үләсе килде. Аңа беркем дә ярдәм итмәде, һәм ул беркемнән дә ярдәм сорамады. Ярдәм сорауның файдасын да күрмәде, чөнки колхозчылар өчен ул халык дошманының ире булып саналды. Бер гаепсезгә хөкем ителгән, ләкин халык дошманы дигән ярлык сугылган хатынының (Фатыйхның анасы) ире булганы өчен. Элегрәк Гаязга – яратып, хөрмәтләп эндәшкән авылдашлары, күршеләре һәм хәтта туганнары да аның белән исәнләшүдән туктадылар, аңа хәтта сәлам бирүдән дә читләштеләр...

Сара боларның барысын да яхшы белә, Фатыйхның күз карашыннан ук күреп, аңлап тора. Ул аңардан хәтта җавап та көтмәде. Кулларын артка чалыштырып, зал буенча йөренгән Фатыйх урындык башына эленгән соры крепдешин күлмәккә кагылды һәм аны, кулына алып, сөеп дигәндәй, күкрәгенә кысты.

– Кичә сандыкта актарынган идем, гаҗәп бит, әй, әнкәйнең иске күлмәге килеп чыкты, – диде ул, чиксез дулкынланып. – Соңгы тапкыр... бәхилләшкән чагында шушы күлмәген кигән иде... җаным...

– Нәгыймә апаныкымы?!

– Әгәр ул хәзер исән булса, син аңар «әни», дип эндәшер идең, шулай бит?!

– Ие...

Фатыйхның әнисе, сугыштан соң, кибеттә сатучы булып эшләде. Әшәке, кабахәт заман! Халык җыйнап, суд ясап, аның әнисен имчәк баласы белән бергә төрмәгә озаттылар. Ни өчен? Фатыйхка, студент егеткә, калага баргач, сатып, әзрәк акча эшләрсең, дип, авыл кибетеннән кырык кап тәмәке биреп җибәргәне өчен! Егетне Тәмте пристаненда, теплоходка кереп барган җиреннән тотып алдылар. Тентеделәр. Казанга юлланган авыл куштаны Хөснулла (күрәсең, ул барсын да белгән!) агач пристань каршында басып торган посттагы милиционерга яшь егетнең букчасын актарттырды. Шул кырык пачка тәмәке өчен аны ун елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. Төрмәдән ул биш елдан соң гына чыга алды. Әгәр дә Сталин исән булса, таш зинданнан исән-сау гына котыла алган булыр иде микән?! Ул ярты сәламәтлеген төрмәдә калдырып кайтты. Ни кызганыч, әнисе төрмәдән кайта алмады, шунда җан бирде. Имчәк баласын, сеңлесе Люцияне балалар йортына тапшырдылар. Кыз шунда үсте, аның кебек үк ата-анасыз калган ятим совет балалары арасында тәрбияләнде...

– Дөрес! – дип көрсенде Фатыйх. – Минем дә бәхетле буласым килде, сине дә, Сара... Бибисара... бәхетле итәргә теләдем. Нәстә, мин бала теләмәдемме? Теләдем, әле ничек кенә теләдем! Тик... курку, ниндидер чарасыз курку харап итте мине. Менә безнең балабыз туар, менә без синең белән бәхетле генә яшәп китәрбез, ләкин тагын шундый ук афәт килеп чыгар да, илленче еллардагы сымак, безне кабат кырып, туздырып атарлар, таш зинданга илтеп тыгарлар, ә йорт-җиребезне төртеп яндырырлар кебек тоелды...

– Заман башка бит инде хәзер, Фатыйх...

– Заманга ышанма син, Бибисара, беркайчан да ышанма. Тарих ул ыс... пираль сымак...

– Нәстә сымак?

– Чорналган тимерчыбык сымак... сүтелеп, кабатланып тора. Илне дә, дөньяны да гаепләмим. Минем бары тик аерым бер кешеләргә карата нәфрәтем көчле һәм ул, беләсең килсә, артык көчле. Шул авыл куштаны Хөснулга ни начарлык кылдым инде мин, җә?! Унсигез яшьлек саф күңелле студент егет идем бит! Чиста уйлар, якты өметләр белән яшәдем... Нәстә дип каныкты ул миңа, җә?! Күргән-белгән очракта да күрмәмешкә сабышырга җарамый идеме?! Җарый иде! Үт тә кит инде, күрмә, име! Юк! Күрә! Килеп доложить итә! Кем алдындадыр ачка җыя! Матур

гына исәнләшеп, үтеп кенә китәсе иде дә бит! Юк! Китми! Әти дә, әни дә исән калган булырлар иде, югыйсә, мине дә, яшь кешене, бер гаепсезгә төрмәгә илтеп тыкмаган булырлар иде! Бик матур, бик тату яшәгән бер гаилә гаепсезгә җир йөзеннән юкка чыкты. Мең-мең ләгънәт сиңа, Хөснул абзый! Хе!!! Үт тә... кит бит инде! Җә! Юк! Үтми! Хәер... этҗан... үзе дә... үз үлеме белән үлмәде, асылынды... Әллә астылар шунда...әллә...ие...хәзер барыбер инде...

– Бу турыда әзрәк сүләшергә иде безгә...

– Ә мин сүләмичә булдыра алмыйм, япма син авызымны! Мин хәзер беркемнән дә курыкмыйм! Туйдым... куркып...

– Үзең өчен кайгырам, Фатыйх, кәефең начар бит...

Фатыйхның җылы айларга чыккач авырый торган гадәте бар. Үзе әйтмешли, «самый эш вакытында» гына башлана ул газаплар. Аяк-куллары тыңламый, тәнендә ниндидер хәлсезлек сизелә һәм ул күңел төшенкелеге белән үрелеп, ниндидер бер яши алмаслык хәлгә җиткерә. Апатия, депрессия кебегрәк нәрсә, кыскасы, хәлсезлек өянәге. Төрмә газабында барлыкка килгән чир иде ул. Фатыйх хәтерли: таш зиндан эчендә утырганда, ул әле тыштагы кышны, көзне дә зарарсыз кабул итә, ә менә төрмә тәрәзәсендә язгы кояшның җылы нурлары чагыла башлауга ук, ул шул кысан камерада җанына урын табалмыйча җәфалана торган иде. Аның шулвакыт кырыкмаса-кырык төрле төстәге кыр чәчкәләре үсеп утырган, иркен яшеллек эченә чумган болыннарга, җәйләүләргә йөгереп чыгасы, егыла-егыла, ауный-ауный әнә шуларның хуш исләрен иснисе, кара җылы туфракка бармак очларын батырып, җирдә ауныйсы килде. Ләкин шул бәхеткә озак кына ирешә алмау, ирексез кош булып, төрмәдә кысылып яшәү әнә шундый мәңге дәвалый алмаслык җан авыруын китереп чыгарган да, күрәсең...

Ни әйтсәң дә, авыл малае бит ул, чын авыл малае! Кайчандыр салам түбәле авылның җанын, яшел киңлекләрнең гүзәллеген тоеп үскән авыл баласы буларак, таш зинданда утырганда, ул үз-үзенә сүз бирде: туган-үскән җиреннән беркайчан да аерылмаска. Һәм ул шул сүзендә торды да: ирекқә чыгуга ук, калада бер генә көн дә тормады, бер генә төн дә кунмады, биштәрен асып, туган авылы Сарлыбашка юл алды...

Хәер, авыруының башы гына иде әле бу. Әлегә ул аягында йөри, урында ятмый. Сузылса, гадәттә, бер ярты айга сузыла. Хәлсезлек аллергия сымак уза: төчкерә-йөткерә, борыныннан су ага, күзләре кызарып, яшьләнеп, суланып тора. Менә хәзер дә ул кисәк кенә буылып йөткерергә тотынды, учын күкрәгенә терәп, кысып, карават кырына тезләнде. Сара аңа су салып бирде...

– Мә, су йот! Даруыңны эчтеңме бүген?

Фатыйх, эчтем, дип баш какты. Шактый озак җәфаланды, авызыннан какырык килгәнче йөткерде. Соңыннан – караватт башында торган чиста сөлгене алып, шуның белән авыз тирәләрен сөрткәләгәч кенә, әзрәк тынычланып калгандай булды һәм, чиксез моңсуланып, башлаган сүзен дәвам итте:

– Ялгыз... мин... ялгызак... Сине дә ялгыз иттем... бәхетсез иттем... кичер мине... бер сөенечем... шатлыгым бар... сеңелкәшне... Люцияне әйтәм... Ходай исән калдырды... ие... ул бүген кайта!

– Люция бүген кайтамыни?

– Кайта... ие...

– Каян белдең?

– Күршеләргә шалтыратты...

– Имәндә икән чикләвек, – дип, салкын гына эндәште Сара һәм шундук ишек ягына борылды.

– Озакка түгел, – дип туктатты аны Фатыйх. – Малае өйләнергә йөри икән, Абрегы...

– Өйләнә? Кемгә?

– Аңлавымча... безнең авылныкына.

– Кызык. Ә кем кызына?

– Шайтан белсен!

– Белергә ие... кем кызы икән соң?

– Бөтен хикмәт тә шунда шул...

– Миннән хәер-фатыйха, – диде Сара, яшертен эчке киная белән. – Ярый... сау бул...

– Ачуланма, Сара... син кал әле монда... Аш куеп җибәрсәң, начар булмас ие... Кунаклар кайта бит... мин сиңа шуны әйтәсе ием... ие... бер сүзем бар иде… сиңа... аерым сүз...

Фатыйх, башын күтәреп, ишек ягына борылып караганда, Бибисарадан җилләр искән иде инде. Каршында торган сулы стаканны аударып, ул Сара артыннан титаклады. Ләкин хәлсез, авыру кешегә булган, җитез хатынны куып җитү мөмкин нәрсә түгел иде.

...Люция ялгызы, туганнарын күрмичә үсте.

Анасын ул берничек тә хәтерли алмый, анасы Нәгыймә хөкемгә тартылгач ук, баланы (имчәк баласын!) аның кулыннан тартып алып, тиз арада балалар йортына озатканнар. Люция әнә шул ятимнәр йортында – елыйсы килгәндә еларга да базмаган нәүмиз балалар кырында, кырыс һәм таләпчән тәрбиячеләр кул астында үсте. Ятимнәр йортында үскән балалар үзләренең бәхетсез балачакларын нигәдер искә төшерергә яратмыйлар. Ә менә Люция, көн кебек ачык Люция, берәр нәрсә булса: «Тимәгез миңа, мин детдум баласы!» – дия торган иде. Юк, бу аклану яисә мактану да түгел (аның нәрсәсе белән мактанасың инде!), бу аның яраткан уены, урысча әйтсәк, конёгы, үзенчә чит, тискәре көчләрдән саклану чарасы иде.

Әтисен ул ике-өч мәртәбә генә күреп калды. Ул аны әтисе дип аңламады да. Өстенә шакшы бишмәт, аягына дәү резин галушлар киеп авылдан килгән атасын күргәч, әле дүрт-биш яшен генә тутыручы сабый бала куркып качты. «Люция, атаң бит ул синең, бар инде, бар, исәнләш!» – дип үгетләгән тәрбиячене дә тыңламыйча, ул чырыйлап: «Кертмәгез аны монда, мин аңардан куркам!» – дип кычкырды. Соңыннан ничектер алар үзара килешә алсалар да, ике арада барыбер туганлык хисләре туа алмады. Җүнле күчтәнәч тә күрмәде ул атасыннан! Бәрәңге белән түгәрәкләп пешергән йомырка алып килгән. Ятимнәр йортында әллә ниләр ашатып кыландырмасалар да, бәрәңге белән йомыркадан аның болай да күңеле булган иде. Кемдер балага шоколад, кәнфит, һич югында берәр банка варенье булса да кыстырып килә, ә бу абзый (ул аңа барыбер «әти» дип эндәшә алмады!) юкка вакыт уздырып йөри. Ата кешенең баласын назлап, башыннан сыйпыйсы да килгәндер, бәлкем, ләкин Люция аңа беркайчан да барып асылынмады, атасын гел ятсынып йөрде. Гаяз аны балалар йортыннан алмады: кыз балага авылда, ач һәм ялангач йортта моңардан да яхшы тәрбия бирә алырмын, дип уйламагандыр, күрәсең.

Бераздан абзый бөтенләй югалды. Атаң үлде, дигән хәбәрне дә кыз бала, бүген кичке аш булмый, дигән сүз кебегрәк, битараф рәвештә кабул итте. Яшь иде бит, ул әле үлемнең нәрсә икәнен дә аңламый иде. Ләкин еллар узу белән, ул әтисе белән булган әлеге сәер күрешүләрне ничектер сагынып, канатланып искә төшерә торган булды. Олыгайгач, әзрәк акыл керә башлагач, кеше бу дөньяны

бөтенләй икенче төрлерәк кабул итә шул. Атасына шулвакыт аны танымаган баласы янында ничек читен булганын ул әле яңа гына аңлый башлады кебек. Әнә шул кыргый атасы янында кыргый булып күренгәненә, масаеп кылануына, киреләнүенә, еллар узгач, аның җаны сызланды. Ләкин Люцияне кичереп була: ул бит сабый бала гына иде. Ә беренче адымны аның атасы, газиз атасы ясарга тиеш иде түгелме соң?! Менә ул аның кызы, менә аңардан туган баласы, ә ул бернишли һәм бернәрсә дә хәл итә алмый. Кыз бала, исән атасы була торып, ятим балалар исемлегенә кергән, ә ятимнәр йорты ул шул ук зиндан, шул ук төрмә, зур аерма юк. Люция әллә ялгыша, әллә чынлап та аның хәтеренә шулай сеңеп калган, ул әтисенең моңсу һәм сагышлы күзләрен әле дә оныта алмый. Күңел түрендә үк йөртмәсә дә, хәтерендә аны нык саклый. Ә ул моңсу һәм сагышлы күзләр: «Анаң үлде, абыең төрмәдә утыра, син менә детдумда, кичер, балам, мин көчсез, сиңа ярдәм итә алмыйм!» – дип, баласыннан әле дә гафу үтенәләр сыман иде...

Тик ни генә булмасын, ул калада түгел, ә салада туган, җиде ай гына булса да авыл һавасын сулап калырга өлгергән. Рәсми булмаган авыл мулласы, коммунистлардан яшереп, аңа башта Хәерниса дип исем кушкан. Ул заманда дәүләтнең теркәү системасы йомшак булган, бик күпләрнең хәтта метрикасы да булмаган. Шулай итеп, Хәерниса исеме беркая да теркәлмичә калган. Анасы төрмәдә үлеп, баланы ятимнәр йортына озаткач та, аның исем-фамилиясен алыштырып, бутап бетергәннәр.

Люция исемен аңа тәрбиячеләр биргән. Шул көнне балалар йортына бер ятим малай һәм бер ятим кызны кабул иткәннәр. Ир балага Рево, ә кызга Люция дип исем такканнар. Ике исемне бергә кушсаң, нинди сүз килеп чыкканы яхшы аңлашыла.

Люция урысчаны әйбәт белә. Балалар йортында татар телен белүче тәрбиячеләр булса да, аның белән татарча сөйләшүче булмады, теле дә урысча ачылды. Биш ел төрмә михнәтен күреп, шуңардан ничек кирәк, шулай котыла алган Фатыйх абыйсы аны бер елдан соң гына эзләп таба алды. Абыйсын ул шундук ошатты. Әтисе кебек кырыс һәм йомыкый түгел, зиндан җәфаларын күрсә дә, елмаеп, балкып тора. Люциянең әле дә онытасы юк, беренче очрашуга ул сеңлесенә бер пакет тәмле шоколад һәм бер төргәк хуш исле мандарин күтәреп килгән иде. Шоколад юк нәрсә түгел анысы, ул кибеттә сатыла, ә менә мандаринны шул заманда каян һәм ничек таба алды икән абыйсы, менә анысы чынлап та гаҗәп?!

Фатыйх сеңлесен авылга алып кайтырга теләде. Ул да абыйсына ияреpгә әзер иде. Ләкин рәсмиләштерү эшләре шактый озакка, өч елга хәтле сузылды. Төрмәдә утырган элеккеге «халык дошманы»на, «Хрущёв язы» килүгә дә карамастан, баланы бирергә ашыкмадылар. Кызлыкка-уллыкка аласы да түгел юкса, опекунлык кына ясатасы бит!

Люция беренче классны авыл мәктәбендә тәмамлады. Яртылаш җиргә сеңгән кара бүрәнәле Сарлыбаш мәктәбен ул катгый рәвештә кабул итмәде. Авыл мәктәбендә татар телендә укыталар, ә аның татарчасы бөтенләй юк, ташка үлчим генә. Ул иң элек татар телендә дәрес биргән укытучыны аңлый алмыйча интекте. Аның хәтта дәрестән качып, укырга бармыйча калган көннәре дә булгалады. Укытучылары аңардан шактый зарлансалар да, Фатыйх абыйсы беркайчан да сеңелкәшен сүкмәде. Люцияне яманлаган укытучыларга да ул: «Килер вакыт, әле шушы кыз мәктәбегезнең горурлыгы булыр!» – дия торган иде. Абыйсының әйткән сүзе юш килде, күрәсең, беренче сыйныфта чак кына утырып калмаган укучы бала башлангыч сыйныфны барлык фәннәрдән дә «бишле»гә генә тәмамлады. Җиденче, сигезенче сыйныфларда укыганда, ул районда һәм хәтта Казан каласында узган олимпиадаларда, бәйгеләрдә катнашып, җиңүче булып

та кайтты. Укытучылар аны мактап туя алмадылар, аның исеме гел алдынгылар рәтендә булды. Фатыйх үзе дә начар укымады. Мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамлады. Ләкин кайчандыр хөкемгә тартылуы аркасында аның киләчәге якты була алмады. Аны авыл хуҗалыгы институтында икенче курста укыганда хөкем иттеләр. Төрмәдән чыккач, ул укуын дәвам итү турында уйлап та карамады. Шуңа күрә Фатыйх бөтен өметен Люциягә баглады. Мәктәптә «бишле»гә генә укып барган кыз бер каршылыксыз югары уку йортына керер дип уйлады. Ләкин тугызны яхшы гына тәмамлап, унга күчкәч, Люциягә әллә нәрсә булды, ул тәмам йөгәненнән ычкынды. Беренчедән, ул авыл мәктәбендә укуның кызыгын тапмый башлады һәм үзен башкалардан югары тотты. Икенчедән, аңа балигъ булу белән, каладан фатир алу (ятим бала бит!) мөмкинлеге туды һәм, шуны раслап, Фатыйхларга рәсми хат килеп төште. Өченчедән, ул бертуктаусыз гашыйк булды, егетләр яратты. Матур, якты чырайлы, кара көдрә чәчле, җиңел йөрешле, яшьтәшләре белән аралашырга яраткан сүзчән кызга тирә-яктагы егетләрнең күзе төшмичә калмады. Бүген кич аны берәрсе озата төшсә, икенче көнне аңар башкасы ияргән булыр иде. Ул заманнарда егетләр белән йөрү дигән нәрсә – авыл җирендә тыелган күренеш. Кызлар саф, тыйнак, ата-ана сүзеннән чыкмыйлар, хәтта уйнак егетләр дә алар янында артыгын кыланудан куркып, инсафлы һәм мәрхәмәтле булып калырга тырышалар. Заманы һәм тәрбиясе шундый. Ләкин Люция боларның барысын да читкә тибәрде. Егетләр белән уйнауның яхшыга алып бармаганын абыйсы аңа күпме генә аңлатып карарга тырышса да, тиз һәм еш гашыйк булучан мут җанлы сеңелкәшенә абыйсының үгет-нәсихәт сүзләре берничек тә барып җитмәде. Люция абыйсының хаклы икәнен аңласа да, үзен тыйнак тотарга сүз бирсә дә, йөрәге белән ул аны барыбер булдыра алмады, егетләр аныкын, ә ул исә аларның башларын әйләндерде. Мондый хәлләрдән соң бик нык аптырашта калган Фатыйх аны тизрәк авылдан җибәрү ягын карады. Хәер, анысы да озак көттермәде: Люция, көч-хәл белән укуын бетереп, «бишле»ләре азайган аттестатын кулына алып, калага юл тотты. Укыр һәм югары белемгә ия булыр дип өмет иткән абыйсы кабат ялгышты. Ул укырга түгел, ә кибеткә, сату эшенә барып керде. Бер-ике ел да узмады, аңар коммуналкадан бер бүлмә бирделәр. Тагын бер-ике елдан, каяндыр акча юнәтеп, тиешле кешеләрнең күңелен күреп, ул инде шәһәр үзәгендә урнашкан ике бүлмәле фатирга кереп тә утырды. Аннан (анысы да озак көттермәде!) ул кияүгә чыкты. Кияве Кавказ кешесе иде. Әллә грузин, әллә осетин, белмәссең! Люция аны, танышуга ук, авылга абыйсы янына өстерәп кайтты. Сослан атлы иде ул. Озын буйлы, таза гәүдәле, сеңелкәш кебек үк кара көдрә чәчле, шул як халкына гына хас булган зур кәкре борынлы, якты һәм шул ук вакытта усал, кырыс чырайлы бер тискәре адәм иде. Ни татарчасы, ни урысчасы! Кияү Фатыйхка ошамады, билгеле, ләкин ул яшьләргә каршы килеп маташмады. «Үзеңә ошый икән – тор инде!» – диде ул сеңлесенә. Соңыннан исә ул аны: «Теләсәң, син башканы да таба ала идең, шулай да бик ышанып бетмә аңа, пропискага кертә күрмә!» – дип кисәтте. Ләкин Люциянең бер җүнсез ягы бар, ул кеше сүзенә колак салырга яратмый. Сеңелкәше бер елдан соң тупырдап торган тап-таза ир бала тапты. Аңа Абрек дип исем куштылар. «Минем иң зур бәхетем – минем балам һәм сөекле ярым!» – дип сөйләнгән Люция кияүгә чыкканның беренче елында үзен шактый бәхетле кеше итеп сизде. Ләкин бәхете озакка бармады. Улы тугач, Люциянең фатирына пропискага керергә өлгергән, үзен хәзер килмешәк дип түгел, ә чын Казан кешесе итеп сизгән Сослан үзен бар кешедән югары куя башлады. Чит хатыннар белән чуалып, хатынының һәр адымыннан көнләшкән һәм һәр көнне бер юкка тавыш

чыгарган Кавказ мужигы аңа кул күтәрә башлады. Люция холкы белән сабыр, чыдам кеше, ул озак кына бу турыда беркемгә бернәрсә дә сөйләмәде. Ләкин бервакыт ошбу «тау ерткычы» аның башын ярып, ияген сугып сындыргач, ул түзмәде – авылдан абыйсын чакыртты. Аны аклый һәм яклый алган бердәнбер якын кешесе ул гына, Фатыйх абыйсы гына иде бу дөньяда! Абыйсы аларга килеп төшкәч, кияү бөтенләй куркуга калды. Абзый йомшак кеше түгел, үз сүзен өздереп әйтә белә. «Кавказ» аңардан курка һәм шикләнә иде. Гаепле кияү аның алдында бертуктаусыз акланды, гафу үтенде һәм башка беркайчан да кул күтәрмәм, дип антлар эчте. Ләкин Фатыйх аны кичермәде. Горур һәм катгый кеше иде ул – Сосланны фатирдан куып чыгарды. Ияге ярылган Люцияне хастаханәгә салдылар. Фатыйх фатирдан куылган «Кавказ»га: «Әгәр тагын бер монда күренсәң, минем «кореш»лар сине исән калдырмаячаклар!» – дип янап китте. Хәер, ул соңыннан хатыны янына әле шактый озак килгәләп йөрде, пропискада торуына ишарә ясап, Люцияне фатирны бүләм, дип куркытты. Әллә сеңелкәше аны бик нык яраткан, әллә ул аңардан бик нык курыккан, Абрекның атасы әле шуннан соң да берәр ел чамасы Люциядә яшәп ятты. Шуңа күрә Фатыйхка, аны бөтенләйгә куар өчен, бер-ике мәртәбә генә түгел, ә шактый күп тапкырлар башкала юлын таптарга туры килде. Люциянең абыйсы аркасында аңар монда көн булмаячагын аңлап алган Сослан бераздан, пропискадан төшеп, каядыр Мәскәү якларына китеп барды. Шуннан бирле аны күрүче дә, аның турында берәр төрле хәбәр ишетүче дә булмады.

Люция, ирен үз янында калдырырга теләсә дә, абыйсының теләгенә каршы килә алмады. Ул ирен бөтенләй онытырга булды, хәтта алиментка да биреп тормады...

Шуннан соң Люция тагын өч-дүрт мәртәбә кияүгә чыгып карады. Язылышып, туйлар ясап чыкты. Болар бар да рәсми төстә булды. Аның тагын кемнәр белән чуалганын чутлап карасаң, кулдагы бармаклар да җитмәс кебек! Люциянең тагын бер сәер гадәте бар: берәр ир-егет белән танышып ала да, аны шундук авылга сөйрәп алып кайта. Фатыйх абыйсы аның мәңге бетмәс ирләре, мужиклары белән таныша-таныша тәмам туеп бетте, беравык аларны күралмас хәлгә җитте. Хикмәт шунда: мужиклар аның янында озак яшәмиләр, хәер, ул үзе дә аларга артык ябышып ятмый торган иде. Абректан соң, ул башка бала тапмады, шул бер баласы белән калды. Инде менә яше кырыктан узган, ләкин беркайчан да ирсез тормаган Люция бүгенге көндә ялгызы гына яшәп ята һәм кабат кияүгә чыгу турында хыяллана иде. Бу юлы ул булачак ирен үз өенә алып кайтырга түгел, ә өйле һәм хәлле иргә кияүгә чыгарга ниятләде. Яратып һәм мәхәббәт уены уйнап түгел, ә исәп-хисап белән. Аерылмаслык итеп. «Җитәкчелек эшендә йөргән, лаеклы ялга чыккан берәр персональ пенсионер булса тагын да әйбәт булыр. Эх, бер бабай, бай бабай!» – дип сөйләнергә яраткан Люциянең ошбу теләге бервакыт чынга аша башлады...

Ләкин аңа хәтле анасына бердәнбер улын, сөекле улы Абрекны өйләндерәсе бар иде.

...Тәнзилә бу йортка керәсе килмичә генә керде. Имән капка аша узгач, ул ишеге ачык калган өйнең бусага түрендә төртелеп, туктап калды. Абрек моны сизде һәм, күтәреп диярлек, сөйгәнен өй эченә кертеп бастырды, ләкин кыз нигәдер түр ягына узарга базмады, ишек катында кагаеп калды...

Фатыйхның йорты башкаларныкына охшамаган. Яхшы нарат бүрәнәдән салынган йорт шактый зур һәм киң. Йортның ике зур залы бар, чөнки ул кайчандыр ике яклы итеп салынган булган. Колхоз салган әлеге йортның бер ягында Фатыйх үзе яшәсә, икенчесендә исә Мәрфуга исемле бер хатын яшәде.

Бу хатын сугышта катнашкан, фронтта санитарка булып йөргән, шуңа күрә дә ул сугыш ветераны санала иде. Гомерендә кияүгә чыгып карамаган, ир затының нәрсә икәнен дә белмәгән мәңге чал чәчле, ябык чырайлы, сирәк тешле бу хатын баштарак Фатыйхны яратмады, аңар эчке бер нәфрәт белән карады. Янәсе, ул зур кеше – сугыш ветераны, ә Фатыйх – криминаль шәхес. Ишекләр төрле яктан кергәнгә күрә, алар бер-берсе белән сирәк күрештеләр. Очрашканда да ветеран хатын Фатыйх белән исәнләшмәде, аны күрмәмешкә сабышты. Хатын беркайчан да Фатыйхтан ярдәм сорамады, хуҗалыкта эш килеп чыкса, ул мәктәптән пионерлар чакыртты. Пионерлар, имеш, яшь тимурчылар ветеран хатынның өенә төшеп, аның өен җыештырып, табак-савытларын юып йөрделәр. Ләкин мондый бәхет озакка бармады: Мәрфуганы инсульт дигән мәкерле авыру китереп бәрде. Үлмәде, – телсез дә, аяксыз да калмады, ләкин эзсез генә китмәде – хатынның йөреше дә, килеш-килбәте дә начар якка үзгәрде. Ул гел хәлсезлектән зарланды, ә култык таягы аның ышанычлы юлдашына әверелде. Мәрфуга авырып киткәч, аның янына Сарманда яшәүче туганнан туган апасы килеп китте, райкомнан һәм хастаханәдән комиссия әгъзалары килеп, авыру хатынга группа бирергә дигән карар чыгардылар. Ләкин ул карар чынга ашмады: Сарманда яшәүче апасы да, комиссия әгъзалары да авыру карчыкны бик тиз оныттылар. Ялгыз карчык үзе генә утырып калды. Үзе генә дип әйтү бигүк дөрес булмас, чөнки беркемгә дә кирәге калмагач, ул әкренләп Фатыйх кулына күчте. Фатыйхны кайчандыр кешегә дә санамаган хатын бераздан күршесен үз улы сымак ярата башлады. Карчыкны ашату-эчертү, керләрен юу һәм башка шундый көндәлек мәшәкатьләр Фатыйх өстенә өелде. Авыру янына кергәндә урамга чыгып, вакыт уздырмас өчен, ул ике арага ишек ясатты. Ошбу гамәл – хөрмәтле сугыш ветераны белән кайчандыр җәбер күргән төрмә кошының берләшү акты сымак кабул кылынды. Әйе, беркайчан да, миңа бу кеше кирәкмәс, дип әйтергә ярамый, син кайчандыр түбәнсетеп караган кешенең бер кирәге чыгуы да бар икән шул...

Авыру карчык алты елдан артык Фатыйх карамагында булды. Үлем түшәгендә ятканда да, ул аңа: «Карадың, рәхмәт сиңа, озак итеп, исән-сау яшәргә насыйп әйләсен үзеңә!» – дип, изге теләкләрен теләде. Мәрфуга үлде, шулай итеп, йортның икенче ягы да Фатыйхка калды. Хәер, Казан каласыннан билгеләнү белән килгән бер яшь укытучы кыз урнашырга дип йөргән иде анда йөрүен, тик әллә кеше сүзенә ышанды, әллә Фатыйхтан (авылдашлары өчен ул кыргый иде!) шикләнде, әлеге йортка керергә базмады...

Йорт чынлап та иркен иде, шактый иркен. Ләкин йортның иркенлеге аның зур булуында гына түгел, ә йорт-җиһазлары аз күләмдә булуына да бәйле иде. Мебель дигән нәрсә дефицит, акчаң булса да, кибетчеләр белән дуслыгың юк икән, ала алмыйсың. Ә Фатыйх беркайчан да фабрикадан чыккан такта ярмасына, ягъни чүбектән ясалган җиһазга кызыкмады. Ул чын агачтан ясалган йорт җиһазы өчен җанын бирергә дә әзер иде. Дөресен әйткәндә, ул аны үз куллары белән ясады. Түрдә торган агач сервант, өйалдындагы кием шкафлары, бүлмәләрдәге киң сәкеләр аның кулы тудырган бер могҗиза иле. Нәфис итеп сырланган фабрика мебельләренә караганда, бәлкем, алар күрер күзгә тупасрак, шыксызрак та булып күренергә мөмкин, ләкин алар аныкы һәм нык, сыйфатлы, мәңгелек иде.

Идәнгә дә конвейердан төшкән гадәти келәмнәр түгел, ә кулдан эшләнгән чуар паласлар җәелгән. Андый паласлар сатуда юк, ул аларны кайчандыр заказ биреп суктыртты. Фабрика келәмнәре бер дүрт-биш елдан тишелеп чыгарга, төсләре уңып, чатлары бөгәрләнергә мөмкин, ә менә мондый чын паласларга шайтан да булмый.

Тәнзилә белән Абрек капма-каршы кешеләр иде. Алар төс-кыяфәтләре белән дә бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. Тәнзилә ак йөзле, уртача буйлы, ә Абрек кара чырайлы, озын буйлы. Табигатьтән ак чәчле, сипкелле кызга күз явын алырдай матур йөзле Абрекның ничек күзе төшкәндер, анысын әйтүе кыен, ләкин кызның да үзенә бер төрле сөйкемле сөяге булуын, күрәсең, инкарь итеп булмый torгандыр. Тәнзилә белән алар стройбригадада таныштылар. КИСИның икенче курсында укыган Абрекны авылга ферма төзергә җибәрделәр. Ул ике ай буе күрше колхозда сыер фермасы төзеде. Фатыйх абыйсында яшәде, күрше колхозга барып эшләде. Өч студент егет һәм биш шабашник. Студентлар кирпеч ташыдылар, цемент белән комны суда бутап, тимер чаннарда измә изделәр. Колхоз идарәсе эшчеләр белән килешүләр төзеп, акча түләү мәсьәләсен дә алдан хәл итеп куйды. Ләкин шабашникларның бригадиры булып саналган Хәяли атлы бер бәндә төзелештә кайнашкан студентларны, мәкерле рәвештә, кыса һәм рәнҗетә башлады. Егетләрне чаптырыпмы-чаптыра, ә тулы эш көне язмый. Яшьләрнең акчасын кисү өчен шулай эшләнә икән, чөнки шуның аркасында бригададагы шабашникларга акча күбрәк эләгә. Алай гына да түгел, Хәяли үзе аз гына да селкенми, терлекчеләр йортында гәҗит-журнал укып, йокы симертеп ята. Тәнендә Кавказ халкының кызу каны уйнаган Абрек, бу гаделсезлеккә түзеп тора алмый, билгеле, Хәялигә телдән кисәтү ясый. «Йә син безнең кебек үк эшлисең, йә син бригададан китәсең!» Хәяли егетнең әлеге кисәтүенә көлеп кенә карый һәм аңар: «Я – бугор! Я не должен выкладываться!» – дип җавап кайтара. Абрек, артык озак уйлап тормый, шул көнне Хәялинең борынын сугып сындыра. Бригадир кача. Шушы колхозда гына гомер кичергән Хәяли төнлә белән, Абрекны кыйнатырга дип, бер машина яшьләр төяп, Сарлыбаш авылына килеп төшә. Нәкъ шул көнне кыр юлында ул Тәнзиләне очрата: төзелештән иртәрәк киткән Абрек авылга җәяү генә кайта. Аланлыкта җиләк җыеп йөргән ак күлмәкле Тәнзилә аңар шулвакыт бер фәрештә булып күренә, ул аның җиләкләр белән тулган кәрҗинен күтәреп кайта. Әле яңа гына унынчы классны тәмамлаган кыз һәм институтның икенче курсында укыган егет арасында яшертен сөю хисләре кабына. Шул төнне ул кызны озатырга чыга, алар төне буе елга ярында учак ягып, сөйләшеп утыралар, ә Абрекны кыйнарга дип килгән авыл яшьләре, көтә-көтә көтек булып, бер дә юкка урыннарыннан кузгаткан Хәялине сүгә-сүгә, килгән җирләренә кире кайтып китәләр...

Шул төнне Тәнзиләне озатырга чыгу исә студент егетнең сәламәтлеген, яшь гомерен саклап калды. Елга ярындагы тәүге очрашу Абрекның әле дә хәтереннән чыкмый. Гыйшык киче мәңгегә онытылмаслык булып аның йөрәгендә яши. Егет иң элек кызның акылын һәм күңел сафлыгын ошатты. Калада андый акыллы, саф күңелле кызлар аз, иркен һәм ирекле тормыш яратучылар, бозыклар шактый...

Яшьләр елга ярында таңга хәтле йөрделәр. Тәнзиләнең әтисе дә, әнисе дә йокларга иртә ята, алар кызларының өйдә юклыгын сизми дә, белми дә калдылар.

– Мин сине аңламыйм, – дип гаҗәпсенде Тәнзилә. – Миңа әлегә тиклем күз атучы булмады! Нәрсәм белән шулхәтле ошадым соң мин сиңа?

– Ә син нәрсә, күз атмаслык кыз түгелме? – дип кайтарып сорады Абрек.

– Белмим, – дип башын аска иде кыз, – егетләр мине нигәдер читләтеп үтәләр, күрәсең, миңа якын килергә куркалар, кеше яулый алмаслык крепость кебек мин, күрәсең...

– Ә мин?

– Син?! – дип көлде кыз. – Син башка!

– Яулый алдым, димәк?!

– Юк, Абрек! – дип кырт кисте ул, үзе турында әзрәк югары фикердә торган егетнең күңелен төшереп. – Мине яулар өчен әле сиңа ул яу юлларын бик озак таптарга туры киләчәк...

– Куркытасың?

– Юк, өркетмим, дөресен әйтәм...

Кызның әнә үзенә шундый якын китермәслек, әзрәк киребеткән кеше булуы, каршылык куя белүе Абрекның, киресенчә, аңа карата булган кызыксынуын һәм аны яулап алу теләген көннән-көн көчәйтте кебек. Тиздән әлеге тырыш һәм уңган авыл кызы Казандагы педагогия институтына укырга керде. Кыз калага күчеп килгәч, гашыйклар ешрак күрешә башладылар. Тәнзилә берни дә сизенмәде. Иң мөһиме, Абрекның кем булуы, нинди нәселдән чыгуы да аны нигәдер кызыксындырмады. Янында Абрек бармы – бар, ул аны яратамы – ярата, әлегә кияүгә чыгу турында сүз барамы – бармый, бармагач, шул нәрсә турында сүз кузгатып тору кирәкме соң?! Юк, кирәкми!

Ике елдан соң, егет аңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясар, дип, кызның уенда да юк иде. Дөресен әйткәндә, ул аңар бик әзер дә түгел иде. Институтны тәмамлагач кына кияүгә чыгарга хыялланган кыз егетнең әлеге тәкъдименнән тәмам аптырашта калды. Ләкин каршы да килә алмады – ярата иде ул Абрекны, алай гына да түгел, аны дус вә якын итте. Ул хәтта егетнең әти-әнисе сөймәгән нәселдән икәнен белсә дә, кыз, аны яратканга күрә, бу нәрсәгә артык зур әһәмият бирмәде. Эш шунда ки: Тәнзилә – Абрекның тәти абыйсына, аның әнисенә, әтисенә, сеңлесенә, гомумән, шушы гаиләгә мәңге кичерә алмаслык кайгы, зыян китергән Хөснул абзыйның оныгы иде...

Кунак кызы кая карарга да белмичә басып торганда, Абрек каладан күтәреп кайткан зур-зур сумкаларны тиз генә түр якка кертеп, чатка өеп куйды. Алар авылга поезд белән кайттылар, бәйрәм алды булганга күрә, поезд эчендә басып торырлык урын да юк иде. Алар әнә шул күчтәнәч төягән, кием-салым тутырылган сумкаларга утырып кайттылар...

– Кер, әйдә, нишләп туктап калдың?! – дип, түр якка өндәде аны Абрек. – Кер, оялма! Кер! Яратам мин тәти абыйның шушы йортын! Үзенә бер төрле уютный ул! Чат бүрәнәдән салынган, на-а-а-рат срубтан! Сизәсеңме, ниндидер бер сере дә бар кебек үзенең. Ошыймы сиңа монда?

– Миңа үз нигезем күбрәк ошый, – дип, төксе генә җавап кайтарды кыз.

– Да-а! Сезнеке дә начар түгел, хәер, һәркемгә үз нигезе якын. Ну, менә безнеке... ягъни... абзыйныкы бөтенләй икенче! Во!

Абрек, телен шартлатып, бармак очын югары күтәрде. Ул шул кыланышы белән сөеклесен әзрәк үпкәләтте дә сымак. Чын авыл кызы булганга, башкача тәрбия алганга, ул кайвакыт Абрекны аңлап та бетерә алмый һәм аның кайбер сәер кыланышларын гаепкә бөгәргә генә тора иде...

– Яратмыйм бу йортны...

– Нигә?

– Сәбәбе бар.

– Нинди? Әгәр сер булмаса...

– Әй... – Тәнзилә җилкәсен генә җыерды. – Сүлисем килми...

– Әйтәм бит, бу йортның сере бар, дип. Яшермә, сөйлә инде...

Кызның шулай дип әйтүе, Фатыйх абыйсы яшәгән йортны яратмавы Тәнзилә тарафыннан аларның нәселен, ыруын өнәмәгән кебегрәк яңгырады. Бу хәл

Абрекны шактый сагайтса да, егет артык игътибар бирмәде. Чөнки ул яшь, ул бүген гашыйк, чөнки аның бүген бернәрсә турында да баш ватып, акыл сатып торасы килми, аның сөясе һәм сөеләсе, сөйгән кешесе белән тизрәк кавышасы килә...

– Матурым...

– Әү?!

– Син мине яратасыңмы?

– Беләсең бит инде...

– Белмим, әйткәнең юк...

– Әй, кыланмасана инде...

– Ни булды сиңа, ә?!

– Берни дә булмады...

– Шулай да...

Абрек сөйгәнен, яннан килеп, кочып алды. Тәнзилә карышмады, башын аның иңенә салып, беразга тын калды. Ләкин Абрек сизде, йөрәге белән сизде, кызның күңеле бер дә тыныч түгел, шактый борчулы иде. Сизсә дә, ул кыздан берни дә сорамады, бераздан Тәнзилә үзе телгә килде...

– Башта безгә кайтырга кирәк иде...

– Кайда? Арҗаккамы?

– Әйе...

– Без сезгә кайттык бит инде, узган атна гына кайттык, атаң да, анаң да риза булып калдылар...

– Синең алда...

– Ничек минем алда?

– Синең алда, әйе, риза булдылар, ләкин соңыннан... Бөтен колак итемне ашадылар...

– Тә-ә-әк! – дип аптырады ул. Сөйгәне алдында юмаланып, назланып торган егет кинәт кенә кызып китте. – Иске авыздан – яңа сүз! Нәрсә, ошатмадылармы? Ни өчен, әйт!!!

– Тынычлан...

– Юк, әйт! Ни өчен? – дип ярсыды Абрек. – Кайсы җирем ошамады? Аларга...

– Бар җирең дә ошады...

– Ну, а в чём тогда дело? – Абрекның, кала егете булгач, тиктомалдан гына әнә шулай шәһәр лексиконына күчә торган гадәте дә бар иде.

– Дело в другом...

– В чём... аңламыйм...

Тәнзиләнең атасы Сәгыйть атлы булса, анасы Рузалия исемле иде. Анасы аның йомшак һәм чиста күңелле, кирәген генә сөйли торган аз сүзле бер хатын иде. Атасы исә, киресенчә, кырыс мужик, астыртын холыклы, киребеткән, кеше сөймәүче, кеше яратмаучы кызыксыз адәм иде. Алар өч бала үстерделәр. Тәнзиләнең тагын ике абыйсы бар. Берсе Чаллыда яши, өйләнгән, авылга сирәк кайта, икенчесе, кечесе әле яңа гына Совет армиясе сафларын тулыландырды. Атасы исә колхозда заправщик булып эшли, бензин белән мазут аның кулында, аның карамагында. Сигез класс кына белеме булган Сәгыйть төшемле эштә йөри, механизаторлар өчен колхозда аңардан да зур кеше юк. Менә шушы кеше, Тәнзиләнең атасы Фатыйхны һәм анасын төрмәгә олактырган Харис абзыйның улы иде. Фатыйх белән Сәгыйтьне кан дошманнар дип атау һич тә дөрес булмас. Чөнки алар беркайчан да үзара дошманлашып, бер-берсенә зыян салып, пычрак атып йөрмәделәр, алар бары тик бер-берсен күрмәскә,

белмәскә генә тырыштылар. Чөнки ике якның да хәзерге көндә үткәннәрдә казынасы, ата-бабалары кылган ялгышы, гөнаһы өчен, бер-берсенә үч тотасылары килми иде. Ләкин шушы ике якның да якын улы һәм кызы – яшь йөрәкләрнең бергә кушылырга теләк белдерүләре исә хәзер әнә шул булган тынычлыкны да җимерергә, дөньяның астын-өскә китерергә тора иде. Тәнзиләнең ата-анасы җор сүзле, шаян холыклы, кеше белән аралашырга яраткан Абрекны шундук үз иттеләр, ләкин аны Фатыйхның туганы икәнен белгәнгә күрә, әллә ни зур шатлык вә куаныч кичермәделәр. Егет кыз өенә кунак булып кына түгел, ә аның кулын сорарга дип кайткан. Аңа ни «җә!», ни «юк» дип тә әйтә алмадылар. Ләкин алар кияү егетенә берни дә сөйләп, берни дә аңлатып тормадылар. Бары тик егетне озаткач кына, атасы Сәгыйть Тәнзиләнең, үзе әйтмешли, «рәхәтләнеп колак итен ашады...»

– Абрек...

– Да, милая...

– Мин ул турыда бик күп уйландым, авылга син мине сорарга кайткач та... кат-кат... уйландым... һәм шундый фикергә килдем...

– Нинди?

– Язмышыма буйсынырга, аның ихтыярына иярергә булдым...

– Ничек була ул? Аңламыйм?

– Әлегә хәтле ничек барган, шулай барсын, дидем... үземә...

– Нәрсә ул...

Абрекның түземлеге бетә башлады. Эшнең нәрсә турында барганын төгәл генә аңламаса да, күңеле белән ул ниндидер ярамаган нәрсә сизенде. Тәнзиләгә өйләнү аңа ниндидер бер киләчәк бәланең башы булып тоела башлады. Чөнки улы энисенә, авылдагы Сәгыйть абзый кызына өйләнәм, дип сүз чыгаргач, энисе нигәдер ярым җитди һәм ярым шаяртып: «Тәти абыең шаккатыр инде бу хәбәрне ишеткәч!» – дип әйтеп, көлеп куйган иде. Көлүе дә ничектер ихлас булмады: мыскыллы, мәкерле көлү...

– Абзый кайда йөри соң? – дип сорады аңардан кыз.

– Шайтан белсен! – дип кулларын җәйде егет. – Кайвакыт шулай югала да куя ул, җан бетереп эзләсәң дә таба алмыйсың! Бервакыт каладан кайттым, капка ачык, ишекләр ачык, бөтен дөньясы ачык... Җир бетереп эзлим, юк, табып кына булмый бит! Күршеләргә кергәндер, дип уйлап куйган идем, карасам, залдагы зур сандык артына төшеп яткан да рәхәтләнеп шунда йоклап ята... Җен кебек бит ул, кыргый...

– Уяттыңмы?

– Юк. Йокласын, мәйтәм... Чәйнек куеп, өстәл янына чәй эчәргә генә утырган идем, артымда ук тәти абый басып тора. Үзе көлә, үзе идиот кебек елмая... «Чәең тәмле булсын, энекәш!» – ди.

– Чәй куйдыгызмы?! – Чарлакка менә торган текә баскыч артыннан карлыккан, пышылдап кына чыккан ир кеше тавышы ишетелде. Бу – Абрекның тәти абыйсы, ягъни йортның хуҗасы иде. Ул түбәдән төшеп килә икән. Кулына талдан үргән һәм бер чаты чалшайган дәү кәрҗин тоткан. Абзый инде болай да тонык һәм басынкы тавышын, эссе көндә салкын чишмә суы чөмергәннән соң, бөтенләй югалткан иде...

– Тәти абый! Сәлам!

– Сә...лам...

Абрек абзыйны кочаклагандай итте. Ләкин ул шактый уңайсыз һәм җайсыз килеп чыкты, чөнки хуҗа абзый минутлык хисләнүләрне, ясалма кылануларны күңеле белән бигүк кабул итеп бетерми иде.

– Шушымы? – диде Фатыйх, кыз ягына ияге белән генә ишарә ясап.

– Шушы! – дип елмайды Абрек һәм тиз арада кызны кочагына да алырга өлгерде.

– Исәнме, Фатыйх абый! – дип эндәште кыз, кысык кына елмаеп.

– Нигә? Мине беләмени? – дип, җилкәсен җыерды абзый.

– Ничек сине белмәсен инде! – диде энекәш. – Сезнең авыл кызы бит! Әнигә әйтеп аңлаттым бит инде, сиңа әйтмәдемени?

– Синең әнкәңнән сүз алганчы, тыңла берәр ялганчы, диярсең. Дөнья кебек серле бит ул синең әнкәң...

– Менә таныш бул: Тәнзилә! Өйләнешергә булдык!

– Өйләнешегез суң...

– Каршы түгелсең, димәк?

– Ә нишләп суң әле мин каршы булырга тиеш?

– Хәер-фатыйха...

– Хәер-фатыйханы, энекәш, ата-анадан сорыйлар...

– Тәти абый!

– Нәстә тагын?

– Син бит инде атам урынына калган кеше...

– Анысы шулай...

– Анам риза...

– Анаң синең бөтен нәрсәгә дә риза: дөнья ярылса да, шөкер, әле дә ярый ярылды, дип утырачак...

Хуҗа абзый, Абрекны калдырып, капылт кына Тәнзиләгә текәлде. Юк, ул аңар ашардай булып, кояштай тулып карамады, аның кем икәнлеген белергә теләп, кызыксыну уе белән дә янмады, әйтерсең лә ул барысына да битараф һәм бу ярәшүләр, кавышулар аның өчен бөтенләй кызыксыз нәрсә кебек иде. Менә дөньяда ул бар, Фатыйх бар, һәм ул үзенең дәвамын инде беркемдә дә күрми торган иде. Андый дәвамның кирәге дә юк кебек, ул беткәч, ул үлгәч, аңар дәвам ниемә соң?

– Фатыйх абый! – Егет кеше сизмәгәнне, бары тик хатын-кыз күңеле белән сизенгән Тәнзилә беренчелекне, ниһаять, үз кулына алды. Әйе, югалып калырга ярамый, тимерне кызуында сугарга кирәк. Яратам, өйләнәм, дип чәчрәп торган егетне кайсы кызның үз кулыннан ычкындырасы килсен икән!

– Әйе...

– Сез мине танымыйсызмы?

– Таныйм да, танымыйм да кебек...

– Мин...

– Яшьләрне танып бетереп була димени суң аларны? Кеше баласы бик тиз үсә, үскәнен дә күрми каласың...

Үз гомерендә бер мәртәбә клубка төшеп карамаган, колхоз эшенә чыгып, колхозчылар белән аралашмаган, шушы җылы почмагыннан, мәшәкатьле хуҗалыгыннан, бирән сарыкларыннан арына алмаган Фатыйх, нидер сизенгәндәй, кинәт кенә катып калды,ябык муенында кылыч башы сымак очланып торган кадыгын бер аска, бер өскә таба уйнатып алды. Сузынкы аксыл йөзе караңгыланып, кара янып чыкты...

– Син нәстә...

– Әйе...

– Заправщик кызы мәллә?!

– Әйе, мин Сәгыйть кызы, әнием Рузалия...

– Бабаң Хөснул, шулаймы?! – Соңгы сүзенә ул каты басым ясап, мыскыл

итебрәк һәм шуннан ниндидер тәм табып әйтте. – Аңлашылды, башка сүзем юк...

Кәрҗинен күтәргән Фатыйх, өстерәлеп диярлек, чолан ягына чыгып китте. «Тәти абый, син кая?!» – дип артыннан атылган Абрекны ул кул изәп кенә туктатты. Егет, тәти абыйсы белән аңлашуның мәгънәсе юклыкка төшенеп, тиз генә кире керде һәм озак кына сүз дәшәргә кыймыйча торды. Ул арада шаулап газда чәйнек кайнап чыкты. Абрек, йөгереп барып, газны сүндерде. Әллә ашыкты, әллә чәйнекне җайсыз тотты – чәйнек капкачы шапылдап идәнгә барып төште. Шул кечкенә кенә чәйнек капкачы да әллә нихәтле тавыш чыгарды...

– Тәнзилә...

– Әйе...

– Аңлат әле... что ваще происходит, а?

– Кая?

– У нас вот...

– Тебе это надо?!

– Надо... знаешь...

Дөресен әйткәндә, Тәнзилә аңар дөресен сөйләргә курыкты. Дөресен сөйләп, ул ике араны суындырырмын, дип курыкты. Дөреслектә исә бу дөреслек яшьләргә түгел, ә турыдан-туры олыларга кагыла иде. Тәнзиләнең бабасы аркасында төрмәгә утырган Фатыйхның язмышы, ике гаилә бер-берсе белән каршы як булсалар да, тиздән башлы-күзле булырга торган яшьләр бәхетен җимерергә тиеш түгел иде кебек. Ләкин кияү егетенең, булачак иренең барысын да беләсе килә, һәм аңа әйтмичә мөмкин дә түгел. Хәер, иң элек аны анасы сөйләргә тиеш иде, ә ул, күрәсең, сөйләмәгән, сөйләшүне кирәк дип тапмаган.

– Моны сиңа мин түгел, ә анаң сөйләргә тиеш иде, – дип башлады ул сүзен. – Безнең Хөснул атлы бабабыз бар иде, әтинең әтисе ягъни. Минем бабам синең шушы тәти абыеңны илленче елларда төрмәгә утырткан...

– Төрмәгә? Ул нәрсә, судья булган мәллә?

– Юк, судья түгел, депутат.

– Депутатлар шундый хәтәр булалармыни?

– Депутат кына түгел, авыл куштаны булган...

Тәнзилә бар булган, белгәнен егеткә сөйләп биргәч, Абрек, ирексездән, уйга калды. Әйе, яшьләр күзлегеннән караганда, артык кайгырырлык нәрсә юк та кебек, ләкин тирәнрәк казынсаң, күңелле нәрсә аз. Беренчедән, бер-берсен яратмаган ике гаиләне татуландыру һәм туганлаштыру шактый авыр булачак, икенчедән, тәти абыйсы шушы уйланмаган хәтәр адымы өчен Абрекны беркайчан да кичермәячәк, кичерсә дә, ул кичерү чын-чынлап түгел, ә бары тик сүздә генә калырга мөмкин иде...

– Чистый бер Шекспир драмасы булды бу! – дип тел шартлатты Абрек һәм, нәрсә булса да эшләргә теләп, ике зәңгәр чәшкәгә дә кайнар су коеп, кечкенә чәйнектән шуларның һәрберсенә чәй тамызып чыкты. – Әйдә... утыр!

– Нигә?!

– Чәй эчәбез...

– Юк... утырмыйм...

– Нишләп?

– Тамагымнан берни дә үтми...

Абрек аны башка кыстамады. Тышта бик иләмсез эссе. Ул сусаган, аның

үтереп эчәсе килә. Чәен шопыра-шопыра эчте. Абрекның чәй күрмәгән кеше сымак, кабаланып, тавыш чыгарып эчүе кызның исә саруын гына кайнатты...

– Бәлкем, безгә чыгарбыз?! – диде кыз.

– Юк, сезгә иртән... Кичкә әни кайта...

– Ул кайтып кына нишләр?

– Безнең әни үткен кеше, абзый белән ничек тә сөйләшер...

...Әйе, Люциянең холкы шундый – гел мөгез чыгарырга ярата. «Уптымилаһи»лыгы белән ул теләсә кемне чатка китереп терәргә мөмкин. Улы белән булачак киленен ярәшеп йөргән җиргә үзе генә түгел, ә бөтенләй чит кеше белән кайтып төште. «Волга» машинасында. Ул пенсия яшенә җиткән, отставкадагы милиция полковнигы булып чыкты. Исеме – Гобәй, фамилиясе – Хәйруллин. Карап торырга болай ярыйсы гына кыяфәтле кебек үзе – олы гәүдәле, киң җилкәле, тулы йөзле, төскә-биткә дә ямьсез кеше түгел. Ләкин картаюы җиткән – җилкәләр салынган, чәчләре сирәкләнгән, йөреше дә, билгеле ки, яшьләрчә түгел, ә картларча гына. Инде кемнәр белән генә яшәп карамаган, кемнәрнең генә күңелен күрмәгән сеңлесенең бу соңгы гамәле дә абыйсы өчен артык зур яңалык булмады. Люция белән Гобәй аның туган нигезен, бусагасын атлап керү белән үк, Фатыйх шаян сеңлесен: «Нигә кирәк бу?» – дигәндәй, үтә дә каты кырыслык белән каршы алды. Бердән, ул сеңлесенең авылга ирләр ташуыннан туйса, икенчедән, милиция хезмәтендә кайнаган әлеге олы яшьтәге абзыйны күңеле белән һич кенә дә кабул итә алмады. Люциягә ияреп кайткан кунак та шуны сизенде булса кирәк, баштарак матур итеп, ике куллап күрешсәләр дә, үзара сөйләшүләр нигәдер барып чыкмады...

Бераздан бик күп күчтәнәчләр төяп кайткан Люция, кунакларга табын әзерләү ниятеннән, аш ягында табак-савыт юа башлагач, Абрек белән Гобәй, тәмәке тартырга дип, тышка, ишегалдына чыгып киттеләр. Фатыйх янында ялгызы гына калырга читенсенгән, Абрекка койрык сымак тагылып йөргән Тәнзилә дә аларга иярде. Абый белән сеңелкәш бер мәлгә өйдә икәү генә калдылар...

– Гобәй ошамады инде алайса?! – дип сүз башлады Люция.

– Әйе, ошамады, – диде Фатыйх.

– Син торасы түгел аның белән, абый, мин торасы! – дип аңлатты тегесе.

– Туйдым мин...

– Нәрсәдән?

– Ирләреңнән...

– Ни булган аларга?

– Ел саен яңасын өстерәп кайтасың!

– Монысы соңгысы булыр, абый, борчылма! – диде хатын һәм үзенә генә хас бер иләмлек белән кеткелдәп көлеп куйды.

– Люция!

– Әү?!

– Көлмә, яме! – дип чәчрәде абыйсы. – Соңгы мәртәбә кисәтәм: бүтән монда беркемне дә алып кайтмыйсың! Минем изге йортыма бу ментны башка аяк бастырасы булма, җәме!

– Әгәр кияүгә чыксам, нәрсә?

– Кияүгә? – дип гаҗәпсенде Фатыйх. – Шуңамы?

– Әйе, без тиздән өйләнешәчәкбез. ЗАГСка гаризаларны бирдек...

– Га-а-җә-ә-әп!!! – дип сузды Фатыйх. – Улың өйләнә, ә син кияүгә чыгасың! Тфү!

– Ә нәрсәсе ошамый?

– Нәрсә таптың син ул карт полковникта?! Син бит ментоннарны сөймәгәнемне яхшы беләсең? Алар бит минем бөтен тормышымны җимерделәр, аңлыйсыңмы син шуны, юкмы? Минекен генә түгел, әтинекен дә, әнинекен дә һәм хәтта синекен дә, ачуым бер килмәгәе!

– Тыңла әле мине, абый! – диде Люция, су краны астында чайкаган кашык-чәнечкеләрен табактагы юынтык суга атып. – Нишләп син һаман да минем тормышыма тыгыласың?! Нәрсә ошамый сиңа?

– Нәрсәгә кирәк сиңа бу карт мент, әйт әле?

– Миңа аның фатиры кирәк.

– Фатиры?

– Әйе, фатиры, машинасы, – дип тезеп китте тегесе, – дачасы, акчасы...

– М...да! – дип исе китеп карап куйды ул Люциягә. – Сеңелкәш... Мин сине башсыз, дип йөри идем, ялгышканмын икән...

– Яшьрәкләр белән яшәп карадым бит инде, абый, берсен дә үз янымда калдыра алмадым. Бу кеше миңа кирәк, менә хәзер кирәк. Достойный, персональный пенсионер, хатыныннан аерылган, балалары белән аралашмый. Ну, әйтик, Абрек тиздән өйләнәчәк! Өйләнгәч, кая алып кайтыр ул хатынын?! Безгә, фатирга. Ә минем яшьләр белән торасым килми, аңлыйсыңмы, аерым торасым килә!

– Теләгең изге, кәнишне...

– Ансыз булмый, абый...

– Яратасыңмы соң син ул кешене? – Фатыйх сеңлесенең әлеге кешене яратмаганын сизеп һәм белә торып сорады.

– Беләсең бит инде, абый...

– Юк, мин берни дә белмим...

– Үз гомеремдә мин бер генә кешене яраттым, ул да булса улымның атасын! Ә син...

Фатыйх, ирексездән, чыраен сытты. Абрекның атасын, ягъни Сосланны ул яратмады, сеңелкәшен мыскыл итеп яшәгәне өчен аны сөймәде. Аларның аерылышуында, Абрекны атасыз калдыруында күпмедер дәрәҗәдә Фатыйхның да гаебе бар иде. Әгәр ул калага барып, Сосланны фатирдан куып чыгармаса, ул әле һаман да шунда яшәп ятар, сеңелкәше исә үзендә ирен куып чыгарырлык көч таба алмаган булыр иде...

– Сезнең аерылуыгызда минем гаебем юк...

– Бар, абый, бар...

– Нәстә! – дип кабат кызды абыйсы. – Оныттыңмыни, үзеңне эт итеп кыйнаганын?! Шешенә-шешенә елап йөргәнеңне оныттыңмыни?

– Әйе, оныттым, – дип килеште Люция. – Ә менә аны, бәгъремне, әле һаман да оныта алмыйм...

Аңламассың бу хатын-кызны! Кыйналып яшәсә яши, әмма шуны (яратам дигән булып!) оныта алмый. Тик андый канэчкечне ничек итеп яратырга була да ничек итеп аны якты хатирәдәй мәңгегә күңелеңдә сакларга була?!

Фатыйх кабат уйга калды. Люциянең карт полковникка кияүгә чыгуы бер нәрсә, ни әйтсәң дә, ул аның, үзе әйтмешли, уйланган эше. Ләкин Фатыйхны бүген бөтенләй икенче нәрсә борчый, алай дип кенә әйтүе аз, ул аның ачуын кабартып, җан тынычлыгын ала язган иде. Абыйсын иң борчыганы – Абрекның Сәгыйть кызы Тәнзиләгә өйләнүе. Әйе, Сәгыйть кайчандыр Фатыйхлар гаиләсенең башына җиткән, тулы, тату гаиләне җимереп аткан авыл куштаны Хөснулла углы иде. Яшьләргә аларга барыбер, утка каршы очкан күбәләк сыман,

нишләгәннәрен һәм кая барып бәрелгәннәрен дә белмиләр. Алар бүген бәхетле, бер-берсен өзелеп яраталар, ә кирәкмәгәнне уйлап, баш ватып утыру алар өчен кирәк нәрсә түгел. Яратмаган, сөймәгән чит бер нәсел белән кушылырга җыена аларның асыл кошы! Алда ярәшү минутлары, туй мәҗлесләре булыр! Нәрсә, Фатыйх шунда барып, шулар белән бер табында утырып, куштан Хөснулның оныгын, булачак киленне мактап, сүз сөйләп торсынмы? Ярар, аталары ялгышын, явызлыгын алар инде оныткан да, ди. Гомер бара, ага, алга, киләчәккә күз ату мәслихәт, ди. Ләкин аларның бабалары кылган әшәкелекне күңелең белән онытырга теләсәң дә, аны барыбер китек җаныңнан этеп чыгара алмыйсың. Нәфрәт хисе, ни кызганыч, Фатыйхның канына сеңгән. Сәгыйтьләр ягы бу каршылыкны күрмәмешкә сабышса да, әлеге кушылу-кавышу мәҗлесләре барыбер яртылаш кына килеп чыгачак, чөнки бер-береңне күралмау хисе инде күптән күңелләргә юшкын булып утыргандыр. Ләкин иң аянычы шул: әлеге гаиләдән бәла-каза күргән, газап-җәфа чиккән, матур, тулы гаиләдә үсәсе урынга, тормыш мәхшәреннән ятимнәр йортында ышыкланырга мәҗбүр булган Люциянең бу хәлгә битараф калуы, әлеге бәлане күрмәскә тырышуы Фатыйхның җен ачуларын чыгарды...

– Син шуны белмәдеңме?! – Фатыйхның басынкы, түбән тавышы бу юлы нигәдер яңгырап чыкты, шомлы яңгырады. Юган тәлинкәләрен ап-ак чиста чүпрәк белән сөртеп, киштәгә тезәргә торган Люция, эшеннән тукталып, абыйсына текәлде. Чыраеның җитдилегенә караганда, абыйсы аның белән уйнап сөйләшми иде кебек. Люция – җүләр түгел, сүзнең нәрсә турында барганын бик тиз аңлап алды...

– Нәрсә?!

– Улыңның кем кызына өйләнгәнен белмисеңме?

– Беләм...

– Белгәчтен, нишләп миңа алдан ук әйтмәдең?!

– Әйтеп торуның кирәген тапмадым...

– Ничек алай?! – Фатыйх, гарьлегеннән буыла язып, утырган урыныннан сикереп үк торды.

– Менә шулай...

– Оят түгелме сиңа? – дип кычкырды Фатыйх. – Синең өчен мин җанымны бирергә дә әзер идем, сеңлем кебек кенә түгел, мин сине кызым кебек үстердем. Үстердем, яшәргә көч бирдем, гомерең буе сиңа җил-яңгыр тидермичә саклап килдем. Ә син шул яхшылыгыма нәрсә белән түләдең?! Төкердең син минем ул яхшылыгыма, матур итеп төкердең! Ел саен борчу китердең, ел саен берәр мужик өстерәп кайттың! Менә шул...

– Яхшы, – диде Люция. – Яхшылыгың өчен түләргә әзермен, хезмәт хакымнан сиңа тиешле акчаны биреп барырмын!

– Син мине аңламадың, җүләр! Миңа синнән берни дә кирәк түгел! Миңа синең аңлавың гына кирәк! Әгәр балаңа әйтеп аңлатсаң, бәлкем, ул уйланган, безгә дошман булган нәсел белән кушылудан тоткарланыр иде! Аңлыйсыңмы син шуны, юкмы?!

– Аңлыйм да, аңламыйм да...

– Аңламыйсың син, аңларга да теләмисең...

– Абый! Ну, мин нишли алам соң инде?! Абрек шушы кызга өйләнергә теләгәч, мин нишли алам? Әйе, аңлыйм, күңелле хәл түгел! Ләкин ни-и-ишлим?! Әйт...

– Әй, сезне! – дип кул селтәде Фатыйх һәм шул көнне өйдән чыгып югалды...

### Икенче бүлек

## Тәнзилә

Мәҗлес Фатыйхсыз гына узды. Табында юк нәрсә юк иде. Каладан алып кайткан күчтәнәчләр янында Люция пешергән ризыклар да күп иде. Нәрсә-нәрсә, ул – аш-суга оста хатын. Ул бүген ике төрле бәлеш куйды, ике тавык тутырды. Бәлеш белән тавык ашап туймаслык булган. Абрек әнисенең пешергән ризыкларын мактый-мактый ашады, ә Абрекның авыл турындагы әкиятен тыңлап арыган полковник (күрәсең, бик нык ашыйсы килгән!) тавык ашын ияк астына агыза-агыза, буяла-буяла ашады. Тәнзилә генә җүнләп ашамады, чемченеп утырды. Әйе, ул кәефсез иде. Тынлыкны Абрек бозды...

– Әни!

– Әү, улым?

– Өйләнешкәндә, хәер-фатыйханы кем бирә?

– Кызның да, егетнең дә əти-әнисе бирә.

– Ну, шулай булгач, – дип, кулын җәйде егет. – Син ризадыр бит? Син безне өйләнештерергә ризамы?

– Риза, улым, риза.

– Әтием юк, аңардан ризалык ала алмыйм. Тәнзилә ягы риза. Шулай булгач, нәрсә дип без монда һаман чүп чәйнәп утырабыз соң? Сөенергә кирәк, шатланырга...

– Анысы шулай, улым, бик дөрес уйлыйсың. Тик менә тәти абыең...

– Тәти абый?! – дип кычкырып куйды Абрек. – Ул минем атам да, анам да түгел! Нишләп соң...

– Шулай да, – дип бүлде аны анасы, – тәти абыеңа тияргә ярамый, ул зур кеше, безнең барыбыз өчен дә зур терәк...

– Әни! Син мине аңламадың! – дип сикереп торды Абрек. – Мин тәти абыйны яратам һәм хөрмәт итәм. Безнең өчен һәм менә бигрәк тә синең өчен аның кем булганын яхшы аңлыйм. Әйе, ул безнең атабыз, хәтта бабабыз урынына калган кеше, әйе, аның сүзе һәрчак сүз булып калыр, чын сүз булып! Ләкин... безнең Тәнзилә белән өйләнешүебезгә аның ни катнашы бар? Тәнзиләләр нәселен сөймәгәнгә, күралмаганга безнең ни эшебез бар? Мин өйләнәм, аңлыйсызмы, мин! Яратып өйләнәм! Тәти абыйның узган гомере ничек кенә газаплы булса да, без хәзер шуның газабын татып яшәргә тиеш түгел, аңлыйсызмы сез, юкмы?!

– Аңлыйбыз, тик...

– Һәм дә... аңлата белергә дә кирәк, – дип, кинәт кенә сүзгә кушылды полковник. Аның тавышы күтәелгәнчә коры һәм рәсми килеп чыкты. – Хәлләр җиңелдән түгел, дусларым, монда барысын да уртага салып, бик нык уйлап гамәл кылырга кирәк. Сез – яшьләр, сез һаман да ашыгасыз, алдын-артын уйлап бетермисез...

– Яхшы, – дип, аның сүзен бүлде Абрек, – сез минем урында булсагыз, нишләр идегез?

– Мин синең урында булсаммы? – Полковник кинәт кенә төртелеп калды. – Хе... мин синең урында булсам, менә мондый хәлне китереп чыгармаган булыр идем. Халыкта шундый сүз йөри: өйләнгәнче, тәкъдим ясаганчы, иң элек кызның нәселен тикшереп кара, диләр. Алданрак кая карадың соң? Нәрсә, бу ике нәселнең гомер буе дошманлашканын, бер-берсен күралмаганлыгын белмәдеңме? Мин моны сиңа Тәнзилә алдында әйтәм, ул миңа үпкәләмәс дип уйлыйм, чөнки дөресе шул, ә дөрес сүзгә, үзегез беләсез, җавап юк...

– Белдем ди, белсәм нәрсә? Нәрсә, мин шуны белгәч, кире уйларга тиеш идемме?

– Синең урында булсам, – дип, аңа кабат төрттерде полковник, – мин әзрәк уйланган булыр идем...

– Нәрсә турында?

– Өйләнергәме, ну... өйләнмәскәме...

– Ә нәрсә уйларга! – дип кызды егет. – Без Тәнзилә белән, өйләнешергә дип, бер-беребезгә сүз куештык! Бетте-китте!

– Син уйлаган белән генә бетми шул әле...

– Ә нәрсә тагын?!

– Улым, – дип тынычландырды аны анасы, – син Гобәй абыеңны да тыңла инде әзрәк, ул, ни әйтсәң дә, дөнья күргән кеше...

– Мин бит сиңа өйләнмәскә дип әйтмим, – дип, акрын гына сүзен дәвам итте полковник, – ләкин аны алданрак хәл итеп, тәти абыеңны шуңар әзерләргә кирәк иде! Мөмкин идеме?! Мөмкин иде! Сезнең хәбәрегез, бәлкем, аның башына күсәк белән суккан кебек булмас иде! Анаң да, син дә ялгышкансыз, абзыйны алдан әзерләмәгәнсез, менә шуңа күрә дә ул безнең яннан качты. Төптәнрәк уйласаң, аны да аңларга була...

– Әйе, була, сез хаклы, – дип килеште Абрек. – Тәти абый белән алданрак сөйләшергә кирәк булган икән...

– Алдан сөйләшүнең дә мәгънәсе юк иде, – дип, сүзгә керде Тәнзилә, – ул безгә барыбер каршы киләчәк иде, аяк тэрәп каршы киләчәк. Чөнки ул бер бабайны гына түгел, безнең бөтен нәселебезне, шул чираттан әтине дә, әнине дә, мине дә һәм туганнарымны да күралмый...

– Ә хәзер нишләргә соң инде? – диде егет. – Буласы булган, хәзер безгә алга карап эш итәргә кирәк, шулай бит, Гобәй абый?

– Шулаен шулай, энем, тик менә тормышлар ни күрсәтер бит, тормышлар...

...Фатыйх шул көнне кичкырын гына кайтты. Артык сүз эндәшмәде, тыныч кына табын янына килеп утырды. Абрек белән Тәнзилә чоланга чыгып ятканнар, ә Гобәй, диванда кырын ятып, телевизор карый иде...

Люция пешергән ризыкларын, тиз генә җылытып алып, абыйсы каршына китереп куйды. Фатыйх тавыш-тынсыз гына ашады. Ашаганын күзәтеп, каршына ук килеп утырган Люцияне, күрмәмешкә сабышып, аңа карамыйча гына тукланды. Соңыннан:

– Әйбәт пешергәнсең, маладис! – дип, сеңлесенә рәхмәт әйтте һәм шырпы тартмасының бер кырыен яньчеп, шуның белән теш арасына килеп кысылган ит валчыкларын актаргалады. – Яшьләр кайда суң әле?

– Бакчада, верандада, – диде Люция, – ял итәләр...

– Төнлә ял итәрләр, бар, чакыр!

– Нәрсәгә?

– Әйтәсе сүзем бар...

Люция балаларны чакырырга дип чыгып киткәч, аның янына Гобәй килеп утырды. Әллә арган, әллә артык күп су чөмергән, абзыйның күзләре шешенгән, йөзе агарынган иде. Йокыга китә-китә телевизор карап ятса да, күрәсең, ул Фатыйх белән Люциянең сөйләшкән сүзләрен ишетеп өлгергән, һәрхәлдә ул шуңардан хәбәрдар иде.

– Җә, – диде ул, өстәл өстендә торган кәсәдән салкын чәй чөмереп. – Яшьләргә ни димәкче буласың?

– Абзый, син безнең эшкә тыгылмасаң иде, – диде Фатыйх. Җавап шактый кырыс һәм тупас яңгырады.

– М...да... – дип сузды Гобәй, – ошатмадың син мине?!

– Әйе, ошатмадым, – дип, туры бәрде ул аңа, – хәер, бер сине генә түгел...

– Тагын кемнәрне?

– Сеңелнең ел саен ир өстерәп кайтканын ошатмыйм...

– Бу юлы соңгысы булыр дип уйлыйк, – дип елмайгандай итте абзый.

– Әгәр шулай килеп чыкса, мин бик шат булыр идем, – дип елмайды ул Гобәйнең сүзенә каршы. Ләкин бу дустанә елмаю түгел, аның төбендә ниндидер ачы киная ята иде. Озак еллар милиция эшендә кайнаган, үз гомерендә кемнәрне генә тотмаган һәм кемнәрне генә утыртмаган, кешенең, үзе әйтмешли, эчке «нутра»сын яхшы белгән элеккеге тәртип сакчысы аның бу кинаясен бик тиз тоеп, аңлап алды. Ул хәзер бернидән дә тартынып тормыйча, җинаятьчеләрне ничек фаш итсә, шулай, аларның бугазларыннан буып ничек селкетсә, шулай – кисәк кенә хуҗага каршы һөҗүмгә күчте...

– Фатыйх...

– Әйе...

– Син үзеңә бик күп нәрсә аласың кебек...

– Нәстә ул?

– Бөтен кеше синең алдыңда баш ияргә, синнән рөхсәт сорарга тиеш. Нәрсә, без дә синнән хәер-фатыйха алырга тиешме? Сеңлеңә өйләнәм бит...

– Анысы, абзый, синең ихтыярыңда...

– Ә шулай да? – дип сүз көрәштерде Гобәй.

– Абзый, син инде олы кеше, сеңелнең синең белән гаилә коруына каршы түгелмен. Яшәгез, бәхетле булыгыз! Аңла, мин аның кияүгә чыгуына каршы түгел, мин бары тик аның аерылып, ел саен яңа кеше өстерәп кайтуын гына өнәп бетермим...

– Мине дә ошатмадың, аңладым...

– Синең Гобәй булуың өчен түгел, ә бывший мент булуың өчендер... бәлкем... Күрдем мин сезнең халыкны төрмәдә, үз күзләрем белән күрдем. Менә шушы ышкурымда татыдым! – дип җикеренде Фатыйх, күкрәк сугып. – Бозлы карда ике сәгать тезләндереп тоттылар. Тезләнмәгәннәрнең аякларын таяк белән сугып имгәттеләр. Ике аягым ике яктан да сынган. Көз-яз сызларга тотына, авыртуына чыдарлык түгел. Әле бу бер генә мисал. Сөйли китсәң... Менә шуннан соң ничек итеп мин сезне, сезнең халыкны хөрмәт итәргә тиеш суң, әйт әле?

– Карале, Фатыйх, – дип кызып китте шулчак Гобәй, – мин Ысталин заманында хакимлек иткән җүләр законнар, кабахәт төрмә сакчылары өчен җавап тотмыйм. Үткәннәрне күптән онытырга вакыт, алга карарга кирәк, алга! Бер сиңа гына килеп кагылмагандыр бит ул андый хаксызлык, бер сине генә рәнҗетмәгәннәр бу дөньяда, аны күпләр, бик күпләр үз ышкурасында кичергән. Хәзерге көнне узган гомер бизмәне белән үлчәп утырырга ярамый, аңлыйсыңмы...

– Әйе, син хаклыдыр, бәлкем, – дип килеште аның белән хуҗа, – тик шул вакытта син хаклы да түгел...

Кызганнан-кыза барган бу бәхәс шушы урында туктап калды, чөнки аны дәвам итәргә Люция белән бергәләшеп килеп кергән яшьләр комачаулады. Алар, тартынып кына, табын тирәсенә утырыштылар. Фатыйх, җыелган халыкка гадәттән тыш әһәмиятле сүз әйтергә җыенган лектор сымак, урыныннан торып басты һәм талдан ясалган таягына тернәкләнеп болай диде:

– Абрек, Тәнзилә, мин сездән гафу үтенәм, мин үземнең узган гомеремне, булган кайгымны нигәдер сезнең бәхетегездән, шатлыгыгыздан өстен куйдым.

Алай ярамый, билгеле, мин бу турыда озак уйладым һәм хәтта берничә таныш кешем белән дә киңәшергә өлгердем... Без инде әкренләп сүнеп барабыз, ә сез яшь, сез әле яши генә башладыгыз. Әгәр дә миннән хәер-фатыйха алуны мәгъкуль күреп, әлеге эш-гамәлне кирәк дип саныйсыз икән, әйтәсе сүзем шул: яшьләр, миннән сезгә хәер-фатыйха...

– Рәхмәт, тәти абый! – Абрек, рәхмәтен җиткерер өчен, тәти абыйсын кочып алмакчы иде, ләкин кирәкмәгән артык хәрәкәт ясап, ул Фатыйхның фәкать кул башын гына кыса алды...

– Сиңа да, Люция, сезгә дә, – диде Фатыйх, – тик бусы соңгысы булсын иде инде, чыксаң, соңгы мәртәбә чык...

– Рәхмәт, абый...

– Мин үземне бүген начар сизәм, чоланга чыгып, бераз гына ятып торсам, каршы килмәссез дип уйлыйм! – диде Фатыйх һәм, әкрен атлап, ишеккә таба юнәлде. Ләкин бусага төбенә җитәрәк ул тукталып калды һәм өйдәгеләргә кызык сүз әйтте. – Сезгә үтенечем бар, зинһар, мине туй мәҗлесләренә чакырып, кунактан кунакка йөртмәгез, җәме...

Хуҗа абзыйның соңгы сүзе нигәдер барысын да уйга калдырды. Ул бер-берсен сөйгән яшьләргә үзенең хәер-фатыйхасын бирсә дә, күңеле түрендә бу ярәшүне һич кенә дә кабул итеп бетерә алмады. Гобәй белән Люция, авыл урамыннан бер җилләнеп кайту теләге белән, өйдән чыгып китүгә үк, Тәнзилә белән Абрек арасында кабат бәхәс купты. Абрекның:

– Күрәсеңме, тәти абый ничек йомшады, үз ялгышын аңлады! – дигән сөенеченә каршы Тәнзилә:

– Ә мин сөенерлек берни дә күрмим! – дип, егетнең авызын япты.

– Нигә алай дисең, матурым?

– Фатыйх абый алдында безнең бабабызның гаебе бик зур, коточкыч зур. Безнең алда хәер-фатыйхасын бирсә дә, күңеле белән ул аны барыбер теләмичә генә бирде. Соңгы сүзен ишеттеңме? Ул әти-әни янына да, безнең туйга да бармаячак!

– Бармаса бармый, әллә ни зур югалту түгел, – дип әйтте бу бәхәстән туя башлаган Абрек.

– Минемчә...

– Нәрсә?

– Сиңа башка кыз табарга кирәк...

– Ни өчен?

– Без синең белән барыбер бәхетле була алмаячакбыз, йолдызлар безгә каршы... Уйла, Абрек, өйләнгәнче барысын да уйла, соңыннан үкенерлек булмасын...

– Син моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

– Ашыкма миңа өйләнергә, бәлкем, башка кеше табарсың...

– Болай сөйләнсәң, табармын да шул!

– Тап, алайса, тап!

Тәнзилә, капылт кына кузгалып, өйдән чыгып китте. Кая киткәне билгеле инде, атасы, анасы янына чапты! Әйе, үз итмәде кыз алар нәселен, караңгы елларның чоңгылыннан котыла һәм шул ачы уйларыннан арына алмады. Абрекка әлеге җан газаплары әллә ни зур читенлек китермәде кебек, чөнки ул – ир кеше, ул күпкә көчлерәк. Ләкин ул әле һаман да Тәнзиләне ярата, чөнки бу сары чәчле кыз аның күңеленә уелып кергән һәм ул, әлбәттә, киләчәк тормышын ансыз күз алдына да китерә алмый иде...

**Өченче бүлек**

## Туй алдыннан

Туйны июнь башында ясарга булдылар. Кыз ягы туйны көзгә күчерергә ниятләп караса да, кияүнең анасы, чатыр торып, әлеге тәкъдимгә каршы чыкты. Калган эшкә кар яуганын сизенгән Люция туйны тизләтергә булды. Тагын бер яңалык: туй авылда түгел, ә калада узачак. Фатирда түгел, ресторанда. Туй хакын, ресторан бәясен ике як та күтәрергә булды: яртылаш. Бу сөйләшү, килешү кәләш йортында, табын артында узды. Кадерле кунак булып кына йөрергә, һәрчак игътибар үзәгендә булырга яраткан Гобәй: «Яшьләрне өйләндергәч, чират безгә дә җитәр инде!» – дигәч, Люция: «Белмим әле, мин кире уйларга да күп сорап тормам!» – дип, табындагыларны рәхәтләндереп бер көлдереп алды...

Фатыйх, билгеле ки, туй алды мәҗлесләренең берсендә дә катнашмады. Янына төшеп, аны чакырып та карадылар. Ләкин ул, авыруга сабышып, әлеге чакыруларның берсен дә кабул итмәде. Әйе, Фатыйхның йөрәк ярасы тирәндә, шактый тирәндә ята иде шул...

Әлеге туй вакыйгалары Фатыйх өчен тагын бер сынау алып килде. Туй алдыннан авылда күңелсез хәбәр, ямьсез гайбәт таралды. Сәгыйть үзенең кызын юкка гына Люция улына бирми икән, бу уйланып, ике нәсел арасындагы ямьсезлекне тигезләү өчен шулай эшләнә, имеш! Фатыйх, билгеле, әлеге сүзләргә артык зур игътибар итмәде, ә менә Сәгыйть аны җитди кабул итте. Кыскасы, бу гайбәт аның тешенә тиде. Бер көнне ул, шактый кызмача хәлендә, Фатыйхларга килеп керде. Өйдә хуҗа үзе генә иде, чөнки кунаклар барысы да, калада узачак туйга әзерләнү нияте белән, Казанга китеп бардылар...

Сәгыйть, әгәр дә ул эчә башласа, төс-кыяфәтен югалта. Тарамаган, юмаган чәчләре, касмакланып, үрә торып баса, күзләре акая, борыныннан нииндидер сары су ага, кибет аракысы эчсә дә, тәненнән авыр махмыр исе аңкып тора...

– Сәлам, кода! – дип эндәште аңа Сәгыйть һәм былчыракка каткан кулын сузды. Фатыйх аңар кул бирмәде, тегесе, аңлагандай, сузган кулын кире алды...

– Сәлам...

– Сүләшергә кирәк ие...

– Мин синең белән сөйләшергә теләмим, – дип кысылды хуҗа, – исерек син!

– Ну, мин исерек... әйе! – дип килеште аның белән кунак. – Дөрес сүлисең... Тик хәлләр бигүк әйбәт түгел...

– Күрәм, хәлең чынлап та әйбәт түгел, айнырга вакыт...

– Айнып була димени монда?! Шундый хәлләр...

– Нинди?

– Утырырга ярыйдыр бит?

– Ярый! Утыр!

Юан гәүдәле Сәгыйть, гөпелдәп, өстәл янына терәлеп торган артсыз урындыкка килеп утырды. Тәүге мәртәбә нәсел дошманының өенә кереп, табын янында ук булмаса да, урындыгында утыра алуыннан үл үзен чиксез бәхетле сизде һәм шул хәлгә сөенгән хәлендә озак кына сүзен башлый алмыйча торды.

– Тыңлыйм сине!

– Шундый сүзләр йөри авылда, гайбәт... Имеш, атамның сезнең нәселгә карата кылган явызлыкларын юар өчен, кызымны... ягъни мәсәлән, Тәнзиләмне Люциянең улына кияүгә бирәм икән...

– Бирәсең бит инде!

– Бирәм, ие! Тик мин монда причум! Махсус түгел бит! Кызымның теләгенә

каршы килә алмадык, ни мин, ни хатын! Алар... яшьләр... бер-берсен яраткач... нишлик... каршы киликмени суң?

– Авыл халкы ни сөйләгәне минем өчен караңгы, – диде Фатыйх бераздан, – мине беләсең, мин гайбәт сүз тыңлап йөри торган адәм түгел. Халык ни сөйләмәс! Ләкин мин синең урында булсам...

– Ие... ие! – дип күтәреп алды кунак. – Нишләр идең?

– Каршы чыгар идем... кызым белән сөйләшеп, аңлашыр идем...

– Белмим, – дип баш чайкады кунак, – аңлар иде микән?!

– Аңлата белсәң, аңлар. Ә син тоттың да, бернинди уңайсызлык кичермичә, кызыңны безнең нәсел кешесенә кияүгә бирә башладың. Кирәк идеме ул сиңа?

– Миңа тек барыбер... яшьләр өчен, Тәнзилә өчен... ие...

– Тәнзиләң! – дип ярсыды Фатыйх. – Бер елаган булыр иде дә оныткан булыр иде. Кияүгә чыкмаслык кыз түгел, башкасын табар иде. Ә син шуны уйладыңмы соң? Абрекка кияүгә чыккач, гомере буе шуны уйлап яшәячәк, аңлыйсыңмы, гомере буе?! Күтәрә алмаячак синең кызың аны...

– Нишләп?

– Артык нечкә күңелле ул синең Тәнзиләң, гомер буе шул үкенечле уйдан арына алмаячак...

– Уйларга түгел... онытырга вакыт, онытырга...

– Онытырга тырышып кына, онытсаң икән дә бит! Онытылмый ул, аңлыйсыңмы, җанда бит ул, канда...

– Җарар инде! – дип кул селтәде Сәгыйть һәм җүләр кеше сымак, кисәк кенә талпынып, урыныннан торып басты. – Юктыр бит?

– Нәстә юк?

– Теге йөз грамм...

– Юк! Мин өйдә аракы тотмыйм!

– Җәллисең, да? Кодаңа?!

– Карале, кода! – дип, мыскыллы елмайды хуҗа. – Син минем өемә үз гомереңдә беренче тапкыр аяк бастың, мин сине чакырмадым, име, кил, дип үтенмәдем. Гафу ит, мин, гомумән, эчкән кешене, исерек кешене яратмыйм! Андыйларга кайчак кеше дип әйтергә дә телем бармый...

– Ә кем кеше соң? – диде Сәгыйть. – Синме?!

– Мөгаен, тик һәрхәлдә мин исерек түгел...

– Мин елга бер генә исерәм, анда да сәбәп булганда гына, – дип батырайды кунак. – Ә син беләсеңме суң...

– Нәрсә?

– Әткәй сине ни өчен сатканын?

– Беләм... энигә, этигә үчләнеп...

– Заманы шундый булган аның, дус дусны, туган туганны саткан, явить иткән... туес... Син миңа әйт әле, нишләп суң атамның хатасы өчен хәзер менә мин җавап бирергә тиеш?!

– Сүз аның турында бармый, сүз хәтер турында бара, ачы хәтер! Атаңның явызлыгы өчен, сүз дә юк, син җавап тотмыйсың. Ләкин эш...

– Этидә генә түгел шул, синең анаң да гаепле булган...

– Минем энидә?!

– Ие... анаң кибетче иде, безнең эти аңардан үз бәясеннән дефицит товар сораган, ә ул бирмәгән...

– Үз бәясенә түгел, ә бушлай!

– Ә бирсә, ни була? Үлмәс ие?

– Ярамаган, аңлыйсыңмы, ул бит әнинең шәхси кибете түгел, райпотребсоюзныкы. Отчёт биргәндә, җитмәгәнен каян алып түләгән булыр иде? Ә?

– Һей, – дип көлде Сәгыйть, – кибетчеләр алар җаен табалар, болай да чумарага яшиләр! Берәр яхшы әйберне арттырып сата да, каплый да куя бурычын!

– Минем әни намуслы кеше иде, ул андыйга бармады. Нишләп суң ул синең атаңа тауарны бушлай бирергә тиеш? Нишләп? Нәстә, ул Алланың кашка тәкәсе мәллә?!

– Синең әниең дә әллә кем түгел иде, беләм идем мин аны, сүлиләр иде...

– Нәстә сөйлиләр иде?

– Ничек итеп кибеттә урлашканын...

– Син!!! – дип акырды аңа Фатыйх. – Син минем әнигә тиясе булма, җәме!

– Ну... шундый булгач... анаң...

– Нинди?!

– Шундый...

– Тимә әнигә, кабахәт! Ишетәсеңме, юкмы...

Язга чыккач, аяк һәм тән хәлсезлеге сизеп, хәлсезлек чире кичергән Фатыйх, кинәт кенә ярсып, кабынып китте. Ул Сәгыйтьне ботарлап атардай булып, якасыннан эләктереп алды һәм, бар булган көченә, ишек ягына этәрде. Артык көчәнүдән тыны кысылды, авыру йөрәге исә чыгардай булып какты...

– Чы-ы-гып кит! Хәзер үк!!!

Авыр гәүдәле Сәгыйть, абынып китеп, башы белән ишек бусагасына барып төште. Инде бу вакыт үзенчә айный, барысын да аңлый башлаган исерек, сикереп торып, кулларын бутый-бутый, Фатыйхка ташланды. Фатыйх, йодрыгын катырып, каршына ыжгырып килгән мужикның кисәк кенә борын төбенә тартты. Фатыйхның аяклары хәлсез булса да, кулы яман каты һәм көчле иде. Әйе, балта остасының кулы берничек тә йомшак була алмый шул. Бу сугудан хәерсез кунак бер урында катып калды, аның борыныннан шаулап кан китте. Икенче сугуында Фатыйх, иплә кенә, аның маңгай астына ямады, исерек, аңын җуеп, гөпелдәп идәнгә ауды...

...Сәгыйтьнең кыйналу хәбәре авылга, бәлкем, таралмас та иде, ләкин моңа зыян күрүче үзе үк сәбәпче булды. Бик озак денгә килә алмыйча җәфаланган Сәгыйтьне хастаханәгә озатырга туры килде. Хәер, анда ул бер генә төн кунды, икенче көнне аны авылга кайтарып җибәрделәр. Ләкин криминаль маҗаралардан хәбәрдар булырга яраткан, Фатыйхны, ялгызлыгы сәбәпле, күпмедер дәрәҗәдә өнәп бетермәгән милиция хезмәткәрләре зыян күрүчене хастаханәдән эзләп таптылар. Кыйналган Сәгыйть, милиция хезмәткәрләренең сүзе буенча, барысын да ничек булган, шулай сөйләп биргән.

Фатыйхны район үзәгенә, милиция бүлегенә чакырдылар. Сорауны кырыс чырайлы, озын буйлы, сакал-мыек баскан олы яшьләрдәге майор алды. Касыйм атлы иде ул. Фатыйх аны бик тиз танып алды, моннан ике ел элек ул, үзенең бригадасы белән, майорның иске мунчасын яңарткан иде.

– Сәлам, брат! – дип, ничектер дустанә һәм якын итеп күреште ул Фатыйх белән. – Әйбәт түгел, бырат...

– Әйбәт түгеллеген үзем дә аңлыйм, гаебемне таныйм, иптәш майор, – дип килешергә мәҗбүр булды ул.

– Нигә дип суктың син аңа?

– Виноват! Сугарга тиеш түгел идем, тик тыелып кала алмадым...

– Сиңа кода да түгелме соң әле ул?

– Әйе, кода, булачак кода.

– Бырат, – дип елмайды майор, – аңла, без сиңа җәза бирү ягында түгел, юк кына нәрсә өчен синең кебек төпле кешене утыртасы килми. Без зыян күрүчедән сорау алдык, протоколы менә минем өстәлемдә ята...

– Нәстә, мине утыртуларын телиме?

– Юк, киресенчә, – дип сөендерде майор, – ул синең өстән гариза язмады. Сорау алган чакта да ул башта сине түгел, ә үзен гаепләде...

– Юк, ул ялгыша, чөнки гаеп миндә, – дип үзенекен тәкрарлады Фатыйх. – Кабатлап әйтәм: мин аңар сугарга тиеш түгел идем...

– Ашыкма син, бөтен гаепне үзеңә генә аударма, – дип яклады аны майор. – Ул сиңа үзе ташландымы?

– Юк, ул миңа ташланмады. Мин үзем гаепле...

– Бырат! Җитәр инде һаман шул исерекне якларга! – дип бүлде аны майор. – Допроста ул үзенең ялгышын таныды һәм шул нәрсә, беләсең килсә, сорау алу протоколына да теркәлде...

– Иптәш майор, ни булса да, мин аңар сугарга тиеш түгел идем!

– Син беләсеңме, хулиганлык буенча нинди статья барын? Синең очракта өч елдан җиде елга хәтле ирегеңнән мәхрүм итү каралган. Куркытмыймы?

– Куркасы юк, майор, мин инде төрмә этапларын узган кеше, – дип батырайды Фатыйх, – теләсә нишләтегез, мин барысына да әзер...

– Яшең бар, бырат, сиңа анда кыенга туры киләчәк. Хәер, сине условный белән дә калдырырга мөмкиннәр. Ләкин анысы да кирәк түгел сиңа, ул төрмәдә утырудан да кайтыш. Шуны аңламыйм: нәрсә бүлешә алмадыгыз соң сез? Сәбәбе бармы? – дип төпченде майор.

– Сәбәбе юк, иптәш майор, мин үзем гаепле...

– Бөгештермә, яме...

– Аңламадым?

– Милицияне шултиклем ахмак дип уйламагыз сез, – дип, астыртын гына елмайды майор. – Күптәнге сер ята сезнең бу кыйнашуыгызда. Аның атасы Хөснулла абзый, ишетеп булса да беләидем мин ул кешене, заманында сине төрмәгән олактырган, шулай бит? Сине генә түгел, анаңны да? Алай гына да түгел, бөтен гаиләгезгә зыян салган, мораль зыян...

– Мөмкин булса, мин бу сорауга җавап бирмәс идем.

– Ихтыярың...

– Кузгатмыйк узганнарны...

– Яхшы, кузгатмыйк, – дип килеште майор. – Өстеңнән җинаять эше кузгатмас өчен, сиңа хәзер зыян күрүче белән килешергә һәм аңардан гафу үтенергә кирәк булачак. Аңладыңмы?

– Юк, аңламадым.

– Минем бу эшне ябасым килә, судка җибәрәсем килми...

– Ни өчен?

– Сине хөрмәт иткән өчен.

– Мунча өчен түгелдер ич?

– Юк, – дип көлде майор, – мунча өчен түгел. Кул кысышып, бер-берегездән гафу үтенәсез дә, и эше бетте, кодагый!

– Юк! Мин аңардан гафу үтенмәячәкмен...

– Фатыйх абый! Ну, нинди кеше соң син, ә! Синең белән җайга салып сөйләшергә телисең, име, ә син шуны тотасың да кирегә борасың...

– Юк, утыртсалар утыртсыннар, әмма мин әнине мыскыл иткән кешедән гафу үтенмәячәкмен! Тимәсен минем әнигә, тимәсен! Әгәр дә тагын тия икән, аны кыйнап кына калмаячакмын, башына җитәчәкмен!

Фатыйхның, утырган урыныннан күтәрелеп, шулай каударланып кычкыруы милиция эшендә хезмәт итү дәверендә күпне күргән майорның исен-акылын ала алмаса да, ул аны барыбер таң калдырды. Ике нәселнең, ике гаиләнең бер-берсенә булган нәфрәте, рәнҗеше кирәгеннән артык тирәндә ятканын майор шунда гына сизенде...

– Минем әнием беркайчан да урлашмады! Ул кешенең бер тиененә дә кермәде! Аны бер хаксызга гаепләделәр һәм харап иттеләр! Тимәгез минем әнигә, ти-и-мәгез!!!

Түземлеген җуя башлаган майорның тәкате калмады булса кирәк, ул өстәл кырына гына беркетелгән төймәгә басты. Ишектә кече яшьтәге ябык чырайлы сержант күренде.

– Тыңлыйм, иптәш майор!

– Керсен...

– Кертергәме?

– Да...

Ишектә Сәгыйть күренде. Кәефсез, чырайсыз. Бер-берсенә ни әйтергә дә белмичә, сәерсенеп карашкан ике коданы шаклар катырып, тынлыкны иптәш майор бозды һәм:

– Син нишләп кешенең әнисен мыскыл итәсең? Ни хакың бар? – дип, зыян күрүчегә ябырылды. – Гафу үтен аның улыннан!

– Мине кыйнадылар түгелме суң? – дигән булды Сәгыйть.

– Сине кыйнамадылар, сиңа суктылар гына! Ә син аның җанын кыйнагансың! Гафу үтен кодаңнан, и эше бетте, кодагый!

Сәгыйтьнең кодасыннан гафу үтенүе шактый киеренке рәвештә узды. Айныгач, сүз сөйләү осталыгын югалткан мокыт, авыз эченнән нәрсәдер мыгырданган булып, Фатыйхка хәлсез генә кулын сузды. Фатыйх, киресенчә, эшне озакка сузмады, – кодасының кулын каты итеп кысты да, ашыгып, кабинеттан чыгып китте...

– Кичер, авылдаш, син дә мине...

...Ике кода арасында чыккан низаг өйдәгеләрне дә читләтеп үтмәде. Әлеге хәтәр вә сәер вакыйгадан соң, каладагылар, җыйнаулашып, кабат авылга кайтып төштеләр. Тәнзилә аларга кереп тормады, әниләренә китеп барды. Аның ни өчен кермәве аңлашыла, билгеле, чөнки һәркемгә үзыруы, үз каны якын. Люция шул көнне абыйсының колак итен озак чәйнәде. Бу очракта үзен хәзер хөкемдар итеп сизгән хатын, кайтуга ук, абыйсына нотык укырга тотынды...

– Абый, ни җитми инде сиңа, җә?!

– Миңа барысы да җиткән, кодаңа менә нидер җитми! – дип акланды абыйсы.

– Безгә үч итеп эшлисең, ахры, син боларның барсын да! Ике якны бер-беребезгә әчеләндереп, туйны булдырмаска җыенасың...

– Сезнең туегызга минем бернинди дә катнашым юк! Өйләнсен Абрек, бәхетле булсын, канса да кансуф! Ә мине калдырыгыз, тимәгез!

– Абый, – дип тигезләргә тырышты Люция. – Безгә бар булган үпкәләрне онытырга вакыт җиткәндер дип уйлыйм, шул уй белән күпме яшәргә була соң инде?

– Син хаклы, сеңел, ие, онытырга кирәк, – дип килеште Фатыйх. – Борчылма, кодаңнан гафу үтендем...

– Абый, син дә безгә үпкәләмә, без сине яратабыз...

– Мин дә сезне бик яратам! – Фатыйх, бик каты хисләнеп, сеңлесе һәм сүзгә кушылырга коты очып торган Абрекны кочып алды. – Сездән дә якын кешем юк бит минем, аңлагыз...

Ул көнне Фатыйх өйдә кунмады, Сарада калды. Тәнзилә артыннан киткән Абрек өйгә ялгызы гына кайтып керде. Күңелсез, кәефе төшкән. Бар нәрсә өчен дә борчылып, ут йотып торган Люция улын: «Ни булды анда, сөйлә?!» – дигән сөаль белән каршы алды.

Абрек шул кичне анасына менә ниләр сөйләде:

– Тәнзиләнекеләр мине яхшы каршы алдылар, теге инцидент турында, авыз ачып, бер сүз дә әйтмәделәр. Сизәм, миннән барысын да яшерергә тырышалар, әйтерсең лә берни булмаган. Әтинең яньчелгән борыны күзгә ташланмаса, кодалар сугышкан, димәссең. Ләкин эшне Тәнзилә бозды, кызды. Аның тавыш чыгаруына аптырамадым, мин аның күңеленә кереп оялаган шайтаннан курыктым. Әнкәй, сиңа гына әйтәм, соңгы вакыт бик нык үзгәрде ул, аңар әллә нәрсә генә булды. Элеккеге Тәнзилә белән хәзергесен чагыштырсаң, җир белән күк арасы. Психозный ул хәзер, бабасына, тәти абыйга карата, сиңа карата да психоз аңарда. Мин аңар болай да, тегеләй дә килеп карыйм, тынычландырам, уйларыннан арындырырга телим. Калада булганда, аның күңелен ачар өчен, йә паркка алып чыгам, йә киногa алып барам, сөйләндерәм, көлдерәм. Ә ул юк! Әзрәк онтылып тора да, кабат шул сәер халәтенә әйләнеп кайта. Мин инде хәзер үзебез өчен түгел, чурт с ним, өйләнешмәсәк өйләнешмәбез, аның үзе өчен курка башладым, акылдан чыкмасын, дим...

– Анысын мин дә сиздем, улым, – дип, сүзгә кушылды анасы, – акылына бәрмәсә ярый инде. Ләкин безгә бер башлаган эштән кире чигенергә ярамый, без инде килештек, сезне кушарга дип килештек, шуңа күрә безгә туйны һичничек тә өзәргә ярамый. Нәрсә, кире уйладың мәллә? Өйләнмәскәме уең?

– Өйләнәм инде! Яратам бит...

– Яратасыңмы?!

– Әйе, ни хикмәттер, бу хәлләрдән соң мин аны тагын да көчлерәк ярата башладым. Буш, җилбәзәк кыз түгел ул, тик күңеле артык нечкә, барсын да тиз тоя...

– Өйләнмичә булмый, халык алдында көлкегә калуыбыз бар. Авыл халкы болай да кырын карый безгә. Тик син сөйләп бетермәдең. Ни белән бетте? Тәнзилә нишләде?

– Башта ул бер сүз дә дәшмәде, елады...

– Елады?

– Әйе, икенче бүлмәдә... Мин кухня ягында эти-әни белән чәй эчтем, бәлеш пешергәннәр иде. Тәнзиләне чәй эчәргә чакырдык, ул чыкмады. Без дә артык ялынмадык. Әтисе белән авыл хәлләре турында сөйләштек. Бераздан ул үзе атылып чыкты. Төсе-кыяфәте киткән, күзләре кызарган, сипкелләре бүрткән... тагын да зураеп, артып киткән... Ярсыган! «Бәлкем, син китәрсең!» – ди бу миңа. «Кая?» – дим. «Өеңә! Бүтән монда кайтмаслык итеп китәрсең!» – ди. «Аңламадым...» – дигән булдым, хотя, аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңласам да. «Минем әтигә кул күтәргән кешеләр белән туганлашуның мәгънәсен дә, савабын да күрмим. Тагын да зуррак бәлаләргә тарганчы, безгә, бәлкем, хушлашырга кирәктер?!» – ди...

– Нәрсә! – дип бүлде аны анасы. – Чыкмаскамыни уе?

– Чыга ул, тик...

– Туйны өзә күрмәсеннәр! – дип ярсыды хатын. – Туй өчен ресторанга акча түләнгән! Менә өзеп кенә карасын әле туйны, башын өзеп атам мин ул кызның! Кара син аны, ә...

– Әни...

– Әү?

– Аның әти-әнисе каршы түгелләр, бөтен хикмәт Тәнзиләдә, аңлыйсыңмы, аның кәҗәләнүендә...

– Аңа ни җитмәгән тагын – сигәк марҗага?!

– Әни!

– Нәрсә әни?!

– Подбирай выражения, а!

– Нәрсә подбирай?! Без аңа һаман да җәймә җәеп торабыз, ә ул шуңар төкерә!

– Әни, аны да аңларга була, әтисе өчен борчыла...

– Атасы бер сүз дә әйтмәдеме шуңа!

– Әйтте, яхшы итеп әйтте! «Кызым! Безнең кода белән ике арада булган ямьсезлекне син оныт, алга, киләчәккә кара, булачак иреңә сыен!» – диде. Күп сүз әйтте аңар әтисе, акыллы сүзләр әйтте, барысын да хәтерләмим. Берәр сәгатьтән ул тынычланды тынычлануын, яныма утырып, хәтта гафу да үтенде. Ләкин мин дә тимер түгел, минем дә күңелем катты. Калмадым, киендем дә чыгып киттем. Туйдым мин, әни, беләсеңме, бу уеннан, туйдым...

– Уен әле башланды гына... улым...

– Тәнзилә, ни кызганыч, – дип сызланды Абрек, – бабасының кылган гөнаһын һаман да җанында йөртә һәм шуңардан һич кенә дә котыла алмый. Нишлисең, шундый инде ул, шундый булып туган, аны хәзер бернишләтеп тә булмый, әнкәй. Хикмәт бу...

– Туй булмый, димәк?

– Туй булачак, әнкәй, һичшиксез булачак!

**Дүртенче бүлек**

## Туй

Ниһаять, туй көне дә килеп җитте. Туй калада уза, ә иң элек авылдан, ата-анасы йортыннан кәләшне алып китешле, һәм бу борынгы йола, илдә совет власте хакимлек итүгә дә карамастан, әле һаман да исән иде.

Фатыйх, билгеле ки, әлеге бәйрәмдә катнашмады, бригада белән яңа эш табып, күрше авылга бура күтәрергә китеп барды. Туган нигезгә, туй кучтәнәчләрен күтәреп, Люция, Гобәй, Абрек һәм аның ике дус егете кайтып төште. Шушы ике дус туйда кияү егетләре ролен үтәргә, ә берсе (егет ягыннан) шаһит булып утырырга тиеш иде. Абрек өстенә туйга дип тектерелгән кара төстәге матур костюм-чалбар, аягына һәйбәтләп кремланган өр-яңа ботинка киде. Кияү егетләре дә, кияүдән калышмыйча, заманча матур итеп киенделәр. Кияү егетләренең берсе, Сафа атлысы (алар Абрек белән классташ дуслар!), кодаларга барып, андагы хәлләрне белеп кайтты. Тәнзилә кияүгә чыгарга әзер, ул Абрекны көтә, ләкин кәләшне алып чыгу җиңел булмаячак, аны яулап алырга туры киләчәк.

– Крепость алырга туры килмәгәе әле! – дип борчылган булды Сафа. – Урам чатыннан башлап, өйнең эченә хәтле засада куелган...

– Нинди засада тагын? – дип көлде авыл йолаларын бигүк белеп һәм шулай ук өнәп бетермәгән Абрек.

– Малай-шалай тора, авыл егетләре, – дип аңлатты Сафа. – Акча ташламасаң, уздырмаячаклар...

– Нинди акча? Күпме? – дип чәчрәде туй акчасын тартып-сузып кына җиткерә алган Люция.

– Вак-төяктер инде, мелочь, өчәр тәнкә ташлап булмас...

– Кибеткә барып, акча ваклатып кайтырга кирәк! – дип каугаланды Люция.

– Борчылмагыз, мин барысын да уйлап куйдым инде! – дип, шулчак сүзгә кушылды Гобәй. – Минем баштан үтте инде ул, үтте...

Полковник кечкенә генә күн чемоданыннан чүпрәк янчык тартып чыгарды һәм аның эчендәге вак тимер акчаларны өстәл өстенә бушатты. Өстәл өсте төрле зурлыктагы тимер акчалар – тиеннәр белән тулды. Иске тимер акчалар яңаларына караганда да күбрәк иде, кулланудан чыккан тиеннәр янында сынып кәкрәйгәннәре һәм хәтта тишелгәннәре, кәкрәеп катканнары да бар иде. Абрек полковникның артык саран икәнлеген, һәр тиен өчен чукынганын яхшы белсә дә, хәйлә гамәлен бу хәтле үк килештерә алыр дип һич кенә дә башына китермәгән иде...

– Абзый, син боларны гомер буе җыйдың мәллә? – дип шаккатты ул, бу хәтле «байлык»ны күреп.

– Тормыш шундый нәрсә ул, кияү энекәш, – дип акыл сатты Гобәй, – барсын да алдан күреп эш итә белү мәгъкуль. Тик торганнан зур акчалар сибәргә ярамый, тиеннәре дә җитеп торыр, әле ансын да чамалап кына тондыру лазем. Акчаны белеп тотыйк, юкка чәчмик, без бит хәзер бер гаилә, шулай бит, Люция?

– Гобәй абыегыз дөрес әйтә, дөрес сөйли, – дип, аның сүзләрен җөпләде хатын. – Улым, син Гобәй абыеңны тыңла инде, ул – күпне күргән, күпне белә торган кеше...

– Сафа! – дип кычкырды полковник. – Акчаны җыйнап, үз кулыңа ал! Әгәр тоткарласалар, акчаны шундук сипмә, иң элек аңлатып, килешеп кара! Бәлкем, кайбер җирдә сүз дә җитәр...

– Белмим инде, белмим, – дигән булды кияү егете, җилкәсен җыерып, – әлегә хәтле мондый маскарадта катнашканым булмады...

Тиеннәрне аңа Люция җыйнап тоттырды. Сафа аны беркая да яшерә алмады, акчалар, тиеннәр генә булса да, янчыкка җыйнагач, шактый авырайды. Шуңа күрә ул аны кулында гына тотып барырга булды. Ләкин алары белән хәл кылынгач, полковник тагын бер хикмәт иҗат итте. Ул шул ук күн чемоданнан ике шешә аракы тартып чыгарды һәм шуларны берәм-берәм икенче кияү егетенең кулына тоттырды.

– Бусы нигә? – дип сорады аңардан Абрек.

– Аракы урынына берәрсенә бирерсез! – диде карт төлке, хәйләкәр генә елмаеп.

– Аракы түгелмени?

– Юк, аның эчендә су.

– Ә ничек шешәгә су салып, аны пичәтли алдыгыз?

– Әче суны ничек тутырсалар, гади суны да шулай тутырып була, энекәш! – дип көлде полковник. – Милициядә хезмәт итсәгез, күп нәрсәгә өйрәнер идегез сез, кәнишне...

Туйга, төп машина итеп, полковникның «Волга»сын бизәделәр. Машинаның

капотына төрле төстәге шарлар, тасмалар тактылар, буферына чуклы-чачаклы ак күлмәк кидерелгән курчак кызын беркетеп куйдылар...

Шулай итеп, алар кызны алырга чыктылар. Рульгә Гобәй үзе утырды, кыйммәтле «Волга»сын машина йөртергә өйрәнеп кенә килгән егетләргә ышанып тапшырмады. «Кортеж»ны, олы күперне чыгып, кәләш урамына борылуга ук, тыкрык башында җыйналып торган авыл яшьләре туктатты. Урамны ике яктан озын бозау арканы белән бүлеп куйганнар. Болар әле Тәнзиләнең туганнары түгел, Гобәй әйтмешли, авыл песиләре генә иде...

– Боларга нәрсә атабыз? – дип сорады Сафа шофёрдан.

– Аракы! – дип әмер бирде Гобәй.

– Дөрес булыр микән? – дип чырайсызланды Сафа. – Тавыш чыкмасмы...

– Бәлкем, мин аларга бер-ике яртылык акча гына бирермен! – диде Гобәйгә Абрек, әлеге юл бүлгән яшьләр арасында үзе аралашкан кайбер таныш дусларын күреп.

– Акчаң күпмени соң?! – дип кычкырды аңа полковник. – Әле бер тиен акча эшләгәнең юк, ярый әнкәң бар, мин бар... Бир! Теге ике яртыны!

Дөресен әйткәндә, бу комсыз полковник Абрекның инде күптән саруын кайната башлаган иде. Төшеп, җәяү генә барыр иде, барып җитәлмәс, бәреп керәлмәс, кәләшен ала алмыйча, авыл халкы алдында көлкегә калуы бар. Шуңа күрә дә ул, тешен кысып булса да, дәшмәскә, полковник ни кушса, шуны үтәргә булды. «Волга» алдына чыгып баскан бер егеткә Сафа машина тәрәзәсеннән генә полковникның ике ялган шешәсен сузды. Егет аларны кулына алып, сөенә-сөенә, төркем ягына йөгерде. Бозау арканы шундук бушады һәм полковник, әлеге тамашадан зур канәгатьлек хисе кичереп, арканны «Волга» көпчәкләре белән таптап узды.

– Хәзер сөенәләр, соңыннан көенәләр инде болар, аракы урынына су эчкәч! – дип сүз йөртте Сафа. Ләкин аның сүзләрен беркем дә җөпләмәде, кәләш йортына хәтле алар сөйләшмичә, тын гына бардылар...

Кайчандыр Фатыйхның кан дошманы Хөснулла абзый яшәгән бу нигез шактый үзгәреш кичергән: йортның бура өлеше тар һәм юка такта белән тышланган, матур итеп буялган, эчтә, бакча ягына чыгарыбрак ак кирпечтән янкорма салынган. Күрәсең, ул хәзерге хуҗаларга аш ягы булып хезмәт итә. Хөснулланың улы Сәгыйть ярлы яшәми, ара-тирә салгаласа да, йортын карый, эшсез ятмый иде. Әле ул быел гына мунчасын яңартты, искесен сүттереп, имән бурадан яңасын торгызды. Бакчаның бер чатында, авыл халкын шаккатырып, ак кирпечтән җәйге кухня салдырып ята иде...

Бизәкләп ясалган, «маңгае»на эшләнгән елы уелган матур капка янында кунакларны Тәнзиләнең туганнан туган апасы Сәлимә каршы алды. Ул чат Тәнзиләгә охшаган: шундый ук сары чәчле һәм шундый ук сипкелле. Сүз дә юк, кәләш апасыннан күпкә чибәррәк һәм сылурак иде.

– Хуш киләсез, кунаклар! Әйдүк! Әйдүк! – дип сәлам бирде Сәлимә аларга. Күрәсең, ул бик тә дулкынлана иде, тавышы калтыранып, ярты сулышыннан киселеп чыга. – Әй...дүк! У...зыгыз!

Булачак кодагыйларның берсе белән Гобәй үзе (Люция өйдә калды!) килеп күреште һәм күз кырые белән генә капка төбендә өелешеп торган малай-шалайларга карап алды. Полковник сүзсез дә аңлады: бу балаларның барысы да акча җыйнарга җыелган иде!

– Безнең өчен капкаң ачыкмы соң, кодагый! – дип сорады Гобәй.

– Ачык, ачык, яхшы кешеләр өчен һәрчак ачык! – дип бертуктаусыз быбылдады тегесе.

– Белмим, белмим, – дип сөйләнде Гобәй, малай-шалайлар ягына кул изәп. – Җырлап кына бирсәк әгәр, уйнап кына, әйтик, бушлай уздырасызмы?

– Җә, җырлагыз суң, җырлап карагыз! – дип татылдады Сәлимә.

– Сафа! – дип кычкырды Гобәй.

– Тыңлыйм, иптәш полковник! – дип, честь биргәндәй итте Сафа.

– Тальянны ал әле!

– Кая әле ул?

– «Волга»да!

Гобәйнең хоббие бар: гармун һәм баянда уйнарга ярата. Ул бер хромка, ике тальян гармун, бер бик яхшы баян хуҗасы иде. Тальянын гел машинасына салып йөри, кирәк чыкканда, шуны алып уйный торган иде. Менә хәзер дә ул, кияү һәм кияү егетләренә ияреп, кыз артыннан килгәч тә, үзен әзрәк авыл халкы алдында күрсәтергә теләп булса кирәк, кулына тальянын алды. Әйе, ул әле үзе дә тиздән шушы авылның кияве буласы кеше. Люция белән алар ике арадагы мөнәсәбәтләрен бер-ике айдан соң законлаштырырга уйладылар...

Гобәй гармунда авыл көен уйнады, начар уйнамады, тәмен белеп уйнады. Кияүне күрүдән бигрәк, әзрәк вак-төяк акча каптырып, шул тиеннәр белән авыл кибетенә йөгерергә хыялланган балалар да, дәррәү килеп, җыру сузган үзешчән сәнгать остасы ягына авыштылар...

Ал салыйммы, гөл салыйммы
Аклы күлмәкләремә,
Кар кабыйммы, су кабыйммы
Янган йөрәкләремә?
Ал да кисә, гөл дә кисә
Тегүче кайчылары.
Үзен-үзе зурга куя
Кызларның кайсылары.
Ак алъяпкычлар тегәргә
Бер метр сатин җитә.
Үзен-үзе зурга куйган
Кызларга исем китә.
Капка төбең кар гына,
Кереп булмый көрәксез.
Чыгам, чыгам, дип әйтәсең,
Чыгалмыйсың, йөрәксез.
Их!
Яшь гомерләр уза, диләр,
Узганын күрсәң иде.
Узган чакта тотып алып
Кирәген бирсәң иде...

Полковник гармунда яхшы уйнаса да, җырлавы артык ис китәрлек түгел иде. Тавышын, кәҗә тәкәсенеке сымак, югары күтәреп җырлый, шуңа күрә дә җырлаган чагында кайбер җирдә сулышы, тавышы җитә алмыйча кала. Мәктәп хорында башлап җырлаучы булган Сафа, полковникның тавышы җитмәгән җирдә, үзеннән нидер өстәп, уртак чыгышларын көчәйткәндәй итте...

Ниһаять, Гобәйләр төркеме капкага таба юнәлде. Кечкенә капканы шундук малай-шалайлар сырып алды. Сафа артык кыланып, уйнап тормады, янчыгыннан бер уч тимер акча учлап алып, аны җиргә сипте. Полковник әйткәнчә, чирәм өстенә түгел (аннан акчаны лупа белән эзләсәң дә

табалмыйсың!), ә чиста һәм тигез урынга чәчте. Бәйрәм бит, бәйрәм булгач, бәйрәм итсеннәр, әйдә!

Ләкин бәреп керү матавыгы моның белән генә тәмамланмаган икән: кече капка эчке яктан бикле булып чыкты. Эчтә, ишегалдында да кызны саклаучылар табылды, болары инде олыраклар – кызның туганнары, дуслары һәм танышлары иде. Сафа янында гына басып торган дустына, икенче кияү егетенә күз кысты. Шактый яшь булуга да карамастан, корсагы олы яшьтәге ирләрнеке сымак бүлтәйгән, таза һәм озын гәүдәле Вильдамир, тырмашып, капка кырындагы биек коймага менеп китте. Койма башына ул нигәдер ярсып, сүгенә-сүгенә менде. Теләге – ишегалдына төшеп, эчтән капканы ачу. Ләкин эчтәгеләр аңар әлеге мөмкинлекне бирмәделәр, аны, койма башына ябышкан кулына таяк башы белән сугып, кире якка төртеп төшерделәр. Бер центнерлы майлы гәүдә гөрселдәп ком өстенә барып төште: шултиклем гөрселдәүдән хәтта тузан бураны күтәрелде. Авыл халкының шаркылдап көлүе астында: «Ди-и-кий народ, дикий!» – дип, акыра-бакыра, җирдән күтәрелгән Вильдамирны шундый мескен хәлендә күреп, хәтта җитди, кырыс холыклы полковник та елмаерга мәҗбүр булды...

– Әй, егетләр, әйдәгез алга, туктамыйк! – дип, Сафа тиз генә капка каршына килеп басты һәм кәкре очлы тимер келәне шакылдатып, эчтәгеләргә сорау бирде. – Кертәсезме безне?

– Кем син? – дип эчтән чәрелдәде бер хатын-кыз.

– Кияү егете! – дип җавап бирде Сафа.

– Акчаңны әзерлә, кияү егете!

– Акчасыз гына булмыймы? – дип сүз көрәштерде егет.

– Юк, безнең Тәнзиләбез бик тә әйбәт һәм ул бик тә кыйбат тора, тиеннәр биреп кенә котыла алмассыз!

– Әгәр дә бер янчык акча бирсәк, нәрсә? – дип, акча янчыгын чылтыратып алды Сафа.

– Юу-ук! Тиеннәрең үзеңә булсын, син безгә кәгазь акча әзерлә! – диештеләр тегеләр.

– Хәзер! – диде Сафа һәм таушалып беткән совет берлеген, кесәсеннән чыгарып, капка ярыгы аша эчкә сузды. – Булдымы?

– Юк, юк, булмады! Тагын берничәне өстә!

– Юк инде, дуслар, договор дороже денег! Сез кәгазь акча сорадыгыз, име, без сезгә аны бирдек, ә хәзер, рәхим итеп, безгә капканы ачыгыз!

Ләкин эчтәгеләр ачмады, тагын берәр тәңкә генә булса да өстәргә сорадылар. Шуннан соң ярдәмгә кунакларны каршы алырга чыккан Сәлимә килде, ул эчтәгеләрдән, артыгын кыланмаска сорап, капканы ачтырды. Сафа шул сөенеченнән янчыктагы бар булган вак акчаны урамга сипте, бу хәтле юмартлыктан тәмам шашкан балалар, бәрелешеп, җирдәге тиеннәрне җыйнарга тотындылар. Сафаның акчаны бер дә юкка шулай сарыф итүе Гобәйнең эчен пошырды булса кирәк. Ачуыннан күркә сымак кабарынган һәм инде яшьләргә ияреп йөрүдән туя башлаган полковник: «Зерә, егет, зерә шулай кыланасың!» – дип, аның артыннан, ата каз кебек шаулап, ысылдап калды. Кунаклар, ниһаять, ишегалдына уза алдылар, арты белән тузан күченә утырган Вильдамир исә төркемнең алдыннан барды. Ләкин алда әле сынаулар бетмәгән икән, аларга чолан ишеген ачмадылар. Бу юлы акчаны күп сорадылар, ә Сафада ул хәтле акча юк. Ул, ирексездән, нишлибез дигән сыман, Абрекка карап алды. Кызны саклаучылар инде биш тәңкә сорадылар. Нишләсеннәр, биш тәңкәне чыгарып

бирделәр! Тик чолан эчен узгач, инде өйгә керә алмыйча интектеләр: өй ишеге эчтән бикле булып чыкты. Юан беләкле Вильдамир ишекне тегеләй дә, болай да тарткалап карады, ләкин кара дерматин белән тышланган нык ишек һич кенә дә урыныннан кузгалмады. Бу юлы ун тәңкә сорадылар. Бусы артык иде инде: чөнки ун тәңкә шактый зур акча. Ишек саклаучылар белән килешеп тә, сөйләшеп тә булмас кебек. Хәер, Абректа анысы да табылды, бәхәсне артык озакка сузмыйча гына, кесәсеннән унлыкны чыгарды. Эчтәгеләр ул акчаны кунакларны каршы алучы Сәлимәгә бирергә куштылар, кияү Ленин башы төшкән кызыл унлыкны, тыныч кына, хатынның учына шудырды. Шуннан соң «сим-сим», ягъни өй ишеге ачылып китте. Кунаклар аш ягына килеп керделәр, анда аларны Тәнзиләнең әнисе Рузалия кодагый каршы алды. Ләкин кәләш аш ягында түгел, түр башында урын алган икән. Гөнаһ шомлыгына каршы, түр ишектә дә шундый ук зәхәр сакчылар басып тора иде һәм алары да кияүне бушлай уздырып җибәрергә ашкынып тормыйлар. Кәләшне сатып алу шактый матавыклы вакыйгага әйләнгәнен аңлап алган кияүнең бераз гына кәефе төште, ул, ирексездән, сүгенеп тә куйды. Акча җыюның артыкка киткәнен сизенгән Рузалия кодагый, ишек сакчыларын тиз генә куып таратып, үз кулы белән түр ягына юл ачты. Ап-ак туй күлмәге кигән Тәнзиләне, ягъни кәләшне таслап өелгән өч йомшак мендәр өстенә утыртканнар. Өй алу һәм кыз яулау мәшәкатьләреннән тәмам арыган, шул вакыт эчендә шактый кырысланып өлгергән кияү егете түзмәде, тыныч кына мендәр өстендә утырган ушсыз (аның уенча!) кәләшкә: «Нәрсә утырасың инде, төш, әйдә!» – дип эндәште. Туй көнендә сөеклесеннән шундый тупас сүзләр ишетермен дип көтмәгән кәләш, кинәт чайкалып китеп, мендәр өстеннән очып төште, ә кияү исә аны чак кына кулында тотып кала алды...

Яшьләр авылда түгел, ә Казанда язылыштылар. Кыз ягындагылар авылда гына язылыштырырга теләсәләр дә, Люция аларга каршы төште. Казанда яңа өйләнешүчеләрне матур заллы ЗАГС биналары көтә, анда язылышу тантанасы да күркәм төстә уза, килгән кунаклар өчен дә җайлы һәм, билгеле ки, инде модага кереп барган Мендельсон маршын да уйнаталар. Ә иске һәм караңгы авыл советы бинасында, теше коелган, авызы чалшайган карт секретарь хатынның күңелсез вәгазен тыңлап тору – күркәм күренеш булырга охшап тормый иде, билгеле...

Туй делегациясе Казан ЗАГСына вакытында барып җитте, авыл белән кала арасы әллә ни ерак түгел, җитмеш-сиксән чакрымнар гына. Язылышу һәм туй мәҗлесе тавышсыз-нисез, шома гына узып китте. Мәҗлестә кыз ягындагылар күбрәк булды, ләкин бу күренеш туйның ямен бозмады, киресенчә, көчәйтте генә. Мәскәү, Себер һәм Үзбәкстан якларыннан кайткан кунаклар туйны шактый күтәрделәр – бүләген дә мулдан салдылар, мәҗлестә дә үзләрен күңелле тоттылар, җырладылар, биеделәр...

Кыскасы, кәләшнең кияүгә кигезәсе балдагы кулыннан төшеп китүен исәпкә алмаганда, өйләнешү гамәле начар узды, дип әйтерлек урын калмады. Тик менә Гобәйнең саранлыгы исә кияү кешегә йөзе белән кайтты: аракы урынына су тутырылган ялган шешәләр биреп калдырганы өчен бик нык үпкәләгән авыл яшьләрен Абрекка, гафу үтенә-үтенә, өч көн буе рәттән яхшы итеп сыйларга туры килде...

...Туй мәҗлесеннән соң кияү белән кәләш Абрекның фатирына кайттылар. Люция моннан бер атна элек кенә Гобәйгә күченеп киткән иде. Туй мәшәкатьләреннән тәмам арыган, талчыккан ике яшь кеше, ниһаять, илле квадрат метрлы фатирда

икәү генә калдылар. Абрек туйда кигән костюм-чалбарларын, күлмәген, галстугын тиз генә салып атып, әнисе алдан ук җәеп киткән ап-ак йомшак урынга, калын матрацлы, мендәрләре кабартылган киң караватка ауды. Рә-ә-хәт! Алар хәзер ир белән хатын, алар бер бөтен, алар бер тән, бер җан, алда – бәхетле киләчәк, шатлыклы вә сөенечле мизгелләр көтә. Бүген исә – күптән көтеп алган татлы мәхәббәт төне, зөфаф киче булырга тора. Тәнзилә озак чишенде. Туй күлмәген салганда, ире аңар салырга булышыр дип көткән хатынның өмете акланмады, караватка сузылып яткан Абрек селкенмәде дә. Ул, түземсезләнеп, сөеклесенең тизрәк янына килеп ятканын көтте. Тәнзилә туй күлмәген җилкәчеккә элеп, зал ягында торган дәү гардеробка урнаштыргач, үтә күренмәле пеньюар киеп алды. Аннан ул, тартынып кына, ире яткан йокы бүлмәсенә керде һәм, эчкә үтәргә кыймыйча, ишек төбендә төртелеп калды. Абрек аны бер кат күздән кичереп чыкты. Әйе, кәләш туйда утырганда да матур иде, кунакларның күзе, әлбәттә, гел Тәнзиләдә булды, ләкин мондый килеш сөеклесен беренче мәртәбә күрә һәм бу хәлдә исә ул тагын да сылуырак булып күренде. Абрек, җилкенеп, Тәнзиләне кочып алды. Сөеклесен берничә кат кулында әйләндереп алгач, кадерләп кенә, йомшак мендәр өстенә китереп салды...

– Ой, әйләндермә, зинһар, болай да башым әйләнгән! – дип зарланды хатыны.

– Туй әйбәт узды бит, җаным, әйеме?!

– Ярыйсы...

Тәнзиләнең җавабы нигәдер икеле-микеле яңгырады кебек. Һәрхәлдә Абрекка шулай тоелды. Әйтерсең лә ул кияүгә чыгуына шат түгел, әйтерсең, аны көчләп биргәннәр...

– Мин сине аңламыйм, җаным! – диде ир. – Син нәрсә, кияүгә чыгуыңа сөенмисеңме?

– Әйе, син хаклы, – дип килеште аның белән Тәнзилә. – Мин бүген бик тә бәхетле, сиңа кияүгә чыктым, яратып чыктым, быел укуны тәмамладым, диплом алдым, инде хәзер эшкә урнашасы гына калды. Юк, син начар уйлама, мин бүген чынлап та бәхетле, бик тә бәхетле... тик...

– Әйе?

– Соң түгел әле...

– Нәрсә соң түгел?

– Кире уйларга соң түгел... дим...

– Мин сине аңламыйм, Тәнзилә, – дип ярсыды ир.

– Аңлыйсың син барсын да...

– Тагын бабаң исеңә төштеме? Тагын шул җүләр уеңны яңартырга булдыңмы?!

– Әйе, искә төште. Өйләнешүебез, гомумән, дөрес гамәл булды микән...

– Кы-ы-зык! – дип кызды Абрек. – Язылышкач кына, син кабат шул җүләрлегеңә тотындың. Оныт! Җитәр! Без хәзер ир белән хатын! Безнең арага бабаңның да, тәти абыйның әллә кайчангы ахмак дошманлыгы килеп керергә тиеш түгел, аңлыйсыңмы?!

– Аңлыйм... да...

– Аңлагач, нәрсә тагын?!

– Уйландыра...

– Ә син уйлама!

– Яхшы, уйламыйм...

– Уйлыйсың бит...

– Кичер мине, Абрек... кичер...

Баядан бирле җайсыз сүз сөйләп, киеренке халәттә яткан Тәнзилә кинәт кенә йомшарып, башын иренең җилкәсенә салды...

– Син шуны аңларга тиеш, Тәнзилә...

– Аңларга тырышам бит...

– Бүген безнең кабатланмас көн...

– Төн инде, – дип елмайды ул.

– Әйе, бүген безнең бәхет төне, бүген безгә кирәкмәгән сүзләр куертырга ярамый, без бер-беребездән бары тик ләззәт кенә алырга тиешбез...

– Ачуланма...

– Мин үз сүземдә тордым, җаным, туйга хәтле орынмадым...

– Син чын егет, Абрек, мин сине шундый яратам...

– Ләкин... «тик» дигән сүзне генә әйтмә! – Ир, назлы гына, аның борын очына чиертеп алды.

– Яхшы, әйтмәм...

– Ир сүзе нәрсә, диләр әле...

– Закон...

– Во! Дөрес!

– Да, җаным, син минем законлы ирем!

– Ә син минеке...

Пеньюар идәнгә очып төште. Күптән кавышуны көткән, зарыгып көткән ике тән, ике җан, бер-берсенә сөенеп, иркәләнеп назланды. Хатынының сусыл чия сымак кызарып, бүртеп торган тулы ореннәрен тешләп өзәрдәй булган ир аны кисәк кенә суырып үпте һәм назлап кочагына кысты. Җиңелчә генә ыңгырашу тавышы ишетелде. Әлеге авазда исә күптән көтеп алынган вакыйганың тормышка ашуына сөенгән җылы наз авазы ишетелгәндәй булды...

**Бишенче бүлек**

## Гобәй

Татарстан халкы үзгәрүчән климат зонасында яши. Җәй ае башланды исә, шундук көзе дә килеп җитә. Чын-чынлап җылы, ямьле көннәр, булса да, шул ике-өч ай гына була. Аннан – яңгырлы көз, карлы, буранлы кыш, язгы ташулар китә...

Җәй буе кешедә эшләп йөргән Фатыйх елның бу фасылы үтеп киткәнен сизми дә калды. Хәер, җәй үткәнгә үкенерлек нәрсә юк иде, тормышы мул әлегә, акчасы җитәрлек. Яртысын Сарага бирергә туры килде, Сара аны бурычка дип алды, әмма Фатыйх аңардан ул акчаны кире сорамады.

Сентябрь урталарында каладан Люция кайтып төште. Гадәттә, алар Абрек белән бәрәңге алган вакытка туры китереп кайталар иде. Бу юлы Абрек кайтмады, ул хатыны белән, юллама алып, ял йортына китеп барган. «Тапканнар вакыт!» – дип сүкте яшьләрне Фатыйх. Ул хаклы иде, – бәрәңгене күп утырта, ә аны алыр өчен шактый көч түгәргә кирәк. Элегрәк бәрәңгене алганда да, утыртканда да, ат кулланалар иде. Рәт араларын да җәй башында ат белән, сука белән сыздылар. Тик колхозда хәзер җүнле ат калмады, атны бөтенләй оныттылар. Халык бәрәңгене язын көрәк белән утыртырга, ә көзен сәнәк белән казып алырга өйрәнде...

Люция ялгызы гына кайтты, Кәефсез кайтты. Яшьләр өйләнешкәч, бер ай да узмады, Гобәй белән Люция дә ЗАГСка барып язылышып кайттылар.

Элегрәк кияүгә чыкканда, туйлар ясатып баш катырган хатын Гобәй белән бу юлы туйсыз-нисез генә язылышты. Ул инде хәзер күптән иренең бер бүлмәле фатирында яшәп ята иде. Бу фатирны Гобәй, хатыны белән судлашып, бүлеп ала алды. Алдан ул хатыны һәм ике улы белән дүрт бүлмәле фатирда яшәде. Шушы дүрт бүлмәле фатирны бүлгәннән соң, хатын белән балаларга ике, ә аерылган иргә бер бүлмәле фатир калды. Гобәй хәтта өйдәге җиһазларны да бүлдерде. Ул иске фатирыннан бер зур диван, бер кухня шкафы һәм язу өстәле алып кайтты. Мебель генә түгел, хәтта табак-савытларны да бүлде, өйдәге пластмасс кашыкларны, чәнечкеләрне өстерәп кайтырга да тартынмады...

– Нәстә булды? Сөйлә! – диде Люциягә абыйсы, өстәл янына чәй эчәргә утыргач.

– Нәрсә сөйлим?

– Кәефең юк бит, күрәм. Абзый нишләп кайтмады? Нигә үзең генә йөрисең?

– Гобәй эшкә урнашты...

– Пенсиядә түгелме суң ул? Пенсиясе яхшы булырга тиеш бит аның.

– Пенсиясе яхшы, персональный. Ләкин эшсез тора алмый, өйдә утыра алмый! – дип сөйләнде Люция. – Әй, эшләсен лә, әйдә!

– Дөресен сүләмисең, димәк?

– Сөйлим, тик сиңа сөйләргә дә куркам...

– Нишләп?

– Тагын кияүдән уңмадың, дип сүгәсеңнән куркам.

– Сүгеп туйдым инде. Сүлә, җә...

– Ай, абый, – дип елады ул, – читен аның белән торулары, бик тә читен, бик тә авыр кеше ул!

– Авыр дип... менә мин дә җиңел кеше түгел, пример, шуннан нәстә?

– Абый, син бөтенләй икенче кеше...

– Нинди?

– Киң күңелле, – дип мактап алды ул абыйсын. – Ә бу вак, метер, саран, һәрбер капейкы өчен чукына торган бәндә... Кибеттән берәр нәрсә алып кайтсам, шуның бәясен сораштырып интектерә. Бер көннәре базардан тана ите алып кайттым, яхшы тана ите, киласы өч тәңкәдән. Базарда ул кыйммәтрәк тора, ләкин ите яхшы, сыйфатлы. Нишләп кибеттән генә алмадың, анда арзан бит, дип, көне буе җанымны ашады. Кибет ите арзан булса да начар, аннан аны гел чират торып алырга кирәк, ә мин, үзең беләсең, чират торырга яратмыйм. Аның акчасын тотмадым, итне үз акчама алдым. Мин хәзер ЦУМда уенчыклар сатам, мине сатучы итеп алдылар. Менә шул...

– Сүлә, сүләп бетер...

– Абрек та, килен дә әлегә эшкә урнашмаганнар. Укып бетерделәр. Килен мәктәптә физика укытырга уйлаган иде, әлегә аны алмадылар, ә Абрек Оргсинтезга урнашачак. Баллы айларында беркая да бара алмадылар, ә мин аларга ял йортына булса да юллама алып бирдем. Моны Гобәй белгән, киленнән ишеткән. Паразит! Ике көн канымны эчте. Юк, абый, яши алмам, ахры, мин аның белән. Абрекка сөйләгән идем, әни, борчылма, ташла ул ментны, безгә кире кайт, диде. Килен дә шуны тукый...

Абыйсы каршысында чәй йотып утырган Люция чәшкедәге чәен өстәл кырында торган юынтык су чиләгенә илтеп түкте. Аннан, күңеле ташып, еларга тотынды. Ачынып, рәтен китереп елады. Ләкин яшь гомерен таш зинданда уздырган Фатыйхның кырыс күңелен хатын-кызның күз яше генә алырлык түгел иде, күрәсең.

– Сеңелкәш, – диде ул, шактый тыныч калып, – әгәр дә син минем киңәшне тыңларга теләсәң, мин сиңа шуны әйтә алам: кемгә чыкканыңны белеп чыктың, гади кешегә түгел, ментка чыктың, аны үзеңчә яхшы кеше итеп күрергә телисең. Ләкин ул син теләгән кеше түгел, аны инде үзгәртә алмыйсың...

– Аңлыйм! – Хатын ничек итеп тиктомалдан еларга тотынса, шулай кисәк кенә елавыннан туктады. – Нишләргә кушасың?

– Түзәргә кирәк, сеңелкәш, түзәргә...

– Түзәргә?! – дип аптырады Люция. – Син миңа түзәргә кушасыңмы?

– Шунсыз булмый, сеңелкәш, булмый, коммунистлар Ходайны юк, диләр, ә Ходай бар ул, ул барсын да күреп, адашканнарга юл күрсәтеп тора. Син гомер буе җүнле ир эзләдең, ирләр артыннан кудың, ләкин үзең теләгәнне таба алмадың. Инде менә Ходай гомер көзендә сиңа шушындый ир бирде. Түз, син аны ничек бар, шулай кабул ит! Бер зур кимчелегең бар синең, түземсез син, артык түземсез! Ә Ходай сабыр булырга куша. Әгәр дә хәзер ул кешедән аерылсаң, халык алдында да, улың белән киленең алдында да оятка калачаксың. Аерылсаң, халык Гобәйне түгел, ә сине гаепләячәк...

– Кайчаннан бирле әле син халыктан курка башладың?

– Мин халыктан курыкмыйм, әгәр курыксам, мин бөтенләй башкача яшәгән булыр идем. Ләкин әзрәк оят дигән нәрсәне дә белергә кирәк! Без бит синең белән хәзер бала-чага түгел, сеңелкәш! Улың, киленең ни әйтер, анысын да уйла?! Үзем өчен түгел, мин синең өчен куркам, аңла...

Дөресен әйткәндә, Люция абыйсыннан мондый җавап көтмәгән иде. Абыйсының Гобәйне яратмаганын (милициядә хезмәт иткәне өчен!) белгәнгә күрә, баш катырып ятма шул адәм белән, бүген үк аерыл, дип үгетләр дип уйлаган иде. Ә хәзер ул әнә бөтеләй икенче төрле сукалый...

...Хатын белән ир арасындагы каршылык, хәер, үзеннән-үзе хәл ителде. Полковник та җавап сүзен озак көттермәде, икенче көнне үк, «Волга»сына утырып, Фатыйхларга кайтып төште. Өйдәгеләр алдында ул үзен, берни дә булмагандай, шактый иркен тотты, хатыны белән булган ямьсезлекләрне искә төшереп тормады. Өйдәгеләрнең аны тыңларга вакытлары да юк иде, алар бакча кишәрлегендә, үлеп-бетеп, бәрәңге казыдылар. Полковник та бу авыр хезмәттән читтә калмады, хатыны җыйнаган бәрәңгене капчыкларга тутырып, берәм-берәм, базга ташыды. Крестьян хезмәтенә күнекмәгән Гобәйнең исә үтереп биле авыртты, кулы, аяклары сызлады...

Ике көндә алар бәрәңгене алып бетерделәр. Ике йөз дә ун чиләк бәрәңге (полковник санап барды!) базга төшеп утырды. Бәрәңгедән котылгач, Фатыйх кичен яхшы итеп мунча якты. Мунчага Гобәй белән Фатыйх икәү керделәр...

Мунчада кунак алып кайткан чех сырасын эчтеләр. Яхшы сырадан хәтта Фатыйх та баш тартмады. Әллә шуның градусы тәэсир итте, әллә полковникның теле ачылыр вакыт җитте, ул, Фатыйх алдында ихластан ачылды...

– Менә син, туган, минем турыда әллә ниләр уйлыйсыңдыр инде, – диде ул. – Әйе, беләм, каты кеше мин, кырыс кеше, шуңа күрә син мине ошатмадың, беләм. Уйлама, мин сиңа һич кенә дә үпкәләмәдем. Ләкин син шуны уйладың микән...

– Нәстәне?

– Сеңлеңне хатын иткән кеше нишләп шундый икән дип?

– Уйладым, ие, тик төгәл җавап таба алмадым...

– Менә шунда да шул хикмәт, – дип җөпләде аның сүзләрен полковник, – кешенең кем икәнлеген белмичә, аның турында беркайчан да ашыгыч нәтиҗә ясарга ярамый. Тарихи ялгышлар, туган, күп очракта ашыгып нәтиҗә ясаганда

барлыкка килә. Кем соң мин? Кулны йөрәк турына куеп әйтсәк, бер гади кеше, синең кебек үк, бер колхозчы баласы. Без алты бала үстек. Сугыш балалары без. Мәңге ач, мәңге ялангач. Әйтмим, синең тормышың минекеннән дә хәтәррәк булган, беләм. Чөнки миңа, синнән аермалы буларак, төрмә юлын таптарга туры килмәде. Ләкин төптән уйласаң, иле дә төрмә кебек иде бит аның, җинаятьчеләр өстеннән надзирательләр торса, алар өстеннән һәрчак дәүләт надзирательләре торды. Белмим, әти-әниләр безне ничек итеп укыта алганнардыр, анысы минем өчен әле дә караңгы. Шунысы анык: авылдан чыгып киткәч үк, югары белем алуны мин үземә бер максат итеп куйдым. Авылда алтмышынчы елларга хәтле халык крепостной хәлендә яшәде, авылдан китеп булмый, паспорт бирмиләр. Хәер, ишле гаиләдә булгач, мин, армиядән кайтуга, калага китә алдым. Башта милиция курсларына йөрдем, соңыннан университетка укырга кердем. Диплом алгач, милиция хезмәтенә җигелдем. Дөресе шул: әйе, мин чынлап та артык кырыс кеше, кайчак явыз да була алам. Ләкин моңа мин генә гаепле түгел, тормыш шуңа өйрәтте, тормышы шундый кырыс булгач, кая барасың? Йә кабул итәсең аны, йә юк. Итмәсәң, синең үзеңне шундук изеп, таптап китәләр! Ә мин үземне, прости, беркемнән дә таптатмадым, мин үзем таптадым аларны, үзем! Шунсыз булмый, брат, безнең эштә шунсыз исән калам димә!

– Күрдем инде мин сезнең халыкны! – диде Фатыйх. – Мыскыл итеп тә карадылар инде...

– Күргәнсеңдер, әйтмим, – дип дәвам итте сүзен полковник. – Әйтер сүзем милиция турында түгел, сүзем бөтенләй икенче нәрсә турында иде бит... Үзем турында. Кемнең нәстә күргәне үзе өчен генә кирәк ул. Ни әйтсәң дә, мин дәүләттән артык зыян күрмәдем. Киресенчә, дәүләт мине укытты, миннән кеше ясады. Мине, беләсең килсә, дәүләт түгел, ә, беләсеңме, кем рәнҗетте?! Хатын, бывший хатын...

– Хатын?! – дип шаккатты Фатыйх. – Люция берни дә сөйләмәде хатының турында...

– Әйе, хатын, инәсен корт чаккыры! Менә кая парадокс! Олыгайган көнемдә аерылырга мәҗбүр итте ул мине! Ул аерды безне, мин түгел...

– Кем иде суң ул синең хатының?

– Фәйрүзә исемле хатын, бер надан адәм шунда. Кем уйлаган бит аны, шулай килеп чыгар, дип...

– Ә мин сине үзең теләп аерылгансың дип уйладым... Люция дә бер сүз сөйләмәде...

– Люция күп нәрсәне белми ул, – дип көрсенде полковник. – Моннан ике ел элек булды бу хәл. Органнарда хезмәт иткәндә, миңа ел саен ял йортына юллама бирәләр иде. Ялдан соң кайтып төштем, име, фатирга кереп булмый. Фатирның ишек йозагын алыштырып куйганнар. Хатын эше булып чыкты! Үзе алыштырмаган, билгеле, кешесен тапкан. Чемоданымны күтәреп, җүләр кеше сымак, озак кына ишек каршында басып тордым. Өйгә кереп булмады! Йозакны алыштыру гына бер хәл, бар булган милеккә арест салдырган. Суд ике елга якын барды. Фатирны бүлдек. Дачабыз бар иде. Үзем тырышып салган. Анысын инде бүлешеп тормадык, балаларга калсын, дидем. Ярар, калсын, ди. Иң аянычлысы шул: бырат, балалар да әнисендә калды. Ике ир бала. Аналары, с...ка, балаларны үз ягына авыштырып бетерде, алар хәзер минем белән бөтенләй сөйләшмиләр, сөйләшү түгел, хәтта очрашырга да теләмиләр. Кече малаем Фаязны туган көне белән котларга дип өйләренә барган идем, мине фатирга кертмәделәр. Ул хәтта яныма чыгып, минем белән исәнләшмәде дә... Менә шул чакта миңа әллә нәрсә булды, туган! Шулчак бик каты еладым мин,

әрнеп, рәнҗеп еладым! Нинди начарлык эшләдем соң мин шулхәтле аларга? Ни өчен алар мине шулкадәр күралмыйлар? Начармы-яманмы, мин бит аларны үстергән, укыткан, ашаткан, аталары бит мин, канса да кансуф! Аңар калса, нинди генә әтиләр юк! Балаларын ташлап качкан алкаш, псих аталар бар. Ә юк... балалары әле шул кабахәтләрне эзләп табалар, аңар ярдәм кулы сузалар, әле шуларга: «Әти!» – дип эндәшәләр. Ә минекеләр... әти, дип тә дәшмиләр... Әти, хәлең ничек, дип, ичмасам, бер шалтыратып хәлемне дә сорамыйлар...

Фатыйх әлегә хәтле каршысында елап торган милиция кешесен күргәне булмады. Тормышта, киресенчә, алар кешеләрне елата. Хәер, ул мескен кеше, аны хатыны, балалары ташлаган, аңар хәзер ничек еласа да, нәрсә кыланса да килешә кебек.

– Ә Люцияне яратам мин, – дип җан танды полковник. – Беләм, соңгы тапкыр үпкәләттем мин аны, бар булган ачуымны ни өчендер аңардан алдым. Алай ярамый, билгеле, шулай да мин аңардан гафу үтендем. Люциясез яши алмыйм мин. Олыгайган көнеңдә ялгызың калу коточкыч нәрсә...

– Гаепне үзеңнән дә, хатыныңнан да эзләргә кирәктер, гаеп күп очракта ике яклы була, – дип фикер йөртте Фатыйх. – Кем иде суң синең хатының? Каян таптың син аны?

– Детдомнан...

– Детдомнан? Ятимәмени?

– Анасы була торып... ятимә... Анасы, минем булачак тёща яшь чагында бик йөремсәк хатын булган, өч ирдән өч бала тапкан. Өч баласы да – өч атадан. Фәйрүзә – беренче бала. Балаларын туйдыра алмый башлагач, ул кызын алты яшендә детдомга илтеп биргән...

– Мескен бала...

– Мескен... әйе... ул чакта мескен иде ул, нәүмиз. Ундүрт яшьләрендә анасы аны детдомнан алып кайткан. Мин аның белән трамвайда барганда таныштым. Әллә ни сокланырлык, күз төшәрлек нәрсәсе дә юк: хәерче генә киенгән, килеш-килбәте дә әллә нәрсә генә... Нигәдер кызгандым мин аны, җәлләдем, кызганып, җәлләп өйләндем... Шулай... тик соңыннан менә үземне кызганырга туры килде... Хәзер аңладым: беркайчан да беркемне дә кызганырга кирәкми... Кешене кызганып, үзең кызганыч хәлдә калуың хәзер икән...

Юк, ул аны кызганмады, кешене кызгану (Фатыйх уенча) – ул кешене бозу гына. Әйе, Гобәйнең фаҗигасе көн кебек ачык, аны берничек тә сызып атып булмый. Тик монда әле ачыкланмаган нәрсәләр дә шактый күп кебек. «Балаларың сине шулхәтле күралмас өчен, белмим, аларга карата ни явызлык кылдың икән суң син, полковник?!» – дип уйланды ул, ирексездән, һәм мунча ләүкәсенә кунаклап, озаклап кына үзен суга манчылган каен миннеге белән чапты. Әйе, яшиселәр алда әле: бу сорауга да, тора-бара, һичшиксез, җавап табылыр кебек...

**Алтынчы бүлек**

## Ана хәсрәте

Фатыйх кыш буе авырды. Яңгырлы юеш көздә үпкәсенә салкын тидергән ир башта хастаханәдә ятып чыкты, аннан өйдә дәваланды. Сара, кышка өен бикләп, Фатыйхларга күчеп килде. Ул мичен утын белән генә яга, ә Фатыйхта күмер күп. Сараның килүенә Фатыйх, яшь бала сымак, чын күңеленнән сөенде, кош тоткан кебек йөрде. «Дөрес эшләдең, Сара, ир кеше түгел, ә хатын ир өенә

килергә тиеш!» – дип шаярткаласа да, хатынның холкын яхшы белгәнгә күрә, аны бөтенләйгә үз янында калдыруга өмет багламады.

Кыш бик салкын булды. Гыйнвар уртасында суык хәтта кырыкка хәтле төште. Кешеләр җылы өйләреннән чыгарга куркып яттылар, юлда йөрүләр тукталды, салкында электр чыбыклары өзелде, фермаларда су торбалары шартлады. Юлларда катып үлүчеләр, аяк-кулларын өшетүчеләр күбәйде. Мондый көчле салкыннарга бары тик мәктәп балалары гына сөенде: алар өч атнага якын укырга йөрмәделәр.

Ләкиң иң куркынычы Фатыйхны алда көткән икән: кырык градуслы салкыннан яшелчә бакчасындагы алмагачларның яртысы өшеп юкка чыкты. Сортлы алмагачлар шактый зур зыян күрде, бигрәк тә кышкылары. Ишелеп-ишелеп алма биргән алмагачлар язын яфрак яралмыйча, чәчәккә узалмыйча, корып, юкка чыгып беттеләр...

Тәнзилә баласын җәй башында тапты. Ир бала. Аңа Айдар дип куштылар. Илдә бала аягын юу дигән бер яман гадәт таралды, яшь ата-ана да бу гамәлдән читтә кала алмады. Иң әүвәл калага Тәнзиләнең ата-анасы барып, кунак булып кайтты. Кодалар буш кул белән бармадылар, шатлыклары зур иде, күрәсең, балага яхшы коляска бүләк иттеләр. Фатыйх калага бераз соңрак барды, бүләк-мазар алып тормады, акчасын гына калдырып китте...

Тәнзилә тулгакны авыр кичерде, баласын авыр тапты һәм гел табиблар сагы астында яшәде.

– Черек хәзерге хатын-кызлар! Хатыныңа гына атап әйтмим, кәнишне, гомумән әйтәм, – дип сөйләнде шулчак Фатыйх. Хатыны янында түгел, Абрекның үзенә генә сөйләде, билгеле. Тәти абыйсы Казанга кунакка килгәч, алар авыл турында төнгә хәтле сөйләшеп утырырга яраталар иде. – Безнең әбиләр унар-унбишәр бала тапканнар, әллә ни артык сакланмаганнар да, бала тапкач ук, эшкә чыкканнар... Югары очта бер Тәгъзимә исемле апай бар иде, хәзер карчык инде ул. Шул, тугыз корсакка унбер бала таптым, дип сөли торган иде. Больниста бала табу дигән нәстә юк иде ул, акушер эшен авылда гомер буе кендек әбисе башкарды. «Әби тәтә», дип йөртәләр иде аны бездә. Әби тәтә тулгакны алдан ук белеп тора, вакытында ярдәмгә ашыга...

– Нишли ул әби тәтә? – дип кызыксынды Абрек. Тәти абыйсы сөйләгән әйберләр аның өчен әзрәк кыргый да, сәер дә иде.

– Әби булучы карчык, бала тугач, баланың кендеген кисә һәм соңыннан аны юындыра. Бер генә мәртәбә килми ул бала тапкан ана янына, берничә мәртәбә килә. Әни бик авыр тапты Люцияне, без инде аны үләр дип тә уйлаган идек, ләкин әби тәтә, маладис, аны саклап кала алды. Менә бит ул ничек, әниең исән калмаса, син дә бу дөньяга килмәгән булыр идең. Әнә шул әби тәтәләр гомер бирә ие инде яңа туган балаларга...

– Үлүчеләр дә күп булгандыр ул заманда?

– Булгандыр, әйтмим, начары үлгән, тазасы калган...

– Табигый сайлау булган, димәк.

– Шулайдыр, – дип килеште Фатыйх. – Ә хәзер медицина барысын да исән калдырырга тырыша. Безнең заманнарда, бигрәк тә сугыштан соң, балаларны күпләп таптылар, чөнки хатын-кызга бала төшерергә, аборт ясатырга рөхсәт юк иде. Аборт ясаткан өчен төрмәгә утыручы ханымнар да булды...

– Әби тәтә дигәнең бушка йөрмәгәндер инде, аңар түләгәннәрдер?

– Әй, кем түләсен инде! – дип кул селтәде тәти абыйсы. – Әйтмим, хәлдән килгәнчә биргәннәрдер, бәлкем! Соңрак, дим...

– Әйе...

– Балагызны сөннәткә утыртырга онытмагыз...

– Кирәк нәрсәме соң ул, тәти абый?

– Дин буенча мәҗбүри нәрсә түгел, әмма чисталык өчен кирәк...

– Ничә яшьтә утырталар?

– Без сине өч яшьтә утырттык, син аны хәтерләмисең дә инде, – дип елмайды Фатыйх. – Таныш бабачым бар иде, шуңар кистердек. Шунысы бар: парсыз елда утыртырга кирәк баланы, парлы елда ярамый. Өчтә, биштә, җидедә... әйтик...

– Бабачы табарсыңмы соң безнең малайга?

– Табарбыз, исән генә булсын, – диде аңар тәти абыйсы. – Сиңа куркасы юк, анаң да, үзең дә коммунист түгел...

– Рәхмәт инде, тәти абый, акчаны да мул бирдең...

– Акчаны юкка сарыф итмә, кирәккә генә тот! – дип акыл өйрәтте Фатыйх. – Бәбине мунча керттегезме суң әле?! Бәби мунчасы якмадыгызмыни?

– Нинди мунча, тәти абый, Казан җирендә? Общийга алып барып булмый бит инде? Номерлар да артык чиста түгел, – дип акланды ата кеше. – Аннан яңа туган баланы мунчага кертеп юалар дип башыма да килмәде. Ваннада югач, шул җитәдер дип уйладык...

– Ванна белән мунчаны чагыштырма инде син, энем, авылда бала тугач, бәби мунчасы ягалар. Өч көн рәттән ягалар. Бәбине дә, бәбинең анасын да мунчага кертәләр. Алып кайтыгыз, әйдә, баланы авылга, бәби ашларын да шунда гына үткәрербез...

– Үзем генә хәл итә алмыйм, хатын белән, әни белән сөйләшергә кирәк...

– Әниең белән үзем сөйләшермен, хатыныңны үзең килештер. Бәби ашына кодаларны да чакырырбыз...

Абрек тәти абыйсын бигүк аңлап та бетермәде. Кайчандыр теше-тырнагы белән ике яшь парның өйләнешүенә каршы торган кешенең хәзер барысын да тигезләргә, җайларга теләп йөрүе, бер караганда, бик тә сәер иде...

...Тәнзилә нарасыйны авылга алып кайтырга теләмәде. Җылы җәй айлары булса да, ул балага салкын тидерүдән һәм, иң мөһиме, күз тиюдән курыкты. Ләкин барыбер туганнарының теләгенә каршы килә алмады: баланы авылга алып кайттылар. Гобәй абыйсы аны «Волга» машинасына утыртып алып кайтты...

Яшьләрне авылда җылы каршы алдылар. Шул көнне Фатыйх бала кайтуга ук мунча якты. Бәби мунчасын, элекке замандагыча, өч көн рәттән якмасалар да, хуҗа мунчаны каты итеп якты. Элек «Бәби мунчасы – әҗерле!» – дип, туган-тумачалар, кодалар, тирә-күршеләр, сабын йә сөлге-тастымал кыстырып, мунчага килә торган булганнар. Андый йола юк инде хәзер. Килен мунчада озак тормады, баланы да тиз генә юып, анасына тоттырып чыгарды. Гомумән, ул әлеге борынгы йоланы бигүк ошатып бетермәде, авылга да теләмичә генә кайтты...

Бәби ашына, бәби чәенә халык күп җыйналды. Оныгы тууына чын күңелдән сөенгән Люция ул көнне ике төрле бәлеш пешерде.

Бәби аягын юарга дип килгән ирләр хуҗага әзрәк үпкәләп утырдылар, чөнки хуҗа табынга аракы куйдырмады. Чәй эчүен эчтеләр, бәлеш тә ашадылар, ләкин аракы куелмау сәбәпле, кайбер ирләр (алар арасында Фатыйх йортына гомер аяк басмаган кешеләр дә бар иде!) шактый күңелсез һәм кәефсез утырдылар. Һәрнәрсәне җайларга өйрәнгән Абрек, хәер, җаен тапкан, баланың

аягын юарга теләүчеләрне бакча ягына алып чыгып китте. Башы эшләгән: Гобәйнең машинасына ярты ящик ак аракы салып кайткан...

Иртәгесен авылга кайткан кунаклар, шул ук «Волга» машинасына төяләшеп, калага таба юл алдылар. Барысы да шат, барысы да канәгать, тик бер Тәнзилә генә нигәдер күңелсез булды. Фатыйх әле кичә генә халык гөрләп торган өйдә кабат берьялгызы утырып калды, хәер, анысы да озакка бармады, кичкә, көтү каршылар алдыннан, түбән очтан Сара менеп җитте. Сараның хәзер үз өендә терлеге калмады, ул, ике дә уйламыйча, сыерын, ике яшь үгезен һәм алты сарыгын Фатыйх көтүенә кушты. Ир белән хатынның әнә шулай ике ихатадагы мал-туарны бергәләштерүләре аларның бер-берсе белән кушылу мөмкинлегенә өмет арттыра иде кебек...

Ләкин бу җәй (Олимпиада елы) ике як өчен дә җүнле җәй булып чыкмады. Өйләргә кайгы җиле бәреп керде: кинәт кенә Тәнзиләнең баласы үлеп китте. Кечкенә Айдар бу дөньяда ай ярым гына яшәп калды. Бу нарасый тиктомалдан шулай тиз генә үлеп китәр дип, беркем дә уйламады, билгеле. Ике як нәсел өчен дә бик зур кайгы булды бу. «Яшьли үлгән бала – изге була!» – дип сөйләнсәләр дә, әлеге сүзләр беркемне дә тынычландыра алмады. Ике як та нәрсә дип әйтергә дә белмәде. Тап-таза баланың кинәт кенә үлеп китүен беркем дә, берничек тә аңлата алмады. Бер көн эчендә бит! Баланың температурасы көчәйгән, аның көне буе эче киткән, ә кичен җан тәслим кылган. Нәрсәдән үлгәнен хәтта табиблар да әйтә алмады, фәкать җилкә генә сикерттеләр. Баланы моргка җибәрмәделәр, өйдә саклап калдылар. «Кем уйлаган бит, кем белгән?!» – дигән сүзләр бик еш яңгырады ул көннәрдә. «Мин сиздем, мин Айдарның үләсен сиздем! Күз тиде балама, күз, авылга алып кайтырга кирәкми иде баламны, кирәкми!» – дип бертуктаусыз тәкрарлады килен. Баласы үлгәннән соң, бик каты бәргәләнгән Тәнзилә соңыннан бөтенләй дәшмәс һәм сөйләшмәс булды. Бусы (табиблар әйтүе буенча) – истерикадан да әшәкерәк нәрсә, бу – үз-үзеңә, үз кайгыңа йомылу, кыскасы, депрессиянең иң авыр бер төре...

Икенче көнне баланы күмү мәсьәләсе туды. Кайда һәм ничек җирләргә? Айдар үлүгә, улы, килене янына йөгереп килгән Люция баланың җәсәден авылга алып кайту турында сүз чыгарды. Сак кына, куркып кына әйтте. Абрек бер сүз дә дәшмәде, Тәнзилә, теләсәгез нишләгез, дигән сымак, кул гына селтәде. Ә үзе сүз саен: «До чего же ненавижу деревню!» – дип сөйләнде. Калада яшәп, кала тормышына күнегә башлаган хатын хәзер әнә шулай урысча гына сибәргә күнеккән иде!

Баланы авылга кайтарып күмүне ике як та хуплады. Мәрхүмне, дин буенча, кояш баеганчы күмеп өлгерергә кирәк. Бу инде гомер-гомергә шулай килә, ул – йола, аны беркем дә һәм бернәрсә дә үзгәртә алмый. Гобәй үзенең яңа «Волга»сында мәет алып кайтудан баш тартты, Абрек йөк машинасы яллады, Айдарның җәсәден төнгә каршы авылга алып кайттылар, Фатыйх өенә куйдылар. Баланың үлем хәбәрен авылга таратмадылар, шуңа күрә мәет янында утырып, өйдә төн үткәрергә бары тик якын туганнар гына җыйналды. Килүчеләр аз булмады. Люция төн кичүчеләргә яулыклар өләшеп чыкты. Элегрәк житеннән эрләнгән һәм инәгә сапланган тегәрҗеп өләшкәннәр, хәзер сабын белән яулык кына өләшәләр. Ул заманнарда кәтүк җебе дигән нәрсә булмаган, шунлыктан кәфенне дә тегәрҗеп белән генә җөйләгәннәр.

Мәет янында тәһлил әйтеп, төн кичерер өчен, бик яхшы укый белгән авыл карчыгын чакырдылар. Ул үзе эшен намус белән башкарды, вакытсыз, бик тә вакытсыз якты дөнья белән хушлашкан мәрхүм баланы догасыннан

калдырмады. Әйе, җир судан туймаган кебек, мәет тә догадан туймыйдыр. Үз алдына пышылдап кына догаларын укыган чагында, ак әби ара-тирә:

Юл буенда печәнне
Юлаучы аты ашый.
Дөнья ачысы ачы түгел,
Үлем ачысы бик ачы,

– дип көйләштергәләп утырды...

Өйдәгеләр төне буе йокламадылар. Үлемтекләр әзер түгел иде. Кечкенә балага артык зур кәфен кирәк булмады, кәфенне Люция үзе үлчәп кисте, аңар Рузалия кодагый да булышты. Баласы янында дөньядан китеп утырган Тәнзилә исә бернигә дә катышмады, хәтта еламады да, хәер, аның инде еларлык күз яше дә калмаган иде...

Үлем кайгысы төн белән көнне берләштерде кебек. Кояш чыгып, көн тууын өйдәгеләр сизми дә калдылар. Мәетне юар өчен дүрт чиләк чиста су кирәк булды.

Суны өй каршындагы колонкадан түгел, ә кизләүдән барып алдылар. Чишмәгә, чиләкләр күтәреп, Абрек белән Фатыйх абыйсы барды. Сөйләшмичә генә бардылар. Абрек абыйсына нидер әйтергә теләп талпынса да, Фатыйх аңар берни дә җавап бирмәде, тын да чыгармады. Алдагы көнне авылда тагын бер кеше җан куйган, туксан яшьлек бер карт кеше үлгән икән. Үлеме дә мәгънәсез: картны ток бәреп үтергән. Шул сәбәпле, авыл халкына бүген мәет чыккан өйләрдә дә һәм зиратта да икегә бүленергә туры килде...

Агач улаклы кизләү янында алар чиләкләренә су тутырып торучы бер яшь авыл кызын очраттылар. Абрек, исәнмесез, дип исәнләшкәч тә, кыз сәлам бирмәде, чиләкләрен көянтәсенә асып, бер сүз дәшмичә китеп барды.

– Тәти абый!

– Әү?!

– Телен йоткан мәллә ул?

– Фәннүр абзыйның оныгы ул, – дип аңлатты Фатыйх, – бабасын кичен ток бәргән...

– Исәнләшмәде дә хәтта...

– Мәет юа торган суны, беләсең килсә, сөйләшмичә генә алып кайталар...

Мәетне поши кыяфәтле, килбәтсез авыл карты юды. Бу карт авылда мулла урынында иде. Укый, юа, мәрхүмне соңгы юлга озата. Аңа Фатыйх белән Абрек булышты. Юу әллә ни озакка сузылмады, шактый тиз тәгәлләнде. Аннан ирләр, зиратка барып, колаша алып кайттылар. Колаша – мәетне салып зиратка алып китү өчен ясалган җеназа агачы. Колашаны зират эчендә торган агач өйдә саклыйлар. Ак кәфенгә төрелгән баланы әнә шул колашага салдылар. Җеназа өстенә чаршау корып куйдылар, ә башына унике данә сөлге бәйләделәр. Бу сөлгеләр шул җеназа агачын күтәреп китүчеләр өчен каралган, ләкин мәетне күмгәннән соң, билгеле, аларга беркем дә орынмый, алар шунда бәйләнгән килеш кала иде.

Мәет салынган колашаны арттан да, алдан да икешәр кеше күтәреп, зират ягына таба атладылар. Борынгы йола буенча, өйдән кырык адым киткәч, мәетне куеп, җеназа укылырга тиеш. Мәет җеназасын урам уртасында түгел, ә зират каршында туктап укыдылар. Анысын да шул ук карт укыды. Ихлас күңелдән.

Хатын-кызлар, Люция белән Тәнзиләдән башка, зиратка менмәделәр. Өйдә

калучылар өй мичено бер кочак салам, бер уч йомычка тыгып, морҗадан төтен чыгарып алдылар. Мәет зиратка барып җиткәнче, әнә шулай морҗаны ачып куеп, мичне элдереп яндырып куялар. Өйдән чыккан мәет өйдәге җылыны алып китмәсен өчен шулай эшләнә...

Авылда бу көнне ике кабер казылды: берсе олы, ә икенчесе кече мәет өчен. Башта гүргә (укучы карт бер генә булу сәбәпле) баланы иңдерделәр, аннан соң – картны. Мәетне ләхеткә төшереп, гүргә иңдергәч, күмгәч, кабернең дүрт чатына дүрт кеше бастырып, авыл карты кабат догасын ирештерде. Абрек белән Фатыйх кабер казучыларга, гүр авызын ачучыга, ләхет алучыга һәм шулай ук кечкенә Айдарны соңгы юлга озатырга килүчеләргә сәдакалар өләшеп чыктылар...

Мәет чыккан йортны соңыннан хатыннар юды. Идәннәрне ишек төбеннән түргә хәтле сыпырып, түшәмнәрне, өй чатларын сөртеп чыктылар. Өйнең тәрәзә пәрдәләрен тартып, корып куйдылар. Кабул ителгән йола буенча, үлек чыккан ызба әнә шулай моңсуланып торырга тиеш. Билгеле, сабый мәете белән олы кешенекен чагыштырып булмый, ләкин Ходай алдында алар икесе дә бер, икесе дә тигез. Өйдәгеләр үзләрен: «Үлгән сабыйның җаны шундук җәннәткә элә́гә!» – дип тынычландырырга тырышсалар да, әле тәпи йөрергә дә өлгерә алмый калган кечкенә Айдарның бу мәгънәсез үлемен күңелләре белән һич кенә дә кабул итә алмадылар...

Өч көн һәм өч төн узгач, Айдарның өч ахшамын уздырдылар, аннан соң җидесен. Өчесенә дә, җидесенә дә халык күп килде, халык күп килгәч, савым да күп килде. Халыкның күп килүе, өчесен, җидесен уздыру мәшәкатьләре үлем хәсрәте кичергән Абрек белән Тәнзиләнең әлеге уртак кайгыларын беркадәр читкә этәрде сымак. Күрәсең, бу дини йолалар мәрхүмне искә алу, олылау өчен генә түгел, ә бәлкем, исәннәрнең кайгыларын онытгырып тору өчен уйлап чыгарылган бер изге чарадыр да...

...Ләкин Тәнзилә бала хәсрәтеннән тиз генә арына алмады. Ул кешеләр белән сөйләшмәс, аралашмас булды. Абрек та хатынын аңламас һәм танымас хәлгә җитте. Хатыны да аны санга сукмый, кешегә санамый башлады. Ире аңар теге яктан да, бу яктан да килеп карады, файдасы гына юк иде. Тәнзилә Абрекка бәйле булмас өчен, бер зур заводка секретарь вазифасына эшкә урнашты. Ул үзенчә яшәде, үзенчә эшләде. Абрек әнисенә дә зарланып алды. Люция килене белән сөйләшеп, аңлашырга теләп караса да, нәтиҗәсе уңай булмады, килен барыбер тормышны үз ягына бөкте. Абрек, аптырагач, авылдан тәти абыйсын чакырды. «Тәти абый, килеп кит Казанга, сөйләшеп кара әле хатын белән, – дип зарланды ул Фатыйхка, – аның белән сөйләшеп тә булмый хәзер, бер сүз әйтерлек түгел, күтәрелә дә бәрелә!»

Фатыйх яраткан энесенең үтенеченә каршы килә алмады, беркөнне җыенып, калага китеп барды. Урамда эссе июль ае иде. Халык үлеп-бетеп печән чаба. Җәй көне авылда эш күп була, ләкин бармыйча да ярамый, туганыңны авыр хәлдә ташлап булмый. Хәер, ул өйдә үзе генә түгел, Сара да бар иде. Хатын хәзер бөтенләй әрсезләнде, айга бер мәртәбә булса да, ЗАГСка барып язылышу турында сүз кузгатмыйча калмый. Барырга туры киләчәк, язылышмыйча яшәү халык алдында да бигүк килешеп бетми. Элегрәк аның халык дип исе китми иде, турысын әйткәндә, орып бирә иде ул халыкны, ә инде олыгая төшкәч, тормышка карата фикерләре үзгәргәч, үзен башкачарак, тыйнаграк тота башлады. Хәтта, әгәр дә яхшы эш тәкъдим итсәләр, колхозга кереп хезмәт куярга да әзер иде кебек. Ләкин ул барыбер үзгә, ялгызак, кешеләр арасында

үзен аерым кеше итеп сизә иде. Халык ягына авышу һәм шул халыкның бер кисәкчеге булу теләге күңелендә әлегә яралып кына килә иде.

Фатыйх килгән көнне Тәнзилә өйгә төн кунарга кайтмады. Бу хәлгә бик нык ачуы чыккан Абрек белгән-йөргән төшләргә шалтыратып, сорашып та карады, ләкин хатын, суга төшкән кебек, кисәк кенә югалды. Берни булмагандай, иртән генә кайтып керде.

– Кайда йөрдең син? – дип ябырылды аңа ире.

– Иптәш кызымда кундым, – дип тыныч кына җавап бирде ул.

– Кем ул? Нинди иптәш кызы?

– Сменщицам. Заводта бергә без... Ул әлегә больничныйда... Нәрсә, кешегә ярдәм итәргә ярамыймы?

– Ә хәбәр итсәң булмый идеме?

– Хәбәр итүне кирәк дип тапмадым...

Тәнзиләнең тупас һәм үзсүзле кылануы теләсә кемне чыгырыннан чыгарырлык иде. Әгәр шул чакны Фатыйх яшьләр янында басып тормаса, ир белән хатынның бәхәсләшүенә шаһит булмаса, бәлкем, Абрек, бу хәлгә түзеп тора алмыйча, хатынына кул да күтәргән булыр иде. Хәер, ул ни этисенә, ни анасына охшамаган, сабыр, тыйнак иде. Ләкин сабыр төбе сары алтын, дисәләр дә, андый сабырлык озакка сузылмаска да мөмкин икән.

Шулай да Абрекка бу очракта артык кызарга түгел, ә тынычланырга һәм хатынының сүзенә колак салу да кирәк иде. Ул Тәнзиләсенә артык бер сүз дә әйтмәде, хатынын рәнҗетмәде, киресенчә, тавыш кубудан куркып, тиз генә фатирдан чыгып югалды. Аның әйтәсе килгән сүзләрен тәти абыйсы әйтәчәген, әйтмәсә дә, дөньяны болгаткан хатынын тәртипкә салып китәчәгенә күңеле вә җаны белән дә инанган иде...

Ике арадагы сөйләшү шактый авыр барды. Фатыйх абыйсының аңлашыр өчен килгәнен сизенгән Тәнзилә, төрле сәбәпләр табып, ачыктан-ачык сөйләшүдән качарга тырышты. Ләкин абзый үз сүзендә нык торды, сүзне вакытында эләктереп алды...

– Тәнзилә, – диде ул, катгый рәвештә, – син кызу эш вакытында минем ни өчен килгәнне яхшы аңлыйсыңдыр...

– Аңлыйм, – диде хатын, – Абрек чакырдымы? Миннән зарландымы?

– Тынычлан, аның монда бернинди катнашы юк. Ул, беләсең килсә, синең өчен кайгыра, синең акылың өчен...

– Ә ни булган минем акылыма?

– Яхшы, сүземне кире алам, – дип артка чигенде Фатыйх, – гаилә бәхете өчен кайгыра ул, аның иминлеге өчен...

– Кайгырудан мәгънә юк, – дип кырт кисте хатын, – Айдар үлгәннән соң, бәхетле, тату гаиләдән берни дә калмады...

– Кая китте суң ул?

– Бала үзе белән алып китте...

– Бала үлеме белән генә бәйләп буламы суң аны?!

– Дөрес, өйләнешкәнче үк, безнең гаилә юк иде инде, ә баламның үлеме исә...

– Нәстә?

– Констатация факта, – дип, үзенчә акыл сатты хатын, – бар булган каршылыкны көчәйтте генә...

Фатыйх кинәт кенә бу хатын алдында үзен көчсез кеше итеп сизде. Әйе, ул кайчандыр авызын ачып сүз әйтергә дә куркып торган тыйнак авыл кызы түгел иде инде. Бу – шушы бер-ике ел эчендә бик нык үзгәргән һәм һәр сүзен

чартлатып әйтергә өйрәнгән, үз фикерен курыкмыйча тиешле урынга җиткерә алган тәкәббер хатын иде. Фатыйх башлаган сүзен ничек дәвам итәргә дә белмәде, бәхетенә, Тәнзилә аңар үзе ярдәмгә килде...

– Фатыйх абый, әйтегез әле...

– Ие...

– Төрмәгә эләккәч, минем бабамны, Хөснулла бабамны каргадыгызмы?

– Юк, мин аны каргамадым...

– Мин моңа ышанмыйм!

– Рәнҗедем... ие... тик...

– Уйламагыз, мин бабайны якларга уйламыйм, сезнең нәсел каршында аның гаебе коточкыч зур, әйе, бик зур. Каргадыгызмы, юкмы?!

– Әйттем бит инде...

– Юк! Сез аны каргадыгыз! Яшермәгез! – дип ярсыды хатын.

– Ие... каргадым, ләкин үзем өчен түгел, – дип килеште аның белән Фатыйх, – беләсеңме кайчан?

– Кайчан?

– Имчәк балалы анамның төрмәдә кыйналып үлгәнен, сеңлемнең югалганын, авылда ачлыктан интеккән атамның үз өендә катып үлгәнен ишеткәч... каргадым... ие...

– Кабатлап әйтәм, мин сезне гаепләмим, – дип тәкрарлады хатын. – Сезнең каргарга хакыгыз бар, ләкин аның икенче ягын да онытмыйк. Каргышыгыз безгә нәсел каргышы булып төшкән. Минем балам да, Айдарым да әнә шушы каргышның бер корбаны булгандыр дип уйлыйм...

– Ялгыш уй бу, сеңлем! – дип ярсыды Фатыйх. – Әлеге очракта бернинди дә нәсел каргышы була алмый, һәм үз үлеме белән җан тәслим кылган баланы шул каргышның корбаны дип һич кенә дә атарга ярамый. Бабаңа, бары тик бабаңа гына төшкәндер, дип уйлыйм, төшсә... минем каргышым! Аңлыйсыңмы?!

– Әйе, ишетүемчә, ул үз үлеме белән үлмәгән...

– Ләкин шуны онытма, килен: кешене каргау ул – гөнаһ гамәл. Мин аны каргарга тиеш түгел идем, чөнки минем каргышым, күргәнеңчә, үземә дә төште, үземә кире кайтты...

– Ничек? Аңламыйм...

– Мине мәңгегә ялгыз итте... кешеләрдән аерды...

– Бу җәзамы?

– Аңардан да зур җәза юк, сеңлем...

– Мин сезне бәхетсез кеше, димәс идем. Сезне ялгыз кеше дип әйтергә дә телем бармый: сеңлегез бар, Абрек бар, Сара апа...

– Тыштан караганда, ие, ул шулай, – дип моңсуланды ир, учын йөрәк астына куеп, – ә менә монда, эчкәрәк керсәң... яхшы нәрсә күрмәссең...

– Әйтә алмыйм, эчегезгә кереп караганым юк...

– Кирәкми дә... керергә...

– Әти белән әни турында әйтә алмыйм, әле минем үземә дә төшәчәк ул...

– Әй, килен, килен, артык нечкә күңелле син, барсын да тиз тоясың! Хис белән генә яшәргә ярамый дөньяда, акыл белән дә эш итү кирәк. Борчылма, бернинди дә нәсел каргышы дигән нәрсә юк, оныт син аны, булса да, сиңа төшмәячәк ул, тө-ө-өшмәячәк...

– Төшәчәк...

– Ничек? Каян беләсең?

– Миңа гадать иттеләр...

– Кем?

– Чегән хатыны...

– Чегән хатынына кем ышана ди инде, дивана...

Килен белән уртак фикергә килә алмаган Фатыйх, яшьләр янында калмады, шул көнне Гобәйләргә китте. Әле һаман да хезмәттә йөргән һәм өйдә утырырга яратмаган Гобәй, ял көне булуга да карамастан, милиция ветераннары белән очрашуга чыгып киткән икән. Люция өйдә калган, ләкин нигәдер күңелсез иде. Абыйсы аңар ни өчен килгәнен аңлатып-сөйләп биргәч, сеңлесе сәер киленнәре турында артык зур кызыксыну белдермәде. Фатыйхны тыңлап арыгач, ул бары тик:

– Торалмаслар алар бергә! – дип кенә әйтеп куйды.

– Нигә алай дисең?

– Булмаган килен өчен күз яше чыгарып утыра алмыйм, – диде төксе генә, – мин иң элек улым өчен, Абрек өчен борчылам...

– Әгәр китсә! Килен...

– Әй! – диде Люция. – Китсә китәр инде!

– Әйтүе җиңел...

Алар полковникның күңелсез фатирында берара озак кына сүз эндәшмичә йөрделәр. Люция пылау пешергән икән, абыйсын аш ягына чакырды. Пылау әзрәк көйгән булып чыкты. Әллә казанга маен аз салган, әллә газда артык кыздырган?! Абый белән сеңел кәефсез генә, сөйләшмичә генә тукландылар...

– Ни булды сиңа? Нишләп кәефсез син? – дип сорады аңардан абыйсы.

Җавап урынына, алдындагы пылавын читкә этәреп, Люция елап җибәрде. Озак елады, күзләре кызарып, битләре күперенгәнче елады. Фатыйх дәшмәде, елап бетергәнен көтте...

– Белмим, яшәп-бетеп булмас, ахры, бу кеше белән! – диде хатын, ниһаять. – Вак кеше ул, саран, полковник димәссең! Һәр капейкы өчен чукынырга әзер бит ул, һәр капейкы...

– Сеңелкәш, кеше шулай инде ул – бертөрле генә булмый, кемдер юмарт, ә кемдер синең Гобәең сымак саран була...

– Нишләргә дисең? Түзәргә кушасыңмы?

– Анысын үзең кара инде, мин сиңа хөкемдар була алмыйм...

– Син шулай дисең, ә монда бөтенләй яңа фактлар ачыла тора...

– Нинди инде?

– Чәчләрең үрә торырлык! – дип сыкранды Люция. Фатыйх сеңлесеннән берни дә сорамады. Гомумән, Гобәй турында артыгын ишетәсе килмәде аның. Ул полковникның кем икәнлеген, аңардан нәрсә көтәргә кирәклеген күңеле белән сизенсә дә, акылы белән исә сеңлесенең законлы ире белән тату һәм кешечә яшәүләрен тели иде. – Беркөнне мин элеккеге хатынының туганы белән очраштым, кырык яшьләрдәге кыз-хатын ул...

– Ә син аны каян беләсең?

– Өйгә шалтыратты, – дип, серле генә эндәште сеңлесе. – Гобәй белән аралашмасалар да, өйдәге телефонны беләләр. Без ул хатын белән кафеда очраштык...

– Сиңа кирәк идеме ул?

– Нәрсә?

– Очрашу?

– Ә кемнең үз ире турында күбрәк беләсе килмәсен икән?!

– Ул хатын ялган сүз сүләргә дә мөмкин, махсус сүләргә. Элеккеге хатыны котырткандыр әле...

– Мин алай уйламыйм, абый, – дип каршы төште Люция, – беләсеңме, иң кызыгы нәрсә? Иң кызыгы шунда: аның хатыны Гобәйнең гаиләдән китүенә сөенеп туя алмаган! Кайбер хатыннар, әгәр ирләре ташлап китсә, үз-үзләрен кая куярга белмичә, кара кайгыга батып йөриләр! Хәтта шуның аркасында үз-үзләренә кул салучы хатыннар да бар! Ә аның хатыны, киресенчә, Гобәйнең китүенә сөенеп туймый, алай гына да түгел, балалары – ике улы да сөенечләрен яшерә алмый. Аларның өендә һәр көнне бәйрәм хәзер, алар һәр бирмеш көннәрен сөенеп, шатланып каршы алалар...

– Гобәйдән котылганнары өченме?! – дип елмайды Фатыйх. – Сикереп-сикереп биемиләрме тагын?

– Биегәннәрен күрүче юк, – дип ачынды хатын, – ә минем өчен иң аянычы шул, абый: алар котылды, ә мин җүләр – шуңа барып каптым!

Люция менә ниләр сөйләде. Гобәй өйдәгеләрнең тормышын тәмам тәмугка әйләндергән. Акча һәрвакыт ир кулында йөргән. Хатыны (заводта эшли) хезмәт хакын айга ике мәртәбә Гобәйгә кайтарып бирә торган булган. Акчаны тиененә хәтле санап, тиешле нәрсә генә алып бирергә өйрәнгән эти кешенең саранлыгы тора-бара көчәйгәннән-көчәйгән. Әйтик, укучы малаена мәктәптә укыр, ашар өчен күпмедер акча бирсә, ул аңардан атна ахырында исәп-хисап алган. Әгәр дә биргән акчаны малае «дөрес» кулланмаса, әйтик, лимонадка яисә туңдырмага тоткан булса, бала шундук җәзасын алган. Башта ул баласын каеш белән ярган, аннан соң ярты көн чатка бастырып тоткан. Күрәсең, мондый явызлыкны Гобәй милиция хезмәтендә үзләштергән. Димәк, ул үзе дә шундый кансыз һәм рәхимсез булган. Бер банка тозлы кыярны сорамыйча ашаганнары өчен бу аяусыз ата улларын каты җәзага тарткан: ике баласын да кышын бер кат юка күлмәктән салкын урамга куып чыгарган. Хатынына акчасын санап кына биргән полковник аның өчен хатын-кыз кирәк- яракларын да (әйтик, күкрәкчә, эчке күлмәк...) кибеткә барып, үзе сайлап ала торган булган...

Люция белән Фатыйх шул көнне музейга бардылар. Өйгә төнге унбердә генә кайтып керделәр. Люциясен югалткан Гобәй шартлар хәлгә җиткән иде. Ләкин хатынын Фатыйх белән бергә күргәч, тавыш чыгармады, шундук тынычланды. Әллә кайдан күренеп тора, ярата иде ул Люцияне, ярата! Ләкин аның яратуы бер нәрсә, менә сәер холкы аңа һаман да тынгылык бирми һәм шуның аркасында ул якыннары арасында үзенә карата бары тик нәфрәт хисе генә уята иде.

Люция аш ягында бәрәңге белән ит турап, тәмле гуляш әзерләде. Гобәй яшереп саклаган яхшы коньягын ачты. Кунак эчмәде. Шулай да алар төн уртасына хәтле тормыш турында озак кына сафсата саттылар. Ләкин Фатыйх сеңлесе сөйләгән сүзләрнең берсен дә өскә чыгармады, полковникны битәрләмәде, хатын белән ир арасына кермәде. Гобәйнең сөйләве буенча, аның уллары да алтын түгелләр, аналарының котыртуы аркасында, атасының шактый күп канын эчкәннәр. Бөтен хикмәт аларның анасы Фәйрүзәдә иде, билгеле. Кеше кайгысын якын итә белгән егет яшьлегендә бу кызга гашыйк булып та, исәп-хисап белән дә өйләнми, ул аны кызганып өйләнә. Өенә бертуктаусыз ирләр ташыган, эчеп-исереп гомер кичергән, күңел ачарга яраткан азгын анасы кызын, аяк астында буталып йөрмәсен, дип, еш кына урамга куып чыгара торган булган, соңыннан ул аны балалар йортына тапшырган. Гобәй, бернигә дә карамыйча, кызны өенә алып кайта һәм аңа өйләнә. Шулвакыт

аның дүрт бүлмәле фатирында Гобәйнең анасы да яшәп яткан була. Читтә үскән һәм бер кешегә дә баш ияргә яратмаган холыксыз Фәйрүзә беренче көннән үк каенанасын күралмый башлый. Килен аны бертуктаусыз кыерсыта һәм җәберли. Халыкта, кайчандыр җәберләнгән адәм, җае чыккач, үзе башкаларны җәберли башлый, дигән гыйбарә бар. Монда да нәкъ шул ук хәл. Явыз киленне күралмас хәлгә җиткән, сигез бала үстергән киң күңелле ана, беркөнне Түбән Камага, икенче улы янына китеп бара. Гобәй дә уртага баса алмый, хатын ягында кала. Балаларның тууы да гаиләгә артык бәхет өстәми. Төрле читенлекләр, ятимлекләр күргән, тулы гаиләдә үсмәгән, ирне ир дип белмәгән хатын балаларында, үзе дә сизмәстән, аталарына карата нәфрәт хисе тәрбияли. Бервакыт аңа кунакка Чаллы каласыннан Илсур атлы энесе килә. Икесе дә шахмат уйнарга яраткан туганнар, әзрәк капкалап алгач, шахмат уйнарга утыралар. Уйнарга утыруга ук, ике малай бүлмәдә туп тибәргә тотына. Боларның типкән туплары берничә мәртәбә шахмат тактасына килеп төшә, фигуралар идәнгә чәчелә. Әлеге хәл берничә тапкыр кабатлана. Туганнар шахмат уенын, ничек кенә тырышсалар да, ахырына тиклем җиткерә алмый. Хихылдашып көлгән малайлар аналарының бүлмәсенә кереп кача. Анасы да аларны бу очракта яклап чыга. Энесе абыйсын тәрбия мәсьәләсендә артык йомшак булуда гаепли, балаларга катырак торырга әйтә. Шахмат вакыйгасы ул әле чүп кенә. Аталарын мыскыл итәргә өйрәнгән балалар йоклап яткан Гобәйнең баш астыннан мендәрен тартып ала һәм эш кәгазьләрен яшереп, бутап бетерә торган булганнар, әтиләре эшкә киткәндә, кул болгап, озатып каласы урынга, аңар балконнан таш атып калганнар. Шуннан соң Гобәйнең туганнары бу йортка йөрүдән туктаган, шулай итеп, холыксыз хатын ирен туганнарыннан да аерган...

Иртә таңнан телефон шалтырады. Аларны Абрек уятты. Тәнзиләне таң алдыннан «Ашыгыч ярдәм» машинасы алып киткән. Люция белән Фатыйх, такси чакыртып, килен яткан хастаханәгә ашыктылар. Бу – гади генә хастаханә түгел, ә нервларны дәвалый торганы булып чыкты.

Абрекның сөйләве буенча, алар бүген төне буе йокламаганнар. Тәнзилә ирен, тәти абыйсын чакыртып, акыл өйрәттерергә җыенганы өчен гаепләгән. Абрек әйтеп, аңлатып караган, ләкин хатыны барыбер үзенекен тукыган. Аңарда истерика башланган, соңынтын килен аңын җуйган. Бәхеткә, «Ашыгыч ярдәм» бик тиз аңына китергән, ләкин өендә калдырмаган, диспансерга алып киткән...

Тәнзилә янына кертмәделәр. Киленнәре яткан палата ишеге төбендә болганып йөргән бер шәфкать туташы диспансерга килүчеләрне табиб бүлмәсенә алып керде. Аларга иртәдән бирле коридор саклап утырган Абрек та иярде.

Профессорны күргәч, Фатыйх шаклар катты. Ул күрше авылда туган, шунда үсеп, шуннан калага китеп кеше булган Сәмигулла атлы кеше булып чыкты. Сарырак чәчле (андыйларны авылда «бакыр баш», диләр!), сипкелле һәм уртача буйлы бу ир заты, якташларын күргәч, урыныннан сикереп үк торды һәм барысы белән дә кул биреп күрешеп чыкты.

– Сәмигулла, синме соң бу? – дип елмайды Фатыйх. Ул әле һаман да ак халатлы профессорның якташы булуына ышанып бетә алмый иде.

– Мин, мин! – дип тәкрарлады якташ. – Өченче елымны эшлим шушында! Җүләрләр йортында...

– Бу җүләрләр йортымыни? – дип шаккатты Абрек.

– Юк, юк, борчылмагыз, – дип тынычландырды аларны бакыр баш. – Бу

әле чын җүләрләр йорты түгел, ләкин шуңар якын. Неврология бүлеге дип атала ул, ягъни мәсәлән...

– Безнең... Тәнзиләбез, – дип шулчак бүлде аны Люция.

– Тәнзиләгез минем якташ булып чыкты, – дип көлемсерәде профессор. – Сөйләштек без аның белән, авыру белән собеседование уздырдым...

– Нәрсә аңарда?

– Куркырлык әллә нәрсә юк, – дип кабат тынычландырды якташы, – невроз аңарда, җиңелчә депрессия. Тик вакытлыча гынамы ул нәрсә аңарда, әллә... озакка сузылырмы? Безнең максат – менә шуны ачыклау. Авыруы артык тирәнгә киткән, дип әйтә алмыйм, әлегә ул үз-үзенә тәнкыйть күзлеге аша карый, баскыч басмаларын санамый... ягъни...

– Анысы нәрсә инде? – дип кызыксынды Фатыйх.

– Фән телендә «умственная жевачка» дип атыйлар аны, безнеңчә, «акыл белән чүп чәйнәү» дип атала. Андыйлар урамда ничә багана, ничә фонарь һәм хәтта көненә ничә адым атлаганнарына хәтле саный башлыйлар. Тәнзиләдә әлегә андый симптомнар күренми...

– Доктор, – диде, ниһаять, кабинетка кергәннән бирле авызына су йотып утырган Абрек, – өмет бармы?

– Өмет бар, нишләп булмасын, өметсез – шайтан, диләрме әле? – дип балкыды доктор. – Дәваларбыз, сүз дә юк, ләкин сезнең ярдәмегез дә кирәк булачак. Әлеге авырудан кеше үлми, кеше үтерә торган авыру түгел ул. Ләкин ул киләчәктә үзенә һәм шулай ук сезгә дә шактый зур җәфалар китерергә мөмкин...

Бу сүзләрдән соң Фатыйхның, ирексездән, күз алдына авыл башында үсеп утырган бөдрә алмагач, кыргый алмагач килеп басты. Ул алмагач авыру һәм кыргый булса да, инде ничәмә еллар исән-сау үсеп утыра, ә менә аның өй бакчасында үскән сортлы алмагачлары бер кыш эчендә корып, юкка чыктылар...

Әйе, Сәмигулла якташларын тынычландырырга тырышса да, һаман да нәрсәдер әйтеп бетерми кебек. Моны бик яхшы сизгән Фатыйх юлдашларын кабинеттан чыгарып җибәрде. Кумады, билгеле, сорады.

– Якташ, ә син хәзер миңа дөресен әйт әле?! – дип текәлде ул докторга. – Миңа дөресен белергә кирәк!

– Дөресе шул, якташ, – дип уйчанланды профессор, – хатынның башында бар, сүз дә юк. Тик, беләсеңме, мин аны чын авыру дип тә әйтә алмыйм. Чөнки бер сөйләшүдә генә пациентны аңлап бетереп булмый, аны озаклап тикшерергә кирәк. Аның башында ниндидер, урысча әйтсәк, навязчивая идея йөри, баштан чыкмый торган үзгә бер фикер ул, үзгә уй. Күрәсең, ул яшь чагында психик травма алган. Күңелендә ниндидер яра бар аның, йөрәк ярасы димме... Һич кенә дә шуңардан арына алмый...

Якташына карап, Фатыйх кабат шаккатты. Буш кеше түгел бу профессор дигәннәре, аңлый бит, барысын да аңлый! Яше буенча ул Фатыйхтан бер ун-унбиш яшькә кечкенә иде. Кайчандыр авылда тал ботагыннан кәшәкә ясап, хоккей уйнап йөргән, авылның болын-кырларында йөгереп, авыр хезмәт күреп үскән шушы гади генә авыл баласыннан профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше бит ул!

Фатыйх Сәмигулладан берни дә яшермәде һәм аңарга Тәнзилә вакыйгасын сөйләп бирде. Профессор аны зур кызыксыну белән тыңлады, чөнки ул Фатыйхның сөйләвендә үзенең алдан чамалаган фаразларына төгәл җаваплар эзләде...

– Аның бабасы кайчандыр мине төрмәгә утыртты, бер гаепсезгә! – диде Фатыйх. – Бабасының гаебе, гөнаһы Тәнзиләгә һаман да тынгылык бирми, ул аны үз гаебе сымак кабул итә. Нәсел каргышы дип тә әйтергә буладыр, хәер, алай дип кычкырып әйтергә дә тел бармый...

– Ә мин әйтер идем! – дип каршы төште доктор. – Тәнзиләнең сезнең нәсел белән кушылуы бик зур ялгышлык булган...

– Көчләп кушмадык, аларны сөю кушты...

– Бөтен нәрсәне дә мәхәббәткә сылтарга ярамый, якташ! Ярар, хәзер инде буласы булган. Ләкин Тәнзиләгезнең күңеле яралы, бик тә яралы. Ул һаман да куркыныч финал көтә. Куркудан курку көтү дип атала ул. Инде финалның кульминациясе килеп җиткән, бәхетсез хатын баласын югалткан. Белмим, онығыгыз нәрсәдән үлгәндер, анысын тәгаенли алмыйм, ләкин Тәнзилә баласын югалтуны әнә шул нәсел каргышының бер чагылышы дип саный. Уйдырма куркулардан арына алмыйча, яраланган күңеле белән шикләнүләр һәм икеләнүләр дәрьясында буталып йөри. Куркудан курку ул, беләсеңме, кайдан барлыкка килә? Андый кеше кайчагында халык алдына чыгып сүз әйтүдән, хәтта ялгыш кына кызарудан да курка. Шуңа күрә дә сезгә әлеге нәсел каргышы турында артык сүз кузгатмаска, чүп чәйнәмәскә кирәк. Хәер, бу гына котылу юлы була алмый, билгеле, ул ялгызы гына калып, үзен тагын да тирәнгәрәк өстерәп алып керергә мөмкин. Андый нәрсәне – навязчивый, безнеңчә сырышкак идея, диябез...

– Безгә нишләргә соң? – дип сорады Фатыйх, матур һәм акыллы сүзләр чәчкән профессорны кисәк кенә бүлеп. – Ничек чыгарга хәзер бу хәлдән?

– Иренең чыгып китүе әйбәт булды әле, – диде Сәмигулла. – Сиңа гына әйтәм, абзый, әгәр дә Тәнзилә, аерылам, дисә, аерылсын, каршы килмәгез! Мин сезгә фәкать яхшылык кына телим...

– Каршы килмәскә, дисең инде?!

– Әйе, әгәр киленегезнең андый теләге бар икән, аерыгыз да җибәрегез...

...Профессор әйткән сүзләр бераздан тормышка да аша башлады. Хастаханәдә дәваланып (зур авырлык белән, билгеле!), өйгә кайтып утырган Тәнзиләне ире Абрек танымады. Ул аннан бөтенләй икенче кеше булып, бик нык үзгәреп кайтты. Аңарда кеше төсе калмаган – дарулардан, уколлардан ялкынсынган, шешенгән йөзенең нуры беткән иде. Ире белән бик аз сөйләште, аны күрмәмешкә сабышты, тәти абыйсының киңәшен тоткан Абрек та хатынын артык борчымады. «Исәнме? Исән!» – фәкать шул гына.

Берәр атнадан соң Тәнзилә, гариза язып, заводтан китеп барды. Ни өчен эштән киткәнен иренә аңлатып-сөйләп тормады, хәер, ире дә артык кызыксынмады. Аннан соң ул авылга кайтып, берәр атна анда торып килде. Килүгә үк иренә:

– Мин Мәскәүгә китәм! – диде. Абрек, бу хәлгә нык аптырап:

– Нәрсәң калган анда? – дип сорагач, хатыны салкын гына:

– Туганый апа кунакка чакыра, – дип җавап кайтарды.

Туганый апа дигәннәре Рузалия кодагыйның туганнан туган апасы иде. Суфия исемле, Мәскәүдә яши. Яшьли Мәскәү урысына кияүгә чыккан, инде ире үлгән. Бала-чагасы юк, ике баласы да үле туган. Суфия Тәнзилә белән Абрекның туенда да булды, заманында зур гастрономның хуҗасы – бу бай хатын туйга кыйммәтле бүләкләр салды. Абрек аны нигәдер ошатмады. Хәер, Суфия үзе дә кияүне генә түгел, кияүнең туганнарын да өнәп бетермәде. Тәнзиләнең Фатыйхлар нәселенә кушылуына ул теше-тырнагы белән каршы

тормаса да, үзе әйтмешли, алдан ук «обречённое бракосочетание»гә карата артык зур илтифатлык та күрсәтмәде.

Абрек акылы белән аңлап бетермәсә дә, күңеле белән Тәнзиләне югалтасын сизенде. Ләкин барыбер аңар каршы килә алмады, читенсенеп булса да ризалашты. Хатыны шимбә көнне кич «Татарстан» поезды белән Мәскәү каласына юл алды. Мәскәүдә ул бер айлар чамасы яшәде, иренә ара-тирә шалтыраткалап торса да, тавышында, сөйләшүендә саубуллашу чаткылары сизелгәләде. Бер айдан соң (көз айлары иде!), Тәнзилә Казанга кайтып төште. Үзгәргән: кәефе яхшы, күңеле күтәренке. Ләкин хатыны белән кабат матур гына яшәп китәргә хыялланган Абрекның бу юлы да өметләре акланмады. Тәнзилә аның белән төксе генә сөйләште, ирен үзенә якын китермәде. Сөюгә, назга сусаган ир тагын коры калды. Ашыгып кына Казанга кайткан хатыны кабат Мәскәүгә җыена башлады...

– Ни булды сиңа, Тәнзилә?! Аңламыйм, нишлисең син?

– Җүләр булып кыланма, яме! – дип кистерде сатлыкҗан хатын. – Мин китәм синнән...

– Бөтенләйгәме?

– Анысын бүген генә әйтә алмыйм, ләкин китәм...

– Нигә? Ни өчен?

– Беренчедән...

– Әйе...

– Суфия апада авыру таптылар...

– Авыру? Нинди?

– Йөрәге тузган...

– Йөриме соң ул?

– Йөри... өйдә генә йөри... эшеннән китте...

– Инфарктмы? Син бит миңа хәбәр дә итмәдең?!

– Юк, инсульт, микроинсульт, моннан бер атна элек булды. Мин аны хәзер үзен генә калдыра алмыйм...

– Икенчедән?

– Икенчедән... китәм...

– Карале! – дип кинәт кызып китте Абрек. – Китә! Китә ул! Ә син минем турыда уйладыңмы соң? Ваще-то, мин синең ирең, законный ирең!

– Кто бы в этом сомневался?!

– Көлмә һәм ыржайма! – дип кычкырды ир. – Китәм, дисең! Ә син миннән рөхсәт сорадыңмы соң?! Син нәрсә, баш булдың соң әле монда? Китә ул! Китмисең беркая да!

– Абрек, – дип йомшарды Тәнзилә, – җибәр син мине...

– Юк, җибәрмим...

– Җибәр, матурым, җибәр...

– Юк!

– Да, отпусти ты меня...

Хатын, күз яшьләренә буылып, әкрен генә зал уртасында торган йомшак кәнәфигә чүкте. Ләкин аның елавына артык игътибар бирмәгән кырыс ир хатынын битәрләвеннән туктамады:

– Нәрсә, мине күз яшьләрең белән алмакчы буласыңмы?! Туганый апаң авырмый да торгандыр әле, Мәскәүдә берәр егет тапкансыңдыр! Яңа сөю, мәхәббәт... пятое... шестое...

– Абрек, җитте инде сиңа! – дип ялынды аңар хатын. – Син минем турыда

ничек шулай начар уйлый аласың? Нинди егет?! Мин әле яңа гына баламны югалттым! Яңа гына авыруымнан арындым! Нинди сөю, нинди мәхәббәт?! Ни сөйлисең син?!

– Белмим инде, алайса, – дип кул селтәде Абрек, – әйе, синдә генә кайгы, синдә генә авыру! Башка кешедә кайгы да, авыру да юк, белмим инде...

– Абрек...

– Ә?!

– Җибәр мине, китим мин...

– Теләсәң нишлә! Нигә китәсең, дип сорамыйм...

– Шулай әйбәт булыр, бәгърем, тормышыбыз җайланыр, синеке дә, минеке дә. Өстән төште бит инде хәбәр...

– Нинди?

– Безгә аерым яшәү кирәк...

– Өстән нинди хәбәр төшкәндер, анысын белмим, ләкин сине Суфия апаең безгә каршы котыртып җибәрде, ахрысы! Син бөтенләй үзгәреп кайттың... Мәскәвеңнән!...

– Суфия апаның үз хәле хәл, ә мин аңар ярдәм итәргә тиеш...

– Яратмыйсың, димәк?

– Кемне?

– Мине! Кемне?!

– Яратам...

– Соң...

– Әйе...

– Яраткач, нигә китәсең? Җүләрлек бит бу!

– Вакытлыча, җаным, аннан соң күз күрер...

– Китәрсең... тик киткәндә мине яратып кит...

– Ярый... – Дулкынланудан Тәнзилә яшь кызлар сымак кызарынды. Ни генә булса да, ул ирен, газиз ирен, танышкан чакларында ничек сагынса, шулай ук чарасыз сагынган иде...

– Тик... вакытлыча гына, димә... яме... яратмыйм ул сүзне...

Тәнзиләнең «вакытлыча» гына китүе шактый озакка сузылды. Шул китүеннән соң, бер мәлгә бөтенләй югалды. Өч айдан соң, Тәнзилә кабат кайтып төште һәм ул ирен ЗАГСка алып барып аерылышты. Абрек аңар каршы килмәде, чөнки ул мондый тормыштан инде күптән туйган иде. Тәти абыйсы белән әнисе дә Абрекның бу гамәле белән килештеләр. Тәнзилә, икенче көнне үк (авылына да кайтып тормыйча!) Мәскәвенә китеп барды. Берничә тапкыр операция ясатып та, йөрәк хастасыннан арына алмаган Суфияне авылга алып кайтып җирләделәр. Туганый апасы Мәскәүдәге фатирны Тәнзилә исеменә яздырып калырга өлгергән, шулай итеп, Сарлыбаш авылы кызы берничә миллионлы Рәсәй башкаласында яшәп калды. Абрек (утызга җитмичә!) өйләнмәскә булды һәм, шау-шулы буйдак тормышыннан бер төрле ямь табып, үзенә ничек кирәк, шулай яшәп китте...

Люция Гобәйдән бер кайтты, бер китте. Полковник, аның кайту-китүләреннән туеп бетсә дә, Люциясен бөтенләй югалтудан курыкты. Аннан соң Гобәйнең икенче бер ягы ачылды, һәм аны, билгеле ки, хатыны Люция ачты. Ир кеше буларак, Гобәй хәзер бернинди хатын-кызга да кирәк түгел, чөнки ул күптән дәртсез вә гайрәтсез иде. Ләкин иреннән: «Без хәзер купедагы пассажирлар сымак, икебез ике ятакта йоклыйбыз!» – дип зарланган Люция Гобәйдән, саран һәм, шулай ук, дәртсез адәм

булуга да карамастан, бөтенләй баш тартудан тайчанды, чөнки аның, ни генә әйтсәң дә, кешегә күрсәтерлек кыяфәте һәм полковник дигән югары дәрәҗәсе бар иде.

**Җиденче бүлек**

## Үзгәреш җилләре

Үлеп, бетеп барган илдә һәлакәтле туксанынчы елларның зәһәр кырыс җилләре исә башлады. Совет дәүләте системасы үзенең шанлы көчен югалтты: илдә чуалыш, таркалыш китте. Партия дигәннәре бер көндә коелып төште, хәерчеләре тагын да хәерчеләнде, байлары череп баеды, акыллы башлары илдән чыгып тайды. Халык телендә «бандитизм», «мафия», «группировка» кебек сәер һәм шомлы сүзләр пәйда булды, акчаның кыйммәте калмады, аны гомер ишетмәгән ваучерлар, вексельләр алыштырды. Дөнья бихисап күп алыпсатарлар, эшкуарлар кулына күчте, алар өстеннән дәүләт структуралары түгел, ә мафия әгъзалары җитәкчелек итте. Коммерсантлар арасында иң таралган сүзләрнең берсе: «Крышаң бармы? Крышаң булмаса – булдыр, ансыз яшәү юк!» – иде. Ә кем соң ул крыша? Нәрсә ул? Кем һәм нәрсә икәне һәркемгә дә ачык – бандитлар!

Үзгәреш җилләре исә башлауга ук, Абрек банкротлыкка чыккан заводтан китеп барды. Дуслары белән җыйнаулашып, берничә урында сәүдә павильоны ачып җибәрделәр. Акчаны Абрекның дусты Алексей исемле урыс егете тапты. Аның атасы кайчандыр Казанда райкомның икенче секретаре вазифасын биләп торган, үзгәреш чоры башлангач, илдә барган әлеге хәтәр чуалышларга бик нык борчылган халәттә йөрәк авыруы алган һәм инфарктган китеп тә барган. Аңардан, мирас булып, өч яхшы фатир һәм яңа «Волга» машинасы калган. Алексей бер зур фатир белән «Волга»ны бик тиз генә сатып, шуның акчасын бизнеска тыкты. Ярдәмгә Абрекны һәм тагын бер таныш егетне чакырды. Акчаны төшемле урынга салдылар. Ярты ел эчендә шактый гына баеп та киттеләр. Акчаларын дәү-дәү капчыкка тутырып йөргән эшкуар егетләрнең башлары күккә тиде, алар үз бәхетләренә үзләре ышана алмадылар. Машиналар, фатирларга ия булдылар, престижлы курортларда ял иттеләр. Ләкин бу бәхет озакка бармады. Ясак таләп иткән бандит төркемнәре боларның гөрләп торган сәүдә нокталарын берәм-берәм яндырырга тотынды. Коммерция эше өчен ясак түләүне таләп иткән, үзләрен төркем әгъзалары дип атаган әлеге көчекләргә акча бирергә хурланган Казан егетләре аларны, тупас рәвештә, кире борды. Тәҗрибәсез эшкуарлар өчен бу зур ялгышлык булды. Кызганычка каршы, алар «первак»лар төркеменә кергән пацаннар иде. Шул төнне әлеге маңка малайлар егетләрнең тагын бер сәүдә павильонын һәм киоскын яндырды, ә иртән Алексейны подъезддан чыгып барган җирдән атып үтерделәр. Чакыру буенча килгән мәнсез милиция әлеге үтерү факты буенча җинаять эше ачса да, нигездә, бернинди дә тикшерү эшләре алып барылмады. Киресенчә, бандитлар Абрекның үзенә яный башладылар. Абрек, аз булса да, үзенә байлык туплап алырга өлгергән иде инде. Ул Нариман урамыннан ике бүлмәле кечкенә хрущёвка, Идел буеннан өч дача һәм ике өр-яңа «девятка» машинасы сатып алды. Улының гомере өчен бик нык борчылган Люция Гобәйдән ярдәм сорарга мәҗбүр булды. Абрекның хәтәр сәүдә эше белән шөгыльләнгәнен алдан ук өнәп бетермәгән полковник: «Милициядә хәзер бардак, алар үзләре бандитларга бәйле, әйдә, син әлегә авылда яшәп тор!» – дип, аны үз машинасында

Фатыйхларга кайтарып куйды. Абрек өчен җан аткан Фатыйх аны аталарча кабул итте һәм хәтта: «Күренеп кенә карасыннар, маңгайларына бәреп атам мин аларның!» – дип, ау мылтыгын корып, әзерләп куйды. Хәер, ау мылтыгының кирәге чыкмады, ләкин барыбер ике «девятка»ның берсен бандитларга бирергә туры килде. Шундый фаҗигале хәлләрдән соң исән калган Абрек, тәти абыйсының киңәшен тотып, әлеге шикле бизнестан китте һәм, коточкыч социаль түнтәрелештән соң, әзрәк тернәкләнеп килгән заводына кабат эшкә кайтты. Инженер булып озак эшләмәде, аны өч айдан соң цех начальнигы итеп куйдылар. Авыр вакытта улына бик нык ярдәм иткән Гобәйне Люция онытмады, аңа карата ничектер ихтирамы һәм хөрмәте артты. Полковникны, ир кеше буларак, бигүк яратып бетермәсә дә, ул, ниһаять, үз язмышы белән килеште, иреннән тырт-пырт китеп йөрүләрен туктатты, аның ваклыкларын күрмәскә һәм ул, ни генә әйтсә дә, каршы дәшмәскә өйрәнде...

Ләкин аларга икенче кайгы китереп бәрде. Гобәйнең саулыгы какшады. Бер ел эчендә генә дә өч төрле авыр операция кичергән ир бөтенләй сулыкты. Люция аны ташламады, һәрчак янында булды. Шуннан соң ул әзрәк терелеп киткәндәй итте, ләкин әлеге бәхет озакка бармады, Гобәйне инсульт бәрде, 22 апрель көнне (Ленинның туган көне) кинәт кенә якты дөнья белән хушлашты. Иртән аның хәле әйбәт булган. «Бүген юлбашчыбызның туган көне, нишләп аны искә алмыйлар?!» – дип, телевизор каналларын бер күчереп, бер алыштырып бәргәләнгән җиреннән башына кан сауган...

Кеше үлгәч, нинди нәрсә таләп ителсә, Люция шуларның барсын да тормышка ашырды. Күмү эшләрен оештырды, ашларын уздырды, каберенә таш куйдырды. Елады, сагынды. Беркөнне зиратка баргач, Гобәйнең кабере янында ике ясалма сары тюльпан чәчәге күргәч, ул бик нык сәерсенде. Кемнәр килгән иренең кабере янына? Кемнәр куйган бу чәчәкләрне? Җавап озак көттермәде: Люция тормышында кабат Гобәйнең ике улы һәм элеккеге хатыны Фәйрүзә пәйда булды. Атасының мирасына кызыккан, атасын танырга теләмәгән, авыр чакларында аңар ярдәм кулы сузмаган малайлар Люция яшәп калган фатирны, дачаны бүләргә тотындылар. Әле дә ярый ул Гобәй белән язылышкан иде, язылышмаган булса, ялгыз хатынны фатирдан чыгарып кына җибәрәчәкләр иде. Әгәр Гобәй фатирга васыять язып калдырса, балалары якын да килә алмыйлар иде, билгеле. Тик ул нигәдер язмады, әллә кысмырланды, әллә башка төрле уйда булды. Васыять язу мәсьәләсен күтәргәч тә ул: «Алар беркайчан да килмәячәкләр, исән чагымда килмәгәнне!» – дип кенә җавап кайтарды. Килми торган балалар барыбер килеп җиттеләр! Байлык кирәк булгач! Балалары белән аралашырга теләгән Гобәй бервакыт кече улын туган көне белән котларга дип баргач, тегесе өеннән үк чыгып качты. Ата кеше өйгә кайткач, бу кайгыдан башын диварга бәрә-бәрә елады. Аптырагач, уллары белән сөйләшергә энесе Илсурны да җибәреп карады. Кайсыдыр судта судья булып эшләүче олы малае Илсур абыйсына, торып, хәтта сәлам дә бирмәде, бары тик: «Безнең әтиебез юк, бу мәсьәлә хәл ителгән!» – дип, коры гына эндәште. Менә шул: «Безнең әтиебез юк!» – дип тәкрарлаган «гобәйчик»лар инде хәзер ире белән бергә җиткергән Люция милкенә ябырылдылар. Мәхкәмә арты мәхкәмә, күз яшьләре, елаш, рәнҗү... Һәм моның әлегә очы-кырые күренәсе юк иде кебек...

Фатыйх илдәге үзгәрешләрне ихластан кабул итте. Ләкин түрәләрнең баеганын, гади халыкның хәерчеләнгәнен күргәч, аның да бу үзгәрешләрдән күңеле көннән-көн сүрелә барды. Колхозларның таркалып, фермерлык хәрәкәтенең көчәюе аны баштарак сөендерсә дә, соңрак эчен пошырды. Яшь

чагында ул Сарадан бала таптырмаганына бик нык үкенде. Хуҗалыкта хезмәт итүче балалары булгач, шәхси фермер булып китү мөмкинлеге дә бар иде. Ләкин берничә фермерның авылда җир кишәрлекләре алып та, әллә нәрсә майтара алмаганнарын күргәч, ул шушы бәхетсез Рәсәйдә фермерлык эшенең беркайчан да алга китмәячәгенә кабат инанды. Чөнки фермер банктан ссуда алуга ук, аны салым бурычлары, ягъни олы процентлар белән катырып куялар. Бәяләр гаҗәеп кыйбат, ә табыш алуы шактый читен. Нәтиҗәдә, мескен фермер фәкать үзенә зыянга, ягъни бушка бил бөгәргә мәҗбүр була.

Авылда мәчет төзеделәр. Халык мәчеткә йөри башлады. Кайчандыр Фатыйхны дөрес юлга бастырырга хыялланган колхоз парторгы да мәчетне якын итте: мулла ук булмаса да, аның ярдәмчесе булып китте. Хәзрәт (шактый олы яшьтә) сырхаулаган чакларда элеккеге парторг вәгазьне үзе укый торган булды. Халык әйтүе буенча, баш муллага караганда, парторг вәгазьне үтемлерәк һәм эчтәлеклерәк итеп укый икән. Әйе, ни генә әйтсәк тә, партия мәктәбен узган кешеләрне тормыш арбасыннан җиңел генә төртеп төшереп була димени!

Авырган чагында бер-ике көнгә генә аның янына менеп торган Сара бөтенләйгә Фатыйх янында калды. Ике арада яшьлектәге кебек ярсу мәхәббәт хисләре ургып тормаса да, алар бер-берсе өчен дус һәм киңәшче булдылар. Әйе, бер алмагач янында икенчесе дә үсеп утырырга тиеш, ә алар ничек аралашалар һәм ничек серләшәләр, анысы инде беркем өчен дә мөһим түгел, бу очракта аларның фәкать үсүе һәм җимеш бирүе генә зарур иде.

...Әлеге вакыйгаларга, бәлкем, шушы урында нокта куярга да мөмкин булыр иде. Ләкин тормыш – «анасын ормыш» кайвакытта бөтенләй көтелмәгән хәлләр китереп чыгара. Көннәрдән бер көнне (май ахырларында) авылга Мәскәүдән Тәнзилә кайтып төште. Озак гомер авыл тирәсендә күренмәгән хатын туп-туры Фатыйхларга барып керде. Үзе генә түгел, малае белән. Чатырдатып татарча сөйләшеп торган бу малайның исеме Айдар булып чыкты. Таныш исем. Тәнзиләнең яшьли үлгән беренче баласының исеме дә Айдар иде ләбаса. Тик иң кызыгы шул: бала Абрек малае иде. Әйе, әйе. Айдар Абрекович. Бәхеткә, шул көнне мәхкәмә юлларында йөреп иза чиккән һәм әзрәк ял итәрмен, дип, авылга кайткан Люциягә дә бу гаҗәеп хәлләргә шаһит булырга туры килде.

Шәһәр төсе кергән, чәчләрен үзгәчә, шәһәрчә үргән, үзен шат, бәхетле хис иткән Тәнзилә, өйдәгеләр белән ихластан күрешеп, кочаклашып чыккач, кечкенә Айдарны туганнары белән таныштыра башлады. Менә бусы синең дәү әниең, менә бусы синең бабаң булыр, дип, ул бер Люция, бер Фатыйх ягына ишарә ясады. Әлеге хәлдән бик тиз генә эреп китәргә ашыкмаган, элеккеге килененә үпкә тоткан каенанасы, ашыкмале, сеңлем, кем баласыдыр әле бу, Мәскәүдә берәрсеннән тапкансыңдыр, дип, малай белән Тәнзиләгә авыр күз карашы ташларга өлгерсә дә, елмаеп, балкып басып торган балада Абрекның һәм хәтта үзенең йөз чалымнарын шәйли алган кешедә шик-шөбһә тудырырлык түгел иде кебек. Айдар чат Абрекка охшаган! Кавказ тек Кавказ!!!

– Тәнзилә! – дип, ниһаять, телгә килде Люция. – Нишләп соң бала туганны безгә җиткермәдең? Ничә ел үтте...

– Сер итеп сакладым, – диде Тәнзилә, – шулай кирәк дип уйладым, бала өчен дә шулай яхшы булыр, дидем. Аның турында бары тик әнием һәм әтием генә белде. Әнием Мәскәүгә килеп йөрде, бала карашты. Мин аларга беркемгә дә әйтмәскә куштым...

– Абрек беләме соң?

– Әлегә юк...

– Нишләп беренче аның янына алып кайтмадың? Атасы янына...

– Атасының башка хатын белән торганын җиткерделәр, шуңа күрә анда кайтуны тиешле хәл дип күрмәдем... – Тәнзилә дөрес сөйли иде: Абрек инде күптән, язылышмыйча гына, үзеннән сигез яшькә яшь Әлмирә исемле бер кыз белән гомер итеп ята иде. Баласын җитәкләп, бер-берсен яратып яшәгән ике кеше янына кайтып төшү Тәнзиләнең тормыш принципларына бигүк туры килеп тә бетми. Табигатьтән бирелгән горурлык һәм шулай ук тыйнаклык хисе аңа шундый кыю адым ясарга комачаулап тора иде кебек...

– Билгеле... ул бит ир кеше, – дип төрттерде Люция, – югалган хатынын еллар буе көтеп утырмас...

– Сез миңа үпкәләмәгез, зинһар, – дип акланды Тәнзилә. – Шулай кирәк булды, юкса минем балам, кадерле балам менә хәзер исән-сау тәпи атлап йөрмәс иде. Әйе бит, улым, шулай бит, җаным?!

Чиксез нык дулкынланган Тәнзилә читтә боегып басып торган сөекле баласын кочып, үбеп алды. Бу хәлне тыныч кына күзәтү мөмкин нәрсә түгел иде, билгеле: шулчак Люциянең, Сараның һәм хәтта Фатыйхның да йөзендә күз яшьләре балкыды.

Абрек үзенең ата кеше булуына, улы барына шактый гаҗәпсенде һәм бу хәбәрне салкын кабул итте. Чөнки шул вакыт эчендә ул Тәнзиләдән ярыйсы гына ерагайды, Әлмирәле тормыш башлагач, элеккеге хатыны белән хәтта хәбәрләшүдән дә туктады. Ләкин авылга кайтып, урамда чабып йөргән кечкенә Айдарны күргәч, ул да эреде. Әйе, бу бит аның баласы, бу бит аның каны! Бу бит ул, бу бит чат Абрек! Тик кечкенәдән үк этисен белеп, күреп үсмәгән Айдарны үз ягына авыштыру җиңел булмады. Абрек аңлады: аңар Айдарга үзен эти итеп таныту өчен, әле шактый вакыт кирәк булачак. Ә балага ата кирәк, ансыз берничек тә ярамый. Менә бит язмышлар ничек кабатлана: кайчандыр Абрекны да шулай (әнисе белән аерылу сәбәпле) этисез калдырдылар. Тик бу очракта үзара яңадан кушылу гамәле мөмкин нәрсә булмаган. Хәер, Тәнзилә үзе дә аны теләми, аның сүзләре буенча, ул үзе дә хатыныннан аерылган бер Мәскәү кешесе белән кушылырга йөри икән. Абрекның улы барлыгын һәм Мәскәүдән элеккеге хатыны кайтканын ишеткән Әлмирә дә, шул хәлдән көнләшеп, өйдә җен бураннары чыгарып алды. Ләкин Абрек аны бик тиз тынычландырды, ул, ашыгып диярлек, «Яхонт» кибетеннән алтын балдаклар сатып алды, өйләнешергә тәкъдим ясап, ЗАГСта туй көнен билгеләтте...

...Тәнзилә авылда бер ай чамасы яшәде. Ташкаладан кайтып, авылда иреккә чыккан кечкенә Айдар бигрәк тә Фатыйхларны үз итте. Дәү әнисе (Люция) күктән төшкән оныгына ничек кенә ярарга белмәде. Казан каласында нинди искиткеч тәмле әйберләр бар, шулар белән оныгын сыйларга тырышты, берничә көнгә Казанга алып барып, аңа Татарстан башкаласын күрсәтеп кайтты. Фатыйх белән онык кырга, урманга барырга, бигрәк тә авыл башына чыгарга ратты. Һич көтмәгәндә, әнә шул нәни Айдарга бабай булды, аны үз итте Фатыйх. Кечкенә сәяхәтләрдән тәм тапкан баланы ул авылның иң матур урыннарына алып барды. Сабый янында үзең дә сабыйга әйләнәсең, дип, юкка гына әйтмиләр, күрәсең. Менә бүген тагын, кечкенә Айдарны җитәкләп, авыл башына юл алды. Айдар җәйләүләргә хәтле җәелгән тирән күл буенда йөрергә ярата. Ул яр астына төшкәч, сандалиен салып атып, су читенә кереп баса, күлгә таш ата, якында гына йөзеп йөргән күл җәнлекләрен – су күселәрен күзәтә, сабыйларча сөенә, соклана. Күлнең бер ягында – бакча, икенче якта – көтүлек, анда сыер, сарык көтүе утлый...

Бүгенге сәяхәт шактый озакка сузылды. Алар күл буеннан еракка –

кыргый алмагачлар үсеп утырган яр борылышына хәтле барып җиттеләр. Алмагачларның берсе яр кырында, хәтәр урында тамырланган. Убылуга ләмәте аркасында яр кыры бик каты ишелгән, алмагачның бөгәрләнеп үскән катмарлы тамыры яртылаш тышка чыгып тора. Берәр елдан соң, әгәр дә ярны ныгытмасалар, бу бәхетсез алмагач текә яр астына, тирән чокырга мәтәлергә мөмкин. Фатыйх, сәерсенеп, әнә шул алмагачка карап торды. Ак чәчәккә чумган алмагачның инде күптән үсүдән туктаган яфраклары вак-вак, чәчәкләре дә нәни баланың бармак башы хәтле генә. Көзгә аның чәнечкеле ямьсез ботакларында ямь-яшел вак алмалар барлыкка килер, тик аларны беркем дә җыймас, чөнки алар ачы, тәмсез, шуңа күрә беркем дә кагылмас. Бар ул алмагач, бар, ләкин аңардан беркемгә дә файда юк, һәм ул беркемгә дә сихәт бирә алмый. Фатыйх үзенең язмышын, ирексездән, әнә шул яр кырында үсеп утырган кыргый алмагач белән чагыштырды. Ул да шул алмагач сымак нәүмиз, алмагач язмышы да, Фатыйхныкы кебек үк, бәхетсез һәм шул яшел алмадай ачы сымак иде...

– Бабай, ә бу кем? – дип сорады аңардан Айдар. Сабый бит, аның өчен бу дөньяда хәзер бар нәрсә дә әнә шулай гаҗәеп тере һәм дәү булып күренә.

– Кем түгел, ә нәстә, улым?

– Нәстә?

– Алмагач...

– Ә нишләп ул шундый?

– Кыргый ул, улым, кыргый...

– А это что такое? – Татарча яхшы ук бытылдаса да, «кыргый» дигән сүзне бигүк аңлап бетерми әле шул онык.

– Дикая... ызначит...

Айдарга бу кызыксыз алмагачка карап тору туйдырды, күрәсең, ул, кинәт кенә алга ыргылып, кыштан калган салам эскерте каршына чапты. Салкында, кар астында каралып каткан эскерт янына барып җиткәч, Айдар аның артына кереп качты. Баланың үзенчә качышлы уйнавы иде бу!

– Улым! Ау-у! Син кайда? – дип уйнап эндәшкәндәй булды Фатыйх. – Ау-у-у!!!

Ләкин Айдар яшеренгән урыныннан тиз генә атылып чыгарга ашыкмады. Фатыйх, салмак адымнар белән, эскерт ягына атлады. «Кеше малае бит, ни генә булмас!» – дип борчылды ул. Хәер, Айдар да озак көттермәде:

– Бабай! Бабай! Ау-у! Мин монда! – дип, шукланып, малай эскерт артыннан атылып чыкты да, кулларын җәеп, бабасына йөгерде...

«Кара, кара, сабый бала, бабай ди бит, әй, бабай, ди! – дип сөенде Фатыйх, эчтән тын гына елап. Ә балалар сизгер була шул алар, Айдар да шундый икән:

– Бабай... ә бабай...

– Әү... улым...

– Син... нишләп елыйсың?

– Болай гына, балам, еламыйм, – дип кочты аны Фатыйх, – күңелем сөенә...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Әскәр
Додуев

# ТАШ СЫРТЫНДА БҮГЕН УТЫРАМ МИН...

## Бомба

Ул курыкты атом бомбасыннан...
Хәтта ялгыш искә төшерү дә
Аның өчен шомлы булды сыман.

Ә бер көнне, шулай иртә белән,
Ул ашыгып эшкә бара иде,
Ашлык төягән зур йөк машинасы
Юл чатында аны таптап китте.

Ә ул, исәр, машинадан түгел,
Атом бомбасыннан курка иде.

## Чират

Зур бер ташка мин утырдым барып,
Юл читендә шунда тукталып.
Ял итәбез гүя өчебез дә –
Мин дә, юл да, таш та, тын калып.

Шулчак яныбызда үскән куак
Үләнгә сүз кушты пышылдап.
Тыныч кына яткан җирләреннән
Таш та, юл да сүзгә кушылды.

Бәхәс купты алар арасында.
Озак кына бәхәс тынмады.
Ишетмәдем берсенең дә сүзен,
Мин бары тик ташны тыңладым.

Таш сыртында бүген утырамын,
Кызык түгел инде берсе дә.
Күп тә үтмәс, ул таш кукраеп
Утырачак минем өстемдә.

---

Әскәр ДОДУЕВ (1953) – *Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре. «Йөзгә йөз», «Кардан баручы», «Юлда» һ.б. карачай, балкар һәм рус телләрендә чыккан егермеләп китап авторы. «Минги-Тау» журналының баш мөхәррире. Нальчик шәһәрендә яши.*

## Елга

Никадәрле елга коя диңгезгә!
Диңгез тыныч, алар суын сизми дә.
Кар эресә, яңгыр яуса тауларда,
Ярсый елга, ташып чыга ярлардан.

***

Мин атладым йөрәгемнең артыннан.
Сөюемнең шактый күп шаһитлары.
Яклаучысы булдым ләкин бер үзем –
Шуңа мәллә калды аннан көл бары.

## Бала күңеле

Менә тагын яз җитте:
Кар эреде тауларда.
Яз күңелне җилкетте:
Бала күңеле – далада.

***

Кыен көнемдә юкса исемдә –
Тик күрешәбез бары туйларда.
Сәрхуш чагында әйтелгән сүзләр
Истә калмый шул, онытылганнар.
Кыен көнемдә мин юк исеңдә,
Хәтта янымда гына йөрсәң дә.

## Йөрәк

Үз эчеңә сыйдырмаган
Кайгы юктыр синең өчен.
Бар байлыгың – кешеләрнең
Хәсрәте, көенече.

Ни кылмыйсың кешеләрнең
Борчуларын сипләр өчен.
Үз кайгыңны белмисең дә,
Ут янасың читләр өчен.

## Тамырларын кояш күргән агач

Һәр яңа көн туган саен, иртән
Сине уйлап тибә йөрәгем.
Теләкләрең чынга ашты менә:
Күптәннән юк икән күргәнем.

Күптән инде мине искә алып,
Күңелеңне сагыш басмыйдыр.
Хәзер инде якты таңнарың да
Мине уйлар өчен атмыйдыр.

Ә мин тагын юлга чыктым әле,
Бер кагыйм, дип, сагыш тузанын.
Тик җаныма ничек аңлатыйм соң
Елларымның синсез узганын?

Өметләрем калган аргы ярда,
Кичералмый ялгышларымны.
Ят дулкыннар кочагында йөзәм,
Кайтар миңа сагышларымны.

Кая гына китеп югалсам да,
Күз алдымда сының торыр бит.
Тамырларын кояш күргән агач
Бер көн барыбер кибеп корыр бит.

***

Бер-бер артлы еллар үтә очып,
Чынга ашмый кала хыяллар.
Ә җырларым минем үзем белән,
Минем белән дөнья куярлар.

Еллар белән бергә гомер үтә,
Сизелми дә кала узганы.
Сагышларда узган еллар китә,
Еламыймын аны кызганып.

Гомер – ак тау, ә ул биек тауга,
Юк, менмәдем селкеп кулымны.
Үкенмимен һич тә, мин заяга
Үткәрмәдем гомер юлымны.

***

Мәҗбүр итмә, зинһар, ант эчәргә.
Карашың әйттермәс ни генә!
Ия була алмам күк сүземә –
Китә алмам кабат кирегә.

Синнән читтә юллар табалсам да,
Мин үземне киләм гел аклап. –
Каргарсың дип куркам китә калсам,
Шул каргышың саклый гөнаһтан.

***

Айсыз төндә ишетелә:
Күккә карап этләр өрә.
Кара төннең ак бураны
Этнең өнен карга төрә.

Ул, буранга ачу итеп,
Ыңгыраша, улый, елый.
Буранның юк анда эше,
Өнен ак кар белән сылый.

Эт улавы күкне яра.
Ул кызганыч әнә шуңа.
Кемдер исә суык төндә
Ыңгырашмый гына туңа.

***

*Мөхетдин Абаевка*

Тауга менәбез. Аяк асты боз.
Әле җитмәсә, кар япкан өстен.
Гафу ит, дустым, мин алга узыйм,
Анаң күз яшен килми күрәсем.

## Каек

Мин алай ук бик карт түгел әле,
Тик тынычлык эзли йөрәгем.
Хыялларым бар да алда чакта
Ник өзелде болай йөгәнем?..

Бөтенесен, язмыш, син бирәсең,
Сорамыймын артык үзеңнән.
Кояш күктә көлеп торган чакта
Үз куләгәң йөри эзеңнән.

Алай ук бик карт та түгелмен күк,
Тик пышылдап, маңгай сырларым,
Куша кабат искә төшерергә
Артта калган яшьлек елларын.

Теләгеңә һәрчак ирешерсең,
Ни көткәнең җирдә булганда.
Сорап сузган кулга охшый каек,
Диңгез тыныч – батмый ул анда.

Хәлем бетсә, таш күк батачакмын.
Төпкә китәр бер көн каек та.
Җиңелрәк ташны күтәрүе
Су төбендә яткан каектан.

## Ике дулкын

Кайчак текә борылышларында
Язмышымны һаман шелтәлим.
Тәмле бәлеш белән сыйласа да,
Аңарга шул бик еш үпкәлим.

Нәрсә кирәк миңа бу дөньяда?!
Белми булыр хәтта Алла да.
Бар өзелеп сөйгән газиз ярым,
Кирәгем юк кебек аңа да.

Берсен-берсе йота ике дулкын,
Кара-каршы әгәр килсәләр.
Яратуын аның өмет итмим,
Исем китми, сөйми, дисәләр.

Без икәү бу тормыш диңгезендә,
Ерак түгел юкса арабыз.
Ул – алдарак бераз, мин – артыннан,
Бер үк ярга таба барабыз.

*Балкарчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе.*



Фәтхулла
Абдуллин

# КЕМГӘ СӨЙЛИМ СЕРЛӘРЕМНЕ...

ПОВЕСТЬ

Буровойда гадәти булмаган тынлык. Көнне төнгә ялгап, дөбердәп эшләгән кырык бер метрлы манара-вышка тынып калган. Янында брезент киемгә төренгән эшчеләр дә күренми. Вышка түбәсендәге лампочкалар да, кемгәдер үпкәләгәндәй, тонык кына яктырталар.

Вышкадан арырак урнашкан культбудкада бораулаучы Баязит кулдашы Зиннур белән шахмат уйнап утыра. Боксёр перчаткасы кигән верховой Булат, яшьлек кайнарлыгы белән, кызып-кызып күнегүләр ясый. Юк-юк та стенаны да дөмбәсләп ала. Беләкләрендә көч-куәт ташып торган егет китереп бәргәч, дивалардагы «Бишьеллык планны – дүрт елда!», «КПССка дан!», «Яшәсен!..» дигән лозунглар да, юлбашчыларның кадакка эленгән портретлары да дерелдәп калтырап куя. Хәер, тәгәрмәчләр өстендә утырган, көчлерәк җил иссә дә чайкалган будкага күп кирәкмени?

Шахматчыларның Булатта кайгысы юк. Терсәккә таянган куллары белән чигәләрен учлап, уенга мавыкканнар. Баязит, катгый карарга килеп, тиз генә бер фигурасын күчерә.

– Шах!

Булат, күнегүләрдән туктап, өстәл янына килеп баса, уйнаучыларга сиздермәскә тырышып, бер фигураны күчереп куя. Шулай да Зиннур моны күреп ала.

– Шаярма әле син, Булат, шаярма! Безнең монда кискен көрәш бара...

Булат күчергән фигурасын кире урынына этәрә.

– Көне буе «Шах!» та «Мат!» Җитәр инде сезгә! – Егет бияләе белән Зиннурның җилкәсенә җиңелчә генә төрткәләп ала. – Әйдә бокслашабыз!

– Нинди бокс?! Күрәсең ич, минем корольгә «покушение» бара.

Зиннур, королен сакларга тырышып, йөреш ясый. Баязит, шуны гына көткәндәй, тиз генә үзенең бер фигурасын шахмат тактасының икенче шакмагына күчерә һәм тантаналы рәвештә башын югары күтәрә.

– Сиңа мат, Зиннур! – Аннары, дөнья чемпионатында җиңү яулаган гроссмейстерларча горур кыяфәттә кулын көндәшенә суза.

Зиннур «ничек булды соң әле бу?» дигәндәй, бер мизгел шахмат тактасына текәлеп тора. Ахыр чиктә, чарасыздан, җиңелүен танырга тырыша.

– Да-а, бүген миңа иртәдән бирле «мат» тондыра башладың әле син, Баязит. Юньлегә булса ярар иде.

– Глина китерергә булса ярар иде, дип юра.

– Әйе, фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килсен иде, – ди ул, елмаеп. Бераздан җитдиләнеп өстәп куя. – Шахмат тактасындагы «мат» – чепуха! Кичәдән бирле простойда утырабыз. Менә кайда ул настоящий «мат!»

Эшчеләрнең борчылуы инде йөзләренә чыга. Әңгәмә үзеннән-үзе эшкә: уртак борчу-мәшәкатьләргә күчә.

– Кичә конторага киткән мастер да күренми...

– Ярый ла, юлы уңып, бер машина глина төяп кайтса...

Бораулаучыларның глина дигәннәре – он кебек төелгән яшькелт тау токымы. Суга салып болгаткач, камырдай үзле измәгә әйләнә. Бораулаганда, скважинаның ян-якларына сыланып, ишелүдән саклый. Борын-борыннан чүлмәк ясау өчен кулланылган бу үзле балчыкны сынлы сәнгатьтә дә файдаланалар.

– Кайчан без адәм рәтле кешеләр кебек туктаусыз эшли башларбыз инде, ә?

– Эшсезлектән үзем дә туйдым, – ди Баязит, исемен төбәп әйтмәсәләр дә, аның бакчасына таш атуларын чамалап.

Зиннурның сүзе бетмәгән икән әле.

– Безнең вахтада син – старший. Сине беләбез. Таләп ит! Требуй! Китерсеннәр! – ди ул. – Көн саен болай тик ятсак, башкалар уч тутырып акча алганда, безгә нәрсә, аю шикелле тәпи суырырга кала инде...

Баязит үз сменасы өчен җавап бирсә, мастерлары Сәетгали барысы өчен дә җаваплы.

– Ярар, мастер кайтканны көтик инде, – ди ул. – Мәсьәләне кабыргасы белән куям, дип китте бит.

– Кабыргасына гына түгел, сыртына салып сөйләшергә кирәк монда. Без Горшковныкылардан киммени? Аңа барысын да бирәләр... Ә безгә?..

Нефтьчеләр мастерларының уйнап йөрмәгәнен белә, билгеле. Баязитка шул ачуларын басар өчен генә бәйләнәләр инде.

Тышта машина тавышы ишетүгә, үзара бәхәсләшкән нефтьчеләр дәррәү тәрәзәгә ташлана: Сәетгали түгелме? Түгел икән шул. Будкага план бүлеге инженеры Люба килеп керде. Кулындагы түгәрәкләп төрелгән ватман кәгазен җәһәт кенә җәеп җибәрде дә, кнопка ярдәмендә, приказлар тактасы янәшәсенә беркетеп тә куйды.

– Әнә, күрегез ничек эшләгәнегезне!

«Яшен» битендәге сурәттә, 48 саны сугылган буровой вышкасы, авызлары колакка кадәр ерылган эшчеләре белән самолётта оча. Ә аларның 47 нче вышкасы «Менә авам!», «Менә авам!» дигән кебек, ташбака өстендә сөйрәлә иде.

Кайсы кая таралган егетләр дә, машина тавышын ишетеп, будкага йөгереп керде. Алар, «Яшен»дә үзләренең карикатураларын күргәч, плановик хатынга ябырылдылар.

– Безнең адәм мәсхәрәсенә калуыбызга сез... – Зиннур аздан гына «контора күселәре» дип ычкындырмады, – конторскийлар гаепле!

Аның сүзен башкалар да күтәреп алды.

– Әйе! Безнең бригаданы вакытында измә белән тәэмин итмәүләренә сез гаепле!

– Ак эт бәласе – кара эткә!

Любовь Степановна – үз эшендә азау ярган белгеч – тиз генә бирешә торганнардан түгел, каушамыйча, каударланмыйча гына дәлилләр китерә-китерә аңлатырга тотынды.

– Без тәэминатчылар түгел бит. Безнең бүлек саннар белән эш итә, – диде ул, ярыйсы гына кызып барган егетләрнең учагына су сибеп. – Горшковныкылар

мең метрга җитеп киләләр. Ә сезнең бораулаган метрларыгыз ташка үлчим генә. Койрыкта сөйрәләсез! Шулай булгач, кемгә үпкәләргә?

Ханым егетләр белән бәхәсләшеп тормады, «вездеход»ка утырды да китеп барды. Аның артыннан әчкелтем бензин исе генә таралып калды.

Кәефләре кырылган бораулаучылар янына, көтмәгәндә, алюмин бидон күтәргән кыз килеп басты. Оялмый-тартынмый гына:

– Абзыйлар, катык кирәкмиме? Свежий катык! – дип, тәҗрибәле сатучылар кебек, товарын мактарга кереште.

Әле һаман ачуы басылмаган Зиннур күзенең агы белән кызга карап алды.

– Нинди катык?! Катык кайгысымыни монда! Базарга барыгыз!

Әмма кыз да тиз генә бирешә торганнардан булып чыкмады. Зиннурның сүзләрен колак яныннан гына үткәреп җибәрде дә, бидонын чирәмгә куеп, сумкасыннан стакан тартып чыгарды, бидон капкачын ачып, бәләкәй чүмеч белән стаканга катык салды.

– Менә, кабып карагыз әле! Мәгез, кем беренче?

Егетләргә елмаеп карап торган чибәр кызның тәкъдименә кем каршы килсен инде. Берьюлы берничә кул стаканга үрелде.

– Ай Алла! Түгәсез бит инде!

Кызның катыгы, чыннан да, тәмле иде.

– О-о, телеңне йотарлык!

– ОРС кибетенең әчегән кефиры түгел инде бу!

– Сеңлем, сөт өсте түгелме соң бу?

Мактаганны кем генә яратмый. Кызның көләч йөзе тагын да яктырак балкыды.

– Сыерыбыз шулай куе сөтле безнең, абый. Катыкны да аертылмаган сөттән генә оетабыз.

Минут эчендә кызның катыгы сатылып та бетте.

– Сеңлем, иртәгә дә... Ә юк, көн саен кил инде син! Безне онытма!

– Яңгыр яумаса, килермен...

– Причём монда яңгыр?

– Яңгыр яуса, юлның юл дияр җире калмый, абый. Тездән пычракка әйләнә.

– И-и, бичаралар, юлсыз тилмерәсез икән.

– Һи, тилмерү генәме? – Кыз катык оетырга гына түгел, сүзгә дә оста булып чыкты. – Гүр газабы кичерәбез. Менә сез безнең авылга юл салсагыз иде ул.

– Нефть чыкса, обязательно салырбыз, сеңлем. Ә авылыгызның исеме ничек?

– Суыксу.

– Кара инде син, ә! Салкын сулы авылда шундый чибәр кызлар үссен әле.

– Ә синең исемең ничек?

– Икенче килгәндә әйтермен.

– Ай-яй-яй! Бигрәк чая икән бу кыз. Авыл баласы димәссең.

– Хәзерге заман балалары туганда ук сигез класс тәмамлап туа, беләсең килсә...

– Шулайдыр... Шулайдыр...

Электрик Зәбиров сүзен әйтеп бетерми, нәрсәгәдер үкенгән кыяфәттә телен аңкавына тидереп, чыртлатып ала.

– Э-эх!.. Эх! Бераз соңрак туасы калган. Ничек яшисен белер идем. – Аннары, кыз тирәсендә бөтерелгән Булатка дәшә. – Булат, син безнең арада иң яше. Бар инде, бу чибәр кызны өенә кадәр озатып куй, адашмасын!

– Ә мин юлны үзем дә беләм. Сез килгәнче, безнең монда җәйге лагерь иде.

Уйласаң, адәм баласына күп кирәкмени? Бер бәләкәй генә чәтертән кыз ирләрнең салынган борынын күтәреп китте.

***

Сәетгали төштән соң гына кайтты. Кул астында эшләүчеләр белән дә салкын гына исәнләште. Аның болай да кырыс чырае тагын да җитдиләнгән иде.

– Глина китерделәрме?

– Китерделәр. Әле яңарак кына китерделәр, – дип төзәтте Баязит. – Как раз эшкә тотынырга тора идек.

Буровойны озак туктатып торырга ярамаганын Баязит яхшы белә. Җир куенында инструмент кысылып калуы бар. Измә килү белән, ул сменасындагы барлык эшчеләрне аякка бастырган иде.

– Мин күршеләрдә булдым, – диде Сәетгали. – Алар, яңа ысул, дип, суга күчкәннәр. Хәзер кайчан измә китерерләр, дип, көтеп утырасы юк. Инеш яныбызда, кул сузымында гына, ди Николай. Миңа тиешле глинаны сиңа бирсәләр дә сүзем юк, ди.

Баязит мастерларының күршеләр дигәне – 48 нче Горшковлар буровое икәнен төшенгән иде инде. Менә ни өчен алар «Молния»дә самолётта очалар икән. Ул дәртләнеп китте.

– Әйдә алайса, без дә суга күчәбез! Ничу монда... Корылык килгән елны дүрт күз белән яңгыр сорап тилмергән кеше шикелле, измә көтеп ятмас идек.

Ярдәмчесе Зиннур, каударланып, аның сүзен җөпләп куйды.

– Әйе, бораулаган метрлар саны да башкаларныкыннан ким булмас... Ату...

Ярый әле телен тешләп өлгерде. Юкса, «акча корты» дип күз дә ачырмаслар иде. Зиннурның ни әйтергә теләгәнен аңлаганнар, үзара күз кысып, елмаешып алдылар.

Сәетгали җиңелчә генә кул күтәрде.

– Ашыкма әле син, Баязит, ашыкма! Яңалыкка – прогресска мин тамчы да каршы түгел. Ныклап сынамаган килеш, яңалык, дип, тота-каба гына тотынсак, ахыры ничек буласын кем алдан әйтә ала?

Егетләр тынып калды. Әйе, беркем дә пәйгамбәр түгел. Алда ни буласын кем белсен? Адәм баласына бу очракта фәкать фаразларга гына мөмкин. Фаразлар өчен дә тәҗрибә кирәк. Тәҗрибәле мастер – дөнья бәһасе! Бу – исбатланган канун. Шушы хакыйкатьне галстуклы җитәкчеләр дә белә. Алар, буровойга бәйле нинди дә булса карар чыгарганчы, тәҗрибәле мастерлар белән киңәшә.

...Тәҗрибә туплаганчы, Сәетгалигә байтак кына лаеш шулпасы чөмерергә туры килде. Солдаттан кайткан егетне әүвәл өйрәнчек итеп алдылар. Ул, мин сезгә «салага» түгел, хезмәт итеп кайткан кеше, дип, борын чөймәде: кая кушсалар, шунда эшләде, буровойда ниләр бар – барысы белән дә кызыксынды. Сер түгел, өлкәннәр яңа эшкә кергән, тәҗрибәсез яшь-җилкенчәктән көләргә яраталар. Шулай берзаман водовозка шофёры машинасын кабыза алмый интегә. Капотын күтәреп, двигателендә чокына. Аның янында тагын ике ир-ат басып тора. Алар «тегесен тегеләй ит, монысын болай ит», дип, шофёрга киңәш бирәләр: үзләренчә ярдәм кулы сузарга тырышалар инде. Сәетгали алар янына килеп басканда:

– Искра юк бит монда! Искра юк! – дип сөйләнәләр иде.

Арадан берсе, көлмәкче булып:

– Сәетгали, бар әле, тиз генә складтан искра алып кил! – дигән иде дә, аның солдатка алынганчы, комбайнда эшләгәнен белмәгәннәр.

– Ә сез аккумулятор чыбыгын яхшылап чистартыгыз. Күрмисезмени, контакт өзелгән, – дип, аларның үзләрен оятка калдырды.

Коеп яңгыр яуганда, бер буровойдан икенчесенә саз ерып йөргән машинаның канатларына гына түгел, аккумуляторына да, контакт чыбыкларына да пычрак чәчрәп катуын, соңыннан селкенеп бара-бара, балчык авырлыгыннан тартылып, ул чыбыкның өзелү ихтималын шофёр кеше белергә тиеш, югыйсә...

Булачак мастерның тормышында верховой, мастер ярдәмчесе, читтән торып техникумда уку... Әнә шулай бораулау һөнәренең баскычларын үтеп, тәҗрибә тупланды.

Нефть, нефть, дип разведкага йөргәндә, кышкы чатнама суык көннәрнең берсендә нефть урынына су бәреп чыкты. Мондый хәлне көтмәгән нефтьчеләр су фонтаны астына эләкте. Киемнәр шакыраеп катты. Кешеләр боз футляры эчендә калды. Андый хәлләрдән соң нефть эшенә төкереп, буровойны ташлап китүчеләр дә булды. Шөкер, Сәетгали сыек буынлылар нәселеннән түгел иде. Дистә еллар дәвамында палаткаларда куна-төнә яшәп, аңа нефтьче һөнәренең борчу-мәшәкатьләрен күрергә дә, шатлыклы мизгелләрен кичерергә дә туры килде. Җир маен табу өчен маңгай тирен түгү генә аз, кәҗә маеңны да чыгарырга кирәк. Җәмәгате Фатыймага мең рәхмәт! Аның таянычы булды. «Башка хатыннарның ирләре көн саен өйдә... Мин ялгызым мендәр кочаклап ятам...» дип, аның колак итен «чәйнәмәде», бәгырен телгәләмәде. Әле алай гынамы? Өч малаен да аякка бастырып килә. Малайларга әтиләрен күрү, Сәетгалинең урык-сурык, айга бер, кайда бер дигәндәй, вакыт табып, бер-ике көнгә кайтканнарын җыеп чутласаң, елына өч айга тула микән? Бораулаучыларның тынгысыз хезмәте турында:

Татлы йокылар йокладым
Сабый чакларда гына, –

дигән җыр суйган да каплаган инде...

...Егетләр тынып калды. Мастерның сүзен көтәләр. Буровойда аның сүзе – закон!

Сәетгали, кул астында эшләүче егетләрне сынаган шикелле, күздән кичерде.

– Балчык китергәннәр икән, әйдәгез, измә белән эшлик әле, – диде ул. Аннары әз генә паузадан соң, мәгънәле итеп:

– Әлегә... – дип өстәде.

***

Гөлгенә, вәгъдә – иман, дип, ике көннән соң, нефтьчеләр янына килде. Әмма вышка тирәсендә таныш кешеләрнең берсен дә күрмәде. Катыгын да, тырнак астыннан кер эзләгәндәй, «Әчегән катыктыр әле», «Кая, таракан төшмәгәнме?» дип, теләр-теләмәс кенә алдылар. Гөлгенә алар сүзенә хурланып, бидон капкачын шартлатып ябып, кайтып китмәкче дә булган иде, Ходайдан сабырлык сорап, тешен кысып кына түзеп калды. Гомумән, бу сменадагы кешеләр төксе, бөтенләй икенче камырдан әвәләнгән шикелле тоелды аңа. «Сөйләшүләренең ата-анасы юк. Үзләре бертуктаусыз кычкыралар. Буровойда дөбердәгән тавышлар болай да баш өянәге кузгатырлык. Арада аты-юлы белән сүгенүчеләр дә бар. Алар өчен син ояласың. Эшне бисмилла әйтеп башларга кирәк лабаса. Болардан ераграк торуың хәерлерәк – бүтән монда килеп булмас. Ике аягымның берсен дә

атламаячакмын», дип уйлап алды. Әмма ике көн элек, «Яңгыр яумаса, килермен», дигән вәгъдәсе келт итеп исенә төшкәч, брезент киемле, битен-күзен сакал-мыек баскан кешедән ике көн элек эшләгән сменаның кайчан вахтага басасын белеште. Әйе, вәгъдә – иман! Сүз биргәч, үтәмичә ярамый. Бу – әнисенең сабагы.

Авылга илтә торган, як-ягын чирәм баскан сукмак урман буеннан үтә. Икенче якта чәчәкле болын җәйрәп ята. Табигатькә хозурланып барганда, ихтыярсыздан, күңелдә җыр туа. Кычкырып җырлыйсы килә.

Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын...

Бераздан сукмак уңга борылып, ат юлына тоташа. Аннан инде авылга да күп калмый. Кыз җырыннан туктый. Ишетсәләр, исәр кеше кебек, көпә-көндез җырлап йөрисең, диярләр.

Гөлгенә нефть эзләүче буровиклар турында уйлап алды. Боларның җитәкчеләре бер сменага бер төрле, икенчесенә икенче төрле кешеләр туплаган бугай. Нишләтәсең, кырык ата баласында кырык төрле холыктыр шул инде. Әллә болар эшләгәндә шулай кырыс кыланалармы? Алай дисәң, теге көнне аның белән матур итеп сөйләштеләр ич. Булат дигәне башта «Катык белән бергә телемне йоттым», дигән иде дә, соңыннан, үҗәтләнеп, аны ярты юлга кадәр озата да барды бит әле. Тасма тел бу юлы ни дияр икән? Кичтән аертмаган сөттән катык оетырга куясы булыр. Әйе... Ә, бәлки, пешкән чөгендер турап, кызыл катык ясаргадыр?! Әйе шул! Шаккатсыннар әле!

Кыз үзалдына канәгать елмаеп куйды, дәртләнеп, адымнарын кызулатты.

***

Баязит, вахтага басканда, тагын су турында сүз кузгатты.

– Нәрсә, мастер, кайчан суга күчәбез? Яңа ысул, диләр ич.

Сәетгали, 48нче буровойдан кайтканнан соң, бу турыда байтак баш ваткан һәм, ахыр чиктә, бер карарга килгән иде инде.

– Әйткәнемчә, яңалыкка мин тамчы да каршы түгел. Әмма безнең татарда, иске балта киндер чабарга булса да ярый дигән мәкаль дә бар бит әле. Йомшак катлам, шуыша торган тотнаксыз плывун шикелле, болай да суга бай була. Ә без аңа тагын су өстәсәк, үзебез үк скважинаның ишелү ихтималын арттырачакбыз. Без ул йомшак катламны үткәндә, глина-измә белән эшләрбез. Ә суны доломит кебек каты токым бораулаганда кулланырбыз. Аңладыңмы?

Баязит аңлаганын да, ризалыгын да белдереп баш какты. Ул мастерларын күзалдында тотып, ихтыярсыздан: «Ну баш та бар инде моңарда!» – дип, үзалдына елмаеп куйды.

***

Верховой Булатның эш урыны кырык бер метрлы буровой каланчасының иң биек мәйданчыгында. Тирә-яктагы басу-кырлар, урман-болыннар, төбендә күз яше кебек чишмә сулары саркып яткан ерганаклар да уч төбендәге сыман аңа. Әйләнә-тирә сокланып туймаслык манзара! Егет, баскычның тимер тоткаларына тотына-тотына күтәрелгәч, барысы да үз урынындамы дигәндәй, тирә-якка күз сирпеп алганнан соң, аның карашы урман буенда утырган Суыксу авылында туктап кала. Дөрес, аңа авылның бер очы гына күренә. Шулай булса да, Гөлгенә яшәгән авыл ич ул! Э-эх, беләсе иде, бу минутларда ул нәрсә эшли икән? Бүген килер микән?

Аңа озак хыялланырга ирек бирмәделәр.

– Булат, ты чего там, уснул чтоли? Ыргакны төшер! Майна!

Зиннур шулай ике телне бутап сөйләргә ярата инде.

Булатка күп көч куясы түгел. Кнопкага гына басасы. Электр ярдәмендә эшли торган чыгыр дөбердәп аска төшеп китте. Мастерның ярдәмчесе Зиннур ыргакка торба башын эләктерүгә, кабаланып (аңа метрлар кирәк, эшсез үткән көннәрнең бурычын кайтарасы бар!), Булатка команда бирде.

– Вира! Тизрәк кылан инде, Булат! Әйдә, вира!

Болары катлаулы түгел. Ә менә күтәрткән торбаңны «смирно» бастырып аска төшергәндә, орды-бәрде генә эшли алмыйсың инде. Монысы, Баязит абыйсы әйтмешли, «ювелирная работа!» Кран ыргагында асылынып торган торбаны җир куенына чумып барганы белән тоташтыру сакланып кына эшләнелә.

Баязит, ярдәмчесе кыбырсый башласа:

– Кая ашыгасың! Каударлану ул, энем, борча тотканда гына ярый, белдеңме? – дип, аны шунда ук урынына утырта.

Сәетгали Булатны эшен җиренә җиткереп, намус белән эшләгәне өчен генә түгел, бигрәк тә кызыксынучан булганы өчен ярата. Әзрәк буш вакыты булдымы, ясле баласы шикелле «Бусы ни өчен?», «Монысы нәрсәгә?» дип, буровикларга бер-бер артлы сораулар яудыра. Җавап табып кына өлгер! Хезмәттәшләре аңа «Почемучка» дигән кушамат чәпәп куйдылар.

Сәетгали, вакытлы-вакытсыз бимазаласа да, егетне:

– Нәрсәгә кирәк ул сиңа? Бар, эшеңдә бул! – дип куып чыгармый.

Әнә бит, Ока елгасы буендагы бер авылда сыерлар көтүче Ваня исемле малай да, малларын эчерергә елгага алып төшкәч, аргы як ярдагы җир катламының төрле-төрле икәнен күреп гаҗәпләнә. Ни өчен берсе ак, икенчесе кызыл, өченчесе... Ә тагын да астаракниләр бар икән?

Кешенең күңеленә ачкыч таба алсаң гына серен сөйли. Җир-Анабыз да шулай: куенына үтеп керә алсаң гына серләрен ача. Көтүче малай да төпченә башлый. Кызыксынып укырга керә. Һәм ахыр чиктә нефть геологиясендә Иван Губкин дигән галим барлыкка килә. Академик дәрәҗәсенә ирешә. Безнең төбәктә җир куенына үтеп керергә омтылучылар унтугызынчы гасыр ахырында да, егерменче гасыр башында да булган, анысы. Бөгелмә алпавыты Николай Малакиенко Түбән Кармалка авылы янында утыз биш сажень тирәнлектә кое казытып, ике мең пот битум һәм сиксән чиләк җир мае суыртып алган. Аннан соң ун ел чамасы узгач, Америкадан Шандор дигән бәндә килеп, Шөгер авылы янына скважина кора. Аппетиты зурдан була ул акча янчыгының. Әмма 354 метр аска төшеп тә көткән нәтиҗәгә ирешә алмагач, кайтып китәргә мәҗбүр була. Дөньяда иң зур капиталистик фирма хуҗасы Нобель дә 1910-1914 елларда Идел буенда эзләнү эшләре башлап карый. Нәтиҗәсе генә уңышсыз. Җир-Анабыз серләрен «сөйләргә» ашыкмый.

***

Инженер дипломы алган Иван Губкин революциядән соң да эзләнүләрен туктатмый. Әгәр Идел-Урал төбәгендә кайчандыр битум табылган икән, кайдадыр, тирәндә нефть булырга тиеш, дип фаразлый. Бораулаганда чыккан тау токымнарына таянып, үзенең фикерен дәлилли. Ә җир мае капиталистларга гына түгел, коммунистларга да кирәк. Чөнки елдан-ел фән алга бара. Төрле тармакта яңадан-яңа ачышлар ясала. Техника камилләшә. Дөньякүләм колач җәйгән прогрессны, «ата коммунист» булсаң да, син берничек тә туктата алмыйсың...

Дистә еллар дәвам иткән эзләнүләрдән соң, Иван Губкинның фаразлары

раслана. 1932 елны, Башкортстанның Ишембай дигән саласы янында сигез йөз метр тирәнлектән нефть фонтаны ата! Аннан соң Татарстан туфрагында да килмешәк Шандорларга, Нобельләргә серен ачмаган Җир-Анабыз әкренләп серләрен «сөйли» башлый. Нәтиҗәдә, Баулы, Шөгер, Писмән яклары танымаслык булып үзгәрде. Бәрәкәте генә булсын...

Элегрәк:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм Азнакайларга.
Азнакайларда да тормыйм,
Китәм әллә кайларга...

– дип, күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә бәхет эзләп чыгып китәргә әзерләнгән яшьләребез дә туган туфрагында кала башлады. Туган җиребездә дә бәхетле булып яшәргә мөмкин икәнлегенә инанды.

«Максат итеп куйса, бу егеттән дә нефтьче чыгачак», – дип өметләнә Сәетгали. Бирсен Ходай! Үзебезнең егет! Нефть исеннән бигрәк, акча исен сизеп, әллә каян килгән килмешәкләргә ышаныч юк. Алар далада, җил уңаена тәгәрәп йөрүче тамырсыз дүңгәләк шикелле... Бүген монда, иртәгә Кәҗә авылында...

Беркөнне Булатны Суыксу егетләре тукмап кайтарган. Атна буе күгәргән күз белән йөрде. Ә ул һаман үҗәтләнеп шунда чаба. Катык сатучы кыз тәмам башын әйләндерде егетнең. «Э-эх, яшь чаклар!..» – дип көрсенеп куя Сәетгали, сүрән генә үзалдына елмаеп.

Уйласаң, үз гомерендә байтак нефтьче тәрбияләп үстерде ул. Араларында галстук таккан, инде ярыйсы гына югары үрләгән җитәкчеләр дә бар. Әнә бит, бүгенге көндә остазын узып, «самолётка утырган» Николай да аның шәкерте.

***

Бораулаучы-разведчиклар өчен шунысы табышмак: бораулыйсың, бораулыйсың, аста нефть бармы – юкмы, белмисең. Хәер, уйласаң, Җир-Анабызның өске каты да төрледән-төрле: кайдадыр уңдырышлы кара туфрак булса, кайдадыр бер тамчы суга тилмергән ком чүле, берсеннән-берсе биек таулар, иксез-чиксез диңгезләр, океаннар... Галимнәрнең, әлегәчә, аларның да серләренә төшенеп бетә алганы юк. Ә җир асты серләре турында әйткән дә юк! Шуңа күрә проект тирәнлегенә җиткәнче, нефть исе киләме-юкмы икәнен ачыкларга (фаразларга дисәң дә ярыйдыр!), җир катламын төрле ысуллар, төрле катлаулы приборлар белән тикшереп карыйлар. Геологлар: «Нефть бар!» – дисә, буровой гөрелтесе күңелгә ятышлы көйгә әйләнә. Әмма алардан соң килгән геофизиклар: «Булуы икеле», – дип, күңелгә шом сала. Андый чакта балтасы суга төшкән кеше кебек йөрисең.

Тикшерү ысулларының магнитометрик метод дигәне дә бар. Сәетгалинең күңеленә аларның сүзе ятышлырак. Чөнки җиде (җиде генәме соң? Җитмеш җиде!) кат җир астындагы хәлне тоя торган приборлары тирәндә магнит дулкыннарын сизә торган массаларның төрле булуын күрсәтте. «Димәк, нефть бар!» дип өметләндерде алар.

Дәртләнеп кенә эшләп йөргәндә, күпмедер вакыттан соң сейсмик приборлар белән тикшерүчеләр килде. Сейсмографларның приборы, гәрчә җир асты дулкыннарын актарып язып бирсә дә, «биредә нефть булуы шикле» дигән нәтиҗә чыгар... Мең метрга җитеп килгәндә, менә сиңа мә! Аларның шиге күңел биреп эшләгән кешенең кулына суккан кебек тәэсир итте.

– Ничек болай була соң инде бу? Берегез бер төрле сөйли, икенчегез икенче төрле?! – дигән сорауга һәркем үз фаразларын фәнгә нигезләнеп аңлатты. Үзен хаклы санады.

Сәетгалинең башы чатнап ярылыр дәрәҗәгә җитте. Хәзер нәрсә, аларның сүзенә карап кешеләр төн йокысын калдырып тир түккән, миллион сумнар сарыф итеп бораулаган скважинаны томаларга, ташлап китәргәме? Юк инде! Ул, тәвәккәлләп:

– Проект тирәнлегенә җитмәдек бит әле! – дия-дия, геологлар белән бәхәсләшә-бәхәсләшә: «Бораууларга! Дәвам итәргә!» дигән карарга килде...

Берничә көн бораулап, тагын да тирәнгәрәк төшкәннән соң, тикшерү өчен кабат геофизикларны чакырып китерде.

Бу юлы геофизиклар җир асты токымнарының электр тогын ничек үткәрүен кат-кат сынагач кына өметле нәтиҗә ясадылар.

Сәетгали, өстеннән тау төшкәндәй, җиңел сулап куйды. Ниһаять! Инде барысы да үз урынына утырды, барысы да тәртиптә, дип куанган иде ул. Тормыш – колагыңны бормыш, дип, юкка гына әйтмәгәннәр инде. Дөнья син уйлаганча гына барса иде дә бит...

Икенче көнне аңа эш белән конторада тоткарланырга туры килде. Берочтан гаиләсенең дә хәлен белеп чыкты. Ул буровойга кайтканда, смена алышынган чак. График буенча Баязит сменасы Донгузов вахтасын алыштырып тора иде. Тыныч холыклы Баязит ачудан кызарып чыккан: Донгузовның тетмәсен тетә.

– Григорий, оятың бармы синең? Күпме әйтергә була! Сездән соң вышка тирәсендә, әйтерсең, Мамай явы узган! Бернәрсә үз урынында түгел! Инструментлар чистартылмаган килеш төрлесе төрле җирдә аунап ята!

– Чит планетада түгел бит. Барысы да вышка тирәсендә, – дип аклана тегесе.

Кырык ата баласында кырык төрле холык, кырык төрле язмыш... Ничек тә боларны татулаштырырга кирәк. Коллектив бер йодрык булып, бер максат куеп эшләсә генә эш бара.

Бүген ул аларны ничек кирәк алай татулаштырса да, тыныч холыклы Баязит булып Баязитны чыгырыннан чыгарган Донгузовка карата чара күрми ярамас дип уйлады. Чөнки ике вахта арасында туган кытыршылыкны ул белә иде.

Донгузовка иптәшләре кисәтү ясасалар да, һаваланып:

– Мин сезнең сыман колхозник түгел. Мин Грозныйда нефтяник булып эшләгән кеше! Ничу мине өйрәтергә! – дип кенә җибәрә. Буровойда эшләүчеләрнең байтагы авыл кешеләре булуына ишарә инде үзенчә. «Мин!.. Мин!..» дип корыга күкрәк кагудан ни мәгънә? Син кимсетергә маташкан колхозниклар кебек намус белән эшләсәң иде әле.

Зуррак проблемалар артыннан йөреп, әллә Сәетгали үзе дилбегәне бушаттымы? Дисциплина булмаса, коллективның таркалуын көт тә тор! Проект тирәнлегенә җитеп килгәндә, моңа һич кенә дә юл куярга ярамый. Тәҗрибәсез яңа кешеләр белән ерак китә алмыйсың. Элегрәк җәй көне брезент чатырларда чебен-черкиләрдән талатып, кышын авылларда фатирда торып та эшләделәр. Хәзер буровикларга куна-төнә ятарга будка-битовкалар китерделәр. Ял иткәндә, әнә культбудкага кереп шахмат, шашка, домино уйный аласың. Радио тыңларга, газета-журналлар укырга була. Шулай булса да, чегән тормышында яшәргә атлыгып торучыны бик җиңел генә каян табасың?

Оргнабор (халык телендә вербовка) юлламасы белән килгән кешеләрне өнәми Сәетгали. Күбесе озын берлек эзләп килгән кешеләр була. Аларга үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын. Бар максатлары: эштер-өштер эшләп (буровойда метрлар артыннан куып), уч тутырып акча алу да, гөнаһлары фаш ителгәнче тизрәк

табан ялтырату. Донгузов чыннан да нефтьче булса, буровойда алдашырга, хәрәмләшергә ярамаганын белер иде. Уйласаң, ә ни өчен Грозныйда төпләнеп калмаган? Һәрвакыт кояш көлеп торган җылы, җимешле як, югыйсә!

Алдашу, хәрәмләшү дигәннән (җирдәге явызлыкка тәмугта урын җитмәс), үткән атнада Донгузов:

– Без фәлән метр бораууладык. Индикатор дөрес эшләми. Ким күрсәтә, – дип, электрик чакырткан.

Сменада ничә метр бораулаганны төгәл күрсәтүче бу приборны буровиклар «әләкче» дип атасалар да, ул һәрвакыт дөресен күрсәтә, берничек тә хәрәмләшә алмыйсың.

Электрик Зәбиров агай тегеләй дә, болай да тикшереп караган, кимчелеген тапмаган. Ахыр чиктә:

– Отлично работает! Син нәрсә, күзгә төтен җибәрмәкче буласың? – дип, кореецча да берничә «мактау» сүзе өстәп китеп барган.

Иптәшләре:

– Зәбиров абый, ә син кореецлар телен каян беләсең? – дип сораштыра, төпченә торгач:

– Мин доброволец булып Корея сугышында катнаштым, – дип ычкындырган. Хәзер үзе юкта аның турында сүз чыкса, «Доброволец абзый», диләр. Абзый үзенең ничек доброволец булып китүе турында гына берни дә әйтми (каян беләсең, бәлки сөйләмәскә кушканнардыр).

Яшьләрдә кызыксыну көчле бит: беләселәре килә!

– Зәбиров абый, Сез ничек, гариза язып, доброволец булып киттегезме? Әллә вербовка беләнме? – дип төпченәләр генә бит.

Абзый, «гариза» сүзен ишетүгә, кабынды да китте.

– Нинди гариза булсын инде! Безне – служба срогы тулгач, өйгә кайтырга атлыгып приказ көтеп яткан солдатларны, беркөн иртән плацка тезеп куйдылар. И шуннан соң часть командиры, кулындагы кәгазьгә карый-карый, «Иванов», «Петров», «Забиров», дип, байтак кына фамилияләрне укыды да соңыннан: «Два шага вперёд!» – дип команда бирде. Без, фамилияләребезне ишеткәч, ике адым алга чыгып бастык. Нәрсәгә юрарга белми аптырашып басып торабыз. Шулчак командирыбыз (бездән сорап тору юк!): «Вы с этого момента являетесь добровольцами! Поедете в Корею!» – дип, безнең, өйгә кайтырга дәртләнеп торган солдатларның, язмышын хәл итте дә куйды. И шундук, товарный вагоннарга төяп, Дәлни Востокка алып та киттеләр.

– Дөнья күреп кайткансыз инде алайса.

– Күрдек инде, күрдек... – ди электрик агай, ачуташ капкандай йөзен чытып. Аннан әйтергәме, юкмы дигәндәй, бер мизгелгә туктап тора. – Ул чорда хәзерге сыман тепловозлар юк. Паровоз, ачуым килмәгәе, станция саен туктап су ала, ташкүмер төйи. Без ул товарный вагоннарда, юынмаган килеш сухой паёк, каткан сохари кимереп, егерме бер көн бардык. Бетләп беттек. Шул – бүрек колакчыны кадәр ярымутрау өчен никадәр солдат башын салды. Яралансам да, ярый әле мин исән калдым.

***

Тимерне кызуында сугарга яраткан Сәетгали икенче көнне кул астында эшләүчеләрнең барысын бергә җыйды һәм КТУ (коэффициент трудового участия) – эшкә мөнәсәбәтеңә яки эшкә ничек катнашуыңа карап, хезмәт хакын билгеләү мәсьәләсен күтәрде. Баязит вахтасындагылар хупласа да, Донгузовныкылар:

– Безнең бораулаган метрлар башкаларныкыннан ким түгел. Ни өчен без хезмәт хакын алардан ким алырга тиеш? – дип, теше-тырнагы белән каршы төште.

Сәетгали, туктагыз, тынычланыгыз дигәндәй, кулын күтәреп, кисәткән шикелле итте.

– Григорий Иванович, монда эш бораулаган метрларда гына түгел. Без барыбыз да бер коллектив, бер команда кешесе! Бер-беребезгә карата хөрмәт кирәк. Смена тапшырганда, бөтенесе ялт иткән булырга тиеш.

Смена төгәлләгәннәрнең ял итәсе бар, алмашка килгәннәргә тизрәк эш башларга кирәк. Сәетгали мәсьәләне үзенчә чиште.

– Карагыз аны, әгәр бер атна эчендә хәл үзгәрмәсә, мин бу мәсьәләне кабат күтәрәчәкмен!

Буровойда мастерның сүзе – закон! Кисәтүнең тәэсире булды – Донгузовныкылар акылга утырды. Кесәңә суга башласалар, утырмый кая барасың! Әби әйтмешли, нибуч, утырырсың!

***

Таң атып килә. Күк йөзендә сизелер-сизелмәс кенә яктылык шәйләнә. Үләннәргә иртәнге чык төшкән. Булат белән Гөлгенә яланаяк инеш өстендәге басмада утыралар. Бүген аларның сүзе нефть тирәсендә.

– Нефть дип нишләп шулай бөтен ил купкан? – дип кызыксына Гөлгенә.

– Радиодан да нефть турында сөйлиләр. Авылга лектор килсә дә, шул нефтьне телгә алмыйча калмый.

– Чөнки нефть ул – ил байлыгы, ди безнең Сәетгали абый.

– Ә аның файдасы безгә булырмы икән соң?

– Ник булмасын?! Сез менә куыклы лампага ни саласыз?

– Шуны да белмәскә! Кәрәчин инде, – ди кыз, үпкәләгән сыман.– Сельпо кибетенә китереп саталар.

– Җир сөрүче тракторларның багына нәрсә салалар?

– Солярка диләрме соң инде, – ди кыз, шикләнебрәк.

– Ә машиналар нәрсә белән йөри?

– Бензин белән инде.

– Менә күрдеңме? Боларның барысы да безнең нефтьтән ясала! – ди егет, бераз һаваланып. Аннары тагынниләр өстәргә икән дигәндәй, бермәлгә тынып тора. Шулчак келт итеп Сәетгали абыйсының сүзләре исенә төшә.

– Ул гына түгел, – ди ул, кабынып. – Өстәлгә җәя торган клеёнка, пластмасса савыт-саба... Барысы да нефтьтән ясала.

Кыз өчен болары Америка ачуга тиң яңалык. Моңа кадәр уена да китермәгән шаккатардай хәбәр.

Булат, аякларын суга тыгып, киленнәр кер чайкаган шикелле, бер алга, бер артка селтәп «чайкарга» тотынды. Берара иртәнге тынлыкны су шупырдаганы бозып алды. Әмма озакка түгел.

– Ай-яй суының салкынлыгы! Җелегеңә үтәрлек. – Егет, салкыннан куырылып, аякларын судан чыгарды.

– Авылга Суыксу исемен юкка гына кушканнар дисеңме?

Чалбар балакларын тезенә кадәр сызганган Булат, басма аша үтеп, чыклы үлән өстеннән яланаяк йөгерергә тотынды. Җылынмакчы инде, янәсе. Гөлгенә тыенкы гына көлеп җибәрде (кычкырып көлмә – бәхетеңне куркытырсың, ди аңа әнисе).

– Иртәнге чык җылырак дип уйлыйсыңмы?

Егет, беркадәр ара йөгереп килде дә, кабат басмага кереп, аяк киемнәрен киде.

Әбиләр җәйге төнне бер саплам җеп кебек, диләр. Күк йөзе инде сизелерлек яктыра бара. Саубуллашырга вакыт. Булат кызны иңбашыннан кочаклап алды.

– Гөлгенә, менә күрерсең, мин, һичшиксез, Сәетгали абый кебек мастер булачакмын!

Бу әле беркемгә дә әйтелмәгән, егетнең күңел түрендә бөреләнеп, аны һәрдаим алгысытып торган хыялы!

– Аның өчен күп укырга кирәктер шул.

– Укуы аның биш елдан артык түгел инде. Ә менә Сәетгали абый кебек тәҗрибәле мастерга әверелгәнче, еллар буе буровойда куна-төнә ятарга, бурильщиклар белән бер пот тоз ашарга кирәк.

Гөлгенә кинәт Булатның кочагыннан ычкынмакчы булып омтылды.

– Кит моннан, тәҗрибә туплаганчы, буйдак булып йөрергәмени синең исәбең?

Булат көлеп җибәрде, кочагыннан ычкынырга талпынган кызны тагын да ныграк кысып кочты, күпереп торган чәчләреннән үпте.

– Җанкисәгем, тәҗрибә туплаганчы өйләнми йөрсәң, беләсеңме, сакалың биленә җитәр! Җә Донгузов шикелле «вечный холостяк» булып калырсың. Әнә, Сәетгали абый тәҗрибә туплаганын көтеп тормаган: институт бетергәч тә яраткан кызына өйләнгән дә куйган. Өч малае бар. Олысы егет булып килә.

Егетнең ихластан сөйләгән сүзләренә ничек ышанмыйсың инде?! Ышана Гөлгенә, ышана! Әмма әлегә аның сыерлар савасы, малларын көтүгә куасы бар. Кыз, егетнең кайнар кочагыннан ычкынып, иңнәренә канатлар куйгандай очынып, авылга йөгерде.

* * *

Сәетгали конторадан күңелсез хәбәр алып кайтты. Күрше буровойда ЧП булган: скважиналары ишелеп, инструментлары забойда кысылып калган. Бу хәбәргә барысыннан да күбрәк Булат борчылды. Әйтерсең, көтелмәгән хәл аларның сменасында, аның ваемсызлыгы аркасында килеп чыккан.

– Сәбәбе нидә икән? – дип төпченә башлады.

– Ашыккан ашка пешкән, ди, – Сәетгали, үкенгән кыяфәттә, җиңелчә генә башын тирбәтеп алды.– Метрлар артыннан куып, суны күбрәк кулланганнар.

Әйе, күп сөйләгән кеше турында да сүзенең суы күбрәк, диләр. Һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш шул.

– Күпме бораулаганнар икән соң?

– Мең метрдан артык, ди.

– Да-а, жалко инде.

Борчылуы йөзенә чыккан Булат тагын телгә килде:

– Хәзер бер чакрым торба җир астында каламыни инде?

– Башыңны эшләтергә кирәк, энем, белдеңме?

– Ә нишләргә соң? Мондый хәлдән чыгарга берәр әмәле бармы?

Әмәле-ысуллары бар инде барын. Әмма аварияләр төрлечә була шул. Барысы турында да тәфсилләп сөйли башласаң, сүзең озынга китәр. Ә бу егет төбенә төшмичә туктамаячак. «Аңа «Почемучка» кушаматы гына аз. Булат бер ябышса, талпан кебек!» ди Донгузов аның турында. Сәетгали, өстән-өстән генә булса да, аңлатырга тотынды.

– Бу очракта, бораусны турбинасы белән өзеп калдырырга туры киләчәк. Ә аның өчен забойга торпедо төшереп шартлатырга. И аннан соң бер якка авышып бораулауны дәвам итәргә була.

Булатның күзләре очкынланды.

– А-а, алай итеп тә буламыни, Сәетгали абый? – диде.

Сәетгали, гадәттәгечә, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп алды.

– Ни чарадан бичара дигәндәй, бик кыен булса да мөмкин инде, була.

Аларның әңгәмәсен тыңлап торган Зиннур, белдеклеләнеп, сүз кыстырып куйды.

– Бик теләсәң, чалбарны да баш аркылы киеп була ди. Так что...

Помбурның сүзләре Булатның бер колагыннан керде, икенчесеннән чыгып очты. Аңа Сәетгали абыйсы сөйләгәне күпкә кызыграк иде.

– Мастерлары сез әйткәннәрне беләме икән соң?

– Ә мин Николайны күрдем инде. План бүлегенә отчёт биреп чыкканда, ул да конторада бүлмәдән бүлмәгә кереп чабулап йөри иде. Киңәшләр бирдем.

Егет шуннан соң гына җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй тынычланып калды.

* * *

Буровойда иң өлкәне – Баязит. Дистә елдан артык инде Сәетгали белән алар бер арбада. Нефть эзләү хезмәтенең күп кенә борчу-мәшәкатьләрен дә, шатлыклы мизгелләрен дә бергә кичерделәр. Сәетгали аңа үзенә ышанган кебек ышана. Шулай да, доганы укыган саен савабы арта дигәндәй, вахтага баскан хезмәттәшен кисәтте:

– Дустым, проект тирәнлегенә җитеп киләбез. Аңлыйсыңмы? Соңгы метрлар булырга мөмкин. Зинһар, су белән саграк кыланыгыз инде, ярыймы! Күршеләрнең хатасын кабатлый күрмәгез!

Баязит, ризалыгын белдереп, җиңелчә генә баш кагып куйды. Олпат ирләрчә салмак адымнар белән эш урынына – платформа күперчеккә менеп басты.

Элегрәк Сәетгали аны укырга да кыстап караган иде дә:

– Миңа хәзер кырык биш яшь. Оныклар белән әвәрә килер вакыт җиткәндә, нинди уку инде ул? – дип кул гына селтәде. Ә үзе буровой эшенең бөтен нечкәлекләрен дә белә. Хет бүгеннән мастер итеп куй, югыйсә.

Сәетгалигә эш барышын көннекен-көнгә журналга теркәргә кирәк. Ул вышкадан арырак урнашкан будкага кереп китте. Стеналарда киләчәктә оҗмах тормышы вәгъдә иткән лозунглар, битен-күзен сакал-мыек баскан юлбашчыларның саргаеп беткән, сабый төчкерсә дә, нидәндер өреккәндәй калтырап куя торган портретлары, дөньяда гаме булмагандай, һаман элеккечә сыңар кадакта эленеп тора иде. Сәетгалигә лозунгларның «Партия торжественно заявляет: что нынешнее поколение советских людей будет жить при коммунизме!» дигәне ошамый. Бик тиз бит! Бик тиз!

Җиңел генә табылган малның кадере булмаган кебек, коммунизм дигәннәренең дә кадере булырмы? Коммунизмга чыгабыз, дип эшләмичә, бот күтәреп ятсаң, кем сине ашатыр? Әби әйтмешли, эшләмәсәң эш көне – ни ашарсың кыш көне? Тешсез әбекәйнең сүзе бер колхозчылар өчен генә түгел, барча гавам өчен дә пәйгамбәр хәдисләре кебек. Буш хыяллар белән генә рухланып ерак китә алмассың... Лозунгларның «... догоним ... перегоним Америку...» дигәне дә бар.

Яшьләр, авыз күтәреп:

– Куып җитәрбез, узып китәрбез
Американы якын елларда,

– дип җырлап йөриләр дә ул. Ә менә ничек куып җитәргә дә, ничек узып китәргә? Бу минутларда ихтыярсыздан Сәетгалинең хәтеренә халык арасында таралган:

– Американы куып җитәргә ярый. Ләкин узып китәргә ярамый. Чөнки безнең артыбыз шәрә. Оятка калырбыз! – дигән мәзәк килеп төште.

Ул, гадәтенчә, сизелер-сизелмәс кенә, үзалдына елмаеп куйды.

Ярар, болар турында югарыдагылар баш ватсын. Һәркемнең үз эше.

Сәетгали өстәл артына барып утырды. Өстәл янында «смирно!» басып торган шкафтан, үрелеп, көндәлек эш журналын алды. Журналга тотынганчы, егетләре бораулаган метрлар турында уйлады. Миллион еллар элек җир куенында барлыкка килгән токымнар серләрен җиңел генә теләсә кемгә ачмаган. Аларга кадәр дә, айлар, еллар буе көчәнеп тә, буш кул белән, тәртәләрен кире борганнар булган бит.

Сәетгалиләр, шөкер, проект тирәнлегенә җитеп киләләр. Керн үрнәкләре дә өметләндерерлек. Ходай кушса... шулай да шикләндерә.

Сәетгали эш журналының кирәкле битен ачты. Фикерләрен туплап, тәүлек эчендә башкарган эшләрне барларга тотынды.

Ул арада кемнеңдер, будка баскычын дөбердәтеп, кабалана-кабалана күтәрелгәне ишетелде. Йә Аллам! Мастерның күңелен шөбһәле уйлар өермәсе биләп алды. Корт чаккыры! Буровойда бер-бер хәл булган ахры?! Ул кулына каләмен тоткан килеш катып калды. Нинди хәбәр алып килер бу аяусыз дөпелдәгән адымнар? Будкага ук кебек атылып, авызы колагына җиткән Булат килеп керде.

– Сәетгали абый, сөенче! Нефть чыкты бит! Нефть!!! Нефть чыкты!!!

Егет эчендә кайнаган шатлык хисләрен тыеп торырлык халәттә түгел иде. Ул, бала-чага шикелле, кулларын баш өстендә болгый-болгый, үрле-кырлы сикерергә тотынды...

– Нефть чыкты!!! Нефть!!!

* * *

Урман буендагы юлдан җилдереп килә торган җиңел машина күренде. «Җилдерә» сүзе бу очракта, бәлки, туры килмидер дә. Чөнки юл тигез түгел – ат юлы гына. Чокырлы җирләрдә машина күздән югалып тора да, уйсулыкны үткәч, калкавыч сыман калкып чыга. Йөртүчесенең моңа исе китми ахры, каядыр ашыккандай, машинасын «чыбыркылавын» белә. Тигез җирләрдә машина, чыннан да, ярыйсы гына җилдерә.

Шофёр янәшәсендә утырган план бүлеге инженеры Любовь Степановна ерактан ук вышка тирәсендә кешеләрнең күплегенә игътибар итте. «Шайтан алгыры! Авария булган ахры. Өч сменаны да аякка бастырганнар. Ике көн элек кенә «48 нче»дә булганы җитмәгән. Инде тагын?! Горшковныкылар өчен дә бер кочак аңлатма яздырганнар иде. Чүп өстенә чүмәлә – монда тагын...» – дип башын чайкап алды. Гадәттән тыш хәл – ЧП, ул бер буровой өчен генә түгел, тулаем идарә өстенә кара тап булып төшә. Югарыдагылар да, шуны искәртеп, «чеметеп» алырга яраталар. Әмма вышкага якынлашкан саен, аның фаразлары иртәнге томан сыман әкрен генә тарала башлады. Чөнки чырайлары кырысланган, борчылып тәмәке пыскыткан яисә инструмент күтәреп тыз-быз йөгерешкән кешеләр дә күренми. Киресенчә, бораулаучыларның йөзендә елмаю, нәрсәгәдер шатлану чалымнарын шәйләргә була иде. «Әһә! – дип

фаразлады ханым, – болар үзләренең беренче урынга чыкканнарын каяндыр ишетеп алганнар да шуңа шатланалар инде». Ханым, аларның куанычына сөенеч өстәмәкче булып, машинадан чыгуга, төрелгән ватман кәгазе «Яшен»не җәеп җибәрде.

– Менә, күрәсезме, ниһаять, сезгә дә бәхет елмайды. Сезнең «47 нче» вышка самолётта оча! Ә ташбакада...

Ханымга җәелеп китәргә ирек бирмәделәр.

– Любовь Степановна, безгә хәзер самолёт кына аз. Безнең вышканы космик ракетага утыртып ясарга кирәк иде. Күрмисезмени, Баязит вахтасы егетләренең кыяфәтен?!

Ханым шунда гына вышка-манараның кыл уртасында скважина өстендә эш киемнәре лыч булып нефтькә баткан кешеләрнең ургылган җир маен туктатып йөрүләрен абайлап алды. Сәетгали дә шулар арасында кайнаша. Ир уртасы булып килгән мастерның йөзе бүген май кояшыдай балкый иде.

– Нәрсә, Сәетгали Исламович, чыганакка туры килдегезме? Әллә инде мәйданга тап булдыгызмы?

Геологлар зур булмаган нефтьле урынны чыганак дисә, зуррагын мәйдан, диләр. Ә тагын да зуррак мәйданны билгәнен, башларын югары чөеп, нефть ятмасы, дип атыйлар.

Сәетгали башын күтәрде:

– Анысын геологлар әйтер инде, Любовь Степановна. Безнең өчен иң мөһиме: йокысыз төннәребез заяга узмады. Нефть табылды!

Ханым, беркавым эшне күзәтеп торганнан соң, һушына килеп, мастер Сәетгали Сабиров җитәкләгән «47 нче» буровой эшчеләренә социалистик йөкләмәдә каралган премиягә приказ әзерләп, иртәгә үк директорның өстәленә куярга кирәк, дип, күңеленә беркетте.

Монысы фаразламыйча да хәл ителә торган мәсьәлә иде.

***

Ургылган нефтьне туктату өчен байтак вакыт китте.

Булат, смена бетүгә, тиз генә юынып алды да, ашыга-ашыга, чиста киемнәрен киде. Көзге алдында кыяфәтен тәртипкә китерергә тотынды.

– Син нәрсә, бүген ураза что ли? Чәй дә эчмичә кая ашыгасың?

– Бүген Суыксуда концерт була. Казан артистлары килгән. Соңга калам.

– Боксёр перчаткаларыңны да ал инде. Суыксу егетләре тагын күзеңне күгәртеп кайтармасыннар.

Булат, исе китмәгән кыяфәттә, кулын селтәп куйды:

– Ә без егетләр белән аңлаштык инде.

Булатның концерттан бигрәк Гөлгенәне күрәсе, тизрәк нефть табылу шатлыгы белән уртаклашасы килә иде. Сөйгәнен сөендерерлек икенче зур шатлыгы да бар егетнең. Сәетгали абыйсы аны ялга киткән Зиннур урынына помбур – ярдәмче итеп куйды. Булат өчен бу зур вакыйга! Аның хыялына таба ышанычлы да, өметле дә бер адым иде...

Егет бүген гомердә булмагандай чиксез шат. Җир-Анабыз, куенында миллион еллар саклаган бер серен ачты! Булат Суыксуга таба әллә атлый, әллә йөгерә, әллә хыялында очып бара иде. Ул урман яңгыратып җырлап җибәрде...



*Фәридә Айдарова 1973 елда Әгерҗе районы Кадыбаш авылында туа. Урта мәктәптән соң Чаллы дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлый. 2002 елда «Иделем акчарлагы» яшь язучылар конкурсында катнаша. Әгерҗедәге «Күңел чишмәләре» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. Хәзерге вакытта Әгерҗедә яши, 4 нче урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта.*

Фәридә
Айдарова

# МИН ОЧЫШКА ӘЗЕР...

## Кырык бердә туган әти

«Әти», диеп өзелеп әйтер сүзне
Әйталмаган безнең әткәйләр.
Ятимлеккә юлның башы булган
Кырык бердә килгән ул җәйләр...

Инде менә оныклары үскән
Кырык бердә туган улларның.
Әти йөзендә дә чагыла күк
Бар хәсрәте авыр елларның.

Ата фатихасы, ата сүзе
Озатмаган тормыш юлында.
Әнкәсенең таянычы, өмете –
Кырык бердә туган улында...

Сорамагыз берни этиләрдән,
Яшьләнгәнен күреп күзләре.
Олыгая барган саен алар,
Тирәнәя яра эзләре.

## Син китергән хис

Якты иде ул көн –
Беренче кар төште.
Мин очышка әзер –
Гүя канат үсте.

Сиздем: ят итмәдең.
Син башладың сүзне.
Мин көткәнмен икән
Моңлы, уйчан күзне...

Аяз көнем бигрәк
Яктылана төште.
Күңелем дә башка,
Шатлык йөзгә күчте...

Тик аерды юллар,
Язмыш үртәп йөртте.
Күрешүләр көтеп,
Дистә еллар үтте.

Очраштырды юллар,
Үчекләгән төсле.
Онытып булмый сине,
Бу олы хис көчле.

Үзең күргән саен,
Ул хис һаман үсте.
Шигъри юллар булып,
Ак кәгазьгә төште.

Офыгым киң киңен,
Тик очалмам төсле.
Сабыр йөрәк саклар
Син иңдергән хисне...

## Юксыну

Кайтавазы ишетелер, бәлки,
Урманнарга керәм.
Куып тотсын иде, дигән сыман,
Алан буйлап йөгерәм.

Каенлыктан тавыш бирмәсме, дип,
Басу буйлап йөрим.
Әллә калды микән күмелеп, дип,
Ак карларны көрим.

Ялган күз яшьләрен күрмәмме, дип,
Ташуларга карыйм.
Челтер-челтер генә көлә белгән
Гөрләвекне таныйм.

Җәйгә чыксам, ак чәчәкләр җыеп,
Такыя үрәм иртән.
Сабый чагым – иң-иң садә чагым
Юксындыра икән...

## «Сөя, сөйми!»

Өзек-өзек фикри берәмлекләр
Йөгереп үтә күз алдымнан гына.
Акылыңны санга сукмый йөрсәң,
Эләгәсең хисләр тозагына.

Җан иректә чакта уйлар иркен.
Акыл йөри һәрчак янда гына.
Хисләр чоңгылына чуму рәхәт,
Әзер булсаң соңрак газабына.

Чапкын йөрәгемне тыя алмыйм,
Акылыма хисем ирек бирми.
Учкаемда гүя күктән иңгән
Ак ромашка көйли: «Сөя, сөйми!»

## Җандагы җылылык

Җай гына барганда тормышлар,
Йөрәккә ут капты. Ут якты
Бер кайнар карашың.
Ышаныр идемме, әйтсәләр:
«Гомергә ялгызың каласың...»

Шулай да үкенмим, үтенмим,
Үпкәм юк язмышка. Яшәтә
Шул тәүге карашың.
Ярату – бер мизгел булса да,
Гомерлек җылылык аласың!

## Урланган хыял

Аерылганнан бирле, сиңа гына
Сыяр серләр күпме җыелды.
Җәйләр үтте сагыну-сагыш белән,
Яфраклар да инде коелды.

Агачларга бәсләр кунды күпме,
Карлар күмде йөргән эзләрне.
Ничә кышлар, язлар үтеп китте,
Аларның да төсе үзгәрде.

Еллар үткән саен арта гына
Сиңа булган сөю хисләре.
Хыялымны минем көз урлады,
Шуңа моңсу көзнең кичләре.

## Син юклык

Болытлар да күз яшьләрен
Кирәк җиргә генә илтеп коя.
Күңелем тулып түгелергә тора,
Син юклыкны тоя, тоя, тоя.
Арыдым мин, күпме түзеп була?!
Билгесезлек – алда, янда – кыя.
Кыяларга менсәм, болыт булсам,
Тамар идем...
Тик нәрсәдер тыя.

Юк, мин җирдә үксеп ята алмам,
Күңелемә кошлар оя кора.
Алда – гомер, шатлык-сөенечләр,
Очар биеклекләр көтеп тора.
Ә шулай да...
Күкне төпсез, диләр,
Күңел – тирәнрәктер:
Югалтуның бар ачысы,
Ташкыннардай кайнап торган хисләр,
Сагыну, сабыр өмет – бар да сыя.

## Минем дөньям

Минем дөньям – кечкенә бер йортым –
Ерак ара түгел синең өйдән.
Кар көртләрен ерып синңа барам,
Аермагыз шул хәрәкәт-көйдән.

Барам, кайтам, йөрим ике арада.
Сәбәп була кайчак. Сәбәпсез дә!
Кар-күбәләк куна иренемә,
Өмет яфрак яра бөресез дә.

Эре, йомшак ак кар бөртекләре
Дулкын сыман уйнап җанга тула.
Җылы, назлы көйләр кочагына
Атыла да йөрәк, янә тына.

Күрер өчен сине сәбәп җитми,
Эзләмим шул күрмәс өчен чара.
Телгәләнгән җанны җөйләп, гүя,
Араларны күмеп, пакь кар ява.

## Кояшлы буран

Синең килер юлларыңда
Кояшлы буран.
Йөрәгемне учка кысып,
Мин көтеп торам.

Кояшлы буран дөньяны
Акка чорнады.
Йөрәгемнең тынычлыгын
Нигә урлады?

Күңелдә дә, урамда да
Кояшлы буран.
Юл табармы көткәнем, дип,
Шикләнеп торам.

Син килдең дә күз ачкысыз
Буран да тынды.
Күктәге кояш баеды,
Күңелдә – янды...



*Зилә Сабитова 1996 елда Арча районының Шекә авылында туа. 2014 елда Шушмабаш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, КФУның биология факультетына укырга керә. Татар филологиясе бүлегенә күчеп, аны кызыл дипломга тәмамлый. Хәзер шул ук бүлектә магистратурада белем ала.*

*Мәктәптә уку дәверендә төрле иҗади бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулый. Хикәя-язмалары төрле басмаларда дөнья күрә. Мәктәп елларыннан ук «Ялкын» журналының яшүсмерләр редколлегиясе әгъзасы булып тора. Бүгенге көндә – «Ялкын» журналында бүлек мөхәррире.*

## Зилә Сабитова

# ТАНЫШ КЕШЕМ

ХИКӘЯ

*Я со странностями шёл к тебе,*
*а ты со скромностью.*

Г.П.

Нокта. Аны һәрчак җиңел генә өтергә әйләндереп була. Тик бу очракта түгел. Нокта куелды. Каты басып. Йөрәкне өздереп. «Тәмам» дигәнне белдереп.

Каләмен читкә алып куйды. Күзләр бермәлгә яшьләнгәндәй итте. Күңел, үтәли җил искәндәй, ыжгырып алды. Гүя Сөембикәнең күңелендәге иң самими серен – назлы гөлен урладылар да ишек-тәрәзәләрне шыр ачык калдырып чыгып чаптылар. Юк, урламадылар, үзе бирде. Гомере буе кем беләндер серләште ул. Арадашчылары кәгазь булды. Бүген көндәлек үз өстенә авыр йөк алды: соңгы хат язылды. Сөембикәнең соңгы тапшырылмаячак хаты иде бу.

***

Диварда еллар аша килеп, төсен җуйган рәсем эленеп тора: күл буенда зәңгәр күлмәктән бер кыз утыра, күк белән сүз куешып, бертөрле киенгәннәр, күрәмсең. Алдында – мольберт. Аннан да алда бер егет чүгәләгән, кулында фотоаппарат, ахрысы. Тасвирлап бирегез әле шул рәсемне, дисәләр, берәү әлеге эшне шулайрак эшләр иде. Сурәтләвен сурәтләр, тик бу гади генә рәсем артында җан яшеренгәнлеген аңлый алмас иде, мөгаен.

***

Кабан күле буендагы гүзәллек чынбарлыктан башка яссылыкка күчтеме: кыз, күзләрен йомып, тирән итеп сулыш алды. Бар манзара вак кисәкләргә таралды да баш миендә яңадан бер сурәткә җыйналды. Ә инде башта оешкан сурәтнең иге дә, чиге дә юк, кысалар белән кысылмаган, чикләр белән чикләнмәгән ул. Күз, диләр, күрә, диләр, күңелнең ничек күргәнен белмиләр. Сурәт кәгазь куенына чумды...

«Сулыш»ны чыгарып бетереп маташканда, нәкъ аның турысына килеп,

челт-челт фотога төшерә башлаган берәү үзенә җәлеп итте кызны. Сөембикә ирексездән башын күтәрде. Борылуы булды, теге «челт-челт»нең барып төшүе булды. Кызның карашыннан түгел, кисәк кенә сикереп чыккан баканың куркыныч бакылдап җибәрүеннән. Кыз, җәһәт кенә торып, булышырга ашыкты, әмма егетнең кул ишарәсен күрүгә, кире үз урынына кайтты. Чүгәләп, «сулышын чыгарып бетерү»ен дәвам итте. Егет исә, кызга игътибар юнәлтмәскә тырышып, әле бер, әле икенче камышны фотога төшергән булды.

– Гафу итегез, егет сурәтен ясау минем планда юк иде, – диде Сөембикә.

Сөембикә – гади авыл кызы. Йөзе – күңеленең көзгесе аның, ни уйласа, шуны укырга мөмкин. Күңелендә ни йөртсә, шуны әйтте, моның өчен бик еш үкенсә дә, кайчак оялса да, кайвакытларда пешерсәләр дә, күңеленә дә, теленә дә сөзгеч куя алмады, әллә теләмәде генәме?

– Бака оясына арт белән утыру да минем планда юк иде дә, утырдым шул. Тормыш шундый инде: планнарны әледән-әле үзгәртеп торырга туры килә. Бәлки, тормыш шулдыр ул, ә? Син уйлаган һәрнәрсәнең әледән-әле үзгәреп торуыдыр? – дип, көлә-көлә сөйләнде егет.

Кызның ботка болгатырга яратучыларны җене сөймәде. Менә эше белән алдырсын ул кеше. Чыраена язылган инде «татар» дип, ә русча такылдый. Их, бер генә татар кешесен очратасы иде! Татарча сөйләшкән татар кешесен.

Сөембикә «иртәгә тулай торакка урнашырга» дигән көнне Казанга килде. Туганнарында әйберләрен калдырып, яраткан урыны – Кабан буендагы тал төбенә сыенып утырган мәл иде бу...

***

Тулай торакка урнашу, кыз күз алдына китергәнчә, җиңел генә түгел икән, йә бу кәгазь, йә икенчесе җитми. Кыскасы, әлеге көн сессия алдыннан чыныгу алуның яхшы гына чарасы булып чыкты. Монда чаптыралар, тегенे яздыралар. Аш бүлмәсендәге суыткычка әнисе биреп җибәргән ризыкларны урнаштырды да, аһ-ваһ килеп, сак кына «352» дип язылган бүлмәнең ишеген ачты. Беркем дә юк икән. Урындыкка утырып, тын алырга да өлгермәде, бүлмәгә атылып берәү килеп керде һәм кызга сынаулы караш ташлады. Сөембикә, автоматтан аттыргандай:

– Привет! Меня зовут Суюмбикя, а тебя? – дип куйды.

– Сәлам. Алия. Әле ярый рус булып тумаганмын, исемеңне гомер әйтеп бетерә алмас идем, – дип елмайды ул.

– Татар икәнсең әле, никтер рус кызы, әй, марҗа дип торам. (Кыз берсендә «урыс кызы», дип, нәрсәдер сөйләгән чакта, әтисе, чын күңелдән көлеп: «Татарда «урыс кызы» дигән сүз юк, «марҗа» гына бар», дигән иде. Шул вакыттан соң гел үзен-үзе төзәтергә күнекте – башта «урыс кызы», аннан «ой, марҗа», дию гадәте кереп калды).

Алия көлеп куйды.

– Юк, рус түгел, тик син шатланырга ашыкма, мишәр мин, – дип күз кысты. – Ә син чыхым ахрысы?

Сөембикә, аңламаганын белгертеп:

– Ничек дидең? – дип сорады.

– Чыхым. Бездә мишәр булмаган татарны шулай атыйлар.

– Ә-ә-ә, әйе, таныш булыйк – чыхым, – диде дә Сөембикә, чын күңелдән көлеп җибәрде.

– Әйдә, бүлмәне җыештырып алыйк әле, Сөембикә...

– ...Көзгене генә ялтырат та, киттек ашарга. Егетең бармы соң?

– Юк, – диде кыз, күзләрен аска иеп.

– Ә минеке бар. Тик булуына караганда, булмавы яхшырак аның. Менә

«Вконтакте»дан укыдым әле бүген, тыңла: «Ир-ат янында рәхәт булырга тиеш. Мин үзем генә дә начар яши алам», – дигән Мерлин Монро. Шәп әйткән, әйеме?

– Белмим, һәр кеше үз тормышыннан чыгып сөйли. Синең тормышыңа бу сүзләр туры килмәскә дә мөмкин бит.

– Тә-ә-әк, кызый, әйдә киттек ашарга.

– Алия, әйдә, бүлмәдә генә ашыйбыз. Мин үзем дә син килгәнче чыкмакчы идем..

– Ник чыкмадың?

– Анда ни.. Егетләр.

– Әстәгъфирулла! Егетләр? Каян килгән?

– Ыхы. Белмим, каян килгәннәрдер.

– Башларында – мөгез, артларында койрыклары юкмы?

– Юк, – диде кыз, Алиянең ни әйтергә теләгәнен һаман аңлый алмыйча.

– Алайса точно егетләр, җеннәр түгел. Соң ник шаккаттың аларга?

– ...

– Киттек әйдә, нәрсә торасың?! Ел буе бүлмәдә ашамакчы буласың мәллә? Таракан үрчетеп. Рөхсәтем юк.

Кызлар аш бүлмәсенә килеп керделәр. Сөембикә, тычкан шикелле, суыткыч янына йөгерде, анда казына башлады: ризыкларын ала, янәсе. Ул вакытта Алия инде егетләр белән танышып та өлгерде.

Сөембикә Алиянең «Сөембикә-ә-ә», дип сузган тавышыннан соң гына суыткычтан «чыкты»:

– Ә?

– Әһә, – диде Алия, – әнә күрешләр белән таныш.

Сөембикә, алар арасыннан бер таныш йөзне күреп алып: «Ә-ә-ә, без таныш, фотоларны кайчан бирәсең?» – дип елмайды. Искәндәр дә, аны тануын белдереп: «Как только, так сразу, – диде, – ә мин синең исемеңне белмим», – дип өстәде аннан.

– Сөембикә.

– Ниче-е-ек?

– Сөембикә.

– Мин аны беркайчан да әйтә алмаячакмын, ахры, – дип моңайды егет, – ә мин Искәндәр булам.

Алия:

– Да-а-а, монда татар булып туып та, эшләре харап икән әле берәүләрнең, – дип, үзалдына сөйләнде.

Искәндәр:

– Что-то не так? – дип, аптыраулы караш ташлады.

– Нет, нет, всё так.

Аш бүлмәсендә «Сөембикә», «Костя», «Сөембикә», «Кәрим», «танышуыма шатмын» ише сүзләр ишетелеп калды.

***

*«Ул көн әнә шулай үтте. Ә төнгә әле мин озак вакыт параллель, перпендикулярлар үткәрдем. Бар нәрсәнең дә ул чакта ук билгеле булуын бары соңрак кына аңлый алдым...*

*Шигырьләр укыдык. Мин – Такташны, син – Есенинны, мин – Тукайны, син – Пушкин, Маяковскийларны.*

*«Урман кызы» «Письмо к женщине»га салмак кына күчеш алды. Ул шигырьне мин яттан белмим, ә менә аерым-аерым юллары һаман да истә,*

*алай гына да түгел, бу юллар колагымда синең тавыш белән яңгырый. «Вы помните, вы всё, конечно, помните...», «Лицом к лицу лица не увидать. Большое видится на расстоянье...»*

*Я знаю: вы не та –*
*Живёте вы*
*С серьёзным, умным мужем;*
*Что не нужна вам наша маета,*
*И сам я вам*
*Ни капельки не нужен.*

*Живите так,*
*Как вас ведёт звезда,*
*Под кущей обновлённой сени.*
*С приветствием,*
*Вас помнящий всегда*
*Знакомый ваш*
*Сергей Есенин.*

*Син сүзләрен оныттың, мин белгән әсәрем булса, әйтеп җибәрдем, белмәгәне булса, ул сүзне төшереп калдырдык, икенчесе белән алыштырдык, сүттек, яңадан җыйдык. Есенин белән Такташ бу мәхшәрне күргән булса, акылларыннан шашарлар иде. Ә безгә күңелле, безгә кызык. «Яшьлек, гомерең кыска синең...»*

***

– Әле күптән түгел генә Казанның Иске Татар бистәсе халкы хәзерге Бауман урамы урнашкан җирләргә җиләккә йөргән. Бүген исә кеше ул тирәгә кызык эзләп бара. Шуның кебек, кызлар да, булган кашларын йолкып атып, урынына яңасын сыза. Авыл кызы. Табигать. Табигый каш. Ихлас елмаю. Шулай иде. Без яшь чакта. Тик менә, улым, калды микән хәзер андыйлар? – дип сорады әтисе улыннан, бернинди җавап та өмет итмичә.

– Калган, әти, бар берәү.

Әтисе, аңышмыйчарак:

– Ни дисең? – дип, янә сорау бирде.

– Калган, дим. Бар икән берәү. Башланмаган бер ипи булган монда, – диде Искәндәр, ипиле шкафта актарынган җиреннән әтисенә таба борылып.

– Алайса, бүгенгә алмый торыйк инде. Син кайчан Казанга китәсең?

– Иртәгә иртән кузгалырмын. Дәресләр төштән соң гына бит.

***

Сөембикәнең авылдан килеше иде. «Алгы ишектән чыгучылар булса, шофёрга шакыгыз, яме», – диде кондуктор. Кыз янында ике егет бара икән. Берсе икенчесенә: «Кызык булып китте, гадәттә, ишектән кергәндә шакыйбыз, ә монда чыкканда шакырга кушалар», – дип куйды. Шул чакта әллә егетләрнең сөйләшүеннән, әллә кондукторның әйткән сүзләреннәнме елмаеп куйды кыз. Кызыл автобус түгел иде ул, йөрәк иде. Йөрәктән дә бит, чыгар алдыннан, кеше бик нык итеп аның диварларына шакый төсле. Йөрәк түзми, ишекләрен шар ача, «син ирекле», дип «пышылдый», гүя.

Автобустан төште дә тулай торакка таба юнәлде ул. Кулындагы авыр сумкаларын әле чиратлаштырып тотып, әле җиргә куеп торып, тәмам изаланып бетте. Чираттагы шундый тукталыштан соң, сумкаларын янәдән кулына алып, атлый башлаган иде, арттан берәү чабып килеп, аларны тартып диярлек алды. Кыз сискәнеп китте. «Уф, кеше куркытып, син йөрерсең инде», – дип елмайды аннан. «Не, ну а чё, испугалась что ли?» – дип көлемсерәде Искәндәр.

***

Аз нәрсә хәтерендә бүген Сөембикәнең. Ярый әле көндәлеге бар. Күз карасыдай саклый ул аны. Оныклары: «Дәү әни, моны синең музееңа куярбыз инде, име?» – дип көлешәләр әнә. Әллә уйнап, әллә чынлап сөйләшәләр. Аннан икенчесе: «Болай да музей бит инде монда, музей-галерея. Әбекәйнең

бу картиналарын эләр урын калмагач, әрҗәләргә тутырып куйдык бит әнә», – ди. Үстеләр шул, инде оныкларының да олы тормышка басар чаклары җитә, студент еллары үтеп бара.

***

«Я со странностями шёл к тебе, а ты со скромностью...» Әлеге сүзләрне кайдадыр, кайчандыр Сөмбикәгә Искәндәр әйткән иде.

*«Син миңа, мин сиңа килдек. Йөрәкләр якынайгач, борылдык та кире киттекме? Барысы да тыныч, артык тыныч иде. Безгә бернинди каршылык – җил-давыл, яңгыр-буран очрамады. Бәлки, ул чакта шулай артык җиңел булганга җиңелгәнбездер дә. Кеше бит бәхетенә авырлык аша килүчән, җиңел килгән – җиңел китә, диләр. Гомумән, адәм бернәрсәнең дә җиңел булуына ышанмый. Шул чактагы җиңеллек өчен хәзер авыр дадыр да, бәлки. Әмма бу җиңел авырлык. Ул сыта, изә, ә сиңа рәхәт, синең күңелең капкасы шар ачык. Җилләр уйнавы да рәхәт.*

*Синдә булган сәерлек бераз миндә дә бар, миндә булган оялчанлык бераз синдә дә бар иде шул.*

*Син нидер сорагач, мин берсендә «бәлки», дигән идем. Ә син: «А как переводится «бәлки?» – дип сорадың.*

*– «Может быть».*

*– Чынлапмы? Я всё время думал, что это слово переводится как «конечно».*

*– «Конечно» – «әлбәттә» була.*

*– А я ещё типо такой крутой, перед родителями всегда выпендривался, вместо слова «конечно!» говорил «бәлки!», нет, они меня не поправляли, потому что и сами не знали.*

*Ә тагын «бәлки» дигән сүз чыгуга, син бу сүзнең басымын куя алмыйча, дөрес әйтә алмыйча интегә идең:*

*– Бәлки.*

*– БелкИ.*

*– БЕлки.*

*– Бәлки.*

*Ә берсендә без, ни өчендер, ачуланыштык. Мин, гадәтемчә, кичен аш бүлмәсенә чыктым. Син юк идең. Менә берзаман ишек ачылды да, син килеп кердең, кердең дә, ничек сүз башларга белми, аптырап, арлы-бирле йөренә башладың. Мин түзмәдем:*

*– Ник кердең? – дидем.*

*– Су эчәргә.*

*– ...*

*– Һәм сине күрергә...*

*– Сө-ем-би-кә! Мин дөрес әйтергә өйрәндем бугай. Сөембикә! Сөембикә-ә-ә?*

*– Ә?*

*– Ник син, ник син шундый матур?*

*Шул чакта оятымнан кай тишеккә керергә һәм ни дип җавап кайтарырга белми, карашымны аска идем.*

*– Гафу ит, – дидең син. Ә ул чакта мин сиңа ачуланмаган да идем. Үпкәли алмадым...»*

***

*«– Ник соң син гел минем маңгайга карыйсың?*

*– Карамыйм мин синең маңгаеңа.*

*– Син гел минем маңгайга карыйсың.*

*Беләсеңме, ник мин гел анда карый идем? Күзләреңә туры карый алмаганга...»*

***

*«Аралаштык, сөйләштек, бик еш ачуланыштык, яңадан дуслаштык. Чираттагы аңлашылмаучанлыклардан соң булды бу. Алия белән чәй эчеп утыра идек. Син кердең, мин игътибар бирмәскә тырыштым. Аптырап басып тордың да чыгып киттең. Чәй эчеп бетергәннән соң, бүлмәгә керсәм, караватымда өч кечкенә конфет ята. Мин кабат аш бүлмәсенә, Алия янына юнәлдем. Аның белән бергә кергәч, шул ук урында зур «чупа-чупс»ка юлыктык. Шул чакта Алия белән: «Әйдә, тагын бер чыгып әйләник әле, киләсе юлы караватта ни булыр, күз алдына китерергә дә куркыныч», – дип көлешкән идек.*

*Өч көн буе сөйләшми йөргәч, мин үзем сиңа кердем. Каршыңа ук килеп утырдым... Синең, азаплана-азаплана, татарча сөйләшкәнең хәтердә. Мин: «Сөйләш русча, азапланма, дигәч, син: «Татарча сөйләшик, мондагыны икебез генә беләбез бит», – дидең. Бүлмәдә аның бүлмәдәше Кәрим дә бар иде. Ни турында сөйләшкәнебезне төгәл хәтерләмим, бары шушы өзек кенә хәтеремдә:*

*– Алда нәрсә булачак безнең белән? – дидең син, миңа туры карап.*

*– Белмим. Анысын мин хәл итмим.*

*Мин син хәл итәрсең дип уйладым ул чакта, ә безнең өчен тормыш үзе хәл итте».*

***

*«Ә берсендә син озак кына, берни эндәшмичә, миңа карап тордың да: «Ник син миннән гел читләшәсең?» – дип сорадың.*

*Ә мин читләшмәдем, бары үз дөньяма башка берәүне дә кертә алмый тилмердем. Синең исә түземлегең чикле булып чыкты...»*

***

*«Сөйләшүнең монысын аермачык хәтерләмим. Башымда сүзләрнең кыйпылчыклары гына сакланган.*

*– ...со своей девушкой.*

*– С кем?*

*– Ну так со своей девушкой.*

*– Ты так шутишь, да?*

*– Юк инде. Шаярмыйм.*

*– Мин хәзер керәм.*

*Кереп киттем. Миңа һава җитмәде, күз алларым караңгыланды. Яшьләрем тәгәрәде. Кире чыкмасам, ул ни дә булса сизенәчәк. Чыгарга, һичшиксез, чыгарга. Йөземә «берни дә булмады» битлеге элеп кире чыктым.*

*– Кая бардың?*

*– Чынаягым калган ич...*

*– Юк. Син аның өчен чыкмадың, чынаягың юк.*

*– Соң белгәч, ник аны шулай авырттырып сорыйсың? Әйе, аның өчен чыкмадым мин. Йөрәгемә кадалган шырпыны тартып алырга дип чыктым...»*

***

*«...Күп мәртәбәләр син:*

*– Я тебе тогда больно сделал, – дидең.*

*Юк. Син йөрәгемдә үз почмагыңны булдырып, шыпырт кына шунда кереп утырдың. Онытылганда оныттылдың, искә төшкән саен авырттырасың. Кечкенә сабыйлар, кәнфит бирсәң, егылып аягын авырттырганнарын да оныткан кебек, мин дә онытылып китәм кайчакта. Ә инде яңадан искә төшсә-ә-ә...»*

***

Киләсе елда Искәндәрне икенче тулай торакка күчерделәр. Башта бу очрашулар ярты елга бер, аннан елга бер булып, тора-бара бөтенләй тукталды.

*«...Соңгы алты ай эчендә без синең белән өч тапкыр күрештек.*

*Син һаман элеккечә. Ник минем гел маңгаеңа каравым турындагы сорауларыңнан алып, нигә кашларым калтыравы турындагыларына кадәр иде.*

*...31 август. Смс-сөйләшүдән:*

*– Иртәгә ничәнче парага?*

*– Икенчегә.*

*– Беренчегә торсаң үләсеңме?*

*– Үлмәм...*

*Икенчесендә, ялгыш кына урамда очрашкач, син мине чәй эчәргә чакырдың. Ә мин:*

*– Юк, мине кызлар көтә, – дип әйтеп салдым.*

*Әйе, алар мине, чыннан да, көтә иде, тик синең белән очрашуымны көткән хәтле түгел, әлбәттә...»*

***

*«...Алия белән сөйләшкәннәрдән:*

*– Ник соң без аны чакырдык? Икебез генә дә утырган булыр идек әле.*

*– Соң син үзең бит... Әллә кайдан номерын эзләп таптың. Чакырмый идек без аны. Чакыра алмый идек.*

*– ...»*

***

*«...Яраттыммы? Әйтә алмыйм. Бәлки, сабый баланың ияләшүе кебек кенә хис булгандыр. Ияләшү генә булса, ник ул әлегәчә дәвам итә? Ник мине җибәрми, тынычлыкта калдырмый?!.»*

*«...Синең белән очрашу-сөйләшүләрне еш искә төшерәм. Тәнем буйлап җылы йөгерә, авыз читем белән елмая төшәм. Юк, авырлык ясамадың син миңа, юк...»*

*«...Аралашулар берзаман бөтенләй тукталды. Алия генә синең ул марҗа кызы белән араларыгыз бозылуын, аннан икенче берсе белән очраша башлавың турында әйтте...»*

***

*«...Поездымнан сикереп төшеп калырга да, кире кереп утырырга да белмичә, һаман ишекләр тирәсендә таптанучы күршем, дустым, таныш кешем... Бу очрашулар, гомумән, әлеге танышлык кирәк булды микән? Белмим. Әйтә алмыйм.*

*Яралар әледән-әле кузгала. Ә бит рәхәт, шул яраның чемер-чемер килеп яңаруы рәхәт. Авырта. Рәхәт. Я-ра-там, ахры, шул. Бәлки, юктыр да. «Бәлки». «БЕлки». «БелкИ».*

*«Нокта. Аны һәрчак җиңел генә өтергә әйләндереп була, тик ноктаны өтергә әйләндерер өчен куймыйлар».*

***

Укып бетергәннән соң, Сөембикә бер егеткә кияүгә чыгып, аның белән башка шәһәргә күченеп китте. Дус кызы аңа: «Сине яратканга чык. Син яратканга караганда, сине ратулары күпкә мөһимрәк. Менә күреп торырсың, иртәме-соңмы үзең дә аны ярата башларсың, андый кешегә битараф булу мөмкин түгел», – дигән иде. Һәм ялгышмады да кебек. Сөембикә бик тә хөрмәт итте. Тик менә яратты микән?..

# ЗИЛӘ САБИТОВА. «ТАНЫШ КЕШЕМ»

Романтик хикәя, беренче мәхәббәтне искә төшерү тарихы, «кәеф прозасы» үрнәге. Әсәр заманча төзелешле: Сөембикәнең яшьлек хатирәләре һәм соңгы хаты шрифт белән аерып куелган. Мозаика кебек аерым күренешләргә таркалып киткән текст аң-хәтер агышы төсендә, әмма бу таркаулыкны мәхәббәт хатирәсе уяткан җылылык җыңә, тәртипкә-гармониягә китерә: хикәя романтизм калыбында кала. Гомер юлын кичкән Сөембикәнең көндәлегендәге соңгы хаты Искәндәргә кагылышлы булу, диварда эленеп торган рәсем һәм андагы сурәтнең яшьлектә, күл буенда җанлануы мәхәббәтнең кеше өчен бик тә мөһим, бик тә кадерле, гомерлек яшәү көче бирерлек хис икәнлеген ассызыклый.

Рәсемнең һәм вакыйганың кабатлануы – Зиләнең матур табышы. Гомумән, кабатланулар эмоциональлекне арттыру чарасы буларак уңышлы кулланылалар. Әйтик, «бәлки» сүзе белән бәйле кабатлау – шундыйлардан.

Әмма барлык кабатлауларны да урынлы дияргә ярамас. Мәсәлән, хикәягә эпиграф куелган: *«Я со странностями шёл к тебе, а ты со скромностью». Г.П.»* – текст эчендә дә егетнең сүзләре кабатлана. Аның көчле позициягә – эпиграфка чыгарылуы аерым йөкләмә белән бәйле булырга тиеш. Бу очракта, Сөембикә белән Искәндәрнең аерылышуында кызның артык тыйнаклыгы сәбәпче, дигән фикер күздә тотыла төсле. Әмма моны текст эчендә калкытып кую кирәк иде. Дөрес, Зилә әлеге фикерне Искәндәр белән әтисе сөйләшүендә искәртә: *«Авыл кызы. Табигать. Табигый каш. Ихлас елмаю. Шулай иде. Без яшь чакта. Тик менә, улым, калды микән хәзер андыйлар?» – дип сорады әтисе улыннан, бернинди җавап та өмет итмичә».* Тик бу гына текст белән эпиграфны тоташтырып бетерә алмаган.

Гомумән алганда, хикәя тышкы чынбарлыкның күңел дөньясында чагылышы итеп уйланылган. Бүгенге татар әдәбиятында бу язу рәвеше киң таралмаган, әмма яши. Гадәттә, мондый текстлар сүзгә аеруча игътибарлы булуны, алымнарда осталык сорый. Шуңа да әсәрдә хикәяләүнең төрлелеге (эклектика) тәэсирне киметә, Сөембикәнең аң һәм кичереш агымына көйләнүенә – аннан «чыгарга» мәҗбүр итә. Танышу вакыйгасындагы романтик хислелек сөйләшүләрдәге гади сөйләм белән үрелә. Гадәттә, хикәяләүдәге төрлелек дөнья сурәтен тәртипсезлек, хаос буларак тергезгән, ягъни модернистик һәм постмодернистик текстларда кулланыла. Романтизм текстта беркадәр якты сагыш белән өртелгән лириклыкның өстен чыгуын таләп итә. Сөйләшүләр, гади сөйләм кергән өзекләр, әлеге очракта, күзгә азрак чагылса яхшы. Әдәбиятта бу «классик текстларда пафосның тотрыклылыгы» дигән таләп белән бәйле.

Икенче фикер-киңәшебез эчтәлек ягына, төп героиня образына карый. Сюжет Сөембикәне ике вакытта – яшь кыз һәм гомер юлын узган дәү әни буларак тасвирлауны таләп итә. Әмма беренче образ «ярыйсы чыккан», дисәк тә, икенчесе – Сөембикә әби хакында мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Аның кирәк өчен генә кияүгә чыгуы, балалары-оныклары барлыгы, рәсем ясавын ташламавы һәм көндәлекләр алып баруы берничә җөмлә белән хәбәр ителсә дә, Искәндәрдән соңгы тормышы тарихка әйләнмәгән. Уйлап карасак, күпне күргән: кияүгә чыгу һәм балалар, оныклар туу шатлыгын да, гаилә белән аңлашып яки аңлашмыйча, яратмаса да хөрмәт итеп яшәүне дә, һәр кеше гомер юлында очрата торган авырлык һәм хәсрәтләрне кичергәннән соң да, Сөембикәнең бердәнбер якты, соңгы хатта искә төшерерлек хатирә итеп «Таныш кеше»сен санавы, асылда, кеше фаҗигасе (һич югы – драмасы) ул. Өлкән Сөембикәне образ һәм характер буларак эшләп бетерү шушы фаҗигане күрсәтергә мөмкинлек бирер иде. Әмма текстта ахыргы хат һәм яшьлек хатирәсе героиняның аннан соңгы тормыш контекстына ятмаган.

Тагын бер юнәлешне үстерергә мөмкинлек күренсә дә, өзелеп калган мотив бар: ул туган телне белүгә карый. Искәндәрнең Сөембикә исемен әйтергә, татар телендә сөйләшергә күпмедер өйрәнүе, аннары рус кызы белән очраша башлавы эпиграфтагы

«скромность» сүзе белән бәйләнештә ментальлеккә кагылышлы фикер үстерүгә оеткы бирә. Әмма моннан файдаланылмаган. Дөрес, татарлыкның тыйнаклык сыйфаты булуы әйтелә кебек, бу Сөембикәнең «күзләргә карый алмаганга – маңгайга каравы» деталендә сизелеп китә.

Тагын бер тәкъдим – геройларга исем сайлау. Сөембикә – татар укучысы өчен символик исем. Шушы яктан махсус уйнатмаган очракта (мәсәлән, Р.Зәйдулланың шул исемдәге хикәясе моңа матур мисал була ала), аны куллану кирәкми, дип саныйм. Искәндәр исеме турында да охшаш фикер әйтергә мөмкин. XX гасыр татар әдәбияты өчен Искәндәр XX йөз башы әдәбиятында татарлык символы саналган Җәгъфәр кебек үк үзенчәлекле. Г.Кутуйдан соң Х.Туфанның аны лирик герое исеме буларак куллануы мәгъшук герой, иҗат кешесенең җыелма образы дәрәҗәсенә куя.

Хикәянең сөйләме – аерым мәсьәлә. Билгеле бер очракларда Зилә сүзләрдән матур, күз алдына килеп басарлык сурәт ясый белә. Мәсәлән, болай: *«Диварда еллар аша килеп, төсен җуйган рәсем эленеп тора: күл буенда зәңгәр күлмәктән бер кыз утыра, күк белән сүз куешып, бертөрле киенгәннәр күрәмсең. Алдында – мольберт. Аннан да алда бер егет чүгәләгән, кулында фотоаппарат ахрысы»*. Бу сурәт текстның төзелеше-тәртибе белән килешеп тора.

Әмма текст дәвамында сүз белән эшләү җитәрлек түгел. Берничә мисал китерик. *«Каләмемне читкә алып куйдым. Күзләр бермәлгә яшьләнгәндәй итте. Күңел, үтәли җил искәндәй, ыжгырып алды. Гүя Сөембикәнең күңелендәге иң самими серен – назлы гөлен урладылар да ишек-тәрәзәләрне шыр ачык калдырып чыгып чаптылар. Юк, урламадылар, үзе бирде. Гомере буе кем беләндер серләште ул. Арадашчылары кәгазь булды. Бүген көндәлек үз өстенә авыр йөк алды: соңгы хат язылды. Сөембикәнең соңгы, тапшырылмаячак хаты иде бу»*. Әлеге абзацта беренче заттан өченче затка кинәт күчү фикер аныклыгын киметә. Күңелнең «үтәли җил искәндәй, ыжгырып» алуын аңлау читенлек тудыра, чөнки үтәли җил үзе тавыш чыгара. Янәшә җөмләләрдә “күңел” сүзен куллану да бу очракта синоним тапмаганлыктан булып тоела. Инде стильгә кергәнбез икән, көндәлектәге язманы хат дип атау да ризасызлык уята.

Тагын бер өзек карыйк әле. *«Кызлар аш бүлмәсенә килеп керделәр. Сөембикә, тычкан шикелле, суыткыч янына йөгерде, анда казына башлады: ризыкларын ала, янәсе»*. Яшь, матур, тыйнак, яхшы күңелле итеп тасвирланган Сөембикәне бер дә тычкан шикелле, суыткыч янына йөгергән, анда казына башлаган зат рәвешендә күрәсе килми!

Яки Сөембикә хатындагы *«Бар нәрсәнең дә ул чакта ук билгеле булуын бары соңрак кына аңлый алдым...»* дигән сүзләр дә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешеннән читтәлеген раслый: текстта моңа аңлатма-ачкыч юк. Нишләп билгеле булган, кем билгеләгән икән? Язмышмы, холыкмы? Әлеге сорау ачык калган хәлдә, текстта мондый өзек калка: *«Син миңа, мин сиңа килдек. Йөрәкләр якынайгач, борылдык та кире киттекме? Барысы да тыныч, артык тыныч иде. Безгә бернинди каршылык – җил-давыл, яңгыр-буран очрамады. Бәлки, ул чакта шулай артык җиңел булганга җиңелгәнбездер дә. Кеше бит бәхетенә авырлык аша килүчән, җиңел килгән – җиңел китә, диләр. Гомумән, адәм бернәрсәнең дә җиңел булуына ышанмый. Шул чактагы җиңеллек өчен хәзер авыр дадыр, бәлки. Әмма бу җиңел авырлык. Ул сыта, изә, ә сиңа рәхәт, синең күңелең капкасы шыр ачык. Җилләр уйнавы да рәхәт»*.

Әлеге фикерне ничек аңларга? Авырлыкка очрамаганга, мәхәббәт югалдымы? Хәзер авыр булу гомуми вакыйгалар барышындагы якты сагыш белән каршылыкка керә – ни өчен? Шул рәвешле, күп кенә сораулар туа.

Гомумән алганда, Зилә прозада кәеф тудыра белә, моның өчен бик нечкә алым-детальләр белән эшләү сәләте бар. Кәеф артында – олы тормыш тарихы, яшәеш фәлсәфәсе дә ачык тоемланырлык итеп, шушы кәефнең текст буенча саклануын да күрәсе килә.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

# «ИЛ КАПКАСЫН КАГАМ...»

Узган гасырның икенче яртысындагы шигърияттә ике шагыйрьнең бер генә әсәре дә йөрәгем кылларын тибрәндерми калмый. Болар: серле рәвештә фамилия белән дә бәйләнгән Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар. Сүзем каләмдәшләре күңеленә, мишәр катылыгы белән, җанга үтәрлек итеп «бәгърем» дип дәшүчән, Казанга ерак Баулы районының Татар Кандызы авылыннан килеп, шул төбәкнең иң данлы бер улына әверелгән, яшьлегеннән үк соң дәрәҗәдә милләтпәрвәр Рәшит абый – татар поэзиясендә метафорик фикерне үткенләндергән, аңа күпсанлы үзенчәлекле троплар алып килгән зур Шагыйрь турында барыр. Аның, Тукайныкындагы кебек, фикер һәм хис тирәнлегенә, көчле лиризмга ия, халыкчанлык белән сугарылган иҗатында поэтик метафора стиль доминантасына әверелгән иде. Аларның икесен дә Ходай Тәгалә иң мөһим елларда татарның күзен ачар өчен дөньяга китергән кебек. Мөстәкыйль дәүләт, рухи ирек өчен көрәш мотивларын иҗатының умыртка баганасы иткән Р.Әхмәтҗан да һич көтелмәгән вакытта, чагыштырмача яшь килеш, милли хыяллар тормыш киртәләренә бәрелеп имгәнгәнче китте…

Тукай белән Рәшит Әхмәтҗанны поэзиябезнең милли-сәяси эчтәлеген, актуальлеген көчәйтү, татар язмышында зур эз калдырган тарихи-иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны тәэсирле һәм гыйбрәт алырлык тасвирлау, чор тарихын әдәбиятка кертеп калдыру кебек сыйфатлар да үзара якынайта. Һәрберсенең лирикасында борынгыдан килгән уңай әдәби традицияләр чагылыш тапты һәм үстерелде. 1980 елдан «Казан утлары»нда әдәбиятка җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иткән Рәшит абый, әлбәттә, «алтмышынчылар» арасында Г.Тукай исемендәге бүләккә иң лаек һәм аны алдан алырга тиеш кешеләрнең берсе иде, әмма, аерым оешмаларның, тәнкыйтьнең язганнарына игътибарсызлыгы, язмышның мәрхәмәтсезлеге, вакытсыз һәм көтелмәгән үлем аркасында ул әлеге премияне ала алмады. Шушы сәхифәгә теркәлгән бу мөһим фикер аның рухына шатлык иңдерсен, тарихка язылып калсын дип телим.

Р.Әхмәтҗан шигърияткә, Тукай кебек үк, стиль сыйфатлары ачык камил каләм иясе буларак аяк атлый. Аңа кадәр үк бу өлкәдә танылып өлгергән каләмдәшләре дә моны күреп таң кала. Тукай, беләбез ки – контрастлар шагыйре. Р.Әхмәтҗановта тасвирдагы капма-каршылык, андагы дәрәҗәдә булмаса да, шулай ук еш күзәтелә, әмма үзенчәлекле, башкачарак. Ул алдагы иҗат чорларында, тормышның капма-каршы якларын тасвирлаудан битәр, төрле хисләр алып килерлек ситуацияләр эзли, таба, шулардан хис һәм фикер уздыруда уңышлы файдалана. Әнисе, туган ягы, яшьлеге, мәхәббәт, тормышның гомуми барышы… – ни турында гына язмасын, аның каләме сагыш янында – шатлык, шатлык янында сагыш яшәве турында сөйли, йә каршылыклы хисләр тудыра, йә төп хисне аңа читрәк икенчеләре белән өретә.

Күптән түгел генә Тукайның Җаек чоры иҗатын чагылдырып мәкалә язганда, үзем дә әсәрләрендә моңарчы игътибар итмәгән, яшерелеп бирелгән никадәр кыю милли-сәяси фикер барлыгына таң калган идем. Аннан Рәшит Әхмәтҗанов хакында күзәтү мәкаләсе хәзерләргә туры килде. Һәм шулай ук анда да үзгәртеп кору елларына кадәр әйтелмичә калган җөмләләрнең, яшерелгән фикерләрнең, үкенеч хисенең күплегенә шаккаттым. Яшьлектә шагыйрьдән башкарак нәрсәләр эзләп укыйсың, хәзер җитдирәк фикерләр көтәсең һәм игътибарлырак буласың, ахрысы. Бүген без Тукай әсәрләрендә тасвирланган затларның кемлеген ачыклау белән мәшгуль. Күпләре турыдан-туры яисә төрле кушаматлар ярдәмендә аталса да, беришләрен эш-гамәлләре генә ача. Р.Әхмәтҗанов шигырьләрендә дә кемлеге төгәлләштерелмәгән, әмма зур күпчелеккә аңлашылырлык тарихи шәхесләр, тирәлегендәге теге яки бу кешеләр чагылып-чагылып

китә. Мисалга Г.Тукайның «Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын…» сүзләрен эпиграф итеп алган бер әсәрен китерик:

*Казанында кычкыралар:*
*«Камыр булма – тимер бул!»*
*Юк, карышмый. Тик йөрәген*
*Халкынамы бирер ул?*

*Мәскәвеннән ыжгыралар:*
*«Булма камыр – бул тимер!»*
*Шүрәле хәлендә калса,*
*Коткарырга кем килер?*

Югарыдагы әсәрдә илбашының катлаулы сәяси хәле тасвирланган, һәм шул ук вакытта аның кискен хәлләрдәге таянычы бары тик үз халкы гына була алганлыгы да ачык әйтелгән.

Тукай атаклы «Туган тел»е белән татар күңеленә мәңгегә узган. Моның шулай икәнлеге турында Рәшит Әхмәтҗан шигърияте дә ачык сөйли. Аның традицияләрендә тәрбияләнгән шагыйрь иҗатында ана тел мотивы – умыртка баганаларының берсе. Р.Әхмәтҗанның теге яки бу әсәре белән Тукайныкылар арасында анык күзгә ташланмаган башка бәйләнешләр дә бар. Аналарның бишек җырларын чагылдырган әсәрләрен, милли теманы яктырткан аерым шигырьләрен укыганда, күңелдә бу уй тумый калмый. Шул ук вакытта шагыйрь иҗатының текстара бәйләнешләрен кычкырып торган әсәрләр дә шактый. Рәшит абый үзе Тукай сүзләренең Изге китабыбыздан ук тамырланганлыгын күрә:

*Очрыйлар да, шәмаилләр укыйм:*
*Анда Тукай язган шигырьләр…*
*Үз халкына бала гына түгел,*
*Алла була ала шагыйрьләр.*

Кемне тетрәндермәс бу юллар?! Монда Тукайны Бөек Көч янәшәсенә кую да, сүзенең Хаклыгын раслау да, аңа Халык мөнәсәбәте дә, аңа хыял-өметләрен тормышка ашыру да, афәтләрдән саклау да, юл күрсәтүдә ярдәм итә алырлык, әмма ул үзе тудырган Бердәнбер Зат итеп карау да чагылыш тапкан. Шагыйрьнең шушы рәвештә язуы укучыны бераз гына куркытып, имәндереп тә җибәрәдер. Югарыдагы дүртьюллыкта Тукай әсәрләрен Коръән сүзләренә тиңләштергән Р.Әхмәтҗанов вакыт-вакыт аларның тормыш белән каршылыкка керүен дә күрә. «Без – халык» әсәрендә, шулай дип әйтергә дә хокукы булмаган татар турында уйланганда, «Халык – зур», дигән Тукай сүзләрен исенә төшерә, әмма «зур» һәм «кечкенә» төшенчәләренә башка мәгънә сала, зур илдә татарның һаман да түбәнсетелүе – «кечкенәлеге» хакында фикер әйтә.

Рәшит абый гомере буе шахталарда бил бөккән, кайвакыт кара икмәккә дә туймаган татарның һаман йокыдан уянмавына, күзен ачмавына, алдынгы милләтләр рәтенә басарга теләмәвенә гаҗизләнде. Тукай кебек үк, ул да бер алдынгы карашлы татарга йөзләрчә маңкортның каршы чыгуы хакында еш язды. Без аның иҗатында яңа «Печән базарындагылар»ның милләтчеләргә булган рәхимсез бәяләре («Маңкортлар һөҗүме»), чын көрәшчеләрнең «яман уйлы»лардан куркып калмавы белән очраштык («Марат Арсланов монологы»). Ул да, Тукай кебек үк, милләткә хезмәтнең иман эше икәнлеген сөйли: *«Вә билләһи… Илгә ирек яуласак без, / Җир өстендә безнең өчен тәмуг бетә. / Дөньялыкта кылган изге гамәлләрнең / Ияләрен җирдә-күктә оҗмах көтә»*.

Р.Әхмәтҗановта электән килгән дини символикага мөрәҗәгать итү үзгәртеп кору елларына кергәч көчәя. Өммәт, кол, гөнаһ, ант, Хозыр, җиде кат күк… Шактый бай лексик кыр бу. Рәшит абый иҗатында Тукай үз иткән халык теле бизәкләре дә мул, фольклордан күчкән образлар кыры да киң. Тукай һәм Рәшит Әхмәтҗан бәйләнешләре турында сөйләгәндә, һичшиксез, аның әдәби элгәресе күтәргән проблемаларны яңа шартларда яңача эчтәлектә ачуын әйтергә кирәк. Болар татарның язмышы, теленең һәм диненең киләчәге, үзаңының торышы һәм аны уяту гамәлләре турындагы уй-хисләр рәвешендә чагылыш тапты. Әйтик, «Тукайның соңгы рәсеме» – милләтнең үзаңын уяту, үстерү, иманлы итү максаты белән сугарылган көрәш поэзиясенең бер үрнәге. Ул бу көрәштә Тукай иҗатына да өмет белән карый, аның бала чактан

җырланган «Туган тел»е халыкны терелтергә, уятырга сәләтле дип саный («Бергәләп җырлыйк»). Шул ук вакытта шагыйрь үз халкының көрәшче һәм талантлы улларын саклый алмавы өчен газаплана. «Тукайның соңгы рәсеме»ндә, мәсәлән, шагыйрьгә миһербансыз имансызларны битәрләү авазлары яңгырый: *«Карурманнар уртасында калып, / Тарихларның кылын тарткан бар: / Асрамага бушлай бирсәләр дә, / Тукай булгач, шактый сатканнар!»*

Р.Әхмәтҗан әсәрләренә Тукай иҗатыннан аерым гыйбарәләр, истә калырлык троплар бигрәк тә ул яраткан темаларны дәвам иткәндә килеп керә («Казанга хат»). Галимнәр халыкка киң билгеле «Ачлык мәйданында» бик күп образларны Тукайныкылар янәшәсенә куеп карый һәм уртаклыклар таба; кояш, корбан һәм башка символларның үзенчәлекле трансформациясе турында сүз алып бара. Р.Әхмәтҗан әсәрләрендә Тукайда да очраган образларга мисал итеп «Бишташ» поэмасындагы Кисекбашны китерергә мөмкин: *«Күзе бар күк явыз Кисекбашның / Кол Галине эзли / Икенче кат үтерергә теләп, / Эзли – өмет өзми». («Икенче таш»).*

Р.Әхмәтҗанов Тукай исемен, сүзләрен милли азатлык көрәшенең бер атрибуты дәрәҗәсендә күрә. «Сәлим Әбү-Бәкер монологы»нда лирик мин йөрәген һәрвакыт Тукайга якынаерга өнди. Тукай һәм Р.Әхмәтҗановның үзара якынлыгы һичкемдә бәхәс уятмый. Р.Әхмәтҗанов каләменең көче дә Тукайныкы белән тиңдәш – милли рухында, тормышчанлыгында, ихласлылыгында, хисси тирәнлегендә, хакыйкатькә омтылышында, метафоралар тудыру осталыгында. Алар икесе дә – пейзаж һәм гражданлык лирикасы осталары, нечкә лириклар, кыю сүзле публицистлар. Милли рухлы көрәшче шагыйрьгә әверелгән Р.Әхмәтҗан иҗатының төп концепциясе, остазыныкы кебек үк, татар кешесенең җанын, күңел төпкелендә яткан хыял-омтылышларын, киләчәккә бәйле өметләрен ачу максатына барып тоташа.

XX гасырның соңгы чиреге татар шигъриятен яктырткан бер язмасында Т.Галиуллин: «Рәшит Әхмәтҗанов лиризм белән моңсу, заман сынын эчке уйлану рухы белән кушып, шәхеснең кичерешләр дөньясын сурәтләү чаралары ярдәмендә сынландыра. Үз чоры татар поэзиясенең үзәк юлыннан атлаучы шагыйрь Халык тарихы, Милләт, Тел язмышы, Тукай шәхесе турында уйлана, шул төшенчәләрне шигърият чыганаклары итеп калкыта», – ди[1]. Тукайны күтәргән, әдәбият тарихында аның янәшәсендә урын бирүләренә ышанмаса да, Рәшит Әхмәтҗан, милли көрәш яндырган йөрәгенең ахыр чиктә туктап каласын сизгәндәй, татар бәхете өчен җан биреп, аның күңелендә яшисенә өметләнә һәм Газинур Моратка багышланган әсәрендә шушы юлларны яза:

*Бу мәңгелек, кочакларын җәеп,*
*Барчабызны чакырып торса да, –*
*Безнең өчен түгел бөек Тукай*
*Атлап кергән алтын бусага.*

*Без – гадиләр. Безнең шикеллеләр*
*Балкып калса кала бүгеннән.*
*Әйдә, энекәш, тын да алмый бергә*
*Могҗизалар көтик үлемнән.*

*Азатлыкны, бәлки, гомерләргә*
*Алмаштырып ала алырбыз.*
*Исәннәрнең әйтүләре мөмкин:*
*– Безнең белән сез дә калыгыз!*
*– Калырбыз.*

**Рифә РАХМАН**

---

[1] Галиуллин Т. Шигърият офыклары // Татар шигърияте: 1980-2000 еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.



*Чувашстанда татар әдәбияты көннәре. 1984 ел. Рәсемдә (уңнан сулга): Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Риф Гатауллин.*



*Шәүкәт Галиев (алда), сулдан уңга: Камил Кәримов, Илдар Юзеев, Рабит Батулла, Фәез Зөлкарнәй, Роберт Миңнуллин. 1984 ел.*



*Шәүкәт Галиев, Ләбибә Ихсанова, Венера Ихсанова һәм Зәкия Туфайлова.*




*Шәүкәт Галиев (сулдан беренче) бер төркем язучылар белән.*

*Сәхифәне* **Камил КӘРИМОВ** *әзерләде.*

*Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, А.Алиш исемендәге әдәби премия, Г.Х.-Андерсен исемендәге почётлы диплом иясе Шәүкәт Галиев (1928-2011 ) күпкырлы талант иясе иде. Әлбәттә, ул – иң башлап, балалар шагыйре. Аның Шәвәлие, Тимерша-Камыршасы, Котбетдин мәргәннәре әллә ничә буын балаларны тәрбияләде. Ул балаларның эчке дөньясын тирәннән тоеп иҗат итте, шуңа да шагыйрьнең шигырьләре мәктәп укучыларының теленнән төшмәде. Дистәләгән китапларының чын сәнгать әсәрләре буларак уңай йогынтысы бала күңелен баетты һәм але дә баета.*

*Икенчедән, ул – лирик шагыйрь. Аның лирик шигырьләрен туплаган «Сиңа әйтер сүзем бар» исемле соңгы китабы 2008 елда дөнья күрде. Хәер, ул юмор остасы да, фәлсәфи фикерләре белән дә кызыклы шәхес иде.*

*Ә җырлары... Монысы үзе бер дөнья. Алар белән заман агышы да, вакыт җилләре дә хисаплашырлык. Чөнки халкыбыз берсен дә онытмый, түкми-чәчми җырлый бирә... Без дә аларны яңадан бер кат искә төшерүне муафыйк санадык...*

# Шәүкәт Галиев

## Саумысыз, арышларым![1]

Исәнме, иркен кырларым,
Саумысыз, арышларым;
Сез минем сабый чагымнан
Иң якын танышларым.

Еракларда, чит җирләрдә
Нихәтле торып та мин,
Исләремнән чыгармадым,
Сагындым, онытмадым.

Агайлар килсә авылдан,
Сүзне гел сезгә бордым, –
«Игеннәр ничек быел?» дип,
Хәлегезне белеп тордым.

Сезнең өчен сусадым мин,
Яңгырлар яумаса да,
Сызландым, өзелгән башак
Тузанда аунаса да.

[1] Мәсгудә Шәмсетдинова көе.

Сөенәм мин, бүген сезнең
Шаулап үскәнне күреп.
Башыгыздан сыйпыймчы бер,
Юлымнан читкә кереп.

Ятсынмагансыз лабаса,
Куенга үреләсез;
Сез миңа, ничә кайтсам да,
Яшәреп күренәсез.

Исәнме, иркен кырларым,
Саумысыз, арышларым;
Бөтенләйгә булсын иде
Бу кайтып барышларым!

## Утыр әле яннарыма[2]

Оныт мәшәкатьләреңне,
Оныт инде беразга,
Сыйпап-сыйпап чәчләремне,
Бер иркәлә, бер назла.

Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.
Син утырсаң яннарыма,
Ял була җаннарыма.

Йөзләреңә төбәп карап,
Килә бер сөенәсем,
Килә бер иркәләнәсем,
Килә бер сөеләсем.

Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.
Син утырсаң яннарыма,
Ял була җаннарыма.

Күземә ашыгып кына
Салкын карап үтмә син,
Өстәп тор сөю ялкынын,
Гел өсти тор, бетмәсен.

Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.
Мин утырсам яннарыңа,
Ял булыр җаннарыңа.

[2] Ифрат Хисамов көе.

## Раушаниям, бәгърем[3]

Диңгезнең дә була төрле чагы,
Бер давыллап ала, бер тына,
Раушаниям, бәгърем,
Бер давыллап ала, бер тына,
Күңелләрем сиңа омтыла.

Хат-хәбәрең юк бу араларда,
Сәлам әйтми синнән җилләр дә,
Раушаниям, бәгърем,
Сәлам әйтми синнән җилләр дә,
Ансыз кыен ерак җирләрдә.

Акчарлаклар очкан Агыйделдә
Тугайларны ялгыз гизәмсең,
Раушаниям, бәгърем,
Тугайларны ялгыз гизәмсең,
Чәчәкләрне миңа өзәмсең?

## Күпме күзләр күреп онытылган...[4]

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме йөзләр чыккан исемнән,
Күпме сүзләр киткән хәтеремнән,
Ә син һаман, һаман исемдә.

Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем.
Айныдым да, сөенеп туялмыйча,
Тагын сине искә төшердем.

Йөрәгемне, ахры, тутыргансың,
Башкаларга анда урын юк.
Күңелемдә синнән бүтәннәргә
«Сөям» дигән назлы җырым юк!

## Тамчылар тамар чаклар[5]

Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар,
Бергә булган вакытларны
Сәгатьләп санар чаклар.

Кама буйлары тал-тирәк,
Тирәксез җирләр сирәк.
Яшьлек яздай шаулар китәр,
Сөеп калырга кирәк.

[3] Васил Хәбисламов көе.
[4] Мирсәет Яруллин һәм Рифкать Гомәров көйләре.
[5] Фасил Әхмәтов көе.

Таллар уйлана инде,
Бөре уяна инде,
Язларында ялгыз йөрсәң,
Йөрәкләр яна инде...

Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар,
Кадерен белгән кешегә
Минутлап санар чаклар...

## Кыңгыраулы мәктәп еллары[6]

Кошлар да бер шулай таралалар,
Сау бул инде, туган оябыз,
Офыкларга карап очар өчен,
Иңнәрдә без канат тоябыз.

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы, моңлы чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы звонок булсын беренчесе –
Син каршыла безне, зур тормыш!

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Онытылмас кая юл тотсак та,
Сагындырыр таныш чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Алда әле заман имтиханы,
Күп сынаулар әле үтәсе,
Максатларга әле ирешәсе,
Хыялларны чынлык итәсе.

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Киләчәккә безне озатканда
Онытылмас дәртле чыңлавы,
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

[6] Хөснул Вәлиуллин һәм Рим Хәсәнов көйләре.

# ФӘННЕ ГАЛИМНӘР ҮСТЕРӘ...

## ИЛИДА БӘШИРОВАГА 80 ЯШЬ



Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Илида Басыйр кызы Бәширова 1938 елның 23 ноябрендә Оренбург өлкәсе Матвеевка районы Иске Әшер авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1956 елда Оренбург өлкәсе Шарлык районы Яңа Муса авылында унъеллык урта мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар бүлегенә укырга керә.

Әдәбияттан беренче лекциядә Хатыйп Госман, хискә бирелеп, Йосыф кыйссасы турында сөйли башлагач, әле генә авылдан зур калага килгән кыз аптырап кала. Аның Галимә әбисе һәр җомга көн, ак яулыгын бөркәнеп, өеп куйган мендәрләргә сөялеп, әлеге кыйссаны укыганда: «Абыйлары Йосыфны коега салганнар бит», – дип елый торган була. Баксаң, әлеге әсәрне өйрәнү бик җитди фәнни эш санала икән.

Университетта татар теле һәм әдәбияты белән бергә рус теле һәм әдәбияты, диалектик материализм, политэкономия, фәлсәфә тарихы, гарәп теле, иске татар теле, чит тел һ.б. фәннәрдән тирәнтен белем бирелә. Татар теле һәм әдәбиятының төрле тармакларын киләчәктә зур галим булып танылачак Латыйф Җәләй, Якуб Агишев, Хәмит Ярми, Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашева, гарәп телен Мирза Мәхмүтов, политэкономиядән Мансур Абдрахманов кебек шәхесләр укыта. Студент халкы менә шушы кешеләр ярдәме белән милли тел, милли горурлык, талант һәм тырышлык дигән төшенчәләрне аңларга, әйтәсе килгән фикерләрен фәнни итеп язып бирергә, әйтә белергә өйрәнә.

Төркемдәшләренең барысы да диярлек сугыш чорыннан соң яңа тернәкләнеп килгән Казан төбәге татар авылларыннан. Кием-салым, ашау-эчү бөтенесенеке дә бер чама. Стипендиягә яшисе. Студентларның барысы да тырышып укырга кирәклекне яхшы аңлый, иртән сәгать сигездә лекцияләр башлана, кичке унда китапханә ябыла. Илида барлык фәннәрне дә яхшы үзләштерә, төркемдәшләре белән дус-тату яши. Төрле темага караган фикер алышуларда катнашырга да вакыт табыла. Менә Г.Ахунов дигән яшь авторның «Яшьлек яме» повесте, менә Н.Фәттахның «Сезнеңчә ничек?» әсәре басылган, төрле курс студенетлары белән зур залда кызу бәхәс бара. Ике курс алда укыган Фәрваз Миңнуллин: «Кызлар алар минем кебек акыллыларны яратмый, аларга бушкуык матурлар кирәк», – дип, әдәби герой һәм прототип турындагы фикерләрне куерта, җитди сөйләшү бара... Татар хорына йөрү мәҗбүри куелган. Рәшидә апа Җиһаншина җитәкчелегендә драма түгәрәге гөрләп эшли, Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» драмасы сәхнәләштерелә. Үзе дә Оренбург өлкәсеннән булган Рим Кәримов Муса ролен дәртләнеп башкара. Якташы Илиданең туган көненә Муса Җәлилнең өч томлыгын бүләк иткәндә, шагыйрь стиленә туры китереп: *«...Гомерең юлы мәңге онытылмаслык / Яхшы китап кебек язылсын. / Синең арттан килгән буын өчен / Адаштырмас эзләр салынсын...»* дигән теләген җиткерә *(1959 ел, 21 ноябрь)*.

Театрларда бара торган барлык спектакльләргә төркемнәре белән йөриләр. Тукай клубында эзлекле рәвештә үткәрелгән җыелышларның берсе дә калмый. Анда Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Кави Нәҗми, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Шәйхи Маннур, Габдрахман Әпсәләмов кебек тере классиклар чыгыш ясый. Алар белән янәшә үк Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Әхсән Баянов, Илдар Юзеев һ.б. килә. Әлфия Авзалова, Илһам Шакировлар оялып кына сәхнәгә аяк баса. Группаның иң чибәре – Нәкыя туташ – Аяз Гыйләҗев белән тормыш корып җибәрә. Хәзер аңа барысы да «Нәкыя ханым» дип кенә эндәшә. Студент яшьләр заман рухында тәрбияләнә. Алдагы эшчәнлегенә түл җыя. Төркемдәшләрнең күбесе татар халкының мәгълүм шәхесләре буларак танылa: Гарәбстанда укып-эшләп кайткан Илдар Әүхәдиев – гарәп теле белгече; Рим Кәримов – Татарстан Радио комитеты дикторы; Тәлгат Галиуллин – профессор, ректор, декан вазифаларын башкаручы, язучы һәм тәнкыйтьче; Фәрит Йосыпов – мәшһүр диалектолог-профессор, төрек теле белгече; Нәкыя Гыйләҗева – Казан шәһәрендә танылган татар теле укытучысы, өч улын үстереп, халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең алты томлык әсәрләрен туплап бастыручы; Алинә Зәкиева – таләпчән авыл советы рәисе; Равил Сәйфетдинов – шагыйрь, укытучы, дин белгече; Әнвәр Мөхәммәтҗанов (җырчы Сәйдәнең бабасы) – туган авылында хөрмәтле укытучы. Галия, Рәгъдә, Рәхимә, Римма, Руфинә, Гөлниса, Раинә, Гөлфия, Илсөяр, Роза һ.б. кызлар киләчәктә үзләрен балаларга белем бирүгә багышлыйлар. Кызганычка каршы, сугыш чоры балалары булуы үзен сиздерә, күбесе тормыштан шактый иртә китеп бара.

Университетны уңышлы тәмамлагач, И.Бәширова 1960-1963 елларда Куйбышев өлкәсе Камышлы районы Бакай авылында татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1963-1966 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасында белемен камилләштерә.

Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген булачак галим Институтта яңа юнәлеш буларак билгеләнгән татар әдәби теле стилистикасына караган мәсьәләләрне өйрәнүдән башлый. Фәнни җитәкче итеп билгеләнгән Хәлиф Курбатов беренче аспирантына, үзе дә әле яңа гына кызыксынып эшли башлаган, рус филологиясендә кызу бәхәсләр тудырган «Матур әдәбият стиле» темасын тәкъдим итә. «Поэзияне яратасыңмы? Халык җырларын туплыйсыңмы?» – дип сорый җитәкче. «Юк, – дип җавап бирә кыз. – Халык җырларын миннән башка да җыючылар бар. Мин прозаны яратам». «Ярар», – ди җитәкче. – Менә дирекциядә сөйләштек, «Татар поэзиясендә сүз-сурәт» дигән теманы эшләргә кирәк булачак. Бездә Кол Галидән алып Роберт Миңнуллинга кадәр язылган поэзия әсәрләре бар. Тирән суга кермичә, йөзәргә өйрәнү мөмкин түгел, әйдә, йөз, тикшер. Бик актуаль тема. Фикер алышу бара. Ул французларда, немецларда эшләнә башлаган. Шул телләрне өйрәнергә кирәк булыр, Шарль Баллиның хезмәтләрен укы», – дип, фәнни җитәкче үзенең фатихасын бирә. Кандидатлык диссертациясе алты вариантта языла, җиденчесе яклауга куела (1971). Яклау вакытында Уфадан академик З.Ураксин, «Поэтик образлылык» *(Өфе, 1979)* монографиясенең авторы Ким Әхмәтйәновтан, җыр кебек яңгыратып җырларлык бәяләмәләр алына. Пермьнән рус стилистикасы өлкәсендә дан казанган М.Кожина үзенең хуплау сүзен җиткерә. Ә.Юлдашев һәм В.Хаков кебек фән докторлары хезмәтне оппонент буларак югары бәяли, бастырырга тәкъдим итә. Нәтиҗәдә, «Сүз белән сурәт ясау» исеме астында аерым монография дөнья күрә *(Татар.кит.нәшр., 1974, 175 б.)*. Китапта, кешеләрнең үзара сөйләшкәндә, бер-берсе белән аралашу коралы буларак файдаланылган тел берәмлекләренең, шагыйрь иҗатында укучыга сәнгатьле фикерне җиткерү өчен ничек итеп тасвирлау чарасына әверелү ысуллары тәфсилләп тикшерелә; теоретик яктан, сүзне сәнгатьле сөйләм берәмлеге буларак өйрәнүнең методикасы билгеләнә; гамәли планда, татар филологиясендә поэзиянең иң кечкенә берәмлеге булып санала торган, сүз-образ (сүз-сурәт) төшенчәсе кулланылышка керә. Алга таба, галимнең фәнни эшчәнлеге турында фикер әйтелә торган мәкаләләрне, «Сүзләрне энҗеләргә тиңләп...» *(Ф.Юсупов, Мәгърифәт, 1998, 21 ноябрь)*, «Сүз-сурәтнең асылын ачучы» дип башлау гадәткә әйләнә *(Д.Рамазанова, Мәдәни җомга, 2008, 28 ноябрь)* һ.б.

1966 елдан И.Бәширова «Татар мәгърифәтче әдипләрнең индивидуаль стиле» дигән

яңа тема буенча тикшерү алып бара. Чәчмә әсәрләрдә, тезмә әсәрләрдән аермалы буларак, сүз белән сурәт ясалганда, аерым сүзнең мәгънә эчтәлегенең нинди (конкрет яисә абстракт мәгънәле, эмоциональ яисә стилистик төсмерле һ.б.) булуына карaганда, әдипнең вакыйга барышын ничек итеп хикәяләве көчлерәк тәэсир итүе ачыклана. Бу яктан килеп, һәр әдипнең үзенә хас язу осталыгы өйрәнелгәндә, берничә авторның иҗатын туплап карарга да мөмкинлек күренә. Авторның әлеге фикерләре, күләмле мәкаләләр булып, аерым җыентыкларда басыла *(Герой. Стиль. Осталык, 1972; Метод, стиль, жанр, 1976)*. Әлеге эшчәнлекнең бер өлеше «Татар прозасында хикәяләү стиленең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире» дип дөнья күрә *(Татар.кит.нәшр., 1979, 96 б.)*. «Татар әдәбияты тарихы»н язганда, үз урынын ала *(2 т., 1985, б.531-541)*. Хезмәттән аңлашылганча, соңгы йөз ел эчендә иҗат ителгән татар проза әсәрләренең телен тикшергәндә, бер хакыйкать ачыла: телнең сәнгать чарасына «күтәрелү» дәрәҗәсен әсәрнең хикәяләү традициясе һәм аның үсеш-үзгәреше билгели. Сюжетны алып баручы затның укучыга нинди мөнәсәбәттә куелуы, хикәяләү традициясе үсешенең нигезен тәшкил итә. Язучының иҗат үзенчәлеге шушы җирлектә ачыла. Бу юнәлештән караганда, татар мәгърифәтчеләре иҗаты ике төргә бүленә. Беренчесе, К.Насыйри, Ә.Уразаев-Кормаши, Г.Фәезханов әсәрләре кыйссаи әдәбият ысулында иҗат ителә. Әлеге төр хикәяләү төрки-татар телендәге «Кыйссасел-әнбия» (1310), «Нәһҗел-фәрадис» (1358) әсәрләреннән, «...пәйгамбәремез әйде», «...шәйех әйде» яисә «...риваять кыйлгучылар шу илә риваять кыйлурлар ки...» дип, гомум хакыйкатьне укучыга җиткерү максатыннан, авторның «кеше сүзен» сөйләп хикәяләве рәвешендә бара. Икенчесе төр хикәяләү М.Акъегет иҗаты белән башлана. Автор укучыга үзенең йөзен ачып, турыдан-туры аңа эндәшеп, реаль җанлы кеше буларак, әсәрендә сөйләнә торган хәлләрнең кайда, кайчан, ничек баруын тәгаенләп, алгы планга чыга, вакыйганы автор үз исеменнән «үз сөйләме» белән хикәяләп бара. Төрки-татар телендә 500 елдан артыграк дәвам итеп килгән хикәяләүнең ысулы яңартыла. Әлеге яңарыш, билгеле бер үзенчәлекләр белән баетылган хәлдә, З.Бигиев, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Ш.Мөхәммәдов, З.Һади, М.Гафури кебек мәгърифәтче язучыларның иҗатында дәвам итә. Тулаем төрки дөньяда классик әдипләр булып танылачак Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камалның беренче әсәрләрендә, сөйләп бирү дәвам ителгәне хәлдә, Ф.Әмирхан белдергәнчә: «мин кәлимәсе мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертү» (1909) гамәленә, ягъни сөйләгәнгә караганда күбрәк фикер белдерелү, ягъни тасвирлап хикәяләүгә өстенлек бирелә бара. Сүзнең мәгънә эчтәлеге, билгеле бер әсәр өчен генә кирәк булган, өстәмә эстетик төсмер белән баетыла. Сүз сүз-сурәткә әверелә. «Уяну», «Буранда», «Хәят», «Яз башы» һ.б. чәчмә әсәрләрдә хикәяләүнең өченче төре классик әдипләр иҗаты белән башлануы билгеләнелә. Г.Исхакый мирасы туган иленә кире әйләнеп кайткач, әлеге юнәлешнең нәзарияте аның беренче хикәяләрендә үк: «...һәр язылган сүз үз вакыйгаларын тасвиры, авторның үз хәлләрен бәяны улмаз» , – дип, нигезләнгән булуы аңлашыла (1900, 1903). Хезмәт рецензентлар тарафыннан: «...китапта теориягә караган фикерләр, аңлатмалар хезмәтнең кыйммәтен күтәрәләр» *(Ф.Газизова, Соц. Татарстан, 1980, 17 октябрь)*; «...книга И.Б.Башировой характеризуется системным анализом языка художественной литературы. Опыт этой работы может быть успешно использован в литературоведческих и языковедческих исследованиях на материале других тюркских языков, тем более, что тюркская проза имела многих общих черт в начальный период своего становления, а татарская проза конца XIX – начала XX века, как известно, оказала влияние на формирование жанра прозы в ряде других тюркских литератур. В этом плане работа И.Б.Башировой представляет интерес для всех тюркологов-филологов» *(Ф.Сафиуллина. Сов.тюркология. – №5. – с.84-85)*; «... Небольшая монография И.Б.Башировой является первой обобщающей работой о языке художественной прозы» *(М.З.Закиев, 1986, с.230)*, – дигән бәяләмәләр ала.

1981-1985 елларда И.Б.Бәширова, «Сәнгатьле күзаллау һәм аның тәгъбирләнеше» темасы кысаларында, Г.Бәширов, Ә.Еники, М.Әмир, И.Гази, Ф.Хөсни, Г.Әпсәләмов, А.Расих, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, Н.Фәттах, Р.Төхфәтуллин, М.Юныс кебек танылган татар совет әдипләренең хикәяләү осталыгын, сәнгатьле сөйләмен өйрәнә. Фәнни-тикшеренү эшенең нәтиҗәләре күпсанлы күләмле мәкаләләрдә чагылыш таба. Алга таба

олуг әдип Г.Бәшировның кулъязмалары тикшерелеп, «Җидегән чишмә моңы» исемле хезмәт дөнья күрә *(Татар.кит.нәшр., 1995, 114 б.)*. «Казан утлары»нда әлеге хезмәт болай дип искә алына: «...Язучы иҗатын аңлауда, аның нечкәлекләренә төшенүдә, иҗат лабораториясенә кереп өйрәнү һәрвакытта да нык ярдәм итә, тикшеренүләр зуррак нәтиҗәләргә китерә ала. Татар әдәбияты белемендә, Нил Юзиевның «Хәзерге татар поэтикасы» исемле саллы хезмәтен, И.Бәшированың «Җидегән чишмә моңы» китабын исәпкә алганда да, әлеге мәсьәлә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала бирә. Бигрәк тә татар прозаикларының иҗат лабораториясен өйрәнү проблемасы – күтәрелмәгән чирәм хәлендә...» *(Рәшит Фәтхерахманов, 1996. – №10. – 149 б.)*.

1986 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының эш планында, «Татар әдәби теле тарихы» дигән зур тема ачыла. Х.Курбатов, И.Абдуллиннар белән берлектә, И.Бәширова әлеге өлкәдә тикшерүләр алып бара. Тарихи планда караганда, әдәби телне аерым чорларга бүлеп, аерым жанр-стильләре буенча тикшерергә кирәклек күз уңына куела. Бу юнәлештә, гомумхалык теле һәм әдәби әсәр теле дигән күренешләрне аерымларга, әсәрнең жанрына карап, телнең үзенчәлекле кулланылуына игътибар итәргә, әлеге нигездә язма норма һәм вариантлылык кебек яңа төшенчәләрне аңлатырга кирәк була. Аерым авторларның әсәрләре тикшерелеп, күпсанлы мәкаләләр языла.

Әлеге тема белән бәйле рәвештә, 1999 елда галимнең «XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылык» дигән күләмле монографиясе дөнья күрә *(Казан: КДТУ нәшр., 1999. – 576 б.)*. Хезмәтнең төгәлләндерелгән икенче басмасы, «XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: жанр-стильләр, аерым грамматик категорияләрдә норма һәм вариантлылык» исеме астында басыла *(Казан, 2008. – 340 б.)*. Һәр монографиягә берничә бәяләмә языла. Т.Хәйретдинова «Хәзинәләр кайтаручы» дигән мәкаләсендә: «...XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар әдәби теленең барлык стильләрендә, 1900-1917 еллар эчендә, җиде меңгә якын татар китабы, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә чыга торган газета-журнал битләрендә тормыш-көнкүрешнең төрле ягына караган мәкаләләр дөнья күрә. Тик ул хәзинә гарәп графикасында басылган, аны хәзер эзләп табарга, җентекләп өйрәнергә, фәнни яктан аңлатырга кирәк. Илида ханым менә шул эш белән мәшгуль. 20 табактан арткан монографиясе әзер, бастыру юлларын табарга кирәк», – дип язып чыга *(Мәдәни җомга, 1998, 25 декабрь)*. Филология фәннәре докторы Хуҗи Мәхмүтов «Әдәби тел тарихы сәхифәләре» мәкаләсендә белдергәнчә: «...Хезмәтнең керешендә күтәрелгән мәсьәләләр үзләре үк игътибарны җәлеп итә. Кереш болай дип аталган: «XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: табигате, вазифасы, чыганаклары, өйрәнелеше». Димәк, биредә проблеманың куелышы ук яңача һәм үзенчәлекле булып тора. Әдәби телебезнең табигатен билгеләү һәм вазифасын күзаллау мәсьәләләре моңа кадәрге хезмәтләрнең берсендә дә махсус рәвештә куелмаган иде шикелле. «...Әдәби тел» төшенчәсенең моңа кадәр төрлечә аңлатылып һәм өйрәнелеп килгән булуына да бүгенге көн таләпләреннән чыгып объектив бәя бирелә» *(Мәгърифәт, 2000, 8 июль)*. И.Низамов хезмәт турында: «Докторлык диссертациясенә торырлык монография», – дип белдерә *(Мәдәни җомга, 2000, 28 июль)*. Нәтиҗәдә, 2000 елда докторлык диссертациясе яклана.

Бу чорда И.Бәширова үзенең фәнни эшчәнлеген Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасында укыту белән бергә алып бара. 1988 елда ул, татар телендә «Гомуми тел гыйлеме» курсын укыту өчен махсус чакырылып, университетта эшли башлый. Татар студентларына беренче мәртәбә, тел тамгаларының (знак) мәгънәсе, структурасы һәм системасы турындагы ана телендә мәгълүмат бирелә. «Гомуми тел гыйлеме»ннән лекцияләр укыр өчен, курсның чыганаклары барлана, программасы, билетлары төзелә, методик кулланмасы языла *(2003, 3 табак, 5 т.)*. Әлеге тәҗрибәләр белән алдагы фәнни тикшеренүләр өчен ныклы нигез салына. Татар телендә стилистика буенча эшләнгән материал гомумиләштерелеп, «Татар стилистикасының теоретик нигезләре» буенча кулланмалар төзелә (2005), «XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле», «Татар әдәби телендә лингвистик терминология», «Хәзерге татар

әдәби теле: Семасиология» темалары кысаларында махсус семинарлар алып барыла, методик әсбаплар языла (2004). Бу эшчәнлек 1988-2006 елларда КДУның татар теле кафедрасында (соңгы алты ел профессор дәрәҗәсендә), 1995-2001 елларда Татар дәүләт гуманитар институтында дәвам ителә. Студентларның курс һәм диплом эшләренә җитәкчелек, төрле юнәлештәге фәнни хезмәтләргә бәяләмәләр язып, оппонент булырга, ел саен уздырыла торган фәнни конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясарга туры килә.

2001 елдан, Институт планы буенча, «Татар теленең күптомлы академик (тарихи) лексикологиясе» төзелә башлый. Татар телендә лексик-семантик категорияләрнең системасын күзалларга, лексик мәгънәгә караган проблемаларны хәл итәргә кирәк була. И.Бәшировага «Җәмгыять» тематик төркеменә берләшә торган сүзләрне барлау, системага салу, анализлау эше йөкләнә. Әмма башта ул «Лексикада системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» дигән татар лексикологиясендә кул тимәгән теманы эшләп бирергә тиеш була. Нәтиҗәдә, «Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» *(Казан, 2006, 192 б.)* һәм «Татар әдәби теле. Семасиология» дип басыла *(Казан, 2010, 532 б.)* Үз вакытында китапка гомуми лингвистика бүлеге хезмәткәрләре Ф.Сәгъдиева һәм Б.Миңнуллин тарафыннан уңай бәяләмә язылып, ул Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының Югары аттестация комиссиясе (ВАК) исемлегенә кертелгән «Ежегодник финно-угорских исследований» журналында басылып чыкты *(Татарский литературный язык. Семасиология // Ежегодник финно-угорских исследований. Вып. 4. – Ижевск, 2011. – с.166-167)*.

Югарыда телгә алынган хезмәтләрдә татар теленең семасиология тармагына караган проблемалар: сүзнең лексик мәгънәсе, мәгънә эчтәлегенең компонентлары (денотат-сигнификат) һәм мәгънә типлары (конкрет, абстракт, структур); татар лексикологиясендә парадигматик һәм синтагматик, ассоциатив-деривацион һәм когнитив-концепт бәйләнеш-мөнәсәбәтләр; лексик-семантик категорияләрне инвариант-парадигма нигезендә төркемләү кебек, татар телендә әлегә кадәр өйрәнелмәгән яңа мәсьәләләр күтәрелә һәм анализлана. Казан федераль университеты профессоры Илдар Низамов «Нәрсә ул семасиология?» исемле күләмле мәкаләсендә: «...Сүзнең хасияти сыйфатлары бихисап, шуларны тел фәненең кайсы гына тармагы өйрәнми: лексикология, сүз ясалышы, морфология һ.б. Менә шушы фәннәрнең лексик берәмлекне нинди яссылыкта, нинди эчтәлектә анализлавына карап, хезмәтнең кереш сүз сыйфатындагы, «Сүз – телнең универсаль берәмлеге» дигән өлешендә күзәтү ясап, галимә бик кирәкле эш башкара. Югыйсә, әлегә кадәр тел фәне тармакларының сүзне өйрәнүдәге функциональ бурыч-максатлары фәннең үзендә дә ачыкланып бетмәгән. Шуңа күрә телне кулланучыларның еш кына кыенлыкта, аптырашта калуына юлыгып торабыз», – дип, хезмәттә һәрьяктан яңа фикерләр күтәрелүен ассызыклый *(Мәдәни җомга, 2011, 29 июль)*.

2007 елда Институтта гомуми лингвистика бүлеге оеша. Семасиология мәсьәләләрен тикшерү белән бер үк вакытта, И.Бәшировага «Татар әдәби теле тарихы»н язу өчен, авторлар коллективын тупларга, хезмәтнең программа-планын төзергә, фәнни юнәлешнең максат-бурычын, метод-ысулларын күзалларга кирәк була. Мең еллар буена дәвам итеп килә торган татар әдәби теленең, аерым чорларга бүленеп, жанр-стильләре аерымланып, озак еллар буена тикшерелеп, укытылып килүе мәгълүм. Бу очракта, татар әдәби теленең тарихын тикшерү максат итеп алынганга күрә, гарәп графикасындагы язма чыганаклар нигезендә, XIII гасырдан – XX йөз башына кадәрге дәвердә фонетика, морфология, лексикология тармакларына хас булган категорияләренең кулланылыш тарихын күзалларга, анализны тарихи эзлеклелек саклана торган ныклы-дәлилле системага нигезләргә кирәк була. Әлеге юнәлештә, беренче чиратта, татар язма әдәби теленең табигатен һәм вазифасын, гомумтелнең шул ук тармакларына караган структур төзелешеннән нәрсә белән аерымлануын аңлау сорала. Дөрес, әлеге мәсьәләнең нәзарият-теориясе рус-европа һәм төрки тел белемендә көн тәртибенә куелган була. Әлеге нигездә татар теленә мөнәсәбәттә, гамәли якны күзалларга һәм конкрет мисаллар белән анализлап бирү зарурлыгы күренә.

2012 елда галим «Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр: татар әдәби теленең билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше» дигән монография язып бастыра *(Казан, 2012, 255 б.)*. Бу хезмәттә төрки-татар әдәби теленең табигатен һәм вазифасын билгели торган традиция-дәвамчанлыгы, эшкәртелү-шомартылуы, диалектлардан өстенлеге, норма һәм вариантлылык, функциональ-стилистик вариантлылык дигән билге-шартлары, татар филологиясендә аларның өйрәнелеше җентекләп барлана. Шулай итеп, гасырлар буена, төрки-болгар, төрки-болгар-кыпчак, кыпчак-татар, классик иске татар дип атала торган дәверләрен узып килә торган әдәби телнең аерым тармакларына хас булган категорияләре кулланылышының тарихын өйрәнүнең теоретик нигезе салына.

Алга таба «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 1т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык» дигән коллектив монография дөнья күрә *(Казан: ТӘһСИ, 2015, 696 б.)*. Хезмәтнең «Фән буларак татар язма әдәби теле тарихы: теоретик мәсьәләләр» дигән кереше *(8-20 б.)*, иске татар язма әдәби теленең табигате һәм вазифасын яктыртуга багышланган өч бүлекчә И.Бәширова тарафыннан языла. Иске татар язма әдәби теленең, унбиш борынгы һәм хәзерге вакытта яши торган утыз тугыз төрки телнең алтысыннан берсе буларак, иске язулы төрки әдәби телләрнең берсе булуының шартлары билгеләнелә. Бу телнең, Идел буе болгар дәүләтендә төрки-болгар (XI-XIII г.), Урта Идел буе Алтын Урдада төрки-болгар-кыпчак (XIV г.), Казан ханлыгында кыпчак-татар (иске татар теле) (XV г.), XVI гасыр урталарыннан Русия (Мәскәү) дәүләтенең Урта Идел буе төбәгендә, иске татар язма әдәби теле, XVII һәм XVIII-XIX гасырларны узып, XIX гасырның икенче яртысыннан XX йөз башына кадәр, классик татар әдәби теле, үзенең матур әдәбият, дини-рухани һәм дөньяви-фәнни әдәбият, эш кәгазьләре, иҗтимагый-публицистика кебек барлык жанр-стильләрендә, язма традицияне саклаганы хәлдә, һәр регионның җанлы сөйләмә формалары белән баетыла килеп, хәрәкәттә булуы яктыртылып барыла, «төрки» һәм «иске татар теле» төшенчә-атамаларының мәгънәсе аңлатыла *(21-205 б.)*. Хезмәткә эчке рецензия язучы Д.Рамазанова болай дип белдерә: «...Эзлекле традициягә нигезләнеп, татар язма әдәби теленең гасырлар дәвамында килә торган тамырлары ачыклана, үсеш-үзгәреш этапларын төгәл аңларга мөмкинлек бирә. Анализның бай фәнни аппаратка таянып баруы тикшерүнең объективлыгын, нәтиҗәләрнең нигезле һәм чынбарлыкка туры килүен күрсәтә. Татар филологиясендә, беренче мәртәбә, татар язма әдәби телен өйрәнүнең торышы турында бай һәм киңкырлы мәгълүмат бирелә, яңа исем-фамилияләр, яңа хезмәтләр китерелә. Шунысы аерым игътибарга лаек: хезмәттә диапазонлы күзаллый белү, авторның бай мәгълүматлылыгы, язма әдәби телне әдәбият, тарих, дини-рухани чыганаклар белән тыгыз бәйләнештә анализлау, мәгълүм казанышларын фәнни әйләнешкә кертү, бүлекнең фәнни-нәзари әһәмиятен күтәрә. Тел һәм тарихның үзара ныклы бәйләнештә баруы, хезмәткә энциклопедик характер бирә».

Төп тема белән бәйле рәвештә, иске татар язма истәлекләрендә графо-орфографик тәртип, язма традиция, норма һәм вариантлылыкны өйрәнүнең методологик нигезе, максат-бурычлары, төп принциплары һәм аларның хәзерге әдәби тел белән бәйләнеш мәсьәләләре җентекләнә *(206-232 б.)*. Әлеге теориягә нигезләнеп, XIX гасыр – XX йөз башында иске татар язма әдәби теленең фонетик һәм график-орфографик үзенчәлекләре тикшерелә. Хезмәткә гомуми нәтиҗә ясала *(355-637 б.)*.

Коллектив монографиянең, җентекле анализ нигезендә, «Болгар дәүләте чоры...» һәм «Алтын Урда чоры Идел буе төрки-язма әдәби теленең фонетик һәм график-орфографик үзенчәлекләре» бүлекләрен филология фәннәре докторы Ф.Нуриева *(233-325 б.)*, «Казан ханлыгы чоры...» һәм «XVII-XVIII гасырларда иске татар әдәби теленең фонетик һәм график-орфографик үзенчәлекләре» бүлекләрен филология фәннәре кандидаты Э.Кадыйрова тикшерә *(2015, 326-389 б.)*.

2017 елда, шул ук авторлар тарафыннан язылып, «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 2 том. Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләр: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык» хезмәте дөнья күрә *(Казан, ТӘҺСИ, 2017,*

*888 б.)*. Бу томда төрки-татар теленең гомумтеоретик мәсьәләләрен кабатламыйча, иҗат ителгән, шәрехләнгән, күчереп язылган, басылган истәлекләрне тикшергәндә, тарихилыкны билгели торган төп принципны грамматик категорияләр нигезендә аңлатуга игътибар ителә. Бу мәсьәлә графо-орфографик тәртипне тикшерү барышында дәлилләнә: теләсә кайсы чорда язылган әдәби истәлекне тел тармаклары буенча тикшергәндә, тарихилыкны күзәтү эше, әдәби тел тармакларының хәзерге торышына нигезләп башлау зарурлыгы күренә.

Фонетика тармагына мөнәсәбәтле рәвештә, хәзерге татар әдәби телендә кабул ителгән тәртиптә, сузык һәм тартык авазларның табигате һәм вазифасы билгеләнә, татар авазларын хәзерге язуда белдерә торган кирилл хәрефләре алгы планга куелып, гарәп графемалары белән сүз башы, сүз уртасы һәм сүз ахырында ничек күрсәтелүен анализлау, графо-орфографик тәртибен күзаллау өчен, төп принцип итеп билгеләнә. Гарәп һәм фарсы алынмалары катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсенә туры китерелеп язылганга күрә, төрки-татар авазларының ничек итеп белдерелүен өйрәнү төп максат итеп алына. Тикшерүне әлеге нигездә дәвам иткәндә, иске татар телендә язма традиция буларак килә торган норманың эзлекле рәвештә баруын, аның вариантларының ничек һәм ни өчен барлыкка килүен билгеләү мөмкинлеге, ягъни әдәби тел тарихы өйрәнүнең дөрес юнәлештә икәнлеге аңлашыла. Төрки-татар авазларының язылышында, татар теленең ун сузык авазы гарәп теленең өч графемасы белән белдерелгәндә, татар телендәге бер үк тартык авазларының гарәп теленең берничә графемасы белән күрсәтелүенә нигезләнеп тә, шул ук вакытта, төрки-угыз һәм төрки-кыпчак сөйләмә теле үзенчәлекләре чагылуы нигезендә дә вариантлылык хасил булуы ачыла. Иске татар телендә графо-орфографик тәртипнең, ике (гарәп-фарсы һәм төрки-татар) әдәби теленең нормасында баруы күренә. Бу мәсьәләләр татар филологиясендә беренче мәртәбә яктыртылу таба.

Монографиянең икенче томында да төрле жанр-стильләрендә язылган текстларда файдаланыла торган тел берәмлекләре, хәзерге татар әдәби телендә кабул ителгән нигездә, морфологиянең мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре һәм аларның грамматик категорияләренә мөнәсәбәттә, структур төзелеше-субстанциональ мәгънәсе ягыннан тикшерелә. Шул ук вакытта, язма текстларда аерым функциональ сөйләм тибын барлыкка китерү өчен, махсус рәвештә сайлап алынган чара буларак кулланылуы игътибарга алынып, аларның функциональ-стилистик мөмкинлекләре анализлана. Нәтиҗәдә, грамматик категорияләрнең (һәм форма, һәм мәгънәләренең) традиция-дәвамчанлыгы, әдәби норма, норма вариантлылыгы, функциональ-стилистик вариантлылыкка ия булуы мөмкинлекләре күзаллана. Әлеге нигездә, язма әдәби телне морфологик аспектта анализлауның принциплары тәгаенләнә. Бу томга эчке рецензия язучылар да, хезмәтнең ныклы системада баруын, әдәби язма телнең яңача анализлануын билгелиләр.

Шулай итеп, И.Бәширова җитәкчелегендә язылган әлеге ике томда, татар әдәби теленең матур әдәбият (поэзия, проза, драма жанрлары), фәнни әдәбият, иҗтимагый публицистика, дини-дидактика һ.б. стильләреннән тупланган бай фактик материал, фонетика, графика, орфография өлкәләрендә һәм морфология тармагына караган мөстәкыйль сүз төркемнәренең грамматик категорияләрендә чагылыш таба торган язма традициянең ни рәвешле дәвам иттерелүе, вариантлылык мәсьәләләренең катлаулы табигате һәм вазифасы билгеләнә. Теләсә кайсы төрки телнең тарихын өйрәнгәндә файдалана алырлык метод-ысуллар нигезләнә.

«Татар әдәби теле тарихы» коллектив монографиясенең өченче томында лексик-семантик категорияләрдә язма традициянең дәвамлылыгы, норма һәм вариантлылык мәсьәләләрен кабул ителгән тәртиптә өйрәнү күздә тотыла.

**Бәхтияр МИҢНУЛЛИН, Фәүзия СӘГЪДИЕВА, Рифат МИРХАЕВ,**
*филология фәннәре кандидатлары*

# КЫЗГАН КҮМЕР

## ХӘБИР ИБРАҺИМГА 60 ЯШЬ

Еллар үткән саен, шагыйрьләр төрле әверелешләргә дучар була. Әлбәттә, шигърият кысаларында калып та шәкел һәм эчтәлек җәһәтеннән төрле нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Ләкин еш кына шагыйрь үз иҗатының офыкларын жанрлар хисабына тагын да киңәйтергә омтыла, үзен әдәбиятның төрле өлкәләрендә сынап карый, чәчмә әсәрләр язуга күчә, драма әсәрләре тудыра. Мондый мисалларны күпләп искә төшерергә була. Шунысы кызыклы: әдәбиятның кайсы өлкәсендә казганса да, авторның шагыйрьлеге барыбер күзгә бәрелеп торучан. Әдәбият фәнендә «шагыйрь прозасы» дигән гыйбарә дә бар. Мондый чәчмә әсәрләр, гадәттә, шагыйранә сурәтле тел белән язылган була, алар гаять дәрәҗәдә метафораларга бай. «Шагыйрь прозасы»нда, фабулага өстенлек бирүдән бигрәк, кеше кичерешләре, табигать күренешләре мул тасвирлана.

Әмма шагыйрьләр төрле булган кебек, аларның прозасы да төрле. Арада кызыклы сюжетка корылган, эпик киңлеккә дәгъва иткән әсәрләр дә еш очрый. Аларда шигърият күзгә бәрелеп тормый, ләкин ул бар, ул каядыр төптә, аның көчле агышын боз аша да тоясың.

Хәбир Ибраһимның прозасында бу юнәлешләрнең барысы да күзәтелә.

Әйе, ул, күпләребез кебек, иҗат юлын шигырь язудан башлаган иде. Әле дә ара-тирә шигырьләре матбугатта күренә килә. Шул ук вакытта Хәбир оста прозаик, танылган драматург буларак та татар әдәбиятында үзен таныта алды.

Шунысы гыйбрәтле: шигърияттә ул, кайберләребез кебек, яшьлек юләрлеге, яшьлек гайрәте белән чәчрәп чыкмады. Мәйданга шактый соңарып, утыздан узгач кына аяк басты. Билгеле, ул балачактан ук тезмә язып мавыккандыр. Әдәбият, язу-сызу белән матавыклану, гадәттә, балачак илендә үк пәйда була. Бу, Туфан әйтмешли, «гүзәл гамь», мәдәният институтында укыганда, тагын да тирәнәя төшә, егетнең асылда җенси мәхәббәткә өртелгән уй-хисләре сәтырлар булып куен дәфтәренә бер-бер артлы тезелә тора. Бераздан әлеге интим лириканы укучы хөкеменә тапшыру нияте дә барлыкка килә. Бу – сиксәненче еллар ахыры. Бар шагыйрь-шөгарә, милли азатлык турында хыялланып, ә кайсысы, чүлмәкчедән күрмәкче, нәгърә орган еллар. Кемгә кирәк синең күңелеңнән чәчрәгән саф, илаһи мәхәббәт чаткылары? Актуаль түгел. «Һәр ишектән борды мәхәббәт сакчысы», дигәндәй, Хәбирнең шигырьләре дә газета-журнал битләренә үтеп керә алмый. Алга китеп булса да, шуны әйтергә кирәк: Хәбир Ибраһим беркайчан да конъюнктурага, көндәлек таләпләргә буйсынмады, үзенең күңеле кушканны гына язды. Ул җил искән уңайга авышучылардан түгел. Мөгаен, бу – шагыйрь өчен иң кирәкле сыйфаттыр.

Ләкин бит дөньяга чыгасы да килә! Күңел түрендәге ихлас хисләр белән уртаклашасы килә. Гомере дәвамында һәр шагыйрь үзенә фикердәшләр, хистәшләр эзли.

1990 елда, «Идел» журналы редакциясендә кәгазьгә күмелеп утырганда, бүлмәмә студент еллардагы танышым килеп керде. Хәл-әхвәл сораштык. Эшчеләрнең тулай торагында яшәп ятуы икән.

– Яшь шагыйрьләр күп киләдер монда? – дип сорады танышым, Саба якларында гына туып үскәннәргә хас мәгънәле елмаеп.

– Шагыйрәләр күбрәк, – дидем мин.

– Безнең тулай торакта бер егет тәрбияче булып эшли, шигырьләр яза. – Танышым елмаеп куйды. – Менә шул сиңа күчтәнәч күндерде. – Һәм ул минем алга бераз саргая төшкән «Социалистик Татарстан» газетасына төрелгән кипкән балыклар чыгарып куйды.

– Шул гынамы? – дип сорадым мин, аның үзе сыман елмаерга тырышып.

– Менә шигырьләре...

Кульъязмаларга күз төшердем. Хәрефләре шулкадәр бөтеренке, юллары гаҗәеп тигез – архивлардагы хаттатлар каләменнән төшкән иске язу үрнәкләремени!

*Төнгә чыксам,*
*Төннәр мине яклый,*
*Сердәшләрем алар, кунагым.*
*Үз-үземә бәхет даулый-даулый,*
*Каләм алам кулга.*
*Уйларым,*
*Талгын гына җирдән күтәрә дә,*
*Алып китә мине еракка.*

Шигырьләр миңа ошады. Аларның көчәнеп язылмавы күренеп тора иде. «Уйлары шундый канатлы икән, инде тагын да ераккарак алып китсен», – дип уйладым мин. Күпмедер вакыт узгач, алар журналда дөнья күрде. Ә ул заманда «Идел» 120 мең нөсхәдә укучылар хозурына тарала иде.

Шуннан Хәбир Ибраһим журналыбызның даими авторына әверелде. Шигырьләре генә түгел, «Төштән соң күзгә күренү», «Аһәң» поэмалары да «Идел» сәхифәләрендә укучыларга барып иреште. Чәчмә әсәрләр авторы буларак та ул биредә ачылды. Безне бер-бер артлы хикәяләре, бәяннары белән сөендерде.

Әйткәнемчә, прозада аның диапозоны гаҗәеп киң. «Арыш арасыннан йөгерүче бала» кебек лирик хикәясе искиткеч җылы тоннарда язылган картина сыман тәэсир итсә, «Тояклы җен», «Мохтар һәм Туктар» сатирик бәяннары нечкә каһкаһә, авторның көндәлек тормыштагы һәртөрле тискәре күренешләргә битараф булмавы белән үзләренә җәлеп итә. Хәбир беркайчан да күнегелгән кысалар эчендә бәргәләнми, аның тыелгысыз хыял куәсенә хәйран калмый мөмкин түгел. Ул безнең шактый язучылар кебек «бисәпид» уйлап табу белән дә мавыкмый, аның дөнья әдәбиятын яхшы аңлавы сизелеп тора, әлеге казанышларны безнең әдәбиятта татар холкына яраклаштырып үзенчә файдалана белә.

«Бәхетсез җаннар» романы, «Кәбисә елы» бәяны кебек әсәрләрендә ул халкыбызның хәзерге тормыш итү рәвешен тасвирлап, татар җәмгатьчелегенең киләчәккә бару юлларын чамаласа, «Стефания» кебек әсәрендә җенси мәхәббәтнең олылыгына, сафлыгына дан җырлый, ләкин бу хиснең, күңелләрне яулап алуына карамастан, кайчагында милләтара чикләрне вата алмавына да ишарә ясый. Үкенечле мәхәббәт турындагы бу якты әсәр миңа Иван Бунинның «Караңгы аллеялар» шәлкемендәге кайбер хикәяләрен дә хәтерләтә. Әмма Хәбир һич тә Бунинны кабатламый, ир-егет белән хатын-кыз арасындагы җенси мөнәсәбәтләр нәкъ татарча, тыенкы сөенеч катыш сагыш белән сурәтләнә.

Үзенә хас лиризм, эпиклыкка дәгъва, каһкаһәгә маһирлыгы турында телгә алгач, аның кайбер әсәрләрендә җиңел юмор хакимлек итүен дә әйтми калу дөрес булмас. «Җиденче кияү» (пьеса варианты да бар), «Бәхетле килен», «Язмыш бәрәне» кебек «көләч» бәяннарында Хәбир бөтенләй башка яктан ачыла. Гүя ул – үзенең персонажларына читтән генә карап, мыек астыннан елмаеп торучы Хуҗа Насретдин холыклы авыл агае. Ул беркемне дә гаепләми, һөҗү укларын атмый, чөнки аңлый: кешенең без тискәре дип атаган сыйфатлары да табигый, әлмисактан килгән, монда инде бернишли алмыйсың. Көләргә генә мөмкин. Һәм бу көлү күп очракта үз-үзеңнән...

Биредә Хәбир Ибраһимның драматургия өлкәсендәге уңышларын да телгә алырга кирәк. Ни генә дисәләр дә (янәсе, безнең халык китапта гына басылган килеш тә пьесалар укырга ярата; андый заманнар да булды, тик хәзер болай өздереп әйтеп була микән?), драма әсәре, асылда, сәхнәгә кую максаты белән языла. Автор театрга ни кирәген, халыкның бүген ни көткәнен сиземләргә тиеш. «Мәңгелеккә» өмет итеп язылган пьесалар, гадәттә, авторның архивында кала. Яхшырак тәкъдирдә, җыентыкта нәшер ителеп, киләчәктә дан-шөһрәткә төренүне көтәргә мөмкин. Хәбирне көндәлек темаларга язучы драматург, дип тәнкыйтьләүчеләр дә бар. Янәсе, күктән йолдыз чүпләми. Югыйсә аның егермедән артык драма әсәре сәхнәдә куелган! Төрле профессиональ театрларда. Әле халык театрларында уйналганнары күпме. Ә бит режиссёрлар тамашачы каршында азмы-күпме уңыш казанырдай әсәрләрне генә сәхнәгә менгерергә тырыша.

Проза әсәрләрендә дә Хәбирнең драматург булуын искәрми мөмкин түгел. Аның күп хикәя-бәяннарында фабула анык, конфликтлар кискен, төенләнеш, чишелешләр үз урынында, текстта артык сүз юк.

Хәбир – авыл малае, буразнадан күтәрелгән – орлыкны кибәктән аера белә. Шуңа

күрә дә ул нәкъ менә бүгенге көн язучысы, бүгенге укучы өчен яза, әсәрләрендә заман проблемалары күтәрелә. Киләчәктә ни булыр – анысы Тәңре хөкемендә.

Хәбир Ибраһим иҗатының төп хасиятен бер җөмлә белән әйтүне сорасалар, мин: «Әтисе белән бәхәс, әтисе белән әңгәмә», – дип җавап бирер идем. Аның әтисе Кәбир агай Тау ягында атаклы кеше иде. Дистәләп еллар авылда колхоз рәисе булып эшләгән, совет заманының иң югары тамгасы – Ленин ордены белән бүләкләнгән шәхес. Кырку холыклы, үзенчәлекле фикерләүгә ия кеше иде, мәрхүм. Мин Хәбирнең туган авылы Борнашка кайтканда (шагыйрьнең кем икәнен белергә теләсәң, аның туган ягын барып кара!), ул инде сиксәнне узган бер карт иде. Әмма әле нык, көр күңелле, гәпләшкәндә, гел киная белән сөйли. Мине, машинасына утыртып, элек үзе идарә иткән биләмәләрне күрсәтеп йөрде. Авылдан ерак түгел ул казыткан күлне дә барып күрдек. Бик тәфсилләп үзенең ерактан – Һолландиядән үк түгелме әле! – яхшы токымлы сыерлар кайтартуын сөйләде. Яхшы ук аралашкач, аның тел төбеннән төпчек улының шигырь белән мавыклануына шикләнеп каравын аңладым.

– Рәт чыгарлыкмы соң? – дип сорады ул, миңа сынаулы караш ташлап.

– Хәбир әйбәт яза, – дидем мин, катгый итеп.

– Белмим, белмим, – диде ул, уфтанып. – Мин гомерем буе «Социалистик Татарстан» гәҗитен укыйм. Анда синең статьялар да чыга. Менә моны мин аңлыйм. Ә бу – минем малай – һаман шул кызлар белән кети-кети уйнаганын яза.

– «Социалистик Татарстан» инде шактый еллар «Ватаным Татарстан» исеме белән чыга иде бу вакытта... – Лирика андый статьялардан югарырак бәяләнә. – Мин инде, әлбәттә, үзем кебек үк «тайгак» юлга кереп киткән каләмдәшемне атасы алдында якларга мәҗбүр идем.

– Җитди нәрсәләр белән шөгыльләнергә кирәк, – диде ул, канәгатьсез төстә. – Сез бит инде малай-шалай яшеннән чыккан.

Аны да аңлап була иде. Әлбәттә, ул безнең өлешкә тигән каләм сырлауны чын эшкә санамый, бу аның башына сыймый. Ул бит безнең Тукай түгеллегебезне күрә! Ә инде күз алдында үскән төпчек улы исә кеше куян куа дип, җил куып йөрсә? Ул бит монда, җирдә калырга тиеш иде. Әнә абыйсы Таһир... Инде үзе калхуз персидәтеле булды! Кәбир агай өчен эш ул бүген нәтиҗә бирә торган, умырып башкарыласы хезмәт иде, билгеле. Ә әдәби иҗатны бәяләве дә, үлчәве дә кыен. Әле үлгәнче үз-үзеңне алдап, буш сүзләр сазлыгына батып калуың да бар.

– Балачактан ук ялкау иде, – диде ул, каядыр еракка, офык ягына карап.

– Әткәй сүгә мине ялкау, дип.

– Кеше бар, дип тормый, җитмәсә: *«Бер дә юкка эшкә тотынмас ул, / Эш үзенә килеп тимәсә!»*

*– «Сүзең дөрес, әткәй, өйрәнмәдем / Уйламыйча бәхет отарга. / – Мин өйрәнгән, эчкә сагыш җыеп, / – Кулда кызган күмер тотарга».*

Безнең барыбызның да эчтәге сагышы тора-бара кулдагы кызган күмергә әверелә.

Хәбирнең «И туган йорт!» дигән нәсерендә туган йортка, мәрхүм әти-әнисенә, туган авылына, үз ыруына булган мөнәсәбәте күздән яшь китерерлек сагышка төреп бирелгән ки, Кәбир агай, исән булса, күзен канәгать кысып, ерак офыкка таба карашын ташлар иде. Төпчегенә мактау сүзе әйтергә саран иде шул ул. Андый җылы сүз әйтүне ир-атка хас сыйфат дип санамый иде.

Ике кыз, ике ул үстергән ата кайчандыр өй каршына ике нарат, ике каен утырткан. Каеннарның берсе нигәдер бераз читкәрәк каерылып үскән, ботакларының авырлыгыннан бераз иелеп, бөкрәеп тә тора сыман.

Агачларның да үз язмышы.

«Бу якларны мин бик яратам. Зөя суы, Бола елгасы, Кыз тавы, Яксаз күле, Әдел кизләүләре борын-борыннан килгән изге урыннар. Изге атамалар», – дип язган иде Мөдәррис Әгъләм, Хәбирнең туган авылын, әти-әнисен кайтып күргәч.

Теге вакытта Хәбирнең шигырьләренә өстәп күндергән кипкән балыкларын Мөдәррис әкәгә биреп җибәрдем мин. Ул инде аларның койрыгын да әрәм итми торган кеше иде, бакыйлыкта нишләп ятадыр... Мин үзем исә кипкән балык яратмыйм.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## ШАМИЛ АНАК
(1928-2005)



Шамил Анак (Шамил Гомәр улы Мәхмүдев) 1928 елның 25 ноябрендә Башкортстанның Әлшәй районы Габдрәшит авылында туа. Дәүләкән педагогия училищесында укыганнан соң, М.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетын һәм аспирантураны тәмамлый.

М.Горький исемендәге Әдәбият институтында (1957-1959), Прага университетында да укыта.

1959 елда шагыйрь туган авылына кайта. Моннан соңгы гомерен туган төбәгендә яши.

Шамил Анак поэзиясе – чынбарлыкны сәнгатьле фикерләү аша күзаллап тасвирларга омтылуы, сурәтле образларга таянып, яңа сүз әйтүе, шигъри формадагы тәҗрибәләре, бигрәк тә ак шигырь һәм ирекле шигырь өлкәсендәге эзләнүләре белән үзенчәлекле. Ул – татар, башкорт, рус телләрендә басылып чыккан ике дистәләп китап авторы.

«Тыйнак табын: шигырьләр» *(Казан: Татар.кит.нәшр., 1982), «Сөю тамгалары» (Өфө: Китап, 1988; (башкорт телендә))* – шагыйрьнең төп басма китаплары.

«Шамил Анак ничектер читтә торып, Казаннан еракта яшәп, 60-70 нче еллар әдәби процессына, бигрәк тә Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалимов, Р.Гатауллиннарның эзләнүләренә шактый көчле тәэсир ясый алды. Сүз ирекле шигырьгә, иркен композициягә, тар рамкалардан «коткарылган» образлы фикерләүгә киң таяну турында гына бармый. Шамил Анак иң гадәти, күзгә чалынып, күренеп, туйдырып, ялыктырып бетергән төшенчәләрнең дә поэзия бөрки алуларын исбат итә алды. Юкка гына ул: «Өйрәнсәң иде иң бөек сәнгатькә – сүз ирке сәнгатенә», дими. Нәкъ менә шул сыйфаты белән ул бер буын яшьләр өчен үрнәк булды.

...Ш.Анак поэзиясе – катлаулы күренеш. Аның шигырьләрен бербөтен итеп кабул итәргә кирәктер. Шигырьнең эчке ситуациясе, фикерләү үзенчәлеге бер әсәрдән икенчесенә күчә, образ катламы тулырак ачыла бара. Алар, бер-берсенә сырышып, ятышып, бина булып күтәрелгән блокларны хәтерләтә», – дип яза әдәбият галиме Тәлгат Галиуллин шагыйрь иҗаты турында *(Тыйнак табынга кил, укучы! // Казан утлары. – 1983. – №11. – 141-143 битләр)*.

Шамил Анак – киң мәгълүматлы әдәбият белгече, оста тәрҗемәче. Ул төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең ике шигырь китабын, шулай ук төрек хикәяләрен тәрҗемә итә.

Шамил Анакка 1990 елда Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә.

Ш.Анак – 1969 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

---

[*] Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» *(төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009)* китабы нигезендә әзерләнде.

# ЮГАЛГАН МОҢ

## ХӘТЕРДӘ КАЛГАННАРДАН

Гаҗәп ки, яшь барган саен, күңел сандыгын ешрак ачасың, андагы хатирәләрне ешрак барлыйсың икән. Анда кемнәр генә,ниләр генә юк... Кемнәр белән генә очрашмагансың да ниләр генә күрмәгәнсең?..

Минем кечкенә, малай чак. Үзебезнең авылда, алты почмаклы агач йортның эчке ягында йоклап ятам. Кинәт, колагыма шулкадәр матур, шул ук вакытта күңелләрнең әллә кай җирләрен тибрәтеп, үзәкләргә үтәрлек моңлы итеп җырланган җыр ишетелүдән уянып китәм. Берәү урамда:

*Уфа юллары пыяла*
*Таш булса таймас иде.*
*Минем йөрәккәем яна,*
*Син булсаң, янмас иде лә,*
*Син булсаң, янмас иде...*

– дип өздереп җырлый иде. Мин шушы уянудан таңга кадәр йокыга китә алмыйча ятканымны хәтерлим. Әйе, элек шулай иде шул. Авылларда тормыш күңелле иде. Кешеләр матур, дус яшәделәр. Аларга миһербанлылык, мәрхәмәтлелек, һәрдаим бер-берсенә ярдәмгә әзер тору кебек уңай сыйфатлар хас иде. Яшьләрдә дә көнозын колхоз кырларында, фермаларда эшләп кайтканнан соң, матур итеп киенеп, гармуннар уйнап, җырлый-җырлый, авыл урамнары аша йөри торган күркәм гадәт бар иде. Син, тыныч хезмәт көненнән соң өйдә ял итәргә, йокларга ятасың. Менә бер мәлне ерактан, авылның аргы ягыннан акрын гына гармун тавышына кушылып җыр ишетелгәндәй була. Ул, көчәйгәннән-көчәя барып, синең йөрәгеңне күкрәк читлегеннән атылып чыгарлык итеп дулкынландырып җибәрә, резонанс халәтенә китереп җиткерә дә, бераз дулатканнан соң: «Йә ярар, җитте. Шушы үзәк өздергеч сихри моңнан йә йөрәгең шартлап ярылыр», – дигәндәй, давыл узгач, табигать ничек тынып калса, җыр да авылның башка урамнарына, тагын әллә кайларга: сәхрәләргә, урманнарга китеп югала. Ләкин күңелдәге шушы җыр тәэсире таңга кадәр басылмый, дәвам итә иде.

Мин иртән торгач, әнидән бу җырчының кем икәнен сорап белдем. Ул, күптән түгел Казанга, заманының мәшһүр җырчысы Сөләйман абый Йосыпов белән җырчы булырга киткән Володька дәдәй – Владимир Майоров булып чыкты (псевдонимы – Вәли Майоров). Кунакка кайткан икән дә, авыл яшьләре белән бергә төннәр буена гармун уйнап урам әйләнеп, җырлап йөргәннәр икән ләбаса.

Шуннан соң миңа Володька дәдәйнең җырлавы турында әледән-әле авылдашлар авызыннан ишетергә туры килде. Кемдер аның җырлавын радио тапшырулары аша ишетүен, Зәй шәһәреннән кайтучылар хәтта аны телевизор экраннарыннан күрүләрен дә сөйлиләр иде. Ни сәбәпле булгандыр, үземнең кечкенәдән җыр, музыка сәнгатенә, гармун тавышына мөкиббән китүемнән булды микән?.. Мин бу тыныч та, киң күңелле, ачык йөзле, һәрвакыт елмаеп кына торучан, озын гәүдәле дәдәйне чын күңелемнән хөрмәт иттем. Очрашып сөйләшергә мөмкин һәр очракны

ычкындырмаска, файдаланырга тырыша идем. Күрәсең, аның үзенең да күңеле кечкенәләргә битараф булмагандыр… Ул да мине үзенчә бик якын итте, яратты. Җае чыкканда, авыл малайлары арасында уңай якларымны күрсәтеп, мине мактап, күңелемне гел үстереп тора иде. Концертлар белән районга кайтсалар, Володька дәдәй артист апаларны һәм абыйларны авылга алып килмичә калмады. Мондый вакытларда авылда чын мәгънәсендә зур бәйрәм була. Ул үзенең артист дуслары белән авыл кешеләрен якыннанрак таныштыра, ә алар авылдашларга Казан яңалыкларын, төрле кызыклы вакыйгаларны сөйли иде. Вакыт уза торды, мин дә үсә төштем, шактый гына нәрсәләрне аңлый башладым. Шул, бик тә күңелле, ләкин кыска гына очрашу мизгелләреннән мин Володька дәдәйнең Татар дәүләт филармониясендә эшләвен, аның хезмәттәшләренең кемнәр икәнен белдем. Ә ул кемнәр белән эшләгән бит әле... Легендар җырчылар: Сөләйман абый Йосыпов, Габдулла абый Рәхимкулов, Флёра апа Сөләйманова, Рәйсә апа Тимофеева, Анастасия Васильева (псевдонимы – Нәфисә Василова) һәм Таһир Якуповлар. (Искә алынган җырчыларның Сөләйман абый Йосыповтан башкалары белән баянчы буларак үземә дә эшләү бәхете эләкте.)

Узган гасырның 60 нчы еллар башы. Республикабыз буенча гастрольләрдә йөрүче тынгысыз җырчы – артистларыбыз тырышлыгы нәтиҗәсендә җыр, музыка сәнгатенә шактый гына талантлы яшьләр килүе мәгълүм. Шулар арасында үзенең табигатьтә сирәк очрый торган бас тавышы белән Зәй районы Фёдоровка авылыннан Владимир Константинович Майоров та бар иде. Моңа кадәр ул колхозда көтү көтә. Чаллы шәһәрендә тракторчылар курсларын тәмамлап, колхозда тракторчы булып эшли. Ә соңрак районның халыкны күчмә кино белән тәэмин итү идарәсендә киномеханик була. Район авыллары буенча кино күрсәтеп йөри. Буш вакытларында ул авылда үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә катнашып, үзенең үзенчәлекле тавыш-тембры белән авыл халкы арасында дан-шөһрәт тә казанып өлгергән була инде. Көннәрдән бер көнне район авылларының берсенә Казаннан концерт бригадасы килеп төшә. Араларында күренекле җырчы Сөләйман абый Йосыпов та була. Алар танышып, сөйләшеп китәләр. Владимир Сөләйман абыйга җырлап та күрсәтә. Аның җырлау манерасы, үз-үзен тотышы, тавыш тембры күренекле җырчының игътибарын үзенә җәлеп итә. Бу вакытта Казанда Татарстан дәүләт филармониясенә җырчылар кабул итү буенча комиссия да эшләп килгән була. Сөләйман Йосыпов Владимирны комиссиягә тыңлатып карау өчен Казанга чакыра. Тыңлап караганнан соң, аны берсүзсез филармониягә җырчы буларак кабул итәләр. Шуннан аның кызыклы да, шул ук вакытта җаваплы да җырчы хезмәте башланып китә.

Ул туган ватаныбызның кайсы гына төбәкләрендә булмый да нинди генә сәхнәләрдә җырламый? Татарстанны әйтеп тә тормыйм, чөнки ул Татарстанда үзенең булмаган авылы да юк дия иде. Башкортстанда дисеңме, Чувашстандамы? Яисә чит союздаш республикалар Казакъстан, Үзбәкстаннарда концерт программалары белән чыгыш ясаулар... Кайда гына булмасын, ул татар җыр сәнгатен үстерүгә һәм аны илебез халыклары арасында пропагандалауга өлеш кертә алуына ихлас күңеленнән шатланып, горурланып сөйли торган иде. Чыннан да, әлеге чорларда безгә халкыңны, туган илеңне, туган җиреңне ярату, аның белән горурлану кебек патриотик тойгылар да ят түгел иде әле.

Шулай беркөнне, якынча 1965 елның көзе булгандыр, авылда яшен тизлегендә, Кечтүк дәдәйнең Володькасы кайткан, аны Совет армиясе сафларына алалар икән, дигән хәбәр таралды (әтисе Константинны керәшеннәр шулай атый иде). Көн озын һәм төн буена кыңгыраулар тагылган җигүле атларга утырып авыл яшьләре белән бергә Володька дәдәй Фёдоровка авылының урамнарын әйләнде. Шул кыңгыраулы, җигүле атларның нәкъ менә Володька дәдәй утырганында, аның белән янәшәдә бер кечкенә генә гармунчы малай да бар иде. Ул үз гомерендә тәүге тапкыр, чын осталарга охшатып, тырышып-тырышып, гармун телләрен елатты. Бу мизгелләрдә, шатлыгыннан һәм дулкынланудан үзенең дә йөрәге күкрәк читлегеннән чыгарга җитешкән әлеге малай – бу юлларның авторы – мин үзем идем. Һавада, аерылышу мизгелләренең якынлашуын сиздереп дигәндәй, «Солдат озату» көе тибрәлде. Авылыбыз урамнары аша армия сафларына китү шатлыгы, шул ук мизгелдә вакытлыча гына булса да, аерылу сагышы белән тулы җыр-моң акты. (Ул заманда армия сафларына китү, чыннан да, зур горурлык иде шул.) Ә иртәгесен Володька дәдәйне

хәрби хезмәткә озатырга дип бөтен авыл халкы җыелган иде. Аның, саубуллашып, басу капкасын чыгып, күздән югалганчы:

*Сау булыгыз, минем туып үскән җирем,*
*Сау булыгыз, урман, басу-кырларым.*
*Сау булыгыз, печән чапкан болыннарым,*
*Сау булыгыз, даннар тоткан сабан туйларым,*

– дип, яраткан композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең «Батырҗан» ариясен җырлап китеп баруы минем хәзер дә күз алдымда тора... Володька дәдәйне армия сафларына озату үзе генә дә чын мәгънәсендә театральләштерелгән бер сәхнә әсәре иде. Авылның өлкән буын кешеләре бу турыда әле хәзер дә искә төшереп сөйли.

Армия сафларыннан кайткач та, ул эшен Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә дәвам итә. Филармониядә эшләү дәверендә, җырчы буларак үзенең яраткан халкына чын мәгънәсендә тугрылыклы хезмәт итте. Районлашлар әле хәтерлиләрдер, безнең керәшен авылларында гына уза торган язгы «Торыйсын» бәйрәмендә дусларын җыеп кайткан Володька дәдәйләр, үзләренең җырлары, тамашалары белән ямь өстенә, ямь өсти торганнар иде. Алар белән очрашулар халык күңеленә бигрәк якын иде шул. Ә үземнең, әнием алып биргән яшел төстәге «Шуя» дигән гармунымны уйнап, Володька дәдәйне җырлатканда, миннән дә бәхетле кеше юктыр кебек тоела иде...

Ихтыярсыздан, күңелгә танылган шагыйрь Әнгам Атнабайның:

*Таңнарда гармун уйнама,*
*Моңлы булырсың, балам.*
*Бу дөньяда моңсызлар күп,*
*Ниләр кылырсың, балам,*

– дигән шигырь юллары искә төшә. Ә 1967 елның ахырында, сәнгать коллективларына гына хас «кытыршы» атмосфераны үз итә алмыйча, ул, филармониядән китеп, Чаллы шәһәренең мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый. Кызганыч, табигать тарафыннан бирелгән асылташларыбыз-талантларыбыз тынгысыз кешеләр ярдәме белән ачылса, талантсыз, каты бәгырьле, моңсызлар тарафыннан юкка чыгарыла шул. Володька дәдәй еш кына филармониядә эшләгән елларын сагынып искә алып сөйләсә дә, язмыш әйдәвенә каршы тора алмыйча, 1968 елда Татарстаннан Казакъстанның Алма-Ата шәһәренә китеп бара. Шул сәбәпле, аның җырлары-моңнары Татарстан җирлегендә бөтенләйгә тынып, югалып кала.

Ул Алма-Ата шәһәренең Офицерлар йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый. Ә 1969 елдан Джамбул исемендәге Казакъ дәүләт хор капелласына эшкә күчә. 1972 елда хор капелласының бетерелүе сәбәпле, Владимир Константинович Алма-Ата хәрби округының ансамблендә башта җырчы-солист булып эшли, ә аннан соң пенсия яшенә кадәр ансамбльнең баш администраторы вазифаларын башкара. Озак еллар буена чит җирләрдә яшәп тә туган җиргә, җанга якын моңга мәхәббәте кимеми, ә киресенчә, беренче мөмкинлек чыгуга, ул, гаиләсен алып, Казанга кайтып төпләнә. Хыялында үзенең чордаш, сәхнә дусларын бергә җыеп, Казан сәхнәләрендә «Чордашларга әйтер сүзем бар» дигән концерт программасы белән чыгышлар да ясау иде. Ләкин ачы язмыш үзенекен итә. 2001 елда ул безнең арадан китеп барды. Тормышта ничек тыйнак, йомшак, тыныч һәм гади булса, соңгы юлга да шулай кешеләрне борчымыйча, хәтта күбесенә сиздермичә дә, тыныч һәм гади генә китте дә.

Мин ышанам: Владимир Константинович Майоров үзенең туган җиренә, сөекле халкына тугрылыклы калган кебек, авылдашлары, якташлары, гомумән, халык күңелендә сүнмәс моңнары белән озак вакыт онытылмас әле.

**Геннадий МАКСИМОВ,**
*музыкант-композитор, педагог*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

# ӘМИНӘ

ХИКӘЯ

Менә өзелеп көткән яз да җитте. Бу вакытта табигать кенә түгел, бар дөнья уяна. Әнә бит ничек матур итеп кояш көлә, ул, үзенең нурларын тәрәзә аша миңа сузып: «Әйдә, Язилә, урамга чык!» – дип елмаеп карап тора.

– Язилә, Язилә, дим!

Мин сискәнеп киттем.

– Каргаларны тәрәзәдән өегездә санап утырырсың, ә хәзер мине генә тыңлыйбыз, яме? – дип, укытучы Ләйлә апа уйларымны бүлдерде.

Теләмичә генә алдыма борылдым. Сыйныфташларымның күзе миндә иде. Алар барысы берьюлы көлешергә тотынды. Бигрәк тә нык көлүчесе Әминә икән.

Әминә – чибәр кыз, үзе гел «бишле»гә генә укый. Ул барысына да булыша, һәрберсенә яхшы мөнәсәбәттә. Әмма мине бөтенләй дә яратмый. Элек чын дуслар идек. Безне бернәрсә дә аермас кебек тоела иде, тик... Аның әнисе үлгәч, минем әни белән Әминәнең әтисе өйләнештеләр. Шуннан соң безнең дуслык бетте. Ул мине яратмый башлады, гел түбәнсетте, мыскыл итте. Тик мин аңа гел туганнарча карадым, яхшы «апа» булырга тырыштым. Менә хәзер дә мыскыллы елмаю аша карап торган йөзенә, ничектер, кызганып төбәлдем.

Бүген алтынчы апрель... Өйгә кайтып кердем дә, гадәттәгечә, сумкамны идәнгә атып бәрдем. Бүлмә кап-караңгы, тып-тын. Бу тынлык күңелгә шом сала. Кинәт ут кабынды, зур торт күтәреп, алдыма әни килеп басты.

– Туган көнең белән, кызым!

Мин әнине кочаклап алдым. Без, көлешә-көлешә, аш бүлмәсенә кердек. Анда Әминә өй эше эшләп утыра иде. Ул, башын күтәрде дә, бераз дәшмичә торгач:

– Йөрисез инде монда шаулашып. Өй эшен дә эшләп булмый. Туган көне, янәсе... Эшсезләргә бер сәбәп инде ул, – дип, идәнгә дып-дып басып чыгып китте.

Без әни белән бер-беребезгә карашып алдык. Икебезнең дә кәеф кырылды. Бәйрәмнең яме китте. Әни тортны әкрен генә өстәлгә куйды да:

– Әйдә, кызым, арыгансыңдыр, чәй эчеп ал! – дип, сүзсез генә чәй ясарга тотынды.

Мин, әлбәттә, Әминәнең бу кыланмышларына түзәр идем, әмма, әниемне шулай мыскыл итеп, кәефен төшереп торуы тәмам ачуымны чыгарды. Бүлмәгә кердем дә ишекне бикләп куйдым. Әминә, һич исе китмичә, көзгегә карап утыруын дәвам итте.

– Нәрсә? Бар, бәйрәм ит!

– Җитте, Әминә! Булды! Инде бар чикләрне дә узып барасың! Әйт, нәрсә җитми, ни кыланасың син? Минем сиңа нинди начарлыгым тиде?

Ул кызарынды. Бөтен гәүдәсе белән өстәлгә таянып, әкрен генә торып басты да, кашларын җыерып:

– Ни өчен кычкырасың соң әле?! Әйе, мин сине күралмыйм. Тик сезнең кебек икейөзле түгелмен, турысын әйтәм! Син яхшы булып кыланып йөрисең, ә үзең әтиемне тартып алырга телисең. Әнием инде миннән китте, ә әтиемне сиңа бирмәячәкмен! – дип кычкырды.

Аннан, Әминә, күз яшьләренә буылып, ишекне шапылдатып ябып чыгып чапты. Мин, аптырап, ни әйтергә белмичә, тораташ булып катып калдым.

Төнлә тәмләп йоклап ятканда, әни белән әти уятты. Аларның йөзләренә курку, борчылу чыккан иде.

– Кызым, тор әле, тор. Әминә, әйберләрен җыеп, каядыр киткән. Ай Алла, кайларга гына китеп югалды икән бу бала? Ярабби, нинди гөнаһларым өчен бирдең соң син миңа мондый хәсрәтне? – дип, әни хәлсезләнеп урындыкка ауды. Әти:

– Ярар, әнисе, борчылма, табылыр әле, – дип әнине юатырга тырышты. Ләкин ничек кенә үзен кулга алырга тырышмасын, ул бердәнбер кызы өчен куркуын яшерә алмады. Мин, җәһәт кенә торып утырдым, һәм:

– Әминә?! Киткән?! Кая? – дип, бернәрсә аңламыйча, әни белән әтигә карадым.

Шуннан соң, көчкә һушыма килеп, нәрсә булганын чамалап һәм бернәрсә абайламый, эчке киемнән генә урамга чыгып йөгердем. Елый-елый урам артыннан урам урадым, кичә ни булганын исемә төшереп иреннәремне тешләдем, тагын да тизрәк йөгерә башладым. Менә мин бер тыкрыкка борылдым. Анда, иске капкага сөялеп Әминә басып тора иде. Бар көчемә «очып» диярлек килеп, аны кочаклап алдым. Шешенгән күзләрен төбәп:

– Язилә?! – дип пышылдады ул.

Мин аны күкрәгемә тагын да ныграк кыстым. Яңгырда чыланган юеш чәчләрен сыйпадым. Үзем бертуктаусыз елавымны дәвам иттем.

– Гафу ит, Әминә! Мин башка беркайчан да болай эшләмәм. Менә күрерсең, без әле бик яхшы яшәп китәрбез! Әтиебез дә безне беркайчан да ташламас! Гафу ит, Әминә!

Әминә мине кочып алды. Һәм миңа таба иелеп, шыпырт кына әйтте:

– Син дә мине гафу ит, апам!

Әйе, бу төнне Әминә нык үзгәрде. Әлеге яз бар дөньяны үзгәртте…

**Алинә НАСЫЙРОВА,**
*Әлмәт шәһәренең Р.Фәхретдин исемендәге*
*1 нче гимназия укучысы*

## Әни

Гомерләре куркынычта булып,
Авыр хәлдә калса нәниләр,
Бала өчен, гомерләре белән
Хушлашырга әзер әниләр.

Әни бит ул – иң-иң күркәм кеше,
Күп сынаулар җыйган үзенә.
Кызыллыклар китермичә яшик
Без дә әнкәйләрнең йөзенә.

Якты көздә шундый бәйрәм бүген,
Эндәшәмен һәрбер балага:
Күмәкләшеп, ак бәхетләр телик,
Чын күңелдән Бөек Анага!

**Елена НУЖДИНА,**
*Баулы районы Крым-Сарай мәктәбе укучысы*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Кайгы

– Туфан абый, санаторийга килеп төшкәч үк күргән идем Сезне, ничә көн инде яныгызга килеп сөйләшергә яхшысынмый йөрим. Бу җүләр хатынның сөйләшергә сүзе юк мәллә, бүтән кайгысы юк мәллә, дип көләрсез төсле. Кеше кайгысы кешегә кайгы булып тоелмый бит ул, үз башыңнан кичмәгәч. Авырсынмасагыз, тыңлагыз әле мине, берәр киңәш бирерсез йә берәр сүз әйтеп юатырсыз. Сез бит минем сыман җүләрләрне күп күргән.

Менә миңа карагыз әле, менә янәшәгезгә басып карыйм әле... Сездән әз генә тәбәнәк, әйеме. Бер метр да җитмеш сантиметр хатын-кыз өчен әз түгел инде. Минем ике абыем бар – икесе дә тегермән кебекләр. Өйгә икәү бергә килеп керсәләр, өй кечерәеп кала. Әти шундый иде безнең. Әни дә миннән тәбәнәк түгел. Бабайлар да шундый булган. Нәсел-нәсәбебез эре сөякле.

Ирем дә, Аллага шөкер, гырнадир кебек. Бөтен ишекләрдән дә башын иеп керә. «Жигули» машинабыз бар, шуны алдан да күтәрә, арттан да күтәрә. Ике потлы герне чөеп уйный.

Ике улыбыз бар. Икесе дә аталарына охшаганнар. Икесе дә Сабан туенда көрәшәләр. Авыр үлчәүдә.

Ирем ягыннан бөтен туганнары да әзмәвердәй ирләр. Хатыннары да үзләренә тиң. Кайвакыт бергәләп кунакка җыелабыз, өстәл артына сыймыйбыз. Кунактан таралгач, берничә урындык җимерелмичә калмый.

Менә хәзер хәсрәтемне сөйлим инде.

Олы улым өйләнде. Бер сүз әйтми-нитми йөрде дә, өйләнәм, ди. Без нәрсә әйтик инде, яше җиткән. Өйләнәсе кызыңны күрсәт, дибез. Алып кайтты өйгә. Ходаем җаным! Буе малаемның кендегеннән генә. Кап-кара чәчле, кап-кара күзле, түп-түгәрәк йөзле. Айсылу дип аталган курчак кебек. Кулга алып уйнарлык инде менә. Ирем белән телсез калып карап торабыз. Булачак киленебез елмаеп карап тора. Малаебыз шуңардан күзен алмый.

Бер сүз дәшмәдек. Чәй эчердем дә чыгып киттеләр болар. Алар чыгып киткәч, ирем әйтә:

– Нишләмәкче була икән моның белән? – ди.

– Юри, кызык ясар өчен генә алып кайткандыр, – дим. «Кызык» ясады малаебыз, өйләнде. Әйтеп карадык әйбәт кенә итеп, тыңламады. Торалар. Шунысы инде юаныч: аерым торалар. Туфан абый, җаным, беләсезме, биеп кенә йөри улыбыз шул курчак каршында. Балалары туды, күренеп тора, анасына тарткан. Туганда ук бер кило булып тугач, артуы да шулай була инде аның.

Ярый, монысына азрак ияләшә башлаган идек, инде икенче улыбыз, өйләнәм, дип, өйгә монысыннан да бәләкәйне ияртеп кайтты. Сап-сары чәчле, Барби курчагы төсле.

Бу юлы түзмәдем:

– Илтеп куй өенә ул баланы, – дидем.

Валлаһи, бала гына. Тугыз-ун яшьләрдә диярсең. Юк икән, унтугызда икән.

Ирем белән икәүләп үгетләп карыйбыз, тыңламый. Яратам, ди. Кайсы җирен ярата торгандыр. Яратырлык җире дә юк аның. Аптырадык инде, Туфан абый. Күңеле суынмасмы, дип, туйны сузып киләбез. Юк, суынмый. Әле, җитмәсә, шул кызның эти-әниләрен алып килгән өйгә. Таныштырам, дип. Абыйсын ияртkән. Ходаем! Дүрт вьетнам йөри инде өйдә. Йөрәгебез алынып тора инде. Әгәр бусы өйләнсә, аның әти-әнисе, туганнары туйга җыелса, олы улыбыз ияртеп килсә хатынының туганнарын, бер көтү вьетнам булып, аяк астында буталачаклар ич.

**К.ШӘЛЕ**

## Өйдә минеке дә бар

«Казан утлары». Дүшәмбе. Планёрка. Журналга язылуны оештыру буенча турыдан-туры җаваплы кеше – Фәнил Гыйләҗевтән сорау алу бара.

– Син хет, подписчикларга таратыр өчен, үзең белән чиста квитанцияләр йөртәсеңме? – ди баш мөхәррир Илфак Ибраһимов.

– Ну, ни, теге... ни, – дип, авыз эченнән ботка пешерә башлый яшь шагыйрь.

– Фәнил! Мин синнән, квитанцияләрең бармы-юкмы, дип сорыйм!

– Ну, ни... сумкада йөреп, бераз таушалганнары бар инде өйдә...

– Өйдә безнең хатыннар да бар! – ди Мирзаевич, җикеренеп.

– Һәм... тоже таушалганнар, – дип өстәп куя Камил Кәримов.

**АХИР**

## Үзебезнең дуңгызлар

Татарстан радиосының яшьләр бүлеге мөдире Рәкыйп Гаффар бервакыт авылга дуңгыз караучы апалардан әңгәмә алырга барган.

– Апа, сез дуңгызларны яратасыз инде, әйеме?! – дип сораган ул бер терлекчедән.

– Яратабыз инде, яратабыз...

– Сез аларны ит комбинатына озатканда елап каласыздыр инде, шулай бит?!

– Ничек еламыйсың ди инде, энем, елыйбыз, ывчу-таки, үзебезнең дуңгызлар бит!

## Мөртәт

Ике язучы Матбугат йорты каршында тәмәке тартып тора. Шул вакыт болар каршына өченче язучы якынлашып килә.

– Күрәсеңме, мөртәт килә! – ди язучыларның берсе.

– Нинди мөртәт булсын. Бу бит язучы Локман Бадыйкшан! – ди икенчесе.

– Соң шул бит инде «Мөртәт»нең авторы!

**Рашат НИЗАМИ**

## Бөек афоризм

Салкын мичтә ипи пешермиләр.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Мөслим районында татар әдәбияты көннәре булып узды. Бирегә Казан, Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Камадан егермедән артык язучы килде. Алар район башлыгы Рамил Муллин белән очрашты, Мөслим белән танышты. Зифа Басыйрова исемендәге Мәдәният йортында язучылар катнашында зур кичә булды. Икенче көнне очрашулар мәктәпләрдә һәм гимназияләрдә дәвам итте. Каләм ияләре шагыйрь Зөлфәтнең туган өе диварына, Татарстанның халык язучысы Фоат Садриевның йортына элмә такталар кую тантаналарында катнашты, Наис Гамбәр, Флүс Латыйфи, Харрас Әюповның каберләренә чәчәкләр салды. Аларның рухына дога багышланды. Язучылар Х.Әюповның чишмәсен дә карады, суын эчте.

## ПРЕМИЯЛӘР ТАПШЫРЫЛДЫ

Әлмәт Татар дәүләт драма театрында Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреатларын һәм стипендиятларны котладылар. Быел бу бүләккә Рәшит Бәшәр («Былбыл оясы» китабы өчен), Гөлзадә Бәйрәмова («Дөнья шигырь яздыра»), Рәфкать Шаһиев («Сагыну хисе») лаек булды. Кызыксындыру премияләрен Гөлүсә Батталова («Бер йотым бәхет»), Екатерина Аничкина («Лунный блюз»), Евгений Турхан («Парала») алды. 10 студентка Саҗидә Сөләйманова исемендәге стипендия бирелә. Лауреатларны «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов котлады. Әлеге чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Эльмира Шәрифуллина, җырчы, композитор, педагог Мәсгут Имашев, С.Сөләймановаың улы Әнвәр Маликов һәм аның җәмәгате Асия ханым катнашты. Ул көнне Саҗидә Сөләймановаың бюсты янында шигъри митинг та булды.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Спас районында каһарман-язучы Абдулла Алишның тууына 110 ел тулуга багышланган чаралар үткәрелде. Туган авылы Көектә әдипнең яңартылган бюсты (авторы – Зөлфия Мөхәммәтҗанова) ачылды. Аның янында тантаналы митинг булды. Ул көнне районга кайткан күпсанлы кунакларны Болгарга алып барып, А.Алишның өр-яңа музее белән дә таныштырдылар. Аннары район үзәгендәге Мәдәният сараенда Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияне тапшыру тантанасы булды. Быел зур бүләккә «Керпенең шәһәргә сәяхәте» дигән китабы, яшь иҗат көчләрен тәрбияләүдә күпьеллык хезмәте, балалар матбугатын үстерүгә керткән өлеше өчен язучы Факил Сафин лаек булды. Аңа бүләкне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов тапшырды. Тантанада Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкара хезмәттәшлек секторы әйдәп баручы консультанты Әлфия Әхәтова, Бөтендөнья татар конгрессыннан шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, Алишның туганнары – шушы районның Иске Рәҗәп авылыннан Флёра һәм Чаллыдан Илдар Алишевлар, Казаннан Гөлшат һәм Азат Сөнкишевлар чыгыш ясады. Әлеге чараларда Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, А.Алиш премиясе лауреатлары катнашты.

***

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Ганс Христиан Андерсен исемендәге Почётлы диплом иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортстан һәм Марий Эл республикаларының атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Миңнуллинга 70 яшь тулуга багышланган кичә булды.

Юбилярны ТР Президенты исеменнән ТР Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев котлады, аңа Рөстәм Миңнехановисеменнән машина ачкычы тапшырды. ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев үзенең тәбрикләү сүзен видеоролик аша җиткерде. Бәйрәмдарны шулай ук Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, Төркиянең Әләзыгъ шәһәрендәге Фырт университеты профессоры Әрҗан Алкая, Азәрбайҗаннан тюрколог, галим, шагыйрь, тәрҗемәче Рәмиз Әскәр, Чувашиянең халык шагыйре Валерий Тургай, язучы Раиса Сарби һ.б. котлады. Каракалпак дәүләт университеты мөгаллим-

нәре Роберт Миңнуллинга чапан бүләк итте. Котлаулардан соң шагыйрь сүзләренә язылган җырлардан торган зур концерт булды.

***

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал исемендәге әдәби премияләр лауреаты, драматург, прозаик Данил Салиховка 60 яшь тулуга багышланган кичә булды. Кичәне алып баручылар Резеда Сәләхова белән Артём Пискунов юбилярга ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлавын ирештерделәр. ТР Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева Данил Салиховка ТР Президенты Указы белән бирелгән «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды. Бәйрәмдарга ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев исеменнән дә бүләк бирелде. ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатын һәм Татарстан Язучылар берлеге котлавын ирештерде. Кичәдә ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшиннардан килгән котлау телеграммалары да укылды. Юбилярны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, ТР инкассация идарәсе җитәкчесе, Актаныш якташлык җәмгыяте рәисе Васим Вахитов, «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев, Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Нурлыева, дистәләп театр коллективлары һ.б. котлады. Кичәдә Д.Салихов пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

Данил Салиховның юбилеен туган ягы – Актанышта да зурлап билгеләп үттеләр.

***

Казандагы «Пирамида» күңел ачу комплексында шагыйрь, популяр җырлар авторы, Муса Җәлил, Һади Такташ, Төркиянең Хөсәен Байкара исемендәге халыкара премияләр лауреаты Рәмис Аймәткә 50 яшь тулуга багышланган кичә-концерт булды. Юбилярны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов котлады. Р.Аймәтнең иҗатына галимә Дания Заһидуллина югары бәя бирде. Рәмис Аймәт сүзләренә язылган җырлардан торган концертта ике дистәдән артык җырчы чыгыш ясады.

***

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында шагыйрә, популяр җырлар авторы, драматург, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнашеваның тууына 90 ел тулуга багышланган концерт булды.

Г.Зәйнашеваның тууына 90 ел тулуны туган ягы Минзәләдә фестиваль итеп билгеләп үттеләр. Анда ТР мәдәният министры урынбасары Эльвира Камалова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов катнашты. Минзәлә сәхнәсендә Актаныш, Мөслим, Сарман, Тукай, Менделеевск районнарыннан килгән яшь талантлар чыгыш ясады.

## ОЧРАШУЛАР

Тукай районы мәктәпләрендә бер төркем язучылар катнашында очрашулар булды. Каләм ияләренең Чаллыга сәфәре шәһәрнең «Энергетик» Мәдәният сараенда шагыйрь, популяр җырлар авторы, журналист Фәннүр Сафинның тууына 70 ел тулуга багышланган «Җырымда юатырмын» дип аталган әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

***

ТР Милли музеенда «Тукай варислары» циклыннан язучы-сатирик, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Кәримов белән очрашу булып узды. Аны музейның өлкән хезмәткәре, әдәби салонның модераторы Флёра Дәминова ачып җибәрде. Аннары музейның генераль директоры урынбасары Лия Саттарова сүз алды. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында филология фәннәре докторы, профессор Рифат Сверигин сөйләде. Очрашуда язучының каләмдәш дуслары Газинур Морат, Марат Әмирхан, Мансур Вәлиев, Вакыйф Нуриев, Алмаз Хәмзин. Марат Закир, Рамил Ханнанов, Фәнил Гыйләҗев чыгыш ясадылар. Чыгышлар танылган артистлар Азат Тимершәех, Рафаэль Сафин һәм яшь башкаручы Гөлшат Шәриповаларның җырлары белән үрелеп барды. Камил Кәримовка һәм әлеге очрашуны оештыручыларга галимә Тәэминә Биктимерова тамашачылар исеменнән рәхмәт әйтте.

## КҮРГӘЗМӘ

Казандагы Каюм Насыйри музеенда үзенчәлекле күргәзмә ачылды. Ул бөек мәгърифәтче К.Насыйриның якташлары – бертуган Фаил һәм Шәүкәт Шәфигуллиннар иҗатына багышланган иде. Күргәзмәне ачу тантанасында Шәфигуллиннарның иҗатташ дуслары, туганнары, якташлары бар иде. Кичәне җырлар, скрипка моңнары бизәде.

2018 елның 11 октябрендә 86нчы яшендә филология фәннәре докторы, профессор, татар теле этимологиясе буенча танылган белгеч **Рифкать Газизҗан улы Әхмәтҗанов** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман М.ЮНУСА «Кипчакская девушка Аксана»; АХИР. Повесть «Дикая яблоня»; стихи С.ГАРАЕВОЙ, Н.ХИСАМОВА, Ш.ГАЛИЕВА.*
*«Литература родственных народов»: стихи А.ДОДУЕВА.*
*Литературный конкурс «Достояние»: повесть Ф.АБДУЛЛИНА «Кому рассказать свои тайны…»*
*«Новые имена»: стихи Ф.АЙДАРОВОЙ; рассказ З.САБИТОВОЙ «Мой знакомый».*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«90 лет со дня рождения Ш.ГАЛИЕВА»: стихи поэта; фотографии Ш.ГАЛИЕВА.*
*«Юбилеи»: Б.МИННУЛЛИН, Ф.САГДИЕВА, Р.МИРХАЕВ. «Науку развивают учёные…» (80 лет И.БАШИРОВОЙ); статья Р.ЗАЙДУЛЛЫ, посвящённая 60- летию Х.ИБРАГИМОВА.*
*«Наш календарь»: 90 лет со дня рождения Ш.АНАК.*
*«Память»: Г.МАКСИМОВ. «Потерявшаяся мелодия».*
*«Белый парус»: А.НАСИРОВА. «Амина»; Е.НУЖДИНА. «Мама».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Чествование матери героини». Художник Х.Якупов; поэт Рифат Салах.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by M.YUNUS «Kipchak girl Aksana»; AHIR. Story «Wild Apple»; poems by S.GARAEVA, N.KHISAMOVA, SH.GALIEV.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by A.DODUEV.*
*Literary contest «Heritage»: story by F.ABDULLIN «Who to tell my secrets…»*
*New names: poems by F.AYDAROVA; the story by Z.SABITOVA «A friend of mine».*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Tukay and Tatar literature»: heading is conducted by R.RAHMAN.*
*«90th anniversary of SH.GALIEV»: poems by the poet; photos by SH.GALIEV.*
*«Anniversaries»: B.MINNULLIN, F.SAGDIEVA, R.MIRKHAEV.*
*«Scientists develop science…»*
*(80 years old to I.BASHIROVA); article by R.ZAYDULLA dedicated to the 60th anniversary of H.IBRAGIMOV.*
*«Our calendar»: 90th anniversary of SH.ANAK.*
*«Memory»: G.MAKSIMOV. «Lost melody».*
*«White sail» A.NASIROVA. «Amina»; E.NUJDINA. «Mother».*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Honoring the Heroine Mothe». Artist H.Yakupov; poet Rifat Salakh.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Герой Ананы зурлау». *Харис Якупов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь Рифат Сәлах.